ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2002



## Tatarstan Respublikası Prezidentı

# UKAZI

## 2002 yılda Tatarstan Respublikasının Ğ.Tuqaɣ isemendəge Dəwlət büləkləren birü turında



Yaqub Zənkiev



İskəndər Rafikov



Şamil Monasıypov, Marat Zaripov,
Kamil Monasıypov, Al'bert Əsədullin

Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqaɣ isemendəge Dəwlət büləklərе komitetı təqdimnəren qarağannan son, **qarar birəm**:

2002 yılda Ğ. Tuqaɣ isemendəge Dəwlət büləkləren tübəndəgelərgə birergə:

1. Yazuçı **Yaqub Kamali ulı Zənkievkə**—«İrteş tannarı» romanı eçen—Tatarstan kitap nəşriatı, 1994 yıl.

2. **Şamil Xəmit ulı Monasıypov, Marat Nəbi ulı Zaripov, Kamil Xəmit ulı Monasıypov, Al'bert Əxət ulı Əsədullin** sostavındağı dəwlət qıllı kvartetına—«Tatarstannın kvartet muzıkası», «Tatar xalqının borınğı kəɣlərе», «Dənyakülәm kvartet klassikası» digən konsert programmaları eçen.

3. Rəssam **İskəndər Wəliulla ulı Rafikovqa**—«Qızlar», «Ana xəsrəte», «Sugış yıllarında», «Qunaqqa», «Bolğar xanı qızı», «Səyembikə-xanbikə», «Awıl sovetı rəise Motıyğullina portretı», «RSFSRnın xalıq artistkası G.Bolgarskaya portretı», «RSFSRnın xalıq artistkası M.Raxmanqulova portretı» kartinalarında tatar xatın-qız obrazları seriəsen tudırğan eçen.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

Qazan, Kreml', 2002 yıl, 25 aprel'

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

# 6

**(956)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсният**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


**ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марс ШАБАЕВ. Июнь иле. *Шигырь* ... 5
Камил КӘРИМОВ. Ак бүрек. *Повесть* ... 6
Рафис КОРБАН. Мин бер генә яшим дөньяда. *Шигырьләр* ... 60
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Жир алмасы. *Хикәя* ... 64
Шәүкәт ГАДЕЛША. Себер ягы—мон ягы. *Шигырьләр* ... 72
Индус СИРМАТОВ. Бүре баласы. *Хикәя* ... 76
Әдхәт СИНУГЫЛ. Төрки болаклар. *Шигырьләр* ... 82
ТАҢЧУЛПАН. Мәңгелек йөрәге. *Шигырьләр* ... 86

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ**

Флера САФИУЛЛИНА. Әдәби-мәдәни юлдаш ... 48

**ӘДӘБИ МИРАС**

Афзал ШАМОВ. Гомерем таңында. *Автобиографик повесть* ... 88
Әхмәт РӘШИТОВ. Кодрәтле ул шигырь дигәнең... ... 121

**ТАРИХ**

Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта ... 127

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Марсель ЗАРИПОВ. Садриевча сөрү ... 153

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рафаэль МОСТАФИН. Бәхетлеләр һәм бәхетсезләр ... 162

**СӘНГАТЬ**

Фатыйма МИҢНУЛЛИНА. Сәнгать—ул җанлы хәтер ... 166

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

26—Шөгарә *(Шагыйрьләр)* сүрәсе ... 171

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Исхакый васыятенең иясе ... 178
Казан ханлыгы җимерелүгә 450 ел тулу уңаеннан БТИҮ мөрәҗәгате ... 186

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Шамун ФИДАИ. Ялкынлы теләк. *Шигырьләр* ... 187

**ЮМОР-САТИРА**

Марсель ГАЛИЕВ. Чәк-чәк фикерләр ... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть К. КАРИМОВА «Мохнатая шапка», рассказ Т. ГАЛИУЛЛИНА «Топинамбур», рассказ И. СИРМАТОВА «Волчонок»; стихи М. ШАБАЕВА, Р. КУРБАН, Ш. ГАДЕЛШЫ, А. СИНУГЫЛ, ТАНЧУЛПАН.
«К 80-летию журнала»: «Казан утлары» в моей жизни»—воспоминания Ф. САФИУЛЛИНОЙ.
«Литературное наследие»: автобиографическая повесть А. ШАМОВА «На заре жизни».
Поэтические произведения известных политических и государственных деятелей. Предисловие и перевод А. РАШИТОВА.
«История»: С. ШАМСИ. «В скандальном доме» (страницы истории Золотой Орды).
«Публицистика»: статья М. ЗАРИПОВА «По методу Садриева».
«Литературная критика»: Р. Мустафин. «Счастливые и несчастные».
«Искусство»: статья Ф. Миннуллиной посвящена творчеству драматурга Ю. Сафиуллина.
Коран на татарском языке.
«К истории литературы»: статья Х. Миннегулова «Обладательница завещания Г. Исхаки».
Обращение ТОЦ приурочено 450- летию падения Казанского ханства.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: дом-музей народного писателя Татарстана М. Магдеева в родной деревне Губурчак Арского района; писатель Н. Хасанов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": KARIMOV'S narrative «Hairy cap»; T. GALIULLIN'S story "Topinambur", I. SIRMATOV'S story "Wolf-cub"; the verses M. SHABAEV, R. KURBAN, SH. GADELSHI, A. SINUGIL, TANCHULPAN.
"Commemorating of 80th anniversary of «Kazan utrary» magazine": «Kazan utrary in my life» SAFIULLINA'S reminiscences.
"Literary legacy": autobiographic narrative of A. SHAMOV "At daybreak of life; poetic works of well-known political and statesmen. A. RASHITOV'S preface and translation.
"History": S. SHAMSI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda).
"Journalism": M. ZARIPOV'S article "By the Sadriev's method".
"Literary criticism": R. MUSTAFIN "Happy and unhappy".
"Art": F. MINNULLINA'S article devoted to creative work of dfamatist U. Safiullin.
Koran in Tatar language.
"To the history of literature": H. MINNEGULOV'S article "Possessor of testament of G. Iskhaki".
The appeal of the Tatar public center devoted to the 450th anniversary of the Kazan kingdom fall.
"Humor and satira": M. GALIEV "I deas by field".
The diary of social and cultural life.
In our covers: house-museum of national writer M. Magdeev at the native village Guburchak; writer N. Khasanov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.05.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—266
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.

## İyün' ile

**İyün' ile beznen Tatarstan,
Sabantuylar ile, cır ile.
Qunaq cıyu bügen quana–quana—
Par atları bulır cigüle.
Əү, kilegez, dən'ya ğawamnarı!
Tatar yortı İdel buyında
Tuy ütkərə. İdel yumart sıylar:
Beznen ənkəy üze—bu yılğa.
Ğasır artı ğasır ütə torğan,
Buysındırmaq bulğan bu ilne.
Xalıqları berdəm, eşçən anın—
Haman isən tatar İdele.
Tarixlarda artıq yuandırmas,
Bik maqtawlı xəzer zamana.
Kemnər kilep kemnər kitməgənnər
Tatar yortı—şawlı Qazanğa?!
Menə awıl. Tərle millət xalqı
Eşli monda totınıp qulğa–qul.
Bəynəlmiləl bəyrəm ütkərüdə
Ğilem birə ala bu awıl.
Tatar yortı oran xəbər sala,
Taratsınnar İdel cillərе:
Saban tuyı bügen! İrtəgədən
Tatar eştə bulır,
Sızğanulı bulır cinnəre!**

**Mars ŞABAYEV**



## Камил Кәримов

# АК БҮРЕК

ПОВЕСТЬ

Ботан бакчасыннан империянең унбиш җанвары качты. Чәнечкеле коймалар, йозаклы читлекләрдән исән-имин котылу мөмкин түгел. Бу җан ияләрен исерек каравылчы үзе азат итте, рәшәткә артыннан чыгаргач, җырлар җырлап олы капкадан озатып калды. Ireккә сусаган җанварлар тиз арада урманнарга, тауларга, чүлләргә, далаларга һәм диңгез буйларына таралып үрчи башладылар. Аларны, болытлардан биеккәрәк күтәрелеп, ике башлы бөркет сагалап йөри.

### Бауның бер очы

Үзең яшәгән шәһәргә бөркет канат җәярлек биеклектән карасаң— түбә дә түбә генә... Бөтен тормыш түбә күләгәсендә.

Шәһәрдә кышкы төн. Кереп яшеренергә ышык җир тапмагандай, анда-санда йөк машиналары урын эзли; буш калай савыт тәгәрәгән тавышлар чыгарып, соңгы трамвай-троллейбуслар чабыша; тәүлекнең егерме дүртенче сәгате килеп терәлгәч кенә, исләренә төшкән йомышлар белән, кешеләр йөренгәли. Төн уртасы. Хәрәкәтнең иң аз чагы: тимер ишекләр бикле, рәшәткәле тәрәз пәрдәләре корулы, утлар сүнгән. Шәһәр тоташ зур күләгәгә әйләнгән дә йоклап ята, хәтта багана башындагы лампалар бәйләме дә, реклама утлары да ул күләгәне эретә алмый.

Урам буйлап Ансар килә. Җәяүлеләр сукмагыннан түгел, машиналар йөри торган ак сызыклы киң юлдан. Тыныч. Төннең шундый чагы бу— юлына кеше очраса: кая барышың, дип, юри генә сорап кара. Өйгә кайтышым, дип җавап бирерләр. Ә менә безнең Ансар дигәнебез олы юлдан аерылып, таш коймалы урамга килеп керде. «Каракүл» берләшмәсенең икенче сменасы өйләренә кайтырга әзерләнә. Ансар бераз алданрак

Камил КӘРИМОВ *(1950)—прозаик. «Ундүрт яшьтә», «Бәхетле кеше», «Вәгъдә», «Күләгәдә төлке бар», «Үзеңне бел», «Ком сәгате» китаплары авторы. Казанда яши.*

килде. Ул әле Венераның кайсы капкадан чыгасын тәгаен белми, телефон номеры гына бар. «Каракүл» берләшмәсе зур, аның бер тирәдә Венера кебек кызлар эшли торган фабрикалары гына да өчәү. Ансарга хәзер таш койма буйлап атлап, каравылчылары, вахтерлары белән шыгрым тулы өч капканың берсенә барып чыгарга кирәк. Анда берләшмә фабрикаларына тоташкан телефоннан өч урынлы санны җыйнап шылтыратасың да—Венера кайсы капкада көтәргә кирәклеген үзе хәбәр итәчәк.

Таш койма кырыендагы баганаларда балкырга тиешле лампалар күзен үк яфраклар белән бергә коелып беткәннәр. Барлы-юклы ай яктысы да ялга чыгар көнен көтеп алҗыган мехчылар чырае төсле сүрән. Койманың яшел төсе танырлык түгел.

Яңа урамда, билгесез тыкрыкларда сизгерлек икеләтә арта икән... Һәр күләгәнең үз төлкесе була, дигәндәй... Кинәт... Койманың икенче ягында кыштырдаган тавыш ишетелде һәм Ансардан ике-өч адым алгарак, канатлы еландай уйнаклап, бер бау очып төште, дөресрәге җир белән күк арасында, үрелсәң кул җитәрлек биеклектә эленеп калды. Ансарның йөрәге биш тибешне бер итеп дөпелдәп куйды. Әллә куркудан, әллә кызыксынудан—Ансар бау очын ике куллап тотып кисәк тарткан иде, аяк очына ярты капчык чамасындагы биштәр шапылдап килеп төште.

## Егетеңне шуннан эзлә...

Завод-фабрикаларда төнге сменада эшләүчеләр тирән йокыдан башкаларга караганда соңрак уяна ала. Тик Венера бүген зәңгәр күзләрен зур итеп ачып тизрәк таң атканны көтте. Йокы качты—төне буе кызга якын да килмәде. Карт кызлардан Ансар кебек сөйкемле егетләр генә түгел, төнге йокылар да кача микәнни?!

Кызларны сәер халык дип беләбез, алар үсмер чакта аймылышкан егетләрнең берәрсен гомер буе сагынып яшәр, аңа «тәүге мәхәббәтем» дигән янгыравык исем кушар. Озын-озак төннәрдә, язмыш сайлап биргән хәләл җефете белән үпкәләшеп ачуланышкан сәгатьләрдә, хәтер яңартырлык минутларда «тәүге мәхәббәт»ләр искә төшкәч, күпме мендәрләр дымлана торгандыр: «И, унҗиде яшьлек чагым, и тәүгем...»

Яшьлек дигәнең үтә дә китә икән. Ул син йоклаганда да, тукталышларда трамвай көткәндә дә, чәй эчеп телевизор карап утырганда, тулай торактагы иптәш кызларың янына килгән егетләр белән үртәшкәндә дә үтә тора. «Каракүл» капкасыннан эш сәгатенне җинеп чыкканда да сигез сәгате үткән була инде ул яшьлекнең...

Ансар белән танышкан көнне Венераның унҗиде яшь чагындагы көндәлекләре ягылып, стенадагы артистлар рәсеме бала-чагалы фотолар белән алышынып, яшь җилкенчәкләр яшәгән бүлмәләр белән ике арага межа төшә башлаган иде инде.

Тормышта киребеткән үҗәт һәм котылгысыз гап-гади бер канун бар—кеше галәттә гел бер ияләнгән сукмактан йөри: эшенә бара, өенә кайта; эшенә бара да тагын өенә кайта. Һәм көн саен шулай кабатлана торгач, бу сукмакка шул хәтле күнегәсен—айларны аванс белән получкаларга, елларны туган көннәргә, гомерне яшьлек белән картлыкка гына бүлеп саный башлыйсың. Таныш һәм такыр сукмакта ялгызаклар нык чиләнә, чөнки үзеңә пар сайлыйм дисәң башка сукмакларга да аяк басарга кирәк. Күпләрнең тормышы бер генә сукмаклы. Шуңа күрә врач—врачка, укытучы—укытучыга, эшче—эшчегә, начальник үзенең секретаршасына, министр министрлар кызына—кыскасы, бергә эшләгән-аралашкан кешесенә өйләнә, яки кияүгә чыга. Ә Венераның эш урынында йөз дә егерме хатын-кыз. Ирләр мәсьәләсенә килгәндә, хезмәт хакы алган көннәрдән соң тиз генә эшкә чыга алмый торган ике слесарь һәм дүрт йөк бушатучы гына, аларын да хатыннары килеп каршы ала...

Димәк, «Каракүл» кызларына башка профессия кешеләренең сукмагына төшү зарури. Эзләнергә кирәк.

Зоопарктан юлбарыс качкан иде. Җәбраил зиратында эзләп табып атып үтерделәр. Шул җанвар яшәгән читлекне күрәсе килде кызның...

Зоопаркка килде Венера. Иптәш кызлары көлеп калды: өйләнердәй егет, дөньясын онытып, буш читлек карап йөрмәс, танцыда булыр, зоопаркка түгел, төнге клубка барырга кирәк сиңа, диделәр. Венера сер бирмәде: «Мин кияүгә чыгарга җыенмыйм! Гороскопка язылган хайваннарыбыз нихәл яшәп яталар икән, күреп кайтыйм...»

Венераның аклануы җавапсыз калмады:

«Безгә дигән арсланнарны читлекләргә ябып бетергәннәрдер. Авылдан килгән бозауларны эләктерсәк кенә инде...»

Яшәешнең һәрбер үзгәрешен саннарга әйләндереп теркәүче галимнәр бер әйтерләр әле: кияүгә чыкмыйм дип йөргән кызларның туксан тугыз бөтен йөздән туксан тугыз проценты мин кияүгә чыкмыйм, дия-дия көтмәгәндә генә кияүгә чыгып китә.

Зоопаркта вәгъдәләшкән килеш, беренче «свидание» кичендә үк Ансар Венераны эштән каршы алырга килмәде. Кыз урамга чыгуга авыр сулап саф һава йотты да үз-үзенә ишетелерлек итеп кенә: «Килмәсә, шуннан ни...» дип куйды. Әйтерсең лә аның уйларын кемдер тыңлап бара да акланырга мәҗбүр итә. Адымнары әкренәйде, күзләр сүрелмәс өмет белән «Каракүл» берләшмәсе тирәсен айкады. Шаяртадыр әле, якында гынадыр Ансар, эшеннән каршы алырга киләм дип бик ышандырып әйткән иде бит ул... Менә күрерсең, трамвай тукталышына житкәндә каршыга килеп басар әле...

Ә Ансар юк та юк. Ашыктырып трамвае да килеп җитте, үч иткәндәй, кешесе дә әллә ни юк. Башка көннәрдә, төнге смена алышыныр чакка туры килсән, трамвайларда тотынып барырлык та урын калмый торган иде. Утырды да китте Венера. Күнеленә килгән беренче тойгы—үртәлү булды: карасана, мин җүләрне, бер күрешүдә үк ышанып... Үзе дә бит, адресларына хәтле әйткән була, зоопаркта маймыл карап йөргән нәмәрсә—берәр хәсис, итәк җиледер әле, йә ике-өч хатын аерган кешедер. И, сайраганын күрсәң... Венера тавис кош тирәсеннән китмичәрәк торганда килде дә кинәт: бу кош сезгә охшаган, диде. Венераның өстендә яшел пәлтә, пәлтә чабуыннан чуар күлмәк итәге чыгып тора, башына кызыллы-яшелле чәчәктән тукылган чуклы шәлъяулык бөркәнгән. Венера Ансарның үртәү сүзләрен елмаеп кабул итте. Тагын да сөйкемлерәк күренергә тырышыпмы, уч төбендәге түгәрәк көзгесенә күз салып өлгерде. Канатланып торган җинел һәм калын чәчләрен тузгытып җил исәр якка борылып басты. Чәче—өлгереп, кишәнкәсенә сыймаган чикләвек төсендә дисәң, кызның күзләре яңгырга чыланган күгән җимеше зәңгәрлегендә иде. Ансар ирексездән кызга иярде. Әгәр, хәзер аннан калышмыйча гел тагылып йөрсәң, бәхетнең нәкъ башкаласына ияртеп алып китәр төсле ул. Сөйләшминитми генә, җанвардан—киеккә, читлектән—читлеккә, пыяла түбәле ботан бакчасыннан кышкы фермага килделәр. Тау кәҗәсе үзенең туган ягын онытып, купшы сакалын җилпеп печән чәйни.

—Менә бу кәҗәнең сакал селкетүе кемгәдер охшаган. Исемен әйтеп тормыйм, чөнки үзем дә белмим.—Венераның елмаюы көлүгә тартым иде.

Ансар як-ягына каранып алды. Алай, бу тирәдә сакаллы җан ияләре икәү генә: берсе тау кәҗәсе үзе, икенчесе Ансар. Курстагы егетләр белән бер чамадарак күреним дип, соңгы айда кырынмый башлаган иде ул—очлы ияген сакал басты. Тора-бара сакал белән мыек бергә тоташты, кызыл ирене уртада чекерәеп калды.

—Рәхмәт,—диде Ансар,—маймыллар яныннан үткәндә дәшми калуыңа рәхмәт.

—Ә мин маймыллар турында бер анекдот беләм.

—Мин дә беләм. Сөйлимме?—диде Ансар, кызлар мәзәгенең беркатлырак икәнен чамалап.

—Оятсыз булмаса сөйлә...

—Әдәпле итеп үзгәртәм алайса... Ир белән хатын аптыраганнан гына, зоопаркка килгәннәр. Үпкәләшкәннәр бугай, хатын ирне үртәргә теләгән, маймыл читлеге янына килеп баскач изүен чишкән, итәген күтәреп ботларын күрсәткән. Ата маймыл түзмәгән, читлекне каерып хатынны агач башына алып менеп киткән дә көчли башлаган. Ир хатынына кычкыра икән: «Йә, йә, башым авырта, кәефем юк, эштән бик арып кайттым, дип, акланып кара инде мона»—дигән.

Венера көлмәде.

Шәһәр күленнән инде көз көне үк чайпалып кергән җыентык күлләвектә соскы борынын көчкә күтәргән пеликаннар яшәргә азаплана. Алар янына җиткәч Венера туктап калды. Нәрсәнедер исенә төшерә алмыйча интеккән кыяфәт белән аяк очына текәлде, дөресрәге кыланды. Чөнки зоопаркта бүтән карар нәрсә калмады, утыз тәнкәлек билетыңны ерта-ерта кайтыр юлынны эзләргә вакыт. Әгәр егет белән танышып өлгермәсән, капкадан чыккач соң булырга мөмкин. Бәлки егетнең артык тагылып йөрергә исәбе юктыр, күнеленә өмет җылысы бөркисе бар.

—Кемнәргә охшаганыбызны белдек, исемнәребезне дә әйтешсәк...

—Мин Ансар атлы.

—Венера дип эндәшерсез.

—Юрфактан. Быел диплом бирсәләр адвокат булып баерга исәп.

—«Каракүл» берләшмәсеннән. Бүрекләр тегәм.

—Фатирант.

—Тулай торакта.

—Менә таныштык та,—диде Ансар, сөйләшүнен рәсми өлешен түгәрәкләп,—исеменне сорый алмыйча зоопарк буйлап ике-өч әйләнеш ясауның кирәге калмады.

Ә көн әйбәт. Февраль аенын кәефе күтәренке чак. Кояшы күзгә күренмәсә дә шәһәр сөтсел пыяла аркылы яктыртылган төсле—ни иртә, ни кич икәнне белерлек түгел, гел бер төрле яктылык. Салкыны да парлылар бер-берсенә сыенып барсын өчен генә. Бозлы түбәләргә бәби сөңгеләр эленгән. Авыл ягыннан җәяүләп кенә буран килә—кырда механизаторлар тота алмаган карлар шәһәр урамына кача.

Венера мулинә җепләр белән чигелгән ак йон бияләенә саф сулышын өрде. Ансар аңласын дип инде. Шәһәрдә кул җылытырлык урын беткәнме? Дистәләгән театр, биш культура сарае, юып капланган тәлинкәгә охшатып төзелгән тирән эчле цирк, планетарий, биш музей, киметеп кенә санаганда да уналты ресторан, егерме дүрт «Бистро» төнге клублар һәм башка җылы урыннар...

Ансар Венераны «Чәй йортына» алып керде. Монда ни теләсәң шул бар: ит белән төрелгән белен, шулпалы өчпочмак, мантый, лимонлы чәй... һәм өч кашык туңдырмага бер кашык чия вареньесы тамызсаң, чырага кадап урам буйлап суырып йөри торган «Пломбир»га «Кала утлары» дигән исем кушыла икән. Чират житеп, өстәл артына утыргач, колак төбендә музыкага бәхетле ярлар чөкердәшүе дә кушылгач, кыз күнелендәге шик-шөбһәләр бөтенләй онытылды. Яна таныш иске дус булып тоела башлады. Эшем кешеләре өчен түгел икән бу ашауханә. Әллә ни житди сүзләр сөйләшмәделәр. Ансарның бер жөмләсе генә аеруча хәтердә калган: «Мин сине иртәгә эшеңнән каршы алам!..» Әйе, икенче көнне үк, һичшиксез күрешәчәкбез дип, туңдырма ялый-ялый вәгъдәләр биргән иде ул. Ә үзе, бүген Венераны каршы алырга килмәде...

Икенче көнне шимбә иртәсендә, әллә гарьлектән, әллә тынычлыгын җуйган күнелне юатыр өчен, Венераның башына бер уй килде. Уй дигәннән бигрәк, кешелек яралганнан бирле, буыннан-буынга күчеп, хатын-кызлар арасында әле һаман көчәя генә барган зәгыйфь гадәт—ирләрнең ялганын фаш итү теләге иде ул. «Адресын дөрес әйткәнме? Буйдак кеше микән? Укыган урыны, исеме—үзенекеме?» Менә шушы

сораулар кичекмәстән җавап таләп итеп, Венерага горурлыгын җиңеп Ансар исемле кешене эзләп китәрдәй көч өстәде.

Иске универмаг артындагы Дегетле урамын бик тиз эзләп тапты ул. Тәрәзәләрен күлгә төбәп туңып калган ике катлы агач йорт ишегенә килеп җиткәч, ишек янагындагы кызыл төймәгә үрелеп маташмады, борылып басты да ишек тактасын биек үкчәле итек табаны белән төйде.

Фатир хуҗасы ишекне болай дөбердәтүгә кисәк кенә аңгыраеп, ялан аягы белән баскыч басмаларын саный-саный, икенче каттан тыпырдап килеп тә төште. Тик, ишек шудырмасына кагылырга ашыкмады, такта аркылы гына кемнең кем икәнлеген ачыкларга керешге.

—Кем бар анда?

—Мин.

—Белмәгән кешегә ишек ачмыйбыз.

—Ансар янына килдем.

—Алып киттеләр аны.

—Кая?!

—Кая-кая?! «Сасы күл»гә, вәт кая.

—Кем алып китте?!

—Берни белмәгәндәй кылануын күр син аның... Карак ялгыз йөрми, бергәләшеп урлагансыздыр әле. Кач лутчы, сине дә эләктерерләр. Кит! Ату каравыл кычкырам!

Тагын әллә ниләр әйтә алыр иде бу фатир хуҗасы, әле ярый ялан тәпиләре февраль салкынын өнәми икән, бик тиз генә баскычыннан менеп шылды.

Венера сөенде дә көенде...

Адресын дөрес әйткән Ансар, алдамаган. Ә менә урлаганы өчен кулга алынуы күнелгә шом сала. Зоопаркта танышкан булып йөрүе Венераның бүрекләр тегә торган цехта эшләгәне өчен генә түгел микән?! Венера шуңа ышанып, өметләнеп, эштән соң сагынып күрешәбез дип көтеп торды... Хурлыгы ни тора... Гомеренә кияүгә чыкмаска антлар бирерсең... Бер ышанычлы егет калмады, таныштың исә, хушлашыр чак та җитә.

## Монысы сержант, тегесе—майор...

Кеше дигәнең гомере буе маҗарага сусап яши: җирдә ялтыравык нәрсә аунап ятса иелеп карый; ботак тишеге күрсә бармагын тыга, чокыр-чакыр төбеннән нидер эзли; пышылдау ишетсә туктап кала; төркемгә юлыкса ерып-сугып кеше арасына керә, тизрәк вакыйганы белә-се, маҗараны башкалардан алданрак күрәсе, яналыкны иң беренчеләрдән булып ишетәсе килә аның...

Ансар, каршысына шапылдап килеп төшкән биштәр янынннан гамьсез генә, серле табылдыкны чишми генә, маҗара аркылы атлап китә алмады. Бу минутта Венера да, беренче очрашу да онытылды, әлбәттә. Беренчедән, ул инде бүген-иртәгә закон сагына басасы яшь юрист; икенчедән, монысы әлбәттә иң зур сәбәпчесе—башкалар кебек үк ул да маҗарага сусап яши.

Төнге урамны аулакка санап кәперәеп йөрерлек түгел икән, Ансар биштәргә тыгылып, чәшке тиресеннән тегелгән бүрекләрне санарга да өлгермәде, әллә кайдан гына милиционер пәйда булды—якадан эләктереп тә алды...

Бүрек индустриясенең үз тарихы бар...

Бу дөньяда бүрегенә карап сәлам бирәләр. Ил башында агайлар утыра. Шуңа күрә сүз ирләр бүреге турында бара... Мавзолейдагы юлбашчыбыз сукно белән тышланган бүрек кигән, ул сарык тиресеннән тегелеп, зәнгәр төскә маңыла һәм колакчасы төшерелеп бәйләнә... Атамыз Сталин, сукно бүрекләрне күн белән тышлатып, маңгаена кызыл йолдыз кадатты... Аннан соң колакчасыз папаха кигән Кукуруз патша тәхеткә

килде. Гади халык аңа охшамаска тырышып куян, бүре, кәҗә, эт һәм төлке бүрек киде... Генеральный секретаребыз су кондызыннан тегелгән йөнтәс бүреген егерме ел буе саклады... Брежневтан соң бик күп бүрекләр идарә итте. Шуна күрә түрәләр башында су эте, болан баласы, чәшке яисә ак төлке ише җәнлекләр буталып бетте.

Бүрек ул—санлы кешенең җәмгыятьтәге урынын билгели торган җылы символ, баштан-башка күчә торган җонлы валюта, адәм башына җитә торган купшы хәвеф...

Ансар тартып төшергән биштәрдә унбиш кешене башлы итәрлек бүрек иде. Мондый очракларда бирелергә тиешле сорауларны яхшы белгәнгә күрә, җинаять процессы кагыйдәләренә туры китереп, алдан ук җавап кайтарды ул:

—Исемем—Ансар, фамилиям—Субаев, 1980 елгы, юрфакның соңгы курсында укыйм. Вакытлыча Дегетле урамындагы сигезенче йортта яшим. Монарчы хөкемгә тартылганым юк. Капчыктагы бүрекләр менеке түгел.

—Ачыкларбыз,—диде милиционер кесә фонарен төбәп.

Җинаятьчене тоткан агайнедә бераз масаю сизелергә тиеш иде, ә бу никтер көчәнеп кенә сөйләшә. Ләкин тавышы таныш. Баядан бирле искә төшерергә азаплана Ансар, әгәр фонарьны үзенә каратып булса...

Шулчак тәртип сакчысы тәмәке кабызырга дип газлы зажигалкасын яндырды. Ялгыш газы күбрәк ачылды бугай, бер карыш буе ялкын күтәрелде, аның яктысында Ансар сержантның йөзен танып өлгерде.

—Вәт сиңа, мә! Райнур! Тавышыңны үзгәрткән булып...

—Әйе, мин сержант Райнур Асланов. Ләкин безнең танышлыкка исәп тотма. Син, гражданин Субаев, җинаять өстендә тотылдың. Бу бүрекләрне сиңа кем ыргытты? Шушы сорауга дөресрәк итеп җавабыңны әзерлә.

—Мин ялганлый белмәдем, хәтерлисеңдер, Райнур... авылдаш, классташ, сержант Асланов.

—Ышанасы килми, урлау ялгансыз булмый ул.

—Төлкегә дигән капкынга керпе дә эләгә.

—Җинаять өстендә тотылдың.

—Исбатлый алырсыңмы, иптәш сержант?!

—Җинаятьчесе тотылгач җинаяте күп аның бездә—табылыр... Менә дигән итеп исбатларбыз Субаев, дипломыңны күрергә мәхрүм булырсың.

—Минем белән юанып, юкка вакыт әрәм итмә, Райнур, бавыннан тартып төшермәгән булсам, бүрекләрне эзләп чын угрылар үзләре килер иде. Тотасы кешегез шушы тирәдә безне күзәтеп торадыр әле.

—Гражданин Субаев, тот капчыгыңны! Киттек!

—Хәзер, капчык күтәреп йөрисем калган икән, үзеңнең аркаңа сал.

—Грубо сөйләшмә!

—Барыбер капчык минеке түгел.

—Синеке шул, минеке диярсеңме әллә?

—Минеке түгел дим.

—Минеке дә түгел...

Кинәт кенә, күктән төшкәндәй, ике егет килеп басты:

—Берегезгә дә кирәкмәсә безгә бирегез.—Һәм егетләрнең берсе капчыкка килеп ябышты.

—Шаяртмагыз,—дип кырт кисте сержант.—Сез хәзер шаһитләр, менә бу каракны,—диде ул, Ансарга төртеп,—кичекмәстән алып китәргә кирәк.

—Шаһитләр... безме?! Сез кемнәр соң, каян килдегез? Бу шәһәрнең исеме ничек? Ни булешәсез? Күрмәдек, белмәдек. Хуш иттек.

Ике егет тигез атлап, дөп-дөп басып китеп тә бардылар. Сержант ни эшләргә белмичә аптырап калды. Шаһитләрне куып китәр иде... Ансар үзе генә кала, беләгеннән эләктереп тегеләрне куа китсәң капчык кала. Күзгә күренгән шаһитләрне югалталармы соң?! Һәр ике як өчен дә бик кирәкле кешеләр алар.

Ансар сержантка ярдәм йөзеннән, ике бармагын авызына кабып, милиционер сыбызгысы шикелле сызгыртып җибәрмәсенме!.. Шуны гына көткәндәй, агач өйләрнең берсеннән тәбәнәк, әмма юантык гәүдәле ир кеше очынып чыкты. Чыкты да йөгергән егетләрне карагклардыр дип уйлап, аларга:

—Стой! Атам!—дип кычкырды.

Шаһитләр тукталып, тавыш килгән якка борылдылар. Чынлап та, ир кеше кулында мылтык иде. Шуннан соң алар бер-берсе белән пышылдашып киңәшеп алдылар һәм әкрен генә капчыклы Ансар янына килеп бастылар:

—Без шаһит булырга риза!

Шушы районда патрульдә йөрүче милиция «Жигули»е килеп туктагач, сержант экипажга рапорт биргәндәй итте:

—Иптәш майор, засаданың тагын бер корбанын эләктердем. Монысы да бүрекле капчыкны бавыннан тартып төшерде,—диде ул Ансарга баш бармагы белән төртеп.—Шаһитләр дә табылды, качып китмәкчеләр иде, менә бу агай ярдәм итте.

Майорның погонындагы йолдызы караңгы төндә дә уттай янып тора. Ул мылтык тоткан ир кеше янына кочагын җәеп дигәндәй килде:

—Рәхмәт, Гадигали агай, син барында бу тирәдә милициягә эш әзәя.

—Эш дип инде, шаһитләрне генә туктаттым.

—Кайчагында опергруппа белән тотарга туры килә әле аларны. Барыгыз, Гадигали агай. Тынычлап йоклагыз... Шаһитләрегез өчен тагын бер кат рәхмәт.

—Агайны җибәрәсез, ә мылтык тотарга рөхсәт язуы бар микән? Иске бистә Мари урманы түгел ул, ауга йөрер җир юк,—диде Ансар, боерулы тавыш белән.

Майор белән Гадигали агай шундый итеп көлделәр... Болай итеп бары тик агач мылтыктан гына көләргә мөмкин иде.

Гадигали агай аксый-аксый китеп барды.

—Тозакны да, шаһитләр белән Гадигали бабайны да алдан ук әзерләп куйдың инде син, әйеме, Райнур?

—Алайга киткәч, шаһитләр белән дә танышыйк. Фамилияң бармы?—диде сержант егетләрнең берсенә фонарь уты төбәп.

—Мирзин.

Мирзин дигәне минут саен чалбарын күтәреп ала. Төшми инде чалбары, тик гадәте—ике куллап чалбар путасына тотына да кисәк-кисәк йолыккалый, пәлтә төймәләре чишелгән. Нервлары какшаган, күрәсең. Гаепле кешеләрнең шуның ише бераәр алама гадәте була, диләр иде психология дәресләрендә. Йә ул еш-еш тамак кыра, черт-черт күзен йома, көннәр буе җыр җырлап йөрергә мөмкин... Ә Мирзин чалбарын күтәреп-күтәреп куймаса, үз-үзенә урын таба алмый бугай.

—Байгушов.

Монысының йөзе өчпочмакка охшаган: маңгае киң, яңаклары ябык, ияге очлы. Сөйләгәндә, коелган алгы теше урынына теле кысыла.

Ул арада махсус машина да килеп җитте.

Әгәр ара-тирә сирена үкертеп алсаң, йә түбәдәге ялт-йолт итә торган утны сүндермәсәң, «Каракүл» берләшмәсеннән милициянең район бүлегенә кадәр араны «Жигули» ике минутта үтә ала. Ләкин сержант Асланов шоферга ашыкмаска кушты, чөнки ул бүген үзенә бирелгән рольне үтәр өчен барысын да ныклап, тагын бер кат яхшылап уйлап чыгарга тиеш иде. Ә Ансарның җене котыра...

—Син мине беләсең, Райнур, ун ел бергә укыдык, кеше әйберенә кызыга торган гадәтем юк. Кеше ярлары дисәләр кызларга да күнел салмыйм хәтта. Теләсәм Алсу җанашыңнан коры калдыра ала идем мин сине. Безнең авылда кыз урлау мәртәбәгә санала...

—Монда дәүләт милке турында сүз бара, Субаев!

—Кыз бала хосусый милек түгел ич. Син урлап өйләнден ана, сержант!

—Яратмаган кызлар урлатмый, Ансар. Без хәзер егерме беренче гасырда яшибез. Йолалар, традицияләр, дин һәм әхлак янара торган чорда. Гел кирегә сукалап утырасын.

—Бу минутта, караклык турында бәхәс куптарырлык сәбәп бар дип исәпләмим мин.

—Алай түгел шул. Кеше кесәсенә керүне караклыкка саныйбыз, ә дәүләт милкен кесәгә салып та, күтәреп тә, машинага төяп тә ташыйбыз... Шартын туры китереп, өй саен рәттән тикшереп чыксан—иң намуслы, иң акыллы, иң гадел дигән хуҗаның да чәлдергән яки эштән болай гына алып кайткан, һичьюгы бушлай кергән берәр әйберсе табылыр. Без бит миллион кешеле шәһәрдә яшибез: миллион авыз, ике миллион кул, ким дигәндә биш-алты миллион кесә...

—Артыгын анлатасы юк, биш ел буе дәресләрдә сөйләнгән болар... Бәхәсле әйбер. Кемдер ярты капчык бүрек урларга җыенган икән, ана карап бөтен ил халкына «урлыйсыз!» дип кычкырыргамы? Әгәр кешен заводта-фабрикада эшләмәсә?! Әйтик, интеллигенция үзенең эш урыныннан нәрсә ташый ала? Безнең кафедра мөдирен генә алыйк, чык бөртеге төсле саф күнелле... Университетта, белгәненчә, кирпеч измиләр, бензин кумыйлар, мануфактура цехлары ачылмаган әле... Аннан нәрсә күтәреп кайтмак кирәк?

Райнурга үз сүзен өскә чыгармыйча ярамый. Ни дисәң дә ул сержант кеше, ә рульдә кичә генә эшкә алынган рядовой «салага». Авторитет бәхәсләрдә яулана ул.

—Мөдирең үз йорты белән яшиме, Субаев?

—Ундүрт катлыда.

—Машинасы нинди маркалы?

—Җыелма велосипеды бар бугай.

—Туганнары олы урындамы?

—Детдомда үскән ул... Йә, әйтерең беттеме?

—Дачасы бармы?

—Кешечә инде. Дачасызлар юк ул хәзер.

—Вәт, күрденме,—диде Райнур, үзе шоферның җилкәсенә төртеп, мин хаклы—дача төзегән агай-энедә житәрлек инде ул чәлдергән материал!.. Шунысы кызганыч, безнең балаларга урларлык нәрсә калмый, алар үсеп җиткәнче дөньяны талап бетерәләр инде...

—Сержант дәрәҗәсенә хәтле ничек үсте микән бу, дип, баш ватам тагы, грамотныйланган син.

—Пагонны бушлай өләшмиләр. Димәк, кирәк чакта җанымны кызганып тормаганмын. Сиңа сөйләп торасы юк, тәвәккәллегемне хәтерлисендер?!

—Авылга кунакка кайткач, танцыга чыкмаганы өчен Алсуның күкрәгенә пистолет терәгәненне әйтәсенме? Батырлыгына клубтагы бөтен яшьләр шаккаткан иде шул.

—Уенчык пистолет бит ул, теге, утыз ике тәнкәлек. Клубка корал күтәреп чыгарга, әллә башыма тай типкәнме? Синең кебек студентларны биш бармагым белән дә каптыра алам мин... Нәрсә трамвайга ияреп барасың,—диде Райнур кинәт шоферга җикеренеп,—тизрәк отделга кайтасы бар.

Милиция бүлегенә кайтып кергәч, сержант белән майор аңлашкан арада Ансар янына бер агай килеп басты. Күрер күзгә җан этәргеч кешедәй тоелса да яңа чупланган бура исе килә үзеннән.

—Сине кем тотты?—диде ул Ансарга, үз итеп.

—Әнә, сержант.

—Мине дә. Юк белән яндым. Мебель фабрикасыннан мин. Диван аягы апчыгып бара идем, апаем, дүрт штукны кесәгә тыгып. Охранникның исе дә китмәде, ә урамда сиздермичә генә болар качып торган. Нәмәкәйгә

дип шушы проходнойга килгәнмен, белмим апаем? Безнең цехныкылар юкса, гел койма ярыгыннан йөри. Эшкә килгәндә генә проходнойдан керәбез. Каравылчыга күңелсез булмасын дип капкага килгән идем... юк белән яндым.

—Үзең әйтмешли, нәмәкәенә кирәк иде инде ул таяклар? Лутчы диванын гына күтәреп кайткан булсаң...

—Бәй, апаем! Анысы зур караклыкка керә бит анын!

—Болай да диван урлагансың диярләр...

—Китче, исәр... Күрәсең ич, салмыш мин, ангырайган башкаем белән тәктомалдан, ялгыш ияреп чыккан дип нык торачакмын. Иртән штрафлап озатырлар. Үзең нәмә белән каптың?

—Бүрек белән, чәшке тиресе.

—Белдем, «Каракүл» берләшмәсенә алыш-биреш эшем төшкәне бар. Бәй, апаем, син дә исереккә сабыш. Икебезне бер «КПД»га ябарлар.

—«КПЗ»гамы?

—Без миндәләлеләргә барыбер ул, апаем... Бер «КПД»га ябарлар... Иртән дус булып аерылырбыз. Тик кара аны, сержантларга каршы дәшә күрмә, авыр сүз әйтмә, «әйе, әйе!»—дип кенә тор. Майордан курыкма, беләм мин аны. Анын генераллары да берни түгел, ә менә сержантлары...

Агайның фикере бүленде. Ансарны күрше бүлмәгә дәштеләр. Сержант Асланов берничә бит чиста кәгазь куеп анлатма язарга кушты:

—Яз әйдә. Почмагында буш урын калдыр. Начальник исеменә яз.

—Беләм, беләм,—диде Ансар,—өйрәтмә!

Венера белән күрешергә дип ашкынулар, капчыктагы бүрекләр, классташ Райнур белән бәхәсләшүләр—барысы-барысы ярты бит кәгазьгә сыйды да бетте.

—Тәк...—Анлатманы укып чыккач сержант Аслановның беренче сүзе шул булды.—Син монда көн кебек ачык хәлләрне генә язгансың. Биш ел буе нәрсәгә генә укыттылар соң сине?

—Анлатма диден, әкият язарга кушмадың ласа.

—Ә син версияләреңне әйтеп кара. Бүрекләр биштәрдә тумагандыр бит, койма башына да жил белән менмәгәндер?! Свиданиегә барам дигәнсен, ул кызның исеме юк.

—Причем монда ул кыз?! Мин аны әле үзем дә бер генә тапкыр күрдем, зоопаркта. Исемен белмим.

Кеше дөресен сөйләргә теләмәсә, мәжбүр итмәгез, юкса, ул барыбер ялганларга керешәчәк. Дөреслекне сөйләп бирсә ул кемнедер югалтырга тиешле була. Гомер буе дөреслекне сөйләп йөрүчеләр һаман саен кемне дә булса югалта барып, ахыр чиктә бер үзе, япа-ялгызы кала. Ансар Венераны югалтырга теләми. Сержантка турысын әйтеп бетермәвенен сәбәбе шул.

—Гражданин Субаев, исемен белмәгән кызны төнге унбердә эзләп киләләрме?!

—Чибәр кызлар төн уртасында да таныла ул... Ни, иптәш сержант, колак очыма телефон номеры чалынды: 3-52 бугай. Проходнойдан шылтыратасы.

—Ә син, причем дисең! 3-52 номеры берләшмәнең унынчы фабрикасы бит инде. Әлеге бүрекләр шунда тегелә.

—Чынлап мәллә?!—Ансар аптырашка калды.

—Белмәгәнгә сабышма. Болайга киткәч, каптың инде, Субаев. Йә бүрекләрне үз өстенә аласың, йә безгә булышасың!

Сержантны инспектор ашыктырды.

—Ашыксак та ярый, Субаевның торган жиренә барып житкәнче, тентү ясаганчы, таң ата.

Һәр эшнең үз тәртибе бар.

Заводта яки фабрикада берәр карак тотылса, жинаять кодексы нигезендә, урлаучының өенә кичекмәстән тентү ясалырга тиеш. Ягъни, өендә урланган мал сакланмыймы—шуны белер өчен. Дөрес, әлеге

малдәнең бер почмагында: инспекторны проходнойда торучы каравылчы чакырырга тиеш, диелгән. Моны ничек аңларга?.. Хикәябезгә кагылышлы булмаган бер мисал китерик. Әйтик, бер шаян ханым, үзенен нечкә биленә урап эшкәртелгән тире алып чыгып карамакчы иде ди. «Күбәләк канаты» аркылы үткәндә каравылчы дәдән, сизгер куллары белән ханымны капшап, әлеге тирене күпертмә койрыгыннан тартып чыгара, шул мизгелдә «Күбәләк канаты» шартлап бикләнә. Тавышка каравылчылар начальнигы йөгереп килеп житә һәм нечкә билле ханымны тәмәке төтененнән ысланган кечкенә бүлмәгә ябып та куя. Карышып-нитеп маташуның хажәте юк, жинәрләр, сменада берьюлы дүртәүләп саклый алар... Ханымның тән жылысы сеңгән тун өлгесен минималь хезмәт хакы белән бәяләп, акт төзелә дә шундук инспекторга хәбәр ителә... Ләкин, ни хикмәттер, инспектордан алдан цех начальнигы килеп өлгерә (белмим, кем житкергәндер ана?!). Ул тиз генә акт кәгазен кесәсенә салып куя һәм инспекторга ияреп ханымның фатирына тикшерергә бара, пүнәтәй рәвешендә. Ханымның өендә имгә дисәң дә затлы мех әйбер табылмый: туны ясалма тиредән, көзге пәлтәсе—якасыз ясалма замша, бүреге—чебурашка курчаклары тегә торган йонлач тукымадан әвәләнгән, чит кешеләрне күрсә эт булып өрергә әзер торган кара песи генә натуральный тунын кабартып аяк астында буталып йөри... Димәк, әлеге хатын гомер буе купшы тауар янында эшләп тә беренче тапкыр гына шаярган. Бәлки аның нечкә биле туна башлагандыр... Артык гауга куптарырлык сәбәп юк... Акт кәгазе цех начальнигы кесәсендә кала, ханымның «эше» халык судына барып житми. Ак чәчәкнен дә күләгәсе бар, ханымның башыннан сыйпап рәхмәт әйтмәсләр, әлбәттә, цех жыелышында аягүрә бастырып оялтырлар. Өч минималь хезмәт хакы күләмендә штраф түләтерләр, бәлки әле ике генә айга арзанрак эшкә дә күчереп торырлар. Тик хөкемгә тарттыру кирәкми. Ханымга да, цех начальнигына да кирәкми ул суд. Ни өченме?

Шәһәрнең яшәү гаме бүреклеләр ярышына корылган: жиеннары—бәйге тотып, уңыш бәйрәмнәре—сүз куешып, атлары—чабышып, машиналары—узышып куандырыр. Бүрек тегүчеләр үзләре дә ярышып яши. «Каракүл» берләшмәсенең һәр ун фабрикасы арасында сыйнфый көрәш бара. Продукциянең сыйфаты, эшкә мөнәсәбәт, вакытны дөрес файдалану, чималны янга калдыру, эш урынындагы тәртип кебек мөһим күрсәткечләрне чагыштыргач ел ахырында кайсы цех начальнигының күбрәк премия аласы ачыклана...

Сержант Асланов «капчыклы бурны» койманың урам ягында тотып алды, шуңа күрә дә әлеге вакыйганы проходнойдагы каравылчыларга сиздереп мәшәкатьләнмәде. Иртәгә белерләр алар бу турыда, ә бүген вакыйгага Асланов үзе хужа.

Шәһәр күленә саф һава суларга чыга торган чаклар, калын боз тынчыган суны томалап куйган. Ансар урнашкан фатир—ике катлы агач йорт, Дегетле урамының теге башында, алгы тәрәзәләре белән шәһәр күленә акаеп тора. Фатир хужасы, түләү мәсьәләсенә килгәндә, студентлардан акчаны ел фасылына карап ала: тәрәзәләр ачылыр чакта, тирләп-пешкән шәһәр күле боз астыннан чыккач, бер айга ун доллар, ә тәрәзәләр ябылып кышка пластилин белән сылап куелгач унбишне сорый.

Челт-мелт лампалы милиция машинасы килеп туктагач, келәт хужасыннан өреккән ата мәчеләр шикелле, подъезд ишегеннән бер кабилә малай-шалай ишелеп төште.

—Һай! Һоп! Уһ!—дип бармак янап калды сержант,—вакыт кына юк, мин сезне өерегез белән бергә...

Яр буендагы әлеге ике катлы агач йорт затонга качкан йөзмә пристаньга охшаган иде. Тәрәзәләре күп күбен, ләкин ишеге бер генә икән. Ишек янагына уелган төймәгә баскач әллә кайдан гына сангырау тавыш ишетелде.

—Ыхтутам?

—Без.

—Апа, мин әле бу,—диде Ансар, сержант тавышына ишекнең ачылмаячагын белеп,—дуслар белән.

—Шушы вакытка хәтле йөргәч, таң атканны көтсәң ни булган. Тәмле йокыны әрәм итеп... Студент халкын фатирга кертерлекме соң... Эштән арып кайтсалар йокы кадерен белерләр иде,—дигән зарлануларга кушылып эчке яктан ишек шудырмасы ыңгырашып куйды. Ишек ачылып китсә дә каршы алучы күренмәде. Сержант кесә фонаре кабызып болдырны айкаган иде, ишек шудырмасына бәйләнгән озын бау күзгә чалынды—бауны икенче каттан торып кына тарталар икән... Такта баскычтан икенче катка менгәч каршыга тагын ишек килеп басты,—үзе зур, үзе калай белән тышланган. Берәм-берәм йозаклар келтерәде, келәләр шалтырады.

—Фатирантларны шәп саклый апагыз,—дип көлемсерәде сержант,—мал кадерен белә!

Пүнәтәйләр эзләп урамга чыгасы юк икән, янәшәдә генә тагын бер калай ишек бар. Күршедән карт белән карчык килеп керделәр.

Хуҗа кеше, биш ел фатирда торган Ансарны танымагандай, усал карап куйды. Төнге «кунаклар» белән мазасызлап йөрүен өнәмәде. Шулай да милициянең күрше-тирәләр җалобасы буенча түгел, ә Ансарны тикшерер өчен килгәннәрен белгәч үзен тыныч тотты.

Тентү беркетмә кәгазе өчен генә кирәк иде, сержант өметләнгән нәтиҗә күз алдында.

Инспектор сержант белән, ник килгәненә үкенгәндәй, йорт эчендәге җиһазларга: ян-ягы фанерадан түгәрәкләп бөгелгән кием шкафына, рамнарына кара җимеш төшләре ябыштырып, кулдан эшләнгән нәзек озын сервантка, агач эшкәртү остаханәләрендә өйрәнчекләр әтмәлләгән дүрт кырлы такта утыргычларга, үз гомерендә әллә ничә кат буяу күргән тимер караватларга тагын бер карап куйды да фатир хуҗасыннан гафу үтенеп чыгып китте.

Фатир хуҗасы, пунәтәй күршеләренә һәм сержантка яхшы күренергә теләп, Ансарның бар мөлкәтен—китаплары белән кием-салымын ишек төбенә өя башлады. Ансар уңайсызланудан күз карашын кая яшерергә белмичә интекте, аптырагач түшәмгә текәлде. Анда олы бер үрмәкүч, яшәүдән туйган җан ияседәй, матча тирәли «бау» күтәреп йөри... Бауның бер очы—аулда...

—Апа, китапларга кагылмагыз, аларның гаебе юк. Берүк идәнгә чәчә күрмәгез! Иртәгә көндез өегезне бушатырмын—бу Ансарның соңгы сүзе иде.

Баскычтан йөгереп диярлек төшсә дә Ансарның ашыгырлык урыны юк.

«Жигули» тагын милиция бүлегенә юнәлде.

—Ансар, туганнарыңамы, дусларыңамы—кайсысына илтеп куйыйк соң үзеңне?—диде Райнур. Ул инде хәзер баягы кырыс сержант түгел. Масаюы сизелми, тавышында кинаяләү тоны да юк.

—Рәхмәт, классташ. Фатирымнан кудырттың, инде туганнарым йөз чөерсен дисеңме?

—Алайса, әйдә безгә!

—Ы-һы!..—Ансарның бу ымлыгы: шушы хәтле кәмитләреңнән соң өеңә чакырырга ничек телең әйләнә, дигәнне аңлатса кирәк...

—Алсу да сөенер. Чынлап, Ансар, әйдә!

—Уйларымны бүлдермә әле, Райнур...

—Менә син, Ансар, бүген авыр хәлдә калдың, фатир хуҗасы алдында дим... Ә мина киресенчә җинел булып китте.

—Үч алгачмы?

—Нинди үч? Бүлешер малыбыз юк ла... Минем урында булсаң син үзең дә нәкъ шулай эш итәр идең бүген.

—Шушы тирәдә туганнарым бар, төшеп калыйм әле мин.

—Үпкәләмә, Ансар,—диде Райнур, «Жигули» туктагач,—егет бул!

—Бик тиз үсәрсен, классташ, мин өйгә кайтып житкәнче өлкән сержант итеп куярлар үзенне.

—Үпкәләсән үпкәлә, тик бүрек каракларын тотарга булыш. Шундый шәп план корып куйдым, шаккатарсын. Синен белемен дә, ярдәмен дә бик кирәк безгә, Ансар. Диплом алгач сине милиция эшенә жигеп булмас. Адвокатлар алар өстәл артына утырып кына безгә караганда да күбрәк акча алалар. Без гаепленәрне эзлибез, куабыз, тотабыз, кан коябыз... Ә син менә аларны яклап яшәрсен, гаепле түгел дип аклап, кире жибәрерсен.

—Конституция бөтен кешене якларга куша.

—Ашыкмый тор, Ансар. Киләчәк турында зурдан кубып сөйләшмик. Син әүвәл үзенне якларга өйрән әле—менә булырсын адвокат!

—Укуны ташлап хулиганнар куып йөрергә кушасынмы?

—Ташлама! Жаен тап. Яз житкәч, кар астыннан тукталыш саен бишәр-алтышар буш акча янчыгы килеп чыга. Без инде трамвай-троллейбуслардагы кесә каракларын жинаятьчегә дә санамыйбыз—шук куллы малайлар гына дибез. Бүрек салдыручылар, машина талаучыларны да күрмәмешкә сабышабыз. Вакыт юк безнен вак-төяк эшләр белән йөрергә. Бер миллион карак төрмәдә утыра, әле тотасылары күпме?! Бүрегә зуррак булган саен кулга алуы кыенрак.

—Беләм,—диде Ансар, сонгы яналыклар турында хәбәрдарлыгын сиздерергә теләп,—каракны хәерче чагында тотып калсан гына, баегач тоттырмыйлар алар...

—Мине анлавын өчен рәхмәт!—диде сержант саубуллашып.

«Рәхмәт» сүзен әллә ничә төрле мәгънә белән әйтеп була икән.

## Йокын ничә сум тора?

Калын-калын кодексларны рәттән укып чыксан, рөхсәт ителә, ярый, мактаулы эш, хокукын бар... кебек сүзләрне бик аз очратырсын. Анын каравы: катгый тыела, жинаять санала, мәжбүри, мәхрүм ителә, ярамый һәм башка шул мәгънәдәге сүзләрнен исәбенә чыгарлык түгел. Сабыймы син, үсмерме, яшь иптәшме, олы яки өлкән яшьтәме—барыбер синен өчен «ярый»га караганда «ярамый» күбрәк. Ярый-ярамый, белә-белми, жинә-жинелә, сөя-сөйми, табыла-югала... Табуга караганда югалтулар күбрәк. Бер бәхетенне эзләп табу өчен күпме югалту кичерергә кирәк.

Ансар урамда калды. Дегетле урамыннан куылгач, бүген инде барып сыенырлык кеше калмаган иде. Төн уртасында кемнен кемгә кирәге бар?

Кышнын бик мактанчык чагы, атналап-атналап салкыннар гайрәтләнә. Тик торган жирдә бигрәк кыен—түмрәннәренне чатнатырлык үткер суык. Жәйге төн булса тан атканчы урамда йөрер иден, кышкы төн кешене сөйми, урамнан бик тиз куып кертә.

Рельслар буйлап атлый торгач, каршыга дежур трамвай килеп чыкты. Йөртүчесе ялгызлыктан туеп пассажирлар эзләп йөри мәллә—шундук ишеген ачып тукталды. Уйлап-икеләнеп торырга вакыт юк, салкын дигәнен ашыктыргач Ансар тимер баскычлардан очып кына менде... Бу кадәр буш урынны күргәне юк иде әле егетнен. Ике вагонлы трамвайга бер пассажиры бар—анысы да кайтыр юлын югалтып гырлап йоклап ята, сәләмә бүрегә аяк астына төшкән. Маршрут буйлап тик әйләнсен, дип, йөртүче кыз аны уятмаска тырышадыр, буш йөргәнче пассажир булыр шунда.

Ансар үзен суыткыч эчендә бикләнеп калган малай-шалай кебек хис итте. Ләкин башка чара юк, вокзал тукталышына житкәнче түзәргә кирәк. Ә анда жылы... Анда тан атканчы рәхәтләнеп черем итеп алырга була.

Төн шул... вокзалнын таныրлыгы калмаган. Көндезге мәхшәр

сүрелгән, залдагы халык тыныч: килгән-киткән поездларга ис китүче юк, уяулары ярты тавыш белән генә сөйләшә. Көнозын ике аяклы ларек сыман шәһәр буйлап чабып арган базар хатыннары да бер күчкә өелеп, сатылмый калган тауарлары өстенә сөялгән килеш йоклап яталар... Аларга ярый, әмма Ансар урындыкка сузылып ятса, башка урынсызлар аны шундук төрткәләп уятырлар иде әле. Их, йокла идең шулар кебек рәхәтләнеп!

Диктор, саташып уянгандай, йокы аралаш кемнәрнедер, ниндидер поездга утырырга үгетләп карый. Залдагылар аңа колак салмый, әллә ышанмыйлар, әллә пассажир буласылары килми. Утырып йоклар өчен махсус күнегергә кирәк. Ансарның ул яктан тәҗрибәсе юк. Йокы дигәнең керфекләреннән тотты инде үзен. Муенның баш күтәрерлек хәле юк. Ансарны күргәч дружинниклар да тыныч кына үтеп китә алмадылар.

—Гражданин, йоклап калмагыз, 111 нче поезд китәр чак җитә,— диделәр алар, яттан шигырь сөйләгәндәй кистереп кенә.

—Поезд?!—Гаҗәпләнүдән бигрәк, Ансар сөенгән иде, чынлап та ял итәр өчен поезд шәп нәрсә бит, әй!—Рәхмәт, егетләр, әле ярый искә төшердегез.

Ансар кассага йөгерде. Билетны ул күрше шәһәргә кадәр генә алды, биш сәгатьлек юл җитәр, кайтканда тагын биш сәгать үтәр. Барып кайтырга ун сәгать—бу кадәр йокы бәйрәм көннәрне генә тәти ул студент кешегә. Йокысы да әллә ни кыйммәткә төшми, бару-кайтуы белән ярты стипендия хакы. «Русия» кунакханәсендә бер төн уздырган өчен дә өч айлык стипендияңнән колак кагарга кирәк. Йокы иң арзан ризык, димәссең, түбәнне югалтсаң.

Поезд кузгалганчы Ансарга юешләп төрелгән соры урын-җир китерделәр. Өстәге сәндерәдә тыныч иде. Салкын җәймәгә тән җылысы үтеп керү белән йокы дигәнең изрәтеп егетне өнсез калдырды. Тик, ләззәтле йокыны кыска-кыска төшләр бүлгәләде. Ул төшләрнең төп үзәгендә гел проводник хатын гына. Студентлар җәйге каникулда төзелешкә кия торган яшькелт-соры куртканы тәненә ябыштырган да әллә кем булып йөри, җаны теләгән кешегә җаны теләгән сүзен әйтә: «Сыер», «йокы чүлмәге», «капчык» дигән сүзләрне аеруча күп куллана. Ансар ана: «Институтынны ташлап бик дөрес эшләгәнсең, синнән рәтле педагог чыкмасые!»—дип әйтергә тели теләвен, ләкин уянып китүдән куркып дәшми кала. Ә төш дәвам итә... Менә проводник хатын милиционер ияртеп килгән, сәндерәдә аның башы гына күренеп тора, аяк очына басып үрелә-үрелә Ансарны күзәтә ул, Райнурга охшаган бу милиционер—борыны бөтен битенә җәелгән, калын кашлары бергә тоташкан—күз өстенә мыек чыккан кебек. Имеш, Ансардан сорау алалар.

«Кая киттең?»

«Йокыга».

«Эзләп тапмас дип белдеңме, алдана торган Райнур түгел мин».

«Әйтерием, фуражкаңнан оялам...»

«Иртәгә розыск белән кайтарам».

«Тыныч йокы, сержант Асланов! Ха-ха-ха, хы-хы-хы, хыр-хыррр...»

Төшләрнең дәвамы юмористик пландарак иде... Алары эротик күренешләр белән алышынды. Урыны-урыны белән оятсызрак мизгелләре дә булмады түгел. Тик ул төшләр, уянгач станция исеменә күз салуга ук, онытылып бетәрләр.

Ун минут чират торырга иренмичә билет алып, Ансар кебек икенче каттагы сәндерәгә менеп ятсаң, икенче ягына борылганда урта яшьләрдәге бер станциягә жителгән булыр. Поезд тәрәзәсенә ябырылып карасаң, бу станциянең ярты гәүдәсе агач авыл, икенче яртысы көймә бүрекле кукуруз патша заманында салынган эре панельле—тиз өелешле йортлар тезмәсеннән торган шәһәр икән.

Юлга чыкканда кулың буш булса рәхәт тә соң! Пәлтәсе белән сарык йонынннан эрләп бәйләнгән баш киемен эләктереп вагоннан чыкты

Ансар. Озак та үтмәде, кайтучы поездга дигән билетын учына кысып, янә сәндерәгә—бу юлысы инде өченче катка ук менеп ятты ул.

Ансарны поезд баскычларындагы бозны вата торган кисәү белән төртеп уяттылар. Өченче катта вагон тәрәзәсе юк, тәбәнәк түшәм генә. Вагон эченең бушап калуыннан чамалап, поездның миллионер шәһәргә кайтып туктаганлыгын абайларга була иде.

Кичәге борчулардан качып, йокы туйдырып йөргән арада, көннең чырае яктырган. Ак эскәтергә йоккан лимон табы кебек кенә кояш беленеп тора, аның түгәрәклеге югалган, чит-читләре тузгыган—тануы кыен. Кояштыр инде, шәт, сөтсел болыт каплаган шәһәр күгендә тагын ни булсын?! Үзәк мәйданга юл күрсәтеп торучы ялангач юкәләрне ап-ак бәс сарган, ерактан караганда алар ялтыравык кәгазьгә төрелгән ясалма чыршы кебек җемелдәп балкыйлар...

## Тарих сакчысы

Ханкала стенасы тирәсендәге чокырларга калын кар өелгән. Кыш уртасында ул кар тарих җәрәхәтенә яна каплаган мамык кебек ап-ак булып тора.

Җәен-көзен әллә кайдан ук акшарланып балкып торган таш диварлар кышкы аклыкка бик җинел кушылдылар. Кышын мондагы һәр манара, һәр бина кардан өелгән текә тау төсле, алардан салкынлык бөркелеп торуы да шуннан бугай. Манараларның берсе, «Ханбикә» атлысы, җәй дә, кыш та төсен алыштырмый—гел кызыл төстә. Аны акшарламыйлар, алтынга манмыйлар, тарихны кимсетергә теләмиләр.

Заманында һәр таш кисәге саен гаскәри мәргән беркетелгән Ханкала стенасын бүген бер үзе саклый Гадигали агай. Саклый дигәч тә, кулында мылтыгы йә дудуры мазар юк. Йөнтәс бүрекле абзыйларның берсенә корал сорап кергән иде ул. Тыңламадылар.

Юньсез кеше генә утлы корал йөртә, синең кебек изгеләргә беркем тими, диделәр. Корал ул угрыларга халык нәфрәтеннән сакланыр өчен бирелә икән, вәт... Кемнең күпме урлаганын коралына, тән сакчысына, «иномаркасына» һәм коттеджына карап белеп була, ди. Тән сакчысы—«текә» агайнеләр өчен уйлап табылган заманча «конвой» гына, имеш... Корал ышанып тапшыра алмыйбыз, ханкалада каравылчы штаты буш түгел диделәр. Министр абзаннар эш сәгатен төгәлләп өйләренә таралышкач монда инде урланыр нәрсәләр калмый бугай.

Гадигали агай элек-электән ханбикәләргә гашыйк. Каравыл киченнән җилләнеп кайтып кергәч Сөембикә җингәгез җылытып куйган кайнар юрган эченә чумасы бар әле аның. Гадигали агайның буш вакыты тарих һавасында үтә, өйдә аяк астында чуалып йөрми. Хезмәт хакы сорап интектермәгәч күргән-белгәннәр каршы төшми.

Һәр тәрбияле гражданинның ике эше булырга тиеш: берсе, әлбәттә, акчага әйләнә торганы, ә икенчесе бушлай гына—җәмәгать эше диләр аны. Беренче эш мәсьәләсенә килгәндә, Гадигали агай хезмәт срогын тиешенчә «утырган» пенсионер, сугыштан соң, ул кырык ел буе уналтынчы завод капкасында каравылчы булып утырды. Әлеге икенчесе—җәмәгать тәртибендә тарих сакчысы булып йөрүе. Дөрес, баштагы мәлдә ул пенсия кенәгәсенә кимсенеп, акча түли алырдай бер оешмага тагын каравылчы булып урнашып караган иде, балавыздан ясалма умарта кәрәзләре эшләү заводына. Бик тынгысыз җиргә эләкте. Янәшәдә генә шәраб заводы ис куа, аның тирәсендә, төне буе ач күселәр төсле, ирләр йөгерешә. Стакан мазар яки кабарга берәр сынык ипи сорап туктаусыз капка дөбердәтәләр. Иртәнге якта ишекләрдәге йозакка чәпәлгән балавыз пломбаларның исәнлеген тикшереп журналга кул куясың да күрше шәраб заводыннан йөзеңне яшереп кайтып китәсең... Ә бер көнне, йозак өстенә исерек чыпчык кунып, йозактагы балавызны чукыган... Шуннан китте ревизия

ясаулар... Урларлык әйберсе булса иде ичмасам, складлары тулы иске балавыз да сумала!

Өйгә кайткач Сөембикә җанашы тиргәде соң үзен: пенсияңне әзсенеп завод капкасыннан чыпчыклар куып йөрүе ничу!.. Әнә, вакытыңны кая куярга белмәсәң тарихны каравылла, дип, бушлай эшләү урынын әйтеп тә бирде.

Баштагы мәлне Ханкала тирәсендә борчулы уйлар белән йөрде Гадигали агай, Кызыл манарасы ава башлаган дип үзәккә үттеләр. Көне-төне белән өенә кайтмыйча манара саклап кунган чаклары да булды абзагызның, ауганын күреп калыр өчен түгел, күңеленнән генә, әллә нинди терәүләр куярга планнар корды. Яшәсен иде әле ул. Борынгыдан калган хәзинә ләса. Кирәксенмәсәләр чит илдән килгән туристлар сырып алмаслар иде аны. Ханымнар алдында кылтайган сыман, фотоаппаратларын аркылы-торкылы тотып фотога төшерәләр, нигезен колачлап үлчиләр, гидлары күрмәгән арада кирпечләрен кырып карыйлар, иснәп тә китәләр... Бүгенге төзүчеләребез салдырган, эченә керсәң чыгасы килмәслек мәһабәт йортлар, сарайлар бар... Юк, туристларга тарихны давай! Инде тарих серләренә төшенәбез дип, Ханкала стенасының казылмаган төшен калдырмадылар. Актаралар гына тарихны... Түзә ул, тарих. Ханбикә манарасы да түзә. Аумаячак ул, нигез өлешенә кыйгач скважиналар бораулап, бетон измә тутырып ныгыттылар аны.

Кояш шәһәр өстеннән китеп көнбатышка авышкач, чиркәүләрнең арзанлы алтын ягылган гөмбәзләре яктырып кала. Кояш баешының кызыл нурлары, аларның бәясен күтәргәндәй, борынгы алтын төсенә кертә, вакытлыча гына...

Ак диварлар буйлап бер әйләнеш ясап, бер мең җиде йөз илле адым юл үтә дә Гадигали агай, археологлар җәйдән үк казып калдырган тирән эчле сандыксыман шакмаклы чокырлар янында туктап кала. Кар өсте шул килеш—димәк, тыныч! Кеше килмәгән, казымаган. Бу сандыкларда әллә нинди табылмаган хәзинәләр ятадыр әле. Сизмичәрәк калсаң, кибет баскан кебек кенә итәрләр. Кремль стенасының нигезенә күрәк төрткән саен хәзинә ияреп чыга. Кая җыялар ул табылдыкларны, кемнәр хуҗа аларга хәзер, исәбе алынамы? Димәк, тарихка каравылчы кирәк. Әле дә инде, монарчы начар каравыллаганнар. Әнә, урта гасырларда манаралар саны унөч булган диләр. Бүгенгесе көнгә сигезе генә исән калган. Адәм рәтлерәк саклардай каравылчысы табылмаган, күрәсең. Гадигали ага килеп житү белән иң әүвәл манараларны санап чыга... Ике башлы бөркет күргәнче сигез манаралы «Хан Шагыйрь» мәчетен күтәреп өлгерерләрме?..

## Кемлегеңне белеп йөр...

Ашыкма син...

Ашыксаң бөтен нәрсә үчегер үзенә.

Әгәр, йокы поезды бер сәгатькә сонарып килмәгән булса, әгәр туксан тугызынчы шәһәр поездыннан төшкән пассажирларны каршылаучылар арба-чаналар сөйрәп перронны каплап алмаса, әгәр тукталыштагы саилче агайның уч төбенә салырга хәер эзләп вакыт әрәм итмәсә, әгәр трамвай көтмичә уку йортына чаклы җәяү генә килгән булса, әгәр унсигез катлы корпусның өч лифты да жирнең тарту көчен җиңәлмичә беренче катта ук туктап калмаган булса... Ансар икенче лекциягә өлгерә ала иде әле.

Ул соңгы лекциягә генә килеп житте.

Егетне гаҗәпкә калдырганы шул—курсташ дуслары аны көлешә-көлешә каршы алдылар. Хәтта, бүген иртәнге жиседән бирле елмаеп карамаган педагог—кафедра мөдире дә студентларына хас эчкерсезлек белән елмаеп азапланды һәм елмаюын сакларга тырышып, криминалистика

өлкәсендәге яна техник казанышлар турындагы плакаттан аерылгач, кулындагы эбонит таягын Ансарга төбәде.

—Сезнең каршыда сирәк очрый торган, әмма типик күренеш. Районның эчке эшләр бүлеге хәбәр итүенә караганда, Ансар Субаев гафу ителмәслек җинаять эшләгән. Менә-менә диплом алам дип торганда, булачак юрист кеше дәүләт милкенә кул сузган. Алибиең бармы, Субаев?

—Юк.

—Алиби юк. Ишеттегезме, бернинди дә алибие юк! Иптәшләренен ышанычы гына бар. Алар Субаевны гөнаһсыз, самими һәм вөҗданлы егет дип теләсә кемгә расларга әзер торалар. Гражданин Субаев, гаебеңне таныйсыңмы?

—Юк гаепне ничек танымак кирәк?!. Хуҗа Насретдин мәзәгендәге хәл бу. Бау урлап кына харап булдым, дигән Хуҗа, бауның икенче башына сыер бәйләнгәндер дип кем уйлаган... Мин дә шулай, бау гына тарткан идем, ярты капчык бүрек килеп төште. Ант әгәр, һич гаебем юк.

—Эчке эшләр бүлеге мөһерле кәгазь җибәрсә синең антыңнан көчлерәк булыр, шулай бит, Субаев?

—Әйе. Ләкин... Шуңа карамастан... ничектер... белмим... кыскасы, гаебем юк.

—Җинаять өстендә тотылуың фактмы?

—Анысы чынлап та факт кебек килеп чыга...

—Димәк, үзеңне акларлык дәлилләрең юк. Гаебеңне танырга туры килә. Башка чара калмый.

—Бар. Чара бар!!!

—Нинди?

—Мин чын каракларны үзем эзләп табарга тиеш!

—Менә бу фикереңдә яшь юрист авазы бар! Диплом эшеңнең темасын үзгәртәбез. Әгәр практикаң беткәнче үз-үзеңне шушы адәм көлкесеннән йолып ала алсаң, диплом эшеңә «5»ле дип исәплә. Инде каракларны тотып китермәсәң... ул чагында синең эшеңне башкалар яклар...

—Бик дөрес.

—Диплом эшеңнең җитәкчесе булып үзем калам. Ә хәзер бар, утыр,—диде кафедра мөдире эбонит таягы белән буш партага таба юл күрсәтеп.

Кафедра мөдире үзенең мәртәбәсе белән теләсә кайсы районның халык судьясына «син» дип кенә дәшә алырлык кеше. Шуңа күрә, аның «утыр!» дигән сүзеннән аерым мәгънә эзләп, студент егетләр дәррәү күтәрелеп көлешеп алдылар.

Ансар дәресләр бетүгә студентлар арасыннан кинәт юкка чыкты—иярмәүләре хәерлерәк, кинәшләреннән туйган. Әгәр алар сүзенә колак салсаң, алар уйлап чыгарган версияләр буенча эзләнергә тотынсаң—бу инде диплом эшен күрше партада утыручы дустыңнан күчереп алу белән бер. Ансарга әйтеп торучы кирәкми.

Кичке аш вакыты.

Бензин имәргә дип колонкалар тирәсенә машиналар тезелешеп яткан... Эш сәгатеннән котылган хатыннар сумка күтәреп базар санап йөриләр. Халыкның, кышлаудан чыккан чагы, кайда яшел үлән күрсә, шунда барып ябырылырга әзер тора. Яшелчә кибетенә кергәннәре беләкләренә кыярга охшаган озынча яшел «уклау» салып чыга. Алар арасында салат яфраклары да күренә. Ниһаять, кибетләргә яшел төс керде, авитаминозга каршы көрәш башланды. Кибет янында башы белән капчыкка чумган ат та солысын ялмарга онытып, кыяр күтәргән хатыннарга ияреп китәргә тора. Аяклар үзләреннән-үзләре «Чәй йорты» ягына атлады, әйтерсең лә шул тирәдә Ансарны Венера эзләп йөри...

Өчпочмак буына килеп кергәч, бөтен мәшәкатьләр онытылды. Кайнар өчпочмак—ит әйбере талонлап бүленгән чорларда да исән калып сокландырган тәгам, шәһәрнең милли горурлыгы!..

Өчпочмак чираты тиз үтә, чөнки сайлана торган товар түгел, микродулкынлы мичтә җылынып өлгергәнен эләктерәсең дә рәхмәтеңне әйтәсең.

Кеше тикшерү дигән алама чир чиратларда яралган булса кирәк. Ак калфаклы ханым, алтын-көмеш балдаклардан салмакланган симез бармаклары белән вак акча санап тилмерә. Чиратның тиз узуы аның акча санау тизлегенә бәйле. Чираттагылар эш юктан гына бер-берсен күзәтә башлый. Һәр профессия кешесе күршесен үзенчә күрә, үзенчә бәяли. Әйтик, чираттагыларның берсе «Руслан» ательесында тегүче ди. Ул өчпочмак сорап тезелгән сафның кием-салымын күздән кичерә дә чыраен сытып читкә борыла, йә бөтенләй китеп үк бара; ләвкә тирәсендәге идәнне таптап биеп торган читекләрне барлап торучысы—аяк киемнәре берләшмәсенең фирменный кибетендәге дизайнердыр; бу чиратка чәч китәрүчеләр дә эләгәдер—тузгыган чәчләрегезне яшерегез; чиратсыз кергәннәрнең якасына ябышырдай булып педагог карап тора; тимер акча санаучы бармакларның шулпалы өчпочмакка батып керүен врач абзаң түзеп карап тора алмый—теге «Руслан» тегүчесенә ияреп китеп бара.

Ансар чиратның «койрыгына» китереп басты һәм әлбәттә, чират ялт итеп аңа текәлде. Үз нәүбәтендә Ансар да алдагы кешеләрне гражданлык һәм җинаять кодексы статьяларына сыйдырып карады. Чиратта күпме кеше бар—һәммәсенә өлеш тия, һәркемнең үз статьясы. Ник дигәндә, закон күзлегеннән карасаң, бу фани дөньяның һәр фигыле, һәр сыйфаты, эзләнү-табышлары, ачыш-югалтулары, сөенеч-көенечләре һәм барча-барча вак-төякләре билгеле бер рәвешкә туры китереп, кодекслаштырылган... һәм кешенең бөтен тормышы статьяларга таркатылган. Кодекс-статьялар синең бәхетеңне бөтен килеш сакларга тиеш.

Чират койрыгы Ансардан соң да сузылды. Янәшәгә туры килгән күзлексез агай кай ягы беләндер игътибарны үзенә җәлеп итеп тора, күз карашларының танышлыгы белән, ахры. Бер ноктага төбәлсә, ул шул ноктада бик күп нәрсәләрне күрә бугай, карашының җитдилеге, уйларының ераклыгы белән шулай тоела.

Ансар кайнар өчпочмакны кулдан-кулга күчереп үзе дә сизмәстән күзлексез агайга иярде. Бер аягына катырак баса икән—атлаган саен, сай чокырга туры килгәндәй, чүгеп-чүгеп ала. Максатлы кешегә охшаган, юкка-барга игътибар итеп тормый—алга карап туп-туры һәм тиз атлый. Шигырь ятлаган мәктәп баласы шикелле авыз эченнән сөйләнә үзе. Ансар эндәшмичә түзмәде, чөнки таныды ул аны. Соң, әлбәттә, бу бит теге шаһитләрне агач мылтык белән куып торткан Гадигали агай.

—Гадигали агай, сезнең берәр хәсрәтегез бар мәллә?

—Дөньяда хәсрәтсез кеше—шамакай гына. Минем яшькә җиткәнче хәзер үк бер нәрсәне анлап куй—кеше сабый чактан ук үзен каравылчы итеп тоярга тиеш. Кая карама байлык...

—Нинди байлык, Гадигали агай?

—Син үзеңне кем диден әле?—Гадигали колакка катырак бугай, теге сорауны ишетмәде.

—Ансар атлы мин, студент...

—Шулай... Көндез пенсиядә, кичен җил куам... Сугышып йөргән өчен пенсия түлиләр. Биш ел сугыштым, һичнинди пуля тимәде. Буй кечкенә булгач исән калдым. Озын егетләрне снайпер чүпләп бетерде. Җинеп кайтучылар арасында калкулары бик сирәк. Иртәгә җиңәбез, дигәндә генә яныма снаряд төшеп шушы аягымны йөз дә сиксән градуска—кайту ягына таба борып куйды. Врачлар бик нык изаландылар. Баштарак бик борчылганыем, мәйтәм, бер аягым алга, бер аягым артка таба йөри торган булып калса нишләрмен?

Гадигали агайга, хөрмәт йөзеннән нindидер җылы сүз әйтәсе килде Ансарның.

—Алайса, сез әле заманында Җир шарын исән-имин саклап

калгансыз икән?!—Бу юлысы Ансар ишетелерлек итеп дәште.

—Әйе, энем, Җир шарына һаман каравылчылар кирәк, олы каравылчылар...

Ансар Гадигали агайны калдырып китәргә ашыкмады, дөресен генә әйткәндә, ашыгыр урыны юк иде аның. Бүген кайдагы мендәргә баш куясын белгән юк әле. Курсташ егетләр янына елышырга туры килерме, әллә тагын поездга утырып, тәгәрмәчле «кунакханә» көненә калырмы?!.

—Әгәр, мен дә жиде йөз илле адым атларга иренмәсән ак диварлар тирәли бер әйләнеп киләбез, кем, энем?!

—Ансар мин, Гадигали агай... Сез мине беләсез, ярты капчык бүрекне хәтерләсәгез...

—Ә-ә... Син шаһитләрнең берсемени?

—Юк шул...

—Алай ук мыни?! Каз ауларга чыккан төлке шәһәргә керми, монда таш арасында нишләп йөрисең, бар «Каракүл»енә.

—Уйланып йөрим, Гадигали агай, чын каракларны ничек тотарга микән, дим.

—Алай ук мыни?! Әйтәм жирле, андыйга охшамагансың үзең.

Байлыкка табынып яшәүче, хөсетле һәм эчкерле кешеләр бер кул белән генә көрешергә тырышыр—икенче кулын кесәсеннән чыгармас. Күрешү—холык көзгесе. Бирәү—ришвәт биргән шәе генә кул суза; йөрәксез һәм кансыз кешеләр авырттырып кысарга тырыша; гамьсез кеше гүя биш салкын сөяк тоттыра. Ярлы куштан—билен бөгеп, бай куштан аркадан сөеп күрешер. Гадигали кушучлап күреште, ләкин колакка катырак кеше булганга, башлаган сүзен бетермичә Ансарның кулын җибәрми торды.

—Әгәр каракларны тота алмасам... Фатирдан кудылар, инде университеттан да куарлар...

—Алама хозяйкага туры килгәнсеңдер, юкса аңлар иде.

—Кеше гаепләп торасы юк, үзем гаепле...

—Юньсез кеше бервакытта да: мин юньсез, дип әйтә алмый, димәк, ничава егеттер син. Әйдә, безгә кайтабыз, Сөембикә жиңгәң дә сөенер. Тик берүк, минем урамда өчпочмак алып ашаганны житкерә күрмә. Юкса, миңа көн бетә. Гомер бакый яшәп шулпалы өчпочмак пешерергә өйрәнә алмады, бахыр...

## «Йолдызлар арасында...»

Әгәр самолет тәрәзәсеннән башыңны тыгып карарга рөхсәт итсәләр өстәл-өстәл сыман тезелеп яткан түбәләрне генә күрерсез. Бөтен шәһәр: завод-фабрикалары, мәктәп-бакчалары, барча кешеләре түбә астында. Һәр түбәнең каравылчысы, бәлки вахтеры яки лифтеры бар. Алар үзләренә беркетелгән түбәнең иминлеген саклыйлар.

Гадигали агайларга күчеп яши башлагач Ансар ныклы бер карарга килде: диплом практикасы чорында төнге каравылчы булып эшкә урнашырга, кемлегенне сиздермичә генә «Каракүл» берләшмәсенең эчен-тышын яхшылап өйрәнергә...

Уку йортыннан бирелгән белешмә дүрт почмаклы кәгазьгә язылса да каравылчылар начальнигы аны әйләндереп-әйләндереп укыды, мөһере түгәрәк иде, шуңадыр инде. Бу оешманың йорты эчке эшләр бүлеге бинасына өстәп салынган. Чөнки, әлеге оешмаларның әти-әниләре бертуган. Житәкчеләре дә бертөрле киенә—бөтенесе фуражкалы, погоннарына йолдызлар сибелгән.

Каравылчылар начальнигының өч йолдызы бар—өчесе дә олы-олы булып бүрткән. Урынбасары—чырае белән начальниктан олырак булып күренсә дә погонында бер йолдыз кимрәк. Замполитка бер зур йолдыз эләккән. Йортның кысан булуы сәбәпле бөтен житәкчеләр бер бүлмәдә. Шуңа күрә, Ансар йолдызлар арасында иде.

Белешмә, кулдан-кулга күчеп, замполит кулына барып житте.

—Төнлә сакта торулар шүрләтмәсме?

—Студентның куркырлыгы юк, байлыгы күп кеше генә куркак була,—дип рас җавап кайтарды Ансар.

—Алайса, милиционерларның нидән батыр икәнен аңлыйсың инде. Окладың күпме булачагын чамалыйсыңмы?

—Студент кешегә җитә.

—Ә безгә каравылчылар кирәкне каян белден?

—Күнелем сизде. Яхшы каравылчылар гел кирәк.

Ансарның бу сүзләреннән соң тәрәзәдән төшкән кояш нурында йолдызлар жемелдәште.

—Студент та студент дисең... Әгәр студент булмасаң без синең белән сөйләшеп тә тормас идек. Каравылда йоклап ятырга студент белән пенсионердан гайреләрне алмыйбыз... Бер төн эшләп, ике төн ял итәсе, дигәч, буш вакыт ярата торган гайрәтле ирләр күп урнашты инде безгә. Сакка куйгач графиклары үзгәрде—бер ел эшлиләр, ике елга утыралар... Мин сине резерв бригадасына кушам. Вазифаң бик гади. Кичке алтыга өлкән дежурный янына җыеласы. Кайсы объектта пост ачык кала—шунда илтеп куярлар. Аңлашылдымы?

—Без, студентлар, күп нәрсәне соңрак аңлыйбыз...

Ансарның беренче эш төненә ничек әзерләнгәнен чамалар өчен Сабантуй мәйданына җиңү алып кайтып килүче чаптарны күз алдына китерү җитә. Көне буе теләктә йөрде ул. «Каракүл» мехчыларының берәр каравылчысы эшенә чыкмый калса иде; балыкка киткән жиреннән табышлырак урынга эләксен; сәгатьләре тукталсын; оныкларын куяр өчен урын тапмыйча өеннән чыга алмыйча ятсын; берәр мажаралы вакыйгага тап булып көнен шаһитлектә үткәрсен, һичьюгы, күршесенең «Лотто-миллионга» акча отканлыгы турында хәбәр ишетеп, эчүгә сабышсын... тик графигы буенча каравылга эшкә чыкмасын!.. Аннан, каравылчылар оешмасына өлкән бригадирдан хәбәр килсен: «103 нче пост ачык. Резерв җибәрүегезне сорыйм...» Һәм Ансарны төн чыкканчы сакларга дип «Каракүл» берләшмәсенә куярлар.

Кулындагы көмеш сәгате ике минутка бер генә кыймылдый төсле тоелды Ансарга, еш караганга, еш тыңлагангамы, акрын йөри кебек... Билгеләнгән вакыттан йөз егерме минут алдан эшкә килгән студентны күреп, өлкән дежурный күкрәгендәге медальләрен челтерәтеп көлеп куйды.

—Беренче вахтаңны матур көндә башлыйсың. Иртәгә получка биреләсе, шуңа күрә эшкә чыкмый калган каравылчылар булмас. Иртәгә акча аласы дигәндә, прогульщиклар юк ул бездә... Сиңа бүген минем белән контор саклап кына утырырга туры килер. Борчылма, монда күнелсез түгел... Әйдә, «йокы чүлмәге», танышыйк, мин Язит абыең булам.

—Мин Ансар, Субаев.

—Көндезен укып, кичен эшләргә дисең инде... Ә берәүләр, киресенчә, көндез эшли, кичен укый. Тик шунысы бар: көндез эшләгән кеше кичен авыр укый, көндез укыган кеше кичен начар эшли, ягъни, йоклый.

—Замполитыгыз шундыйрак фикер әйткән иде инде.

—Хакыйкатьне беләбез.

—Белә торып биш йөз каравылчыны йоклатып яткырасызмы?

—Уятып йөрер өчен махсус «Проверящийлар» бар. Тик менә, биш йөз постны йөреп чыгар өчен аларга бер төн генә җитми.

—Язит абый, үзегез дә йокы аралаш эшлисездер әле?!

—Мин көндез укымыйм, постымда уяу торырга тиешле кеше,—дип әйтүе булды Язит абыйның, шуннан тотынды телефон чәрелдәргә...

«Алло, Язит абый, бишенче бригада әле бу. Постагыларның фамилияләрен язып алыгыз. Прогульщиклар юк!»

«Алло! Отдел! Егерменче бригаданың рапортын язып куегыз: прогульщиклар юк»!

«Алло! Телефоныгыз гел «занято», көчкә туры китердем. Постлар ябык. Ниме, Язит абый, иртәгә получка булыр микән?»

Ул арада өстәлдәге бәләкәй тартмадан, оператор кызның куркынган тавышы ишетелде.

—Язит Язилевич, бишенче супермаркетның контроль уты кабынды, пультка куйганнарына ярты гына сәгать иде әле!

Язит Язилевич кулындагы телефон трубкасын күкрәк кесәсенә тыкты да селекторга үрелде.

—«259»... «259»... «259»... элемтәгә керегез.

—«Волга»... «Волга»... Мин «259». Ни булды?

—Тиз генә бишенче объектны тикшерегез. Әгәр, реле-фәләне эшләмәсә, электрик килгәнче шул тирәдән китмәгез. Аңладыгызмы?

—Әйе!

«259» нчы номерлы МПГ (милициянең патруль группасы): «Кибетне пультка тапшырдык, директоры өй ачкычларын онытып калдырган, шуңа ачып кергән, инде бар да тыныч»,—дип рапорт биргәндә, Ансарның көмеш сәгате белән ун минутлап кына вакыт үткән иде әле.

Ниһаять, бригадирлар шылтыратудан туктап, кадерле объеклар пультка куелып беткәч, дежурный бүлмәсендә кыска гомерле тынлык урнашты. Язит Язилевич зур кульяулыгын куш учына җәеп маңгай тирен сөртте. Аш ташый торган олы термосны авыштырып ике стакан чәй агызды.

—Әйдә, студент, сугарылыйк, чәй икебезгә дә житәрлек. Хәзер, тирләп-пешеп оперативниклар кайтып житәр. Чәйне алар өчен дип күп йөртәм.

«Каракүл» капкасына сакка куярлар әле, дигән өмет мае беткән шәм кебек сүнде. Бүген Ансар, артык солдат булып резервта ята. Өметсезлектән йокы басты, хәтта Язит Язилевичның мәтрүшкәле каты чәе дә ул төшенкелек халәтен куып тарата алмады. Ансар, эч пошканнан гына «кызыл почмакка» кереп, президиум өстәленә менеп яткан иде, ялгыш йокыга китте...

Авыл жирендә әхлакый кодекска әверелгән ырымнар бар. Әйтик, бусагага утырырга ярамый, мал чалган урынга төкермә, өй эчендә сызгырма, зыярат өстеннән җиләк өзмә, чүплеккә икмәк ташлама, кош оясына тимә, мунчада йоклама ише нәсихәтләрне бозсаң зур гөнаһ булачак икән. Әлбәттә, «гөнаһ» сүзен балалар «зыян киләчәк» дип аңларга тиешләр. Президиум өстәленә менеп ятма, сәяси төшләр саташтырыр, дигән юрамышлы ырымны белми иде әле Ансар. Психиатрларның раславынча, төш—өндәге уйларның дәвамы, әйтергә кыймыйча йөргән сүзләрнең яңгырашы, чынга ашмый калган хыялларның гәүдәләнүе һәм курку хисенең йөгәннән ычкынуы икән... Менә безнең Ансар, җыелыш саен дәрәҗәле йодрыклар белән төелгән кызыл постаулы президиум өстәленә чалкан ятып, үзе яшәгән шәһәрнең Баш бүреге белән сөйләшә...

«Бер миллион карак төрмәдә утыра, ә җинаять кимеми, киресенчә арта гына. Милиция гаеплеләрне конвейердан бушатып өлгерә алмый, судтагы эшләр әрдәнәләп өелгән, адвокатларга чират. Юрфакта бер урынга йөз абитуриент килә. Илгә тимер ишекләр житкереп булмый, йозак бизнесы чәчәк ата. Сез, йөнтәс бүрекләләр, җавап бирергә уйлыйсызмы?»

«Син чәпчемә, җинаять ул—базар вирусы. Бәяләр арткан саен җинаять артачак, чөнки урлаган кешенең дә чыгымнары арта».

«Сез шулар яклы. Хәрәм байлыклары кесәгә сыйсын өчен акчаларның нульләрен кистегез, ришвәт биргәндә долларлар сыйсын өчен конвертларны озынайттыгыз, яшерен маллар сыйсын өчен банкларны күбәйттегез...»

«Кесәңә күпләп акча кергәч фәлсәфәң үзгәрер әле. Базар ул—акча өчен яшәү. Бөтен эшне акча гына эшли ала. Акча ул—тәрбияче, акча—җинүче, акча—азатлык, акча—яшьлек, акча—акыл...»

«Алайса, сезнең акылыгыз—кесәгездәме?!»

«Безне сайлап куйдылар».

«Сайлау—урлаучыларның урыннарын алыштыру гына түгел микән? Нократ ярында тотылса, Сез аларны министрлыкка куясыз, министрлыкта азынгач Чулман аръягына Хан итеп җибәрәсез. Шуңа күрә мандат өчен көрәш, саклану өчен көрәш баталиясенә әверелә...»

«Әй, студент, ярлы белән бай бәхәсләшә алмый. Синең алда акланырга җыенмыйм. Шуны бел—Яңа йортка күчкәндә иске нигездә чүп-чар өелеп кала. Син белгән нәрсәләр әнә шул социализм нигезендә өелеп калган чүп-чарлар гына. Якты киләчәккә барып җиткәч ул чүп-чарлардан котылырбыз».

«Русияне караклык эпидемиясеннән дәваламыйча торып якты киләчәккә чыгу мөмкин түгел! Караклык сүзенең синонимнары бик күп: урлау, талау, хосусыйлаштыру, мәхрүм итү, үзләштерү, дефолт ясау, рөхсәтсез алу, ришвәт бирү, сугыш ачу, илләрне яулау... Бөтен җинаятьнең нигезендә караклык ята!..»

«Сугыш ачу—илләрне урлау дип әйтергә телисеңме?»

«Әлбәттә! Һәм ул ил өстендә сугышып Империя казнасыннан күпме акча талана! Безне сугышлар белән таласыннар өчен үзебез налог түлибез! Чит илләр котыла алмаган бүгенге караңгылыкны без үзебезгә якты киләчәк итеп куярга тиешме?»

«Студент! Акыллы сүз тиз туйдыра! Югал күземнән!..»

Ансар шабыр тиргә батып уянып китте. Төшендәге әңгәмәдән соң гәүдәсе авырайган иде аның. Ләкин, студентларча уяулык белән, үзенең эш урынында икәнлеген абайлап ул тиз генә президиум өстәленнән төште. Талымсыз йокысы белән көрәшеп йөргән арада бишенче супермаркеттан тагын хәбәр килгән булган.

Өченче тапкыр хәбәр алгач, оператор кыз Язит Язилевич янына үзе йөгереп керде:

—Тагын бишенче... Контролька кабынды.

Селектордан диалоглар чәчелде.

—«259», кай тирәдә сез хәзер?!

—Отделга житәбез. Капкабыз күренә инде.

—Срочно борылыгыз. Бишенче маркетка! Никтер, тагын шылтырады. Теге директор түгел микән... Кунарга урыным юк дигән иде. Бәлки борчып тормабыз?!

—Бернинди ни-ни! Кибет гостиница түгел ул! Ишетсен колагыгыз! Хәзер үк объектка китегез! Хәбәрләшеп торыгыз!

—«Волга», «Волга!» Мин «259». Бишенче суперны басканнар. Тәрәзәсен ватып кергәннәр. Берсен эләктердек. Икесе качты. Куып киттек.

—«259»!!! Объектның иминлеге өчен без җавап бирәбез. Берсе эләккәч калганнары тотылыр. Кибет яныннан китмәгез!

—Ватык тәрәзә саклап төн чыгаргамыни инде?

—Мин сезгә резерв каравылчымны җибәрәм.

—Минме? Язит абый?!—дип гаҗәпләнде Ансар. Дөресен генә әйткәндә аның өлкән дежурныйдан: «Юк!» сүзе ишетәсе килгән иде.

—Әйе, Субаев. Такси илтеп куяр үзеңне.

—Шаярталардыр әле, директоры ачкандыр да...

—Юк инде, студент иптәш! Эфирдан ялган сөйләшергә ярамый. Безнең сөйләшү шәһәрнең бөтен постларында ишетелеп тора. Менә хәзер проверяющий дәдәң килеп житәр.

—Барыбер ялган «тревога» бу. Бер сәгать эчендә, бер җирдән өч хәбәр килсен дә, ышан имеш...

—Практикада әллә ниләр бар, Субаев. Әйтик, әлеге кибет ишеге янагындагы кыңгырау күрше урамнарга ишетелерлек итеп ике тапкыр чыңлады ди. Ике тапкырында да милиция килде, ә «ЧП» дигән нәрсә юк. Димәк, кыңгырау өченче тапкыр чыңласа милиция әүвәлге кебек чатыр-чабып килми дигән сүз. Урларга ниятләнгән кешегә шул гына кирәк тә: тәрәзәне вата, кыңгырау чыңлый башлый, милиция ашыкмый,

шул арада кибетне чистартып та өлгерәләр... Ә син, Субаев, ышанмыйм дисең. Бер объект төн чыкканчы ун тапкыр «тревога» күтәрсә егетләрне ун тапкыр җибәрәчәкмен!..

Ансарны ватык тәрәзә янындагы йомшак кар өстенә бастырып куйгач экипаж аңа хәерле төн теләде:

—Студент! Әбиеңә сәлам әйтикме, бәлки тун китерер?!

## Каравылчыны кем саклый?

Беренче эш төне Ансар теләгәнчә килеп чыкмады. Бәлки бүген, икенче төнендә юл унар?! «Каракүл» капкасына өстәмә сакчы итеп куярлармы, тагын бөтенләй башка объектка җибәрерләрме? Сабырлыкны йолыккалап диплом практикасының санаулы көннәре үтә.

Язит Язилевич Ансарны ишектән керә-керешли үк эшкә кодалый башлады.

—Получкадан соң дөньяның асты өскә килә. Бүген резервны төткәр генә. Кая телисең—шунда җибәрәм! «Росбакалея» базасына кеше кирәк, буладыр бер. «Коопторг» складында урын бар—ике. Алты винзаводның өчесе каравылчы сорап «каравыл!» кычкыра—өч!.. Кәрәз эшләү заводы—дүрт. Мебельләр эшләү фабрикасы икенче капкага кеше сорый, менә сиңа биш. Промбаза ягындагы гаражга, галантерея әйберләре базасына, «Исле гөл» фабрикасына... кыскасы, санап бетергесез. Ә синең кебек запас егетләрем өчәү генә. Шуннан чамала инде калганын.

—Өч постка безне куярсыз куюын, ә калганнары нишли?

—Нишләсен, тора шул килеш. Каравылчылары юкны белмәсәләр, тора... Капка биек, йозак зур, эт өрә.

—Мин үзем рядовой каравылчы чагымда Идел ярындагы причалда төзелеш материаллары саклап кунгалый идем. Навигация ачылуга, дәү-дәү баржалар яр читенә Себер наратларын китереп аудара, саны-хисабы юк, тау-тау өелә. Шунда ук аның тактасын ярдыралар, идән-түшәмлек итәләр, ишекләр, тәрәзә рамнары ясап төрле төзелеш оешмаларына озаталар. Идел ярында көндез тыныч. Ә менә төнлә, житмәсә, бер ялгызың калгач... моторлы көймәләр «һөҗүм» итә башлый. Йөзеп киләләр дә әрдәнәдән ике-өч наратны бау белән тагып алып китәләр. Мин бит инде аларның артларыннан су өсләтеп куып йөри алмыйм. Яр читенә басып Идел өстенә йодрык селкеп озатып калам. Анысы ярый, Себер наратының бетәсе юк, тик урласыннар... Мәгәр, эшкәртелгән, юнылган, читләтелгән такталарны саклый алмасаң эш харап! Сакта торам шулай бервакыт. Утыз кубометр юнылган юка тактаны өеп, өстеннән яшел буяу белән сызып тамгалаганнар, яшел пута бәйләгән төсле. Күчтәге берәр тактаны суырып алсаң буяулы пута өзелә дә иртән смена алышынганда ревизия ясарга туры килә. Каравылчының айлык хезмәт хакы шул тактаның кубометрын түләргә дә житми. Такталар өстенә менеп утырдым, мин сиңа әйтим, кулга ботаклы такта башын кысып тоттым—корал янәсе. Таң атканчы Идел өстен күзәттем. Белмим, кай арада гына күз йомылгандыр, уянсам—йә Раббым, ун тактадан җилләр искән. Ничек үземне күтәреп китмәгәннәр?! Коелдым да төштем, такта күче белән... Ярый әле, иртән алмашка килүче каравылчы хәлемә керде, әллә кайдан гына банкылы яшел буяу табып, яңа такталар өстенә сызды да куйды. Борчылма, ди бу мине юатып, мал югалган саен кесәгә тыгыла башласаң, каравылчыга гел бушлай эшләп йөрергә кала, пенсияң дә, стипендияң дә кулыңа эләкмәс ди... Менә шулай, Ансар туганым. Вәт. Менә шулай итеп мин сине яңа урынга әзерләдем... Кайсы объектка барасым килә дисең әле? Росбакалеягамы, базагамы, причалгамы?

—«Каракүл» берләшмәсенә җибәрсәгез иде, Язит Язилевич.

—Бара тор!

Язит Язилевич үртәгән сыманрак итеп елмаеп калды, ни хикмәттер,

элеккеге студентлар тире исеннән җирәнеп «Каракүл»гә бармас өчен җан талашалар иде, ә бу егет үзе үк ашкынып тора.

Кич әллә нинди бүген, кояшы бар—жылытмый, болыты күренмизимагур кар бөртекләре очып йөри. Язгы җилләрне сизенгән тупыллар кай якка авышырга белмичә аптырап торалар... Бәйдәге этләр өй тирәсенә килгән бәйсез этләргә өреп кала.

Җәяүле бураннан бераз гына өстәрәк, каршы яктан тагын бер җил исә—анысы чана шуасыны китереп, кызыктырып торган карлы түбәләрне себереп йөри. Аяк асты ялтыравык боз гына—машиналар егылам-егылам дигәндәй, таеп-таеп китә. Яз исе, сөт комбинатына йортка кергән солидол заводы исе белән алышына, ул да булмый: РТИ заводыннан ияреп килгән кыздырылган каеш исен яңа кыркылудан чыккан сарык көтүе исе күмеп китә. Димәк, «Каракүл» берләшмәсе ерак түгел.

Ансар яшел таш коймага җиткәч теге—капчыклы бау эленеп торган урында тукталмакчы иде, тыелып калды. Йә тагын Райнур сагалап йөридер. Сизмәве хәерлерәк.

Каравылчы кенәгәсендәге фото кисәген чын йөзе белән янәшә куеп карагач кына якты чырай күрсәттеләр Ансарга, юкса каравыл начальнигы бик кырыс кешегә охшаган.

—Ярыйсы,—диде ул Ансарның инбашына сугып,—безгә бергәләп сакта торасы. Икенче смена бетеп өченчеләре кергәндә эш кызулана. Чамалыйсыңдыр инде, цехлардан чыккан берсен тикшереп калырга кирәк.

—Тентепме?

—Һушлы егет икәнсең... Әйдә, кунак бүлмәсе белән таныштырам. Теләгән чакта алмаш-тилмәш ял итәрбез.

«Кунакханә» аракы әрҗәсе хәтле генә бер бүлмә иде. Стенаны янган кирпечтән өяргә кушалар, сулый диләр, ә бу бүлмәнең стеналары тәмәкеле төтеннән тончыгып, күптән сулаудан туктагандыр инде. Утырган килеш йоклар өчен баскычлап кагылган сәке һәм мамык түшәвен хәзинә эзләүчеләр ботарлаган тирән эчле утыргычтан гайре һичбер җиһаз сыймаган.

—Бераз җилләнеп керим әле, юкса чебеннәр уяныр,—диде Ансар, елмайганга сабышып.

—Бар, койма эчен айкап кил. Ашыгып йөрмә, смена алышынырга иртәрәк әле.

«Каракүл» берләшмәсенең һәр алачыгы таш коймага терәп салынган. Ансар йөри торгач, цех ишегенә килеп төртелде. Керергәме—юкмы? Әгәр шушы цехта Венера очраса, ни дип сүз башлыйсын да белми иде әле ул.

Бер көтү сарыктан туналган тире төяп электр арбасы килеп туктаган иде, Ансар аңа ишек ачып торды. Тик арбаның ничек күздән югалганын хәтерләми калды, чөнки цех эченнән үтәли җил алып килгән авыр истән куркып ул авызын-борынын гына түгел, ялгыш күзләрен дә каплаган иде. Бу исне күз алдына китерер өчен: сабынлы йон исенә көйгән йон исен кушарга, пешкән йон исенә кипкән тире исен өстәргә һәм шул тирәдә мичкәсе-мичкәсе белән формалин түгәргә кирәк... Теге җил Ансарны җилтерәтеп урамга куып чыгарды, цех эчендә ниләр барын күрәсе бар иде. Ул, күкрәк читлеген урам һавасы белән кабартып, үҗәтләнеп цех уртасына ыргылды.

Урамнан алып кергән һавасы җиткәнче генә цех эчен күзәтеп өлгерде ул. Электр арбасына төялгән тиреләрне олы ванналарга бушатып торалар. Ике агай, трусик белән майка өстенә капланган каеш алъяпкычларын шыгырдатып, олау чаклы мичкә авызыннан—баркастан озын кисәү белән тире чүпли. Ике станок очкыннар очырып тиренең йонын тигезләп кыркып бара. Түрдәге... юк, анысын күрергә Ансарның сулышы җитмәде. Ул яңадан урамга йөгереп чыкты. Шәһәр күлендә тончыккан чабак су өстенә сикергән кебек, йотлыгып-йотлыгып һава сулады, янә цехка керде. Тик бу юлысы тагын да тизрәк борылып чыкты. Түрдәрәк—центрифугалар

тире сыккан арада әбәткә утырган ханымнарның кулында арчылган йомырка белән ипи сыныгы күргәч, Ансарның өченче көн ашаган ризыклары өскә күтәрелә башлады. Тизрәк икенче ишек эзләргә кирәк иде.

Монысы буяу цехы иде, ахрысы. Анилин пары әчеттереп-әчеттереп күзне кисә. Эшчеләр кулында зәңгәр, көрән, кара төстәге тиреләр уйнаша. Ләкин боларны инде тире дип әйтү килешмәс. Боерык кәгазьләренә теркәүгә мех дип исем кушарлар аларга. Матурлык тусын өчен жирдә корбаннар кирәк. Колхоз базарына килсәгез, чәчәк сатучы ханымның мутон тунына күз салыгыз әле—өстендә көмеш дулкыннар бии... бу тунны—кайчандыр тигәнәккә батып, көтү тузаныннан ютәлләп һәм җәй буе эче китүдән интеккән корчаңгы сарык ябынып йөргәндер дип кем уйлар?!

Тагын бер ишек.

—Егетем, унынчы цехка чит кешеләр кертелми!

Ансарның юлына аркылы төшкән кеше—тавышына, басып торышына, киеменә караганда, һичшиксез остаз булырга тиеш, һәрхәлдә Ансарга шулай тоелды.

—Мин сезнең кеше,—диде Ансар каравылчы кенәгәсен күрсәтеп,—Венераның эш урынын күрсәтегез...

—Кайсы Венерадыр бит, бездә өчәү алар...

Бу цехның үзенчәлеге шунда: җиһазлар-станоклар бәләкәйрәк, эшчеләрнең өстендә ак халат, кая карама чиста—әле генә бәйрәм өмәсе үткәрелгән диярсең... Ә тиреләре чәшкенеке, кулдан-кулга гына йөртәләр.

Венераларның берсе тире кыручы.

Икенче Венера әзер мехны өлгеләп кисеп тора.

Өченче Венера тегелгән бүрекләрне ундүртәрләп тартмаларга тезә. Әйе, өченче Венера Ансар эзләгән кыз иде.

—Исәнме, Венера?

—Исәнмесез. Әнә мастер, әнә цех начальнигы.

—Миңа син кирәк.

—Гафу итегез, мин кияүдә инде.—Һәм Венера көчәнеп кенә елмайгандай итте. Их, елмаймаса ни булган инде, болай да Ансарның күңеле китек.

—Бу мин бит, Ансар, хәтерлисеңме, зоопаркта...

—Хәтерләмим, сезнең ишеләргә бернинди катышым да юк?

Әйтер сүз булмаса да авыз ачылып калган чаклар була икән ул. Китте Ансар. Аңлашырга—ятлар бар, гафу үтенергә вакыт тар... Венерага үпкәләргә иртәрәк әле.

## И чибәр кыз...

Әгәр, кыр чәчәкләре арасында берәр роза үсеп утырса, аны озак тотмаслар, өзәрләр шул, өзәрләр...

Әгәр, кеше юл башында салкын чишмә очратса, сусаудан интекмәсә дә барыбер аның суына иреннәрен чылатыр...

Әгәр, иртәнге кояшны үзенә сыйдырган чык бөртеге сиңа карап торса, шул чык бөртеген учыңа аласың килер...

Әгәр, болында кеше күзеннән яшеренеп сусылланып пешкән жир җиләге тапсаң, авыз итмичә түзәрсеңме?

Әгәр, әгәр, әгәр...

И чибәр кыз—кыр чәчәкләре арасындагы ялгыз роза, ымсындырып торган салкын чишмә, кояшлы чык бөртеге, сусылланып пешкән жир җиләге бит син...

Венера чибәр кызларга хас язмыш кешесе. Ансарга кул селтәргә тырышуы, танышу шатлыгын нәфрәткә алыштыруы, әйтелмичә калган сүзләрне тыеп, киресенчә дорфа сөйләшүе—болар барысы язмыш кайтавазы гына.

Тулай торакларда кызлар кияүгә чыкмасын өчен бөтен шартлары кылгән. Кер юарга өйрәтмәс өчен кабул итү пунктларын торакка терәп салганнар. Сазамыклар блогында елак балалар тавышы чыгарырга рөхсәт юк, балаң туса—почмак эзләп китәсең. Берүк, ашарга пешерә күрмәгез дигәндәй, тулай توракның аскы катына урам ягыннан ишек уеп, «Бистро» ачтылар, үзалдына зарланып йөргәндә күңел юатыр өчен телевизор бар. Тән җылысы кирәксә—төне буе «Бистро» ирләре ишек шакып йөри... Ләкин, инвентарь саны сугылган җиһазга әверелгән кызлар гел кияүгә чыгу турында хыялланып яши. Ник дисәң, тулай торак әсирлегеннән бары тик никах кына коткара ала...

Яшьлеген унсигезгә җиткереп, шәһәр урамнарына адашып килеп кергән мәлне, Венера бер егеткә юлыкты. Атнага җиде тапкыр килә. Ыспай киенгән, галстугы тагулы, чәче открыткадагы шаһзадәләрнекедәй пөхтә итеп алынган, сөйләшүләре магнит тасмасына язылган кебек—һичбер ялгышсыз. Кыз күңелен тәмам алгысытты, гел балкып кына тора. Унбиш көн үтте дигәндә, унбишенче тапкыр килүендә, кызларның бүлмә иданен юып чыккан чагы иде. Гөлләргә су сибелгән, урын-җирләр алыштырылган. Ишек бусагасыннан түрдәге плинтуска хәтле тулай торакларда сирәк очрый торган киң палас җәелгән. Егеткә туфлиен салып керергә туры килде. Аяк савытыннан чыккан үкчәдә биш тиенлек иске акча кадәр оек ертыгы күренеп калды. Бетте... Унбишенче очрашудан соң Венера егеткә борылып та карамады.

Унтугыз яшь тулып узганда...

Венераның алтынчы трамвайда йөри торган айлык билеты тулай торакта онытылып калган иде. Ай ахыры. Ишекләренә КРС (контрольно-ревизионная служба) дип язылган машиналар чат саен. Венераның беләгеннән тотып алдылар. «Билетсыз йөрүче»не каптыргач, ревизор агай сөенеченнән икенче беләгенә дә кызыл тасма бәйләп куйды, үз эшенең тәмен белә, сөйкемсез. Венераның «Проездноем бар, өйдә калган», дигән сүзләреннән ревизорга кушылып пассажирлар да көлә башлады. Көтмәгәндә арада баш түбәсенә түбәтәй каплаган озын буйлы егет килеп чыкты да Венера өчен билетын күрсәтте.

—Ә үзен куян тиресен бөркәнәсеңме?—дип бәйләнделәр егеткә.

Егет үзе штраф түләде.

—Безнең якларда КРС дип сыер фермасының капкасына гына язалар иде, ревизорлар түгел, рэкетирлар болар дип аклана башлады Венера егет алдында,—билетым бар, өйдә генә калган, билләһи, ант әгәр. Ышанмасагыз, әйдә, тулай торакка кайтабыз, күрсәтермен,—дигәнен сизми дә калды.

Ә егет?

—Ышанам ич инде, ышанам. Андый хәлләр була ул,—дия-дия, тәмам тагылды.

Танышып, «Мәхәббәттә гөнаһ юк» сериалының өчесен карап өлгерделәр. Ләкин ни хикмәттер, егет урамда йөрсә дә, өйгә керсә дә, өстәл артында утырса да түбәтәен салмый гына бит. Түзмәде Венера:

—Гел түбәтәйдән йөргәч колхоз базарында җиләк-җимеш сатучы танышларың күптер,—диде ул, башта шаяртып. Егетнең җавабы әзер иде.

—Әгәр эшләпә кисәм буем тагын бер карышка арта.

—Бу түбәтәй башыңа ябышмагандыр ич?—диде Венера, бу юлысы инде үпкәләвен яшермичә.

—Ә мин аны сизмим, әллә бар, әллә юк. Кайчак йокларга ятканда да салырга онытам.

—Түбәтәйле колга күргәнем бар ла...

Һәм Венера сериалның калган өлешләрен үзе генә карарга булды.

Ә бер көнне ана егерме яшь тулды. Йоласына туры китереп, шушы түгәрәк санны билгеләп, бүлмәдәш кызлар белән цәйлүн чәе эчеп утырганда, чакырылмаган кунак килеп керде. Буе—сикерсә дә ишек

кашагасына башы тимәс, шөкер, түбәтәйле колга түгел. Бәдәне—һава белән өреп тутырылган пинжәк кигән төсле. Күзләре—яна гына калыккан йолдызларын көнләшерлек. Исән калган чәчләрен төзәткәләде, баш кагып кына күреште.

—Мин йортлар идарәсенең дежур электригы, сезнең чакыру буенча килдем.

—Ә безнең беркемне дә чакырганыбыз юк,—дип гажәпләнде кызлар,—бөтен җиһазлар тәртиптә, ут чыгарлык түгел.

—Йөз чөерергә ашыкмагыз, кызлар, бүлмәгездә мина эш житәрлек әле. Әйтик, үтүгегезнең регуляторы эшләми, электр плитәгездән янган каеш исе чыга, телевизорыгыз чытыр-чытыр итә... Шулаймы?

—Әйе шул, каян белдегез?!—кызлар аптырашка калдылар.

—Белми ни, бүлмә саен бер үк ватык инде ул.

—Алайса, бәйрәмебезне сизеп кергәнсездер,—диде Венера, дусларын тынычландырырга теләп,—рәхим итегез, ватык-мотыкларыбыз бик күп. Без күңел ачыйк, ә сез вакытыгызны әрәм итмичә эшкә тотыныгыз. Җырлагыз, кызлар!

—Юк, юк, җырлаганчы паспортын тикшерик.

Электрик егет кызлар керфек каккан арада күкрәк кесәсеннән паспортын чыгарып өлгерде.

—Кулыгызга бирмим, менә, сезне кызыксындырган битләрен актарам. Күрәсезме, артык пичәтләре юк, балалар исемен яза торган урыны чиста. Ә сезнең, сул күзегезнең уннан жиденче керфегеге коелып, сөрмәгезгә кунып калган,—диде электрик һәм паспорт белән Венераның борын төбендә жил уйнатып алды. Паспортыннан «шипр» исе килә иде. Венера аның бер сөйкемле гадәтенә игътибар итте: матур итеп көлә белә ул, чукынчык, авызын ерып битенә жыерчык чәчми, күзләре белән генә елмая бугай.

Кайда ничектер, тулай торакта чәйне электр чәйнеге белән үлчәп сөйлиләр. Кызлар ике чәйнек бушатканда үтүк төзәлгән иде инде.

—Калган эшләрегезне иртәгә күрсәтерсез, берьюлы төгәлләсәм тагын килер өчен сәбәп калмый,—дигән булып чыгып китте электрик.

Венера уйга калды.

Икенче көнне телевизор төзәлде. Венера ныграк уйга калды... Өченче көнне күмерләнеп беткән розеткалар алышынды... Венера тынычлыгын югалтты... Ә дүртенче көнне, ишек төбендә адымнарын ишетү белән үк кызый елмаюдан тыела алмады... Бишенче көнне электрик күренмәде. Сөйләшенгән вакытка Венера каршысына түм-түгәрәк гәүдәле яшь хатын килеп басты. Әүвәл эндәшмичәрәк торды. Аннан соң...

—Венера дигәннәре синме?!!

«Әйе!» дигән бер сүзгә ялганып киткән җөмләләрне кабатлап торуның кирәге юктыр. Ирен югалтудан курыккан йөкле хатын тарафыннан көндәшкә ни әйтелергә тиеш дип исәпләнсә, барысы да әйтелде. Хәер, Венера артыгын ишетмәде, иң кирәклесен генә отып калды: «Туймас жан ул. Әтәч булып кына туасы калган аңа. Кулыннан бөтен эш килә, шуңа масая. Паспортының никах пичәте сугылган битен алып куйган... Өйдән чыгуга балдагын кесәсенә сала...»

Тәмам йомылды Венера. Кибетләрдә йөрмәс булды. Шәһәр транспортларында янәшәсендә ирләр туры килсә икенче утыргычка күчеп утырды. Күршеләр сөйләштермәсен өчен кулына китап тотты. Берара, шулай боегып көн итә торгач, егерме бер яшь тә тулып китте.

Күп уйлаган кешене «унөченче хезмәт хакы»ннан мәхрүм итәләр...

Көзге төн ай-һай озын, уйланырга уең житмәс. Венера йокыны уйга алыштырды. Тырыш жил тәрәзә артындагы өрәңгенең соңгы яфракларын өзә. Өзә дә, Венерага санап барырга кушкандай, өлгенең кин пыяласына алып килә. Өрәңгенең иң очындагы нечкә чыбыклары жилне тарап кыз бала елаган тавыш чыгара. Һәм Венераның, кайнар юрган астыннан чыгып, шул елак жилне бишеккә салып юатасы килә. Көз

ахыры—квартал ахыры, ел ахыры, ә өзеләсе яфраклар бар әле. Шуңа күрә җил икешәр-өчәр смена буена тынмый, шәһәр Советы графигына сыешырга теләгәндәй, ашыгып-ашыгып туктаусыз яфрак өзә, якынлашучы кышка урын әзерли.

Өзелгән яфракларны саный-саный төннең иң тыныч чагы җитә. Тулай торакта ул тынлык иртәнге өч белән биш арасына туры килә. Аннан соң инде, беренче сменага ашыгучылар уяна башлый. Кухняда чәйнекләр дөбердәшә, табалар чыжлый, шабырдап су ага, ишек ярыкларыннан янган май исләре бәреп керә.

Көн яктысын уянгач кына абайлап өлгерде Венера, кичә тәки йокыга кителгән икән. Ләкин баскычларда үкчәләр тыпырдашудан һәм шуңа өстәп пружиналы ишекнең еш-еш итеп бәргәләнүен исәпкә алсаң, инде трамвай тукталышында басып торыр чак җиткән. Өлгермәсәң—эшкә сонарасың, сонарсаң—проходнойдан кертмиләр, «прогул» куйсалар унөченче зарплатага зыян килә...

Венера утырырга тиешле трамвайның йөртүчесенә дә егерме бер тулды микән, никтер күренми?! Тукталыштагы халыкны сыйдырыр өчен ким дигәндә, ике катлы ике трамвай кирәк хәзер, әле башка тукталыштагылар да өстәләр. Өч тыкрык читкәрәк китеп олы урамдагы машиналарга ялынырга туры килә. Машиналар тыз да быз йөреп тора. Венера кулын күтәргән килеш гел өметләнде. Иртәнге йөгерешкә чыккан өлгер егет ише генә, бер зәңгәр «Волга» үтеп киткән иде, кисәк туктап кирегә чигенде. Ишеге ачылуга Венера кереп тә утырды.

—Троллейбуска кадәр генә алып баралам.

—Җидегә чаклы табельныйга килеп өлгермәсәм...

—Унөченче зарплатаң түт-тү-үт!

—Аңлавыгызга рәхмәт, буш итмәм.

—Мине дә шеф-директор—нәкъ җидегә көтә. Сине илтсәм үзем өлгермим.

—Алайса, төшереп калдырыгыз мине.

—Такси тотасыңмы? Ха-ха-ха!—дип көләргә теләге барлыгын аңлатты егет,—таксиларнын нәкъ смена алыштырган чагы... Йә, ярар инде, синдәй кызлар өчен унөченче зарплатам җәл түгел.

Һәм зәңгәр «Волга» «Каракүл» берләшмәсе ягына борылды.

Эштән кайтышлый Венера, яшел коймага борынын терәп торган таныш «Волга»ны күргәч, юри генә якынайган иде, егетнең авызы ерылды. Тагын кабина ишеге ачылды.

—Әгәр директорың күрсә, рульсез дә калырсың әле.

—Директор төшке ашта.

—Сәгать дүрттәме?

—Аларның шулайрак көйләнгән, иртәнге ашлары унбердә, төшкесе дүрттә...

—Ә кичкесе?

—Кичкене ашамыйлар, тазарудан куркалар... Буш вакытта—машина үз кулымда, шулай килешенгән. Юкса, ике мең тәңкәгә кайсы шофер ризалашсын?! Буш вакытларда «ундүртенче зарплата»га эшлим...

—Мин сезгә күпме тиеш инде? Иртәнгесе өчен дә...

Егет кинәт тормозга басты.

—Төшереп калдырам...

Венера, директорларга охшарга тырышып, утыргычка ныграк чумды.

Көн саен диярлек, егет килеп ала, китереп куя. Вакыты иркенрәк чакта шәһәр буенча йөртә. Гел юлда...

Директорлары дингез буена өч көнлек симпозиумга киткәч, Венерага өч көнлек программа тәкъдим ителде. Беренче көн. Җомга. Көндез урамга, кич аулак урындагы «Башак» ресторанына. Икенче көн. Шимбә. Иртән Аккош күленә, көндез «Алтын дага» ресторанына, кич дус тиешле танышларда банкет. Өченче көн. Якшәмбе. Көндез «Нарат» ресторанына, кич наратлыктагы дачага...

Эштән кайтуга Венераның җавабы әзер булырга тиеш. Әлбәттә, «юк» дигән җавап шул мизгелдә үк әзер иде, ләкин Венера дәшмәде. Бу шоферның кемлеген ахырынача ачыклар өчен ике арада сынаулы тынлык кирәк.

Егет мондый тынлыкларны авыр кичерә икән.

—Беләсенме, Венера туташ, ирләр гадәттә ике төрлегә бүленәләр: бер ишләре өйләнеп газиз хатыны белән гомер буе яши. Аерылышу турында ләм-мим, авыз да ачтырмый. Ә үзе гомер буе сөяркәләр белән типтерә. Икенче берәүләр, киресенчә, сөяркәләр турында ишетергә дә теләми. Аның каравы, хатыннарын еш алыштыра. Син шуларның кайсысын яклыйсың? Беренчесенме, әллә икенчесенме?

—Өченчесен!

—Ниндиен?..

—Бердәнбер хатынына гына табынып яшәүчесен.

—Мәхәббәт яклы.

—Әйе шул. Юкса яшәүдән ни мәгънә?!

—Мәхәббәт килә дә китә ул, Венера туташ, ә хатын кала.

—Димәк, син, «Волга»лы егет, беренче төркемдәгеләрдән икән. Хатының бер, сөяркәләрең мең дә бер...

—Бик мөмкин, Венера туташ, бәлки, мөгаен... белмим тагы. Күпме китап укыганым бар, академиклар, зур җитәкчеләр, врачлар, педагоглар... бөек кешеләр турында. Кайсын гына алма... бөек кешебез хатыныннан туйган, аңа сөяркә кирәк... Кызык өчен, телевизордагы чит ил фильмнарын рәттән карап барганда да төп геройлар сөяркәләр хәзер... Һәм мин дә бөек кешеләр каныннан яралган, ахрысы.

—Туктат әле машинаңны, никтер күңел болгана башлады...

Венера соңгы сүзен тротуарга аяк баскач кына әйтә алды.

—Бигайбә, сөяркәң булалмадым инде...

Ансар белән танышканда Венерага егерме бер яшь тулып, егерме икенченең бер-ике өч ае кимеп өлгергән иде инде. Бер күрүдә үк кызның күңеленә хуш килде ул егет. Зоопаркта чакта, тоткындагы җәнлек-җанварларны кызганып, кош-кортларны юатып, ябылудагы чәчәкләргә соклана белүе өчен үз итте ул аны. Моңарчы очраган кешеләр арасында Ансар кебеге юк иде сыман... Ә баксаң исә Ансары да шул бер үк иш икән!.. Кемгә генә ышанырга соң бу дөньяда?! Дөньясы ике генә көнлек бит—аның да бер көне яшәлгән.

Тулай торакка елап кайтырга ярамый, кайткач та еларга ярамый. Анда яше егермедән узган кызлар бер Венера гына түгел.

Ул ярты сәгать чамасы тукталып ак каен кәүсәсен сыйпап торды...

### «Гыйшыклы тегүче»

Фабрикада бүрек тегүчеләрнең эш сәгате бетүгә, каравылчыларның кызу эш сәгате башлана. Эш бетте дип исәпләнсә дә, эшчеләр проходнойга күчләре белән өерелеп килмиләр. Кеше робот түгел, сәгате суккач сүндереп куеп булмый. Күпчелек халык эш киемен салу белән душка керә, анда инде су буе чират, житмәсә юыну-киенү дигәндә һәркемнең житезлеге төрлечә. Планны арттырып үтәү белән мавыгып душка соңга калучылар да бар... Шуңа күрә, смена алышынганда бер сәгать буена капка аркылы халык әрле-бирле йөренә.

«Каракүл»дә куна калучылар да юк түгел. Икенче катка күтәрелсәң, йон җыйгыч камераларда ким дигәндә өчәр кеше очрый. Урын-җир йомшак, вентилятор йон суыргыч торбалардан мамыклы җылы һава өрә. Таң атканчы өч кешегә ярты чиләк «шулпа» (су кушылган спиртның эшчеләр арасындагы атамасы) җитә.

Әгәр «Каракүл»нең бөтен эшчесе, бер булып җыйналып, капкага ябырылса аларны тентеп чыгару мөмкин булмас иде. Ә тентергә кирәк...

Чөнки алар затлы мех арасында кайнашалар, бераз эш урынына күнексән, затлы нәрсә кулга иярә башлый, нәфесне азындыра. Күп бит ул, бакчы, бихисап.

—Әй, студент, урыныңа бас!—дип әмер бирде каравыл начальнигы,—оялып нитеп маташма, теләсәң кайсын тот та тенти башла. Миңа ярамый, унсигез ел шушында эшләгәч бөтенесе үземнең балаларым төсле, тентергә кулым күтәрелми. Резервка дип каравылчыларны шуңа сорыйбыз инде без. Кара аны, берсен дә тәк кенә җибәрмә, кыюрак бул!

—Бәлки шикләләрен генә тентергәдер. Урлаган кеше әллә каян күренә ул.

—Каракның бүреге янмый, ышанма син мәзәккә. Каравылчы өчен шиксез кешеләр юк.

Җәй көне булса бер хәер, өстә артык кием йөрмәс, сыланып торган джинсы чалбар белән кысан күлмәк эченә егетләр һәм кызларның үз гәүдәләреннән гайре артык берни сыймас. Күлмәкләре дә күчергеч кәгазь кебек, эчендәге-тышында, мех яшереп чыгам димә. Ә менә кыш көне калын-калын киемнәр аркылы кеше капшау өчен көч кирәк икән...

—Күбрәк бил тирәсен тикшер, башка җиргә яшерә алмаслар,—дип өйрәтеп торалар Ансарны.

Иң әүвәл Ансар өч егет каршысына килеп басты. Егетләр, сүз әйткәнне дә көтмичә, алдан ук төймәләре чишелгән пәлтәнең колачын җәеп, ян-якларын да күрсәтер өчен дигәндәй, баскан җирләрендә бөтерелеп алдылар, кәефләре шәп, өйрәтелгәннәр болар... Ясалма мех якалы плащ-пәлтә кигән бер кыз адымын акрынайтты, ул путасын шулкадәр нык будырып бәйләгән ки—биле муены чаклы гына, юк-юк, чәч толымы калынлыгы гына калган. Ансарның тентергә көче җитмәде. Шуннан соң кызый иң башына асылган озын буйлы сумкасын ачып күрсәтте. Ярар, бусы да үтеп китте... Шундук юан бер ханым килеп басты. Баягы нечкә билле кызны шушы ханым сурәтенә китерим дисәң, аның биленә, ким дигәндә биш... җиде, унике сарыкның тиресен урап куярга кирәк. Сырма кигән яланбаш ирне Ансар җиңеннән тартып туктатты, тыңламаска маташа тегә. Тәки күзгә чекрәеп карап тора. Әллә монарчы бер дә тентемәгәннәр үзен?! Усал агайдыр әле. Бәлки урамда әшнәләре көтеп торадыр, шуңа масаядыр. Билләһи, мех чәлдергән кешегә охшый, бил тирәсе төзек формасын югалткан. Ансар сабырсызланып аның сырма төймәләрен чиште дә, пинжәк аркылы чеметеп карады һәм мыймылдап торган симез корсак тирәсеннән чирканып, кулын тиз генә тартып алды (Каравыл начальнигы кая югалды соң әле?!).

—Гафу итегез, инструкция кушуы...—дип авыз ачкан иде Ансар, тегесе сорау белән бәрелде.

—Фамилияң бармы?

—Субаев. Резерв.

—Җәл. Менә дигән каравылчы чыгар иде синнән.

Телогрейкалы ир үтеп киткәч каравыл начальнигы пәйда булды.

—Фабрика директоры ул... Шәп иттең, кирәген бирдең! Юри дәшми тордым. Кызык иң. Унсигез ел буе эшләп бер тентисем килә иде үзен. Безнең карамакта тагын өч фабрика. Инде ике генә директорны капшыйсың калды. «Каракүл» берләшмәсенең директорлары күп лә ул...

—Булса ни, әллә директорларның кулы юкмы?—дип акланса да Ансарның күңелендә авыр юшкын калды.

—Директорлар берәм-сәрәнгә кызыкмый. Кыюлыгың җитсә, капкадан чыкканда җинел машиналарын тикшерерсең. Ха-ха-ха...

Каравыл начальнигы көлә-көлә егылыр дәрәҗәгә җиткәндә Ансар каршысына Венера килеп басты.

Судта очратса шаккатмас, тик менә шушы урында очратырмын дип уйламаган иде кыз. Әллә керфекләре кашына тиде Венераның, аптыраудан аның күзләре киптергечкә тамган ике тамчы язу карасы төсле җәелделәр бугай. Ә бит бу күзләрнең өлгереп пешкән күгән җимеше

төсле чаклары да бар иде. Венера шаккаткан килеш ишеккә юнәлде, ләкин Ансар уяу иде, чөнки ул бу очрашуга әллә кайчан әзер. Тормоз педаленең дөбердәвеннән күбәләк канатлы тимер рәшәткә кызның юлын бүлде. Үзенә таба сузылган кулларны күргәч Венераның күзләре янә үз хәленә кайтты. Өлгереп пешкән күгән жимешенә охшаса да, карашы шулкадәр үткен, әгәр егет бер мизгелдә йөзен читкә борып өлгермәсә, электр дугасына белештермичә карап торган кешеләрнекедәй өч көн буе кадап-кадап, сулкылдап-сулкылдап, кан савып күзләре авыртасы иде аның.

Ул арада чират үсте. Каравыл начальнигы икенче коридорны ачарга мәҗбүр булды. Зур чиратта мут хатыннар да табыла.

—Мин бу бабайга тентетеп тормам инде, яшь егет кулларыннан кытыкланасым килә.

—Студент чиратына кем ахыргы?!

—Гыйшыклы тегүче диген син аны...

Юл ябык. Венера таш сын гүя. Ансар кулларын яшерергә урын табалмый. Ике арадагы тынлык киеренкелеккә әверелде. Кем-кемне җиңәр икән? Венераның горурлыгымы, әллә Ансарның үҗәтлегеме? Йөрәк ныклыгы менә шушындый тынлыкларда сынала инде... Венера җиңелде, чөнки әлеге көтелмәгән очрашудан аның кинәт хәле китте. Ул куенын ачты.

—Тенте, давай, эзлә!..

Кызыл пәлтә канат җәйде... кызыл бәрхет күлмәк, кызыл челтәрле бәби итәк, кызыл җиң, кызыл түш... Ансар ике куллап, бар көче белән Венераның биленнән кысып үзенә якынайтты.

—Син дә мине аңламагач, Венера!

—Аңлаучылар табылыр.

Ансарга да җиңелер чак җитте... Куллар тыңламады.

Венера, кып-кызыл ялкынсыман, җилфер-җилфер дөрләп, карлы төн эченә кереп югалды. Янып бетәрме бүген?.. Ялкын... Кызыл чәчәк...

Күз алдындагы кызыл томан таралып өлгермәде, бер егет үтеп китте.

—Әй, коллега, буразнада тугарылган ат шикелле бик онытылма әле син анда!—Каравылчылар начальнигы тавышы бу.

Дөрестән дә әлеге егет шома гына чыгып сызды түгелме? Йөзе дә таныш. Карасана: маңгае кин, яңаклары ябык, ияге очлы—өчпочмаклы йөз. Таныш, бик тә таныш. Хәтер дигәнең вак-төякләр белән әллә ни күмелеп өлгермәгән. Капчык тапкан төндә Ансарлар янында бөтерелгән шаһитләрнең берсе—Байгушов ич бу!

Ансар тиз генә урамга йөгереп чыкты... Ләкин урамда өчпочмакка охшаш берни дә күренмәде, җилләр генә исә...

## Гут бай, мадам!

Мәхәббәт сүзен шагыйрьләр уйлап чыгарган. Янгырашлы, аһәңле бу сүз башкалар күңеленә дә хуш килгән—отып алганнар, кабатлаганнар... Хәзер инде бөтен җир шары, хәтта шагыйрьләр үзләре дә шушы—уйлап чыгарылган газаптан интегә. Мәхәббәтнең үзенә генә хас чирләре бар. Әйтик, физик чирләр... Йөрәк сызлый, күзләр тоныклана, үгет-нәсихәтләргә каршы колак саңгыраулана, буыннар йомшара, гәүдә җиңеләя, сагыну дәрәҗәсенә карап ябыгуы сизелә... Психик чирләре дә җитәрлек. Гашыйк кеше ялгыз минутларда кулына каләм ала, мәхәббәт теориясен баета, шагыйрьләр белән очраша, үз-үзе белән сөйләшеп йөри башлый. Гашыйк кешенең зиһене чуала, хәтере начарлана, аппетиты бетә... Без әкренләп физиологик чирләрне санауга күчәбез... Ул кеше ашаудан калырга мөмкин. Көнчелек уты кабына, күңеле нечкәрә, бала-чага турында хыяллана башлый. Төшләренең сюжеты катлаулана, төне-төне белән гыйшыклы төшләр борчый. Колагында туктаусыз кемнеңдер исеме шаулап тора, яисә берәр җырның өзеге чатнаган патефон тәлинкәсе кебек кабат-кабат мыгырдандыра, телгә күчә... Бик күп ул чирләр... Һәм ул чирләрне

дәвалый алырдай бер генә табип та тумаган, тумады, тумас та... Бу чирләр вакыты житкәч әкренләп үзеннән-үзе бетә. Вакыты житкәч—кавышкач... Шунысы сәер, без һәммәбез дә мәхәббәт сырхавына сабышырга теләсә кайчан әзер...

Ай ахыры, беренче квартал ахыры. Маллар кышлауда. «Каракүл» берләшмәсенә чимал житми. Ә чимал дигәнен—чи тире. Суеласы сугымлыклар беткән. Жәнлек хужалыкларында үрчү чоры. Чит илдән кергән чималны күтәп атналар заяга үтә. Ләкин акционер Венераның ул проблемаларга исе китми. Ул эшеннән жәяү кайтып бара. Аның тазиз башкайлары шагыйрьләр уйлап чыгарган газап белән тулы. Әллә кайдан гына, кылт итеп, сабыйлар жыры искә төште, уйларны бүлдерә дә кайтып-кайтып кабатлана.

Чоландагы ак майга, иялӛште күселәр...

Әле генә Ансарны кулга алынды дип фараз кылдык, бактың исә, ул мал арасында сакта тора.

Мияу-мияу, пескәем, хыянәтче икәнсең...

Шушы жыр юньләп уйларга да ирек бирми, килә дә янгырый, килә дә янгырый... Димәк, тәти егетебезнең минем белән танышуы яратудан түгел, бүрек чәлдерү ниятеннән генә. Димәк, ул мине алдан ук күзәтеп йөргән, әзер продукция складында эшләвемне белгәч танышырга сәбәп эзләгән.

Чоландагы ак майга иялӛшкән күселәр...

Нияте тормышка ашмады егетнең, милиция комачаулады... Ә ник соң андый кешене каравылчы итеп куйганнар?! Алдап-юмалап котылдымы икән? Әллә бөтенесе бер мафия микән?

Мияу-мияу, пескәем, хыянәтче икәнсең...

Карале син аны, тасма телне, тыйнак, сабыр, тәртипле булып кылана. Оста караклар гел шундыйдыр инде ул. «Каракүл»нең үзендә генә аз иде ди синең ишеләр?! Товарыбызның ун проценты, күзгә күренмәс бүрек шикелле, әллә кая юкка чыга. Бүрек нәрсә ул... Менә тунны әйт син. Фирменный кибетләребездән тун сатып алган кешене күрмәссең дә. Бактың исә, мутон тун кигән хатын-кызлар адым саен. Каян алалармы? Әнә шул—«ун процент» Ансар кебекләр аркылы тарала торгандыр... Нәтижәдә... Экономияләнгән материалны экономияләргә туры килә. Бүрекләрнен, үзкыйммәте арта, туннарның размеры кечерәя, киеп карамыйча ни яраганын белер хәл юк...

Саклый торган маенны үзен ашап киткәнсен...

Яхшы гына егет кебек үзе, бәлки тәрбияләргә соң түгелдер әле. Тиешле органнарга хәбәр итәргә кирәк. Тик бүген үк түгел, иртәгә. Мактыйсы кешеңне бүген макта, гаепле кешенне иртәгә орыш... Ашыкмаска, тагын берәр тапкыр күзгә-күз очрашырга, бәлки сүз катып карарга кирәктер?!

Икенче дежурствога Ансар килмәде, аның урынына култык астына немецча-русча сүзлек кыстырган «керпе» чәчле—икенче бер студентны жибәргәннәр. Тентеп чыгарганда немецча кылана. «Хэндехох!» дип кулларны күтәртә, «Гут! Гут!» дип билләрне капшый. Соныннан «Гут бай, мадам!» дип саубуллашып кала. Беренче курс студенты булса кирәк, бөтен кеше белгән сүзләрдән гайресен отып өлгермәгән. Ичмасам, «Гут бай, мадам!» дип кычкырып калмаса соң! Егетләр куенында сөелеп карамаган кыз бала «мадам» була диме?! Үртәлде: кимсенде Венера... Ансар да студент бит, тик ул болай ук дорфа түгел...

## Гафу итегез...

Ә Ансарны бу кичтә, ай-ваена карамыйча, ашханәгә куйдылар. Үз каравылчылары, эшкә килеп житкәч кенә, ишек төбендәге бозлыкка

таеп егылган да бүтән тормаган... Авыр туфрагы жинел булсын.

Директордан башлап идән юучысына кадәр күмәкләшеп, Ансар килгәнне күтәп торалар иде.

—Гафу итегез, без, килгән кешенең дукаментын тикшереп тормыйбыз, сине кем жибәрде, шуны гына әйт тә?—дип дәшүчесе хужаларыдыр, ахрысы.

—Язит Язилевич кушты.

—Ә-ә... Алайса ышанычлы кеше икәнсең. Әйдә, иң мөһим урыннарны күрсәтеп чыгыйм. Иң-иң-иң главные—менә шушы суыткыч. Бүген кич ит белән май китерделәр, пломбасын күз карасыдай сакла, яме! Он склады, йозагына мөһерле кәгазь ябыштырылган, ачкыч белән төртә күрмә.

Жаваплы «нокталар» белән таныштырганда, бөтенесе ияреп йөрде.

—Жиләк-жимеш склады,—дип дәвам итте хужа,—шунда ук консервлар саклана. Бишенче складта вак-төяк нәрсәләр. Ашханәгә тәрәзә ватмыйча керерлек түгел, үзең анла инде, төне буе йокламыйча, тәрәзә санап йөрергә туры килер. Мәчене дә урамга чыгарасы түгел, ишекне үзебез ачып керәбез. Төнлә ачыксаң складларда актарынып йөрмә, әнә плитәдә калган аш, калжалар, чәй дә бар. Без киттек. Ишегенне тыштан биклибез, ә син эчтән ныгытып биклә. Иртән бергәм-сәрәмгә ачма. Бөтен кешеләребез жыелып беткәч кенә кертерсең безне.

—Ник алай?—вакытны сузарга теләде Ансар, аның бүген ашханәдә каласы килми иде.

—Акционерлаштык без. ЗАО—«Токмач» булдык. Бары—уртак, югы—бергә! Бер генә пешекчебез дә склад тирәсендә ялгызы иснәнеп йөрергә тиеш түгел.

—Контроль дигәнегез бер-берегезгә ышанмау икән.

—Устав кушкан нәрсә...

—Уставмы? Бик дөрес әйтәсез. Гафу итегез, безнеңчә инструкция дип атала ул. Мин сезнең сумкаларыгызны тикшереп чыгарырга тиеш. Хәзер үк каршыма тезеп куегыз.

Башкалар үзара күз атышып торган арада, бер тәвәккәле бәпкә чыгарган каз шикелле жинел сумкасын Ансар алдына китереп тә куйды. Савыт-саба юучы булып эшли торгандыр, ахрысы. Үзе кәй, үзе чандыр, бармаклары каезлап киптерелгән юкә чыбыклар сымак кына.

«Селтеле суда юылып беткән бу апа!»—дип уйлап куйды Ансар, аны кызганып.

—Дөрес эшлисең, энем,—диде ул хужага таба борылып.

Хужа ике айлык сәяхәткә чыгарга дип тутырылган юл капчыгы кадәр сумкасының бавын кысыбрак тотты.

—Ниткән хурлык бу! Шушы гомер эшләп, мондый кимсетүгә түзәргә...—Ул шундук телефон янына кучеп утырды.—Алло, Язит Язилевич! Эх, Язит абый, Язит абый, гафу итегез, ну синнән мондый этлекне көтмәгәнием. Каравылчы дигән булып тикшерүче жибәргәнсең ич... Нәрсә дисең?.. Студент кынамыни?! Рәхмәт, Язит абый, дөрес итәсең, икенчесен жибәр. Монысынмы?.. Хужа ханым телефон трубкасын йөрәгенә кысты.—Бар, жанкисәгем, каян килдең—шунда олак!

—Язит Язилевич янынамы?! Рәхмәт!

—Тиле, мәкинә баш, шалапай, котырган,—һәм шунын ише калдыкпостык сүзләр белән озатып калдылар Ансарны.

«Ур-ра!» кычкырып кайтып керүен ошатмады Язит Язилевич, аны янына утыртты да бәйнә-бәйнә анлатырга кереште.

—Шатланырлык нәрсә күрмим. Ашханә дип, көләп карама, алар безнең заказчиклар. Ел саен даими рәвештә акча күчереп торалар. Шул акчага без каравылчылар яллыйбыз, синең кебек студентларны асрыйбыз. Килешми, игелекле оешмалардан көлү бер дә килешми. Заказчикның зарланганын яратмыйлар бездә. Сумка актару, кызлар тентү ошап китсә мин сине янә «Каракүл»гә жибәрә алам, үзенә үпкәлә. Бар, сыпыр!

«Каракүл» дигәч Ансар тагын «Ур-ра!» кычкыра язды.

—Әй, студент, кара аны, әгәр берләшмәдән дә жалу килсә... замполитка синең хакта рапорт язам, әйтте диярсең!..

—Гафу итегез, Язит Язилевич, сүзегездән чыкмам.

«Каракүл» берләшмәсенә житәрәк, Ансар урам таксофоны табып, кафедра мөдиренең өенә шалтыратты.

—Алломы?

—Әйе! Өегезгә шалтыратуым өчен гафу итегез, кафедрага килгәнегезне көтеп торырлык сабырлыгым калмады. Вакыт юк, эшкә ашыгам. Өметле бер очрашуга әзерләнәм. Алдан ук сезнең белән киңәшәсе иде... Шаһитләрнең берсе—Байгушов, берләшмәдә эшли икән...

—Алло, егетем, Иске бистәнең ярты халкы «Каракүл»дә эшли, моның ни яңалыгы бар.

—Туры килүе сәер шул. Төн уртасында аяк астыннан шаһит булып калкып чыккач та шикләнгән идем.

—Ә син соң, Субаев, ул кичне төн уртасында мехчылар тирәсенә үзең каян килеп чыктың? Аптыраган икәнсең. Байгушов та яшь кеше, нигә әле ул да синең кебек кызлар куып йөрмәскә тиеш? Шикләнәм дип, төнлә очраган һәр кешене кулга алыргамы? Сүзең беттеме?

—Юк, бетмәде...

—Алло, егетем, шаһитләрнең кемлеген каян белдең?

—Хәтер шәп минем... Райнур Асланов—теге сержант, беркетмәгә кул куйдырганда хәтерләп калган идем.

—Шуннан, егетем?

—Шул. Белештем. Байгушов әзер продукцияләр складында йөк төяүче. Товарга әйләнгән бүрекләрне бәйләме-бәйләме белән генә кулдан уздыра. Бер урында озак эшләгән кеше үзләштерү алымнарына жиңел өйрәнә ул.

—Аңлашылды. Хуплыйм. Сорауларым өчен гафу, Субаев, версияңнең ныклыгын сынамакчы идем.

—Рәхмәт.

—Диплом эшеннең чиреге язылды дип исәплик.

—Тагын бер кат рәхмәт. Зинһар өчен, өегезгә шалтыратканга ачуланмагыз. Гафу итегез.

Эш урынына, яшенә карап үзеңнән күпкә олы кеше белән сөйләшкәндә: рәхмәт, гафу итегез, зинһар өчен... кебек йомшак сүзләрне кызганмаска кирәк. Бу—дипломатик мөнәсәбәтләрне ныгытырга ярдәм итә.

«Каракүл»гә барып житкәнче юл буе «Ур-ра!» кычкырып барды Ансар, янгыратып түгел, сөенечен тыеп кына. Ләкин урамда очраган узган-барганнарга аның «Ур-ра! дигәне «Урла! Урла!» дип ишетелде бугай...

## Яшьлек дустың милиционер булгач

Райнур өнгә охшаш детектив төшләреннән көч-хәл белән арынып күзләрен ачты. Вакчыл кайната төсле санап кына йоклатырга күнеккән будильник, шылтырарга онытып, колак төбендәгесе тукталып йокыга талган. Әле ярый төгәллек дигән гадәт сизгерлеккә өйрәткән—патрульгә чыгар чак житүгә күзләр ачыла, йокы кинәт кенә туеп китә. Башка сәгатьләр уята башлаганчы аякка басасың.

Әгәр беренче көнне үк чакырылган унайга Райнурларга килеп керсә, өйнең зал ягында бихисап күп сәгать күреп аптырашка калган булыр иде Ансар. Телевизор өстендә—мәрмәр плитәгә уеп ясалган сәгать, серванттагы савыт-сабалар арасында шырпы тартмасы хәтле генә электрон сәгать. Стенада герлесе, күкелесе, чаңлысы, агач тартмалысы... Райнурның нәчәлствосы тынгысыз һәм дә ки кайгыртучан полковник. Эшкә төгәл йөрүчеләрне бик, ә иртәрәк килүчеләрне аеруча ярата. Шуңа күрә бәйрәм саен сәгать өләшә. Ә бәйрәмнәр күп... Ял һәм бәйрәм көннәренең саны

ел әйләнәсендә йөз тәүлектән арта... Аннан соң, милиция хезмәткәренен эше дә мактаулы, патрульдән исән-имин кайткан саен сәгать өләшерлек. Райнурның уйларын хуплап бүлмәдәге сәгать йөрешләре көчәйгәндәй булды. Вакыт! Киң юрганның икенче яртысы суынган—хатыны Алсу, инде әллә кайчан торып кухняда кайнаша. Райнур ике мендәр арасына кысылган башын күтәреп, кәккүген көчкә тыеп торган сәгатькә карады. Вакыт! Хәзер биш минуттан нәни тәрәзәдән кәккүк бәрелеп-сугылып килеп чыгар да хуҗасын уятырга оныткан будильник өчен, чаңлы-чансыз, көйле-көйсез сәгатьләр өчен үрнәк булып кычкыра башлар. Вак-кыт!.. Көн саен шулай...

—Хатын!—дип өзгәләнеп кычкыруга, камырлы куллары белән нәрсәгә тотынырга белмичә беркавым аптырап торгач, Алсу кире кухняга кереп китте.

—Яна мәллә!

—Сонга калам, бүген политуку көне. Тиз...

Ул арада Алсу ике кулына ике электробритва тотып аны көтеп тора иде инде. Райнурның утыз ике теше сумса турый, ике яңагында ике бритва «камыл чаба». Бу мәшәкать ир белән хатын арасында шулкадәр килешенеп башкарыла ки, хәтта, читтән күзәтеп торучы булса, мондый хәлләр көн саен кабатлана бугай, күнеккәннәр,—дияр иде.

Гаиләдәге ызгышлар йә акча күплектән, йә акча юклыктан чыга. Иренең каршы дәшәргә чарасы юклыгыннан файдаланып, Алсу ике бритва гүләвен җиңәрлек итеп кенә тезеп китте:

—Туйдым бу эшеңнән. Юньле-башлы ялың юк. Исән-имин кайтырмы бүген, дип, көн саен утка төшеп көтәргә кирәк. Таптың һөнәр... Хезмәтенә күрә акчасын түләсәләрие ичмасам! Әнә, күршең, уналтынчы заводта токарь гына, йөзлекләрне ай саен башланмаган пачкасы белән алып кайта, акцияләренең бәясе күтәрелә башлаган ди. Ялы-ял, ашы-аш, эше-эш ичмасам...

Иртәнге ашка кушып нотык сөйләсәләр тамак тиз туя икән. Райнур кабыл-тибел әзерләнеп чыгып китү ягын карады. Башка вакытта, политуку буласы көннәрдә ул бер кат фатир стенасын күздән кичерә иде. Чөнки, ике бүлмәле фатирының бер стенасы гадәттәгечә чәчәкле кәгазь белән әчләнмәгән, ә соңгы айлардагы докладлар, вәгъдәләр, карарлар, Указлар игълан ителгән газеталар белән тоташтан ябыштырылган иде. Эшкә китәр алдыннан бер кат танышып чыксаң, политукуларда бик җиңел була. Мәгәр, генерал булырга теләгән сержант моның өчен, ким дигәндә, ике-өч сәгать иртәрәк уянырга тиеш. Бүген Райнурның стенадан газета укып торырлык вакыты калмады.

Ир бусагага утырып аяк чолгавын җәеп салды. Казна итеген киеп өйдән чыгып киткәнче әйтеләсе сүзләр бар иде әле ана. Алсу Райнур каршысына килеп басты, ашыгырга исәбе, юкса аның шәхси милиционеры бу итекләргә шулкадәр тиз кереп баса, «Уф!» дип көрсенергә дә өлгермисең.

—Уф!.. Кичә син алып кайткан зарплатаны квитанцияләргә алыштырып йөрдем. Квартплата түләдем, баланың яслесенә дә түләр чак җиткән иде, язгы пәлтәннең тышлыгын әйләндерергә бирдем, җир участогы өчен взнос тапшырдым, йорт әйберләрен страховать итәргә килделәр, коттеджлар идарәсенә барып ссуданың бер өлешеннән котылдым...

—Яхшы булган,—дип җөпләде Райнур.

—Яхшы булмый ни, минем акчага яшәргә калгач.

—Минем акчаны бик азга чыгарма әле син. Бушлай кием бирәләр. Ел саен кәчтүнен, күлмәген, ботинкасын, итеген дигәндәй... Аларны кушып сана. Сатып ала калсаң арзан түгел.

—Мундирың белән мактанма, театрларга киеп барырга да ярамагач... Эш киеме генә ул сезнең өчен. Завод эшчесенә дә комбинезон бирәләр ул...

Озын җөмлә ишеккә кысылып калды.

Әрләшкәндә кешенең йөзеннән нуры сүнеп тора. Хәер, Райнур

эштән кайтканчы Алсуның йөзе тагын нурлана үзе. Аның пыр тузынып йөрүен гаиләдә берәр вакыйга якынлаша дип юрарга кирәк. Гелән шулай ул, иртән иртүк күчәреннән ычкынган көпчәк шикелле, атылып-бәрелеп бөтерелә дә кичен Райнур эштән кайтуга, менә сиңа сюрприз! Йә танышкан көннәре, йә кавышкан төннәре. Йә улларының туган көне, йә үзенеке. Райнур шушы бәйрәмнәрне барлап куен дәфтәренә теркәгән иде. Ачып караса... бүген Алсуның туган көне. Эш белән мавыгып онытыла күрмәсен, кибеткә кереп бүләк юнәтәсе булыр.

Көн әйбәт бүген, кояшка бер карап алсаң кәеф күтәрелә. Вак болытлар, итәкләренә капкан утны сүндерә алмыйча, Идел өсләтеп ачык бәке эзләп йөриләр. Ашык-пошык очып килгән каргалар, үз ояларын өнәмичәрәк, тополь ботагына яңа планнар корырга тезелгәннәр, кайберләре үзләрен бик «важный» тота—авылга кайтып китәселәредер инде... Шул каргалар төсендәге бер мәче, капка өстенә менгәч, як-ягына каранып алды да, этләр уянганчы дигәндәй, күрше мәчеләрнең ишек алдына сикерде.

Замполитның рапортына өстәп «Пионерская правда» газетасындагы яңа мәкалә буенча фикер алышкач, профком председателенең паспортлар алыштыру турындагы белешмәсен тыңлап, кичке мәктәпкә йөрүче һәм йөрмәүче бердәнбер егеткә бармак белән төрттереп тә күрсәткәч, политукучылар эш урыннарына таралды.

Урам—милиционерның эш урыны.

Райнурларның «зәңгәр» билле, аксыл «Жигули»е, киң елгага чыккан жилкәнсез көймә кебек, шәһәр агымына ияреде. Язгы көннең холкын аңламассың. Политуку беткәнче, кояш инде болытларга үпкәләп әллә кая китеп барган. Күк йөзе күгәргән. Көн тоташ күләгәгә әверелгәч сузан-сузан йортларның, киң бәдәнле агачларның күләгәсе югала икән, кешеләр дә шәүлә ияртеп йөрмиләр.

Игътибар итегез, милиционер утырган машинаның бөтен тәрәзәләре чиста булыр. Тирә-юньдәге тәртипне җентекләп карап барыр өчен киң экранлы телевизор кебек ул тәрәзәләр. Шәһәрнең тигез ритмлы чагы: ашыгасы кешеләр урыннарына барып житкән, завод-фабрикаларда тыгыз эш сәгате. Маршрутлы таксилар жилкенчәк кенә, трамвай-троллейбуслар да пассажирларны кабаландырмыйча салмак йөренәләр. Урамда күренгән жан иясе йә пенсионер, йә студенттыр шунда. Күзгә төртерлек артык үзгәреш сизденме—димәк, ритм бозылган, димәк, ниндидер тәртипсезлек дигән сүз.

—Стоп!—дип имән бармагын тырпайткан иде Райнур, шофер егет шундук аңлап алды һәм бизәнү әйберләре кибете янындагы чуалышка таба руль тотты.

Ишек төбендә чират. Студентлар-пенсионерлар түгел, ә берниндиижтимагый һәм сәяси үлчәмгә дә сыймый торган ирләр өере.

—Фу, тройной одеколон саталар. Хәзер дефицит нәрсә ул, әллә хатынның туган көненә бер-ике шешә аласы инде?

—Өстәвенә Парижда чыкканы да булса,—диде шофер егет Райнурны үртәп.

—Өендә берәр шешә хушбуй тотуның зыяны юк, дару урынына булыр, алып килим әле. Озак тормам,—дип, тәвәккәлләгән иде, киредән утыргычка утырды.

—Кемне күзлисен?

—Авылдашымны күрдем, Ансар Субаевны.

—Студент кешегә дә кирәк нәрсә ул, «тройной».

—Сәер төлке. Әнә кара, бер шешә алды инде, ә үзе тагын чиратка тыгылып маташа.

Сержант Райнур, шыпырт кына килеп, Ансарны култыклап алгач, кайберәүләр чиратны ташлап киту ягын карады.

—Сәлам, якташ, артыннан күзәтеп йөри икән дип уйлама тагын, Алсуның туган көненә бүләк эзләп килүем иде.

—Минем исемнән дә тәбрикләргә онытма.

—Мангай почмагын үбәрмен инде: «Ансар өчен!»—диярмен.

—Хет теләсәң кайсы җирен үп, минем хакта искәрергә генә онытма.

—Үпкәләү килешми сина, Ансар.

—Кем үпкәләгән? Минме?

—Яшьлек дустым милиционер булгач караклар куып йөрим дип зарланасындыр.

—Үзем сайлаган һөнәр. Бүген булмаса иртәгә дигәндәй, барыбер җинаятьчеләрне киметер өчен укылган. Шәп практика бу минем өчен, рәхмәт сина...

—Үзенә дә рәхмәт, Ансар.

—Анысы ни өчен тагын?!

—Теге кичне үҗәтләнеп беркетмәләр төзетеп маташмаган булсаммы? Син тынычлап кайтып йоклар идең дә, вәссәлам. Ә мин ни эшләргә тиеш? Минем өстә бер «Каракүл» берләшмәсе генә түгел лә.

—Беләсеңме, Райнур, ни өчен безнең илдә җинаятьне киметеп булмый? Беләсеңме?

—Иркенләп җавап бирерлек вакытым юк.

—Алайса үзем әйтәм. Җинаятьчеләрне сержантлар белән студентлар куып йөри, ә олыраклар шуларны санап утыра.

—Оста икәнсең, бик тирәнгә кермә... Бүген бу чуалышта берәмләп-берәмләп тройной одеколон алып маташуынның серен белмәс дисеңме? Лотокка кибет эченнән әрҗәләп товар ташып торучы ике егетне мин дә таныдым, шаһитләребез. Берсе—Байгушов, икенчесе—Мирзин. Мирзин кибетләргә товар ташучы автохуҗалыкта шофер, әнә теге «Москвич» рефрежираторы аныкы. Ә Байгушов аңа ярдәм итеп йөри, вакыты иркен, ул бүген икенче сменага бара. Бу ике егет арасында бәйләнеш барлыгы көн кебек ачык. Болайга киткәч, эзләренә төшәрсең, Ансар! Ярый, комачауламыйм, эшенә тыкшынмыйм.

Алар очраклы рәвештә күрешкән кешеләр сыман гына кул биреп саубуллаштылар. Ләкин Райнур китәргә ашыкмады.

—Ансар, әгәр Алсуның туган сәгатенә икәүләшеп кайтып керсәк, ә?! Их, сөенер иде карчык! Классташларны бик сагына ул. Әллә тәвәккәллибезме, якташ?!

—Миңа ни, мәҗлесегездә ятим бала кебек утырырмын шунда...

—Ниткән мәҗлес, алай зурлап үткәрмибез, юбилей түгел лә. Ятим дигәннән, теге кызың белән бергә килегез. Бәйрәм көнне кунак сыя ул.

—Венера белән арабыз бозылды.

—Минем аркада...

—Бәлки аңлашыр да идек, сөйләшергә теләми.

—Гаепле икәнмен, үзем җайлармын. Бүген кич Венера белән икегезне табыныбызның түр башында күрмәсәм исемем Райнур булмасын... Тәк, кичке алтыда нәкъ шушы урында очрашабыз. Пока!

Райнур алтынчы ярты тирәсендә тулай торакка килеп керде. Козырегы матчага текәлгән фуражкалы сержантны күргәч, яшьләр арасында «кайнана» дигән кушаматы телдән-телгә күчкән вахтерша ханым аягүрә басты. Сөенеченнән солдатларча сәлам бирергә дә уйлаган иде, кулбаш сөягенең тамыры сузылыр дип курыкты.

—Сержант Асланов! Махсус задание белән йөрим. Менә танык-лыгым,—дип Райнур куен кесәсенә тыгылып өлгермәде, вахтер аның кулына асылынды.

—Син үзең тере дукамент бит, жаным. Милиционер күрсәләр безнекеләр шым булалар, жаным. Юкса бик кыен урынга эләктем. Сулъякта кызлар яши, уң якта ирләр блогы. Ә төн уртасында, кайсы ягың уң да, кайсы ягың сул икәнен аңларлык түгел. Әллә ни рәвешле тулганышып бетәләр. Менә шуңа күрә әйтәм, жаным, әгәр буйдак милиционер дусларың артса монда алып кил, кәләшле итәрбез үзләрен. Хет гозер дип аңла моны, жаным, хет теләк дип кабул ит.

—Тырышырбыз,—дип кырт кисте Райнур, сүз куертырга вакыты юклыгын аңлатырга теләп,—«212» бүлмәне генә әйтегез дә...

—Ирләребез сулга йөри идем, баскычтан икенче катка менгәч тә сулга борыл, жаным. Уңга китә күрмә, анда ирләр...

Бүлмә ишеге нык ябылган, тартып карыйм әле, дип, тоткага ябышкан иде Райнур, кәгазь төргәген култыклап, бәби итәкләре белән җил чыгарып, бер активист кыз үтеп китте:

—Катырак шакыгыз, иптәш милиция, карт кызлар колакка катырак булалар.

Тәки ачылды ишек дигәннәре. Бүлмәдә йозак саен бер кыз. Ансарның тасвирлавыннан чамалап Райнур дүрт кыз арасыннан Венераны бик тиз танып алды.

—Исәнмесез, Венера?!

Җавап урынына Венераның кырыс тавышы яңгырады:

—Кызлар, кайсыгыз милиция чакыртты?!!

Дүрт кыз бик нык көләселәре килгән кешеләр сыман хихылдаган булдылар.

—Венера, бүген минем эш сәгатем бетте инде, формадан килеп керүем өчен ачуланмагыз. Срочно сезнең ярдәмегез кирәк,—диде Райнур, кызларның ерык авызлары ябылачагын алдан ук сизеп,—икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзләр бар иде.

Өч кыз, әйткәнне дә көтмичә, аякларындагы җинел чүәкләрне урам киеменә алыштырдылар.

—Юк, юк,—дип, аркылы төште аларга Райнур,—безнең үзебезгә урамга чыгып сөйләшергә кирәк, кеше ишетмәсен.

Чыгып барышлый гына ишкәрде Райнур, коридор буйлап атласаң, бүлмә саен бәрәңге исе килә икән: кыздырылган, томалап пешерелгән, бөтен килеш көйдерелгән, шулпалы бәрәңге исе аңкып, ашыйсыны китереп тора. Әйе шул, армиягә киткәнче Райнур да Алсулар торагына «чикмәнле бавырсак» ашарга еш килә иде. Дөньяда гел бәрәңге белән генә яши ала торган ике төр тереклек бар: берсе аның—тулай торак буйдак-сазамыклары, икенчесе—колорадо коңгызы...

Әгәр Венера янында Райнур урынына Ансар булса ул әүвәл урамдагы пейзажны күздән кичереп телгә күчерер иде. Ишек төбенә җыелган тамчыларның кичке салкыннан шүрләп каядыр югалуларын, сыерчыклар кайтасыны алдан ук сизеп нервылары какшаган чыпчыкларның урам малайларыдай усал сызгырышуларын, машина көпчәкләре астында ярмаланып уалган иске кар шыгырдавын һәм тагын әллә ничаклы үзгәрешләрне сизгән булыр иде Ансар... Венера да бу үзгәрешләрнең һәммәсен тоеп-күреп торды.

—Синең ярдәмеңнән башка эш бармый. «Каракүл» берләшмәсендә безне кызыксындырырлык бер гражданин бар, беләсең син аны, бергә эшлисез.

—Әгәр Ансар исемле студент дисәгез... Аның белән безнең арада берни юк.

—Берни дә юкмыни, Венера?!

Райнурның елмаеплар торып, тавышларын йомшартып, күзгә текәлеп каравына Венера ачылырга мәҗбүр булды.

—Мин бит аны җүнле кеше дип уйлаган идем,—иптәш сержант,—юрфакны тәмамлап киләм дигәние үзе.

—Уйларың дөрес, гел шулай уйла.

—Ничек инде?!

—Ансар кебек егетләр күбрәк тусын иде әле! Күңеле саф, кулы чиста, сүзе хак аның. Әйбәт кешене күп итеп мактап булмый, кыскасы рәнжеткәнсең син аны, Венера. Мәсьәләнең асылына төшенмичә торып егеттән йөз чөерәләрмени?!

—Рәнжеткән дип, йөзенә төкермәгән лә, укасы коелмас.

—Ансар махсус эш белән йөри... Ни, диплом практикасы үтә.

Профессиясе сәеррәк анын, аңлыйсыңдыр...

—Ник соң үзе шулай аңлатып бирмәде?

—Тыңларга теләмәгәнсеңдер. Яраткан кешеңе аны—бер күрүдә үк анларга кирәк. Фатир хуҗасының каһәрләвенә ышанып, нинди мировой кияүдән коры кала язгансың.

—Язган гынамы, югалттым инде, хәзер ул мине гафу итмәс...

—Бик теләсәң кавыштыра алам мин сезне. Әгәр, һәр сүземне тыңлап, мин кушканны үтәп, киреләнмичә, артык эреләнмичә түзсәң... бүген үк, хәзер үк очраштырам. Ризамы?

—Риза...

—Тәк. Әнә, теге «Жигули»ны күрәсеңме?.. Арткы утыргычына кереп утыр. Мин киосктан газеталар алып киләм, яна Указлар игълан ителмәде микән?

Венера зәңгәр билдәмәле «Жигули»ның герб сурәте төшерелгән ишеген ачып җибәрүгә Ансарны күреп «Ah!» итте. Ансарның «Исәнме, Венера?!» дип ялынуына һичьюгы «Сәлам!» дип кенә булса да җавап бирергә кирәк иде, ә ул биш минут буена телсез калды.

—Яшьлек дустың милиционер булгач рәхәт, ә?!—диде Венера, ниһаять, хәлне аңлап.

—Алам дигәннең авызы яман.

Райнур килгәндә Ансар белән Венера ингә-ин терәлеп, нәрсә турындадыр хыялланып утыралар иде. Сөйләшкән сүзләре ишетелмәсә дә йөзләренә караганда аларның һичшиксез мәхәббәт хакында аңлашкан минутлары икәнлеге күренеп тора.

—Бик беләсегез килсә, бу машинада мәхәббәт сүзләре яңгыраганы юк. Әйдә, сайрашыгыз. Ә машина сезне-безне хәзер Аслановлар гаиләсенә алып кайтыр.

—Кая, кая?

—Райнурларга, Венера. Райнур минем якташ, классташ, хезмәттәш тә.

—Ай-һай, шома егетләр дә соң сез.

—Без дигәнчә барып чыкса... ялгышмадык дип исәпләрбез.

—Әгәр барып чыкмаса...

—Ул чагында...—дип җөмләсен уртага бүлде Ансар,—мине утырталар.

Венера аптыраудан аягүрә сикереп тормакчы иде «Жигули» түшәменә башы бәрелеп кире утырды.

—Абау, нык авыртты.

—Көньяк халыклары башлары белән сулы чүлмәк күтәреп йөри алалар. Вәт, ташбаштыр алар?!

—Баш чүлмәк ташыр өчен түгел ул. Шаяртмагыз, Райнур... Ничек инде Ансарны утырталар? Ни өчен? Тәки гаебе бармы? Ник миннән яшерәсез? Ышанмыйсыз икән, сөйләргә теләмисез икән... Юлларыбыз аймыл, туктатыгыз машинагызны, төшеп калам.

—Кызма әле, кызый, кеше юатып арган инде, болай да...—диде Райнур тизлекне арттырып.—Йә, Ансар, кайсыбыз сөйләп бирә, синме, әллә минме?

—Син сөйләп кара, Райнур!

—Тыңла, Венера... Ансарның синең янга килеше булган, ялгышмасам, эштән каршы алырга.

—Һәм беренче тапкыр...

—Бүлдермә, Венера. Әйе, вәт, Ансар сине көткән арада «Каракүл» тирәли вакыт уздырып йөри. Шулчак ул запас капка янындарак таш койма өстеннән эленеп калган бау очын күреп ала һәм бала-чага кебек аны тартып карый. Бауның икенче очына ярты капчык бүрек бәйләнгән икән, Ансар алдына килә дә төшә... Без гадәттәгечә, мех берләшмәсен башкаларга караганда күбрәк күзәтәбез.

—Тик торгандамы?

—Юк, Венера, «Каракүл»дән күпләп мех югала дигән сигналлар

ешайды, күзәтүне көчәйтергә диелде. Ул көнне мин булмасам барыбер Ансарны кем дә булса эләктерәсе иде. Чөнки бау турында шыптыратканнар иде инде.

Бу юлысы Ансар түзмәде.

—Күрү белән сезгә шылтыратканнар, бауны тартып карамаганнармы?

—Алар да шул, Ансар, синең кебек түзмичә капчыкны сөйрәп төшергәннәр. Без, тизрәк «табылдык»ны үз урынына куеп, бауны янадан ыргыттык. Чын угрыларның алырга киләсе бардыр дидек. Ансар килеп тагын бөтен эшне бозды. Аның юрфакны тәмамлап маташуын бөтен авылыбыз белә. Тукта, мин әйтәм, гөнаһсыз Ансарны эзләнүгә җигик әле, укымышлы кешенең белеме ярап куяр, дим. Күреп торасыз, дөрес иткәнмен. Инде бүгенге көн тәртибенә килгәндә, эш сәгате тәмам. Хатынымның туган көне икәнен онытмагыз! Белеп тор, Венера, минем Алсу Ансарның яшьлек мәхәббәте.

Шулаймы, дигәндәй, Венера Ансарга текәлде.

—Райнур гомер буена дуслык белән мәхәббәтне бутады. Мин мәхәббәтен югалтып йөрүчеләрдән түгел, яраткан кешемне беркемгә бирмәм.—Һәм Ансар дустына сиздерми генә Венераның җылымса кулын кысты.

Чәчәк сатучыларны куандырып яз килә...

Райнурларга кайтасы юл чәчәк сатучылар янышнан үтә. Кул җылысына алгысынып, авыз ачмасыннар дип, лалә таҗларын тегәрҗеп белән бәйләп куйганнар, кояш баеп көн сүрелгәч ул җепләрне сүтә башладылар. Төнгә каршы чәчәк үзе дә йомыла. Сатылып бетмичә калганнарын иртәгә тагын бәйләрләр. Яз кеше гомерендә бик кадерле чор, аның ашыктырып үстерелгән чәчәкләре дә бик кадерле... Сатучы кулындагы яшел чиләктән Ансарның бер айлык стипендиясенә торырлык бәйләм алынды. Өч кеше кулына өчәр чәчәк тиде...

Алсу ишекне ачып җибәрүгә, нәрсәгә сокланырга кирәген онытып, исен-акылын җыя алмыйча торды. Әле, аңа дип үрелгән өч бәйләм чәчәккә омтылды, әле мәктәпне тәмамлаганнан бирле күрмәгән классташына сарылды, хәтта Ансарга ияреп килгән сөйкемле кызга—Венерага да елмаеп өлгерде.

Әгәр, килгән кунакларны җәлеп итәрлек ялтыравык җиһазларын, алтынга манылган савыт-сабаларын, чәчәкле-чуклы китапларын, һичьюгы тыелган видиотасмаларын да булмаса, чәй кайнаган арада кунакларынны алдарлык шаян малай үстер.

Райнур бердәнбер (төпчек түгел) улына Садир диме, иркәләбрәк янгырасын өчен «Садик» дип дәшә.

—Садик, эзлә, өй эчендә шоколад бар!

Райнур үзенең Садирын милиционер итәргә тели. Биш яшьлек тиктормас тәмле тамакның шәхси ихтыяҗларын исәпкә алып көн саен күнегүләр үткәрә.

—Садик, эзлә! Өй эчендә шоколад бар.

Райнур шоколадны үз куллары белән яшереп куя да улынын эзли-эзли әлсерәгәнен күзәтеп сөенә: «Югалган әйбер эзли торган җирдә ятмый», «Син гел бер урыннан эзлисең», «Шоколадны табуы җинелрәк...», «Көндез өй эчен игътибар белән күзәтеп йөрергә иде»,—кебек күрсәтмәләре белән нәни «милиционер»га эзләргә булыша. Әтисе яшенә житкәндә Садир, ким дигәндә, милиция капитаны дәрәҗәсенә ирешергә тиеш. Райнур шулай тели, династия дигән сүзне шулай гына кабул итә ала ул.

Ниһаять, яшерелгән шоколад табылгач, чәчәк бәйләме тирәли табынга чакырдылар. Кулына кашык-чәнечке тоткач сөйләшүдән туктасан, ашап-эчәргә генә килгән икән дип уйларлар. Бүген Алсуның бәйрәме, хатирәләр өч кеше арасында: «Хәтерлисенме?», «Исендәме», «Теге чакны»... дип башланып китә. Дүртенче кеше—Венера, кайсын тынларга белми. Садир да шул хәлдә икән:

—Әни, синең туган көнең ничәдә бетә? Аннары Ансар абый белән Венера апаның туен башларыек...

Искә алулар шушы минутта кырт өзелде. Венераның тел өстендә калган бер йотым сөтле чәе эремчекләнеп тамак төбенә утырды... Соңгы бишьеллыкта болай каты итеп тамак кырган кешене ишеткәне юк иде әле Райнурның.

—Һи, якшәмбе көн яралган нәмәрсә, апанны әнә, теленнән яздырдың. Бүген-иртәгә кулга алынырга торган Ансарга кияүгә чыгып тулай торактагы җәннәтеннән колак каксынмыни ул?!.

—Минем алай дигәнем юк...

—Ә нәрсә дигәниең?

—Әйтмәдем...

## Ике чиләк ислемай

Кем сүзедер, имеш шәһәрләрнең берсендә эксперимент үткәргәннәр ди: сизмәгәндә генә барлык каравылчыларны тәүлек буена эшкә чыгармаганнар. Статистлар шундук хисаплап өлгергәннәр—каравылчысыз төндә дәүләт милкен әзрәк урлаганнар ди... Әле, каравылчыларның үзләренә түләнә торган хезмәт хакын да кушып санасалар югалтуларның күплегеннән компьютерлар телсез калыр иде... санамаганнардыр.

Каравылчы белән йозак арасында охшашлык бар, алар икесе дә мөлкәт саклар өчен. Аермалары да шунда ук, йозак салкын тимер кисәге, ә каравылчының җаны бар: берәр җылы сүз әйтсәң, йозак кебек йомарланып тормас, хәзер йөзе ачылыр. Каравылчы янындагы кайбер ишекләргә йозак эләләр...

Язит Язилевич, мине бүген «Исле гөл»гә җибәрегез әле.

—Кызык кеше син, Субаев, башка резервныйлар кая җибәрсәң шунда атлыгып торалар. Ә син... Әле мех берләшмәсенә җибәр дип ялвара идең, инде «Исле гөл» фабригына телисең! Ислемай иснисең килдеме? Күп иснәсәң туйдыра ул. Нәрсә калган анда сиңа?

—Өйләнәсе елым быел, сайланып калырга кирәк.

—«Исле гөл» фабрикасы дигәч тә әллә кызлары хуш иследер дип уйлыйсыңмы?

—Язит Язилевич, җибәрегез инде, күреп кайтыйм.

—Бар. Тик кара аны, Язит абыегызга берәр хушбуй җибәрәм дип кыстарлар, ала күрмә!

Кыш белән яз әбәкле уйный. Куыша торгач, көн уртасындарак яз кышның эзенә баса һәм кар астыннан гөрләвекләр йөгереп чыга, тал бөреләренә гыйшык керә, купшы кызларның җинел пәлтә чабуыннан күренеп торган юка күлмәк итәкләренә тамчылар чәчри, малайларның чалбар балаклары җеби... Ә кайвакыт, бу тирәдә йөрмичәрәк торсана, дигәндәй, кыш төн уртасында язны куып тота да кирәген бирә. Һәм гөрләвекләр, ерак сәфәрдән гайрәтләре чигеп, бозга әверелә, тал бөреләре кысыла, кызлар җинел пәлтәне салып якалысын кия, ә тамчылар—җиргә төшәргә куркып түбәдәге сөңгеләргә ябышып кала.

Календарьга карасаң кыш өчен күнел әрни, язның өченче аена кердек. Сыерчыклар, алып кайткан җырларын җырлап бетереп, авыл хуҗалыгы эшләренә керешерләр—берәр атнадан. Кеше өстендәге киемсалымга карап та ел фасылының җылыга авышуын тоясың. Бүрек сатучыларга сезон ябыла. «Каракүл»некеләр урламыйчарак торырлар микән? Угрының кулы тик тормас шул... «Табышсыз кайткан көннәреңдә ничек түзәсең?»—дип сораганнар бурдан. «Яңа күн итегемне күршемнең ишегалдына атам да сиздермичә урлап алып чыгам, шунсыз йоклый алмыйм»,—дип җавап биргән теге. Бүреккә кызыгучылар туктамаслар, тавык фермасына ияләшкән төлке шикелле, җае чыккан саен ояларына ташырлар.

Ике капка урам аркылы күзгә-күз карашып тора: берсе—«Каракүл»,

икенчесе «Исле гөл» фабрикасы. Һәр ике капка да игезәкләр сыман охшаш. Бары тик әрдәнәләп өелгән бихисап күп һәм төрле фасондагы ислемай шешәләре өеменнән чамалап кына кайсы капканың кемнеке икәнен белеп була. Ул шешә өемен күз алдына китерер өчен иллеләп вагон йөкне бер күчкә өеп, бер-ике вагонын чәчеп, өч-дүрт вагонын ватып сибәргә кирәктер.

Зур тимер ишекнең ачылышына борынга йөз төрле хушбуй исе килеп бәрелде. Хуш истән күнел сөенә хәтта.

—Аромат, нинди аромат!—дип берөзлексез кабатлады Ансар.—Төне буе, туйганчы иснә, акча сораучы юк.

Спирт белән эш итүче урыннарда каравылчы итеп хатын-кызларны куялар. «Исле гөл»нең каравылчыбикәсе Ансарны күргәч, сыерчык оясы хәтле генә пыяла бүлмәсеннән чыкты, биленә таянып басты: аяклары бер-берсе алкынсу буасына каккан субайлар кебек, җиңе сызганылган, беләкләре каезланган сөян төсле—үзе ак, үзе ялтырый, куллары бокс бияләен учына сыйдырырлык.

—Субаевмы?!

Мондый тавыш белән сорасалар фамилиян Чуртов булса да Субаев диярсен.

—Шылтыратты Язит Язилевич, сезгә каравылны ныгыту өчен житез егет җибәрәм диде. Бүген, кичкырын ишек алдына цистерна китерделәр—алтмыш биш мең литр спирт! Бушатып өлгермәделәр. Сиңа башка эш йөкләмәм. Шул мичкәне таң атканчы исән-имин саклап чыксаң... Мин монда, телефон төбендә утырырмын. Ник дисәң, «проверяющийлар» килүе бар. Шиклерәк нәрсә сизсәң, цистернага тимер белән сук, тавышына очып килеп житәрмен, минем кулга эләксәләр... Сорауларың бармы?.. Ярый, ишек алдын өйрәнә тор. Сәгать унбергә хәтле цехлар эшли, тыныч.

—Ишек алдыгызда адашмам микән?

—Капка каравылчысына ияреп йөр, аның барыбер эше юк.

Капка каравылчысы—алтмышны үткән, житмешкә житмәгән агай иде—Ансарны күрү белән күзлеген алыштырды.

—Абый, мине кечкенәгә санавыгызмы, нык зурайта торган күзлегегезне кидегез?!

—Һай, энем, һай, берүк көлдерә күрмә, юкса бума ютәлем кузгала. Кичә генә, Мирзинның анекдотыннан көләргә тотынган идем, ютәлдән тукталыр хәл юк, тәки «скорый» чакыртып укол кадатырга туры килде. Син студентмы?

—Әйе, абый.

—Яшәртеп дәшкән буласың, рәхмәт инде. Бу күзлегемә аптырама, бик җаваплы минутларда гына киям мин аны.

—Кешеләр белән танышкандамы?

—Һәм капкадан кереп-чыгып йөргән машиналарның боерык кәгазьләрен тикшергәндә. Әйдә, фабриканы кабул ит, энем... Менә бу цехта пар белән эш итәләр, ислемай шешәләрен пешеклиләр. Алга барабыз. Монысы лаборатория, әнә тегендә ишегалды калай мичкәләр белән тулганмы? Ул мичкәләрдәге сыеклыкны композиция дип атыйлар. Бер мичкәгә... «Ландыш» композициясе дип язылган, димәк, ландыш исе килеп торган ислемайлар, хушбуйлар ясарга китә дигән сүз. Әнә—»Сабантуй», «Тройной», «Сирень» композицияләре... Мичкәләрнең барысы да лаборатория аркылы үтә.

—Теге цехта нәрсә?

—Әкренрәк атла, мин өченче-дүртенче тизлекләрдә йөри алмыйм. Аяклар сызлый. Элек Берлинга хәтле җәяү йөри идек... Хәзер шулар чыга торгандыр инде... Теге цехта композицияләр спирт белән бутала.

—Әзер продукцияләр цехы кайда?

—Менә ул—эче тулы ислемай, чиләге-чиләге белән агызып алырга була. Бездә ике сменалы эш. Төнге унбердән соң бу цехның ишегенә бозау хәтле йозак элена.

«Исле гөл»гә килгәч хуш исле жилләрдән күнел сөенгән иде, инде туйдыра башлады.

—Сиңа ике киңәшем бар, энем. Каравылда торганда угрыларга юлыксаң икегез дә куркып калырсыз: син дә, угры да. Мондый мизгел озакка сузылмый, ике куркакның берсенә йөрәк керә—батырая. Алданрак йөрәклән, чөнки дөреслек синең якта. Икенче киңәшем... Угры күрсән куып кына чыгар, тота күрмә... Куян шәп йөгерә, бик теләсә төлкене куып житә ала. Ләкин минем әле төлке тоткан куянны, генералын кулга алган сержантны күргәнем юк.

—Абый, сезгә ничә яшь хәзер!

—Яшьнең күплеге белән мактанмыйлар. Атлаганда уфылдап, сулаганда гыжылдап, бөкре күләгә ияртеп йөрүчеләрнең барысы да минем яшьтә, кем, энем. Ярый, пост сәгатем тулды. Кичке алтыдан соң капка аркылы транспорт йөрми, иртәнге тугызларда килеп житәрмен.

—Абый, абый, теге машина фабриканыкымы ул?

—«Москвич»ны әйтәсеңме? Сәүдә гаражыннан, Мирзинныкы. Машинасын күрсәм дә көләсем килә. Бик жор егет. Ремонт белән чиләнә. Еш ватыла. Ватылгач калдырып кайтып китә. Иртән иртүк запас часть алып килер ул, тумблерын алыштырасы диде. Капканы ачып чыгарырсын шунда. Ну, Мирзин, искә төшсә көләсе килә... Ә мин көлгәндә машиналарның сигнализацияләре эшли башлый...

Һәм бабай бума ютәлен тыя алмыйча китеп барды.

Икенче смена таралышыр алдыннан әйләнеп керде Ансар. Керсә, каравылчыбикә көтеп тора икән үзен.

—Жиңнәреңне сызган, студент, эшкә тотынабыз. Әнә берәүсе килә дә, эшен иртә бетергән...—Каравылчыбикә ул эшчене ике кулын сузып каршы алды.—Кая әле, бәгырькәем, куен кесәнә тыгылып карыйм. Әһә, шампунь «Особый». Әгәр икенче кесәңнән дә кулыма ияреп чыкса, студент акт яза тора. Әһә, бәхетең икән, калган кесәләрең буш. Тагын эләксәң, кызганыр димә. Бар, юлыңда бул!

—Тентергә бик нык өйрәнеп китеп, трамвайларда ялгыш кына кеше кесәсенә керә күрмә тагы... Шампуньны бир инде, үзеңнеке мәллә?!

—Әле син, рәхмәт әйтәсе урында... китер әле, пропусканны!

—Ярый, ярый, апа, рәхмәт, ачуланма, гаеп итмә, үпкәләмә...

—Күптән шулай диләр аны. Чәчеңне кер сабыны белән юарга өйрән.

—Ә синең фетр эшләпәң ник бүлтәйгән?—дип каршы алды ул икенче эшчене.—Һи, «Наташа»ны шунда яшерәләрмени? Кулыңа гына тотып чыгарлар...

Өченче эшче каравылчыбикәнең күзгә карап кесәләрне күрә торган карашларыннан шинеп төште.

—Нәрсә, туймас жаным, «Бүләк»нең бөтен наборын берьюлы алып чыгыйм дип тырыштыңмы? Кешеләр, әнә, берәмләп кенә урлый. Бизәкле тартмага салмасаң бу ислемайларның хакы бер тиен... тартмасы кая? Яле, бу кесәнә бигрәк калын дәфтәр кыстыргансың, стена газетасы журналисты түгелсеңдер ич?.. Сүтелеп жыела торган булгач рәхәт шул, бөклисең дә кесәгә саласың... Бар, күземә күренмә!

Күп еллар буе бер урында каравылда торганнарга сабырлык бирсен, дип шаккатып тора Ансар. Болай тентү өчен йөрәк кирәк. Ә бу каравылчыбикә житез, үз эшен бигрәк яратып башкара. Бер кешене дә кул тидермичә үткәрми.

—Кил тизрәк, вакытны алма, оялып торма. Синең жиң эчендә гел берәр шешә эликсир була торганые. Сулышыңны өрмә зинһар, туйган ул спирт исеннән.

—Ташладым мин ул гадәтне. Ышанмасаң, менә кара жиңнәрем буш.

—Авызымдагы тешләремә дә ышанмыйм мин, тәмлерәк ризык капсам телемне тешли... Дөрес, жиң эчең буш... Һи, житмеш сумлык

эликсир өчен җитмеш долларлык итегеннең кунычын бозгансың.

Ә колакчасын ияк астыннан бәйләгән бәләкәй иргә кул да тимәде.

—Чыгарып сал!

—Буш кул белән чыгып барам.

—Ату мин сине белмим ди. Чыгар диләр, чалбар төбенә җирәнмичә кул тыгар хәлем юк. Сина әй-тәм!

—«Памперс» бит ул...

—Алыштыр...

Теге ир читкә борылды да бер шешә «Геракл» хушбуе чыгарды.

Кыскасы, сонгы кеше итеп цех начальниклары да чыгып киткәч, өстәлгә тау чаклы хуш исле товар өелеп калды.

—Уф!—дип тирән итеп авыр сулап куйды каравылчыбикә.

Ансар аның авыр сулышы җиңеләйгәнен көтеп торды.

—Инде боларны кая куябыз?

Каравылчыбикә әүвәл елмаюын сиздерде, аннан җәһәт кенә җитдиләнде.

—Башта исәбен белергә кирәк.

—Санап тордым, сиксән дүрт флакон.

—Җөп сан икән... Мин үз эшемне эшләдем, акт язу синнән. Икешәр данәдән сиксән сигез акт.

—Тотылган кешеләрне кайтарып җибәргәч, ничек төзисең ди ул актны, ичмасам таныклыкларын алып калмадыгыз?!.

—Вәт. Тезеп куясы шушында сиксән дүрт кешене, төне буе сорау алып акт язып утырасы. Ә фабриканың ишек алдын, мичкәдәге спиртны кем саклар?

—Белмим шул...

—Син белмәсән—мин беләм, китер портфеленне. Сиксән сигез икегә төгәл бүленә ул.

Һәм каравылчыбикә тентеп җыйган байлыкны ком чүмәләсе кебек итеп кенә беләге белән ике өемгә аерды.

—Хәзер артың белән борылып бас... Бу күч кемгә?

—Икесе дә сезгә,—диде Ансар ачуын сиздермәскә тырышып.

—Мина кеше өлеше кирәкми. Эше дә, ашы да уртак тиеш.—

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ**

**«QAZAN UTLARI»NA 80 YIL**

**Флера Сафиуллина,**

*филология фәннәре докторы, профессор, КДУның татар теленә өйрәтү кафедрасы мөдире.*

## ӘДӘБИ-МӘДӘНИ ЮЛДАШ



***«Казан утлары» журналы гомерем буе миңа әдәби-мәдәни юлдаш булды. Университетны тәмамлап чыкканнан соң, 1960 елдан бирле мин аны даими алдырам. Әмма аның белән танышуым бала чактан ук башланды...***

***... Без мәктәп өенең бер ягында торабыз. Анда безгә кадәр дә укытучылар яшәгәндер. Бу калай түбәле йортның түбәсенә без, кечкенә кызлар, ничек менгәнбездер инде, ләкин шул түбә астында китаплар, журналлар өелеп ятканы хәтердә. Мин анда латинча хәрефләр белән язган Муса Җәлил, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Ибраһимов һ. б. исемнәрне укыганыбызны хәтерлим. Шунда ук гарәпчә «Безнең юл» дип язылган журналлар да бар иде...***

***Ары таба «Совет әдәбияты» журналы минем иң яраткан журналыма әйләнеп китте. Аны беренче битеннән соңгысына кадәр укып чыкмаган чагымны хәтерләмим дә...***

***«Казан утлары»—татар әдәбияты һәм мәдәниятенең елъязмасы. Киләчәк буын әдәби-мәдәни тарихны бу журнал буенча өйрәнәчәк. Казанышларыбыз, байлыгыбыз да, язмышларыбыз да шул басмаларда чагылыш тапкан...***

***Журнал битләрендә шәхес культы белән бәйле югалтулар нәтиҗәсендә халыктан аерылган әсәрләр дә дөнья күрә. XX гасыр башында милләтпәрвәр***

Нишлим ди мин шушы хәтле ислемай белән, чәч китәргәндә дә сибәргә яратмыйм... Кырынгач сөртенмим.

—Иптәшләренә өләшерсең. Каян алганыңны әйтмә.

—Фатирга алып кайтыйммы?

—Хужана бир, сатып керсен, стипендияңә өстәлер.

—Кирәге юк.

—Кибеткә тапшыр. Ярты бәягә, кайсы сатучы да ала.

—Кирәге юк.

—Нинди отказ ди ул! Тот сумкаңны!

Ансар теләсә-теләмәсә дә өлешенә тигәнне портфеленә тутырырга мәҗбүр булды. Соңыннан хәл ителер әле. Каравылчыбикәнең мондый гадәтләре төзәтелер. Ләкин бүген түгел. Бүген теге машинаның серенә төшенәсе бар...

Ул урам салкынына ашыкты. Вагон мичкәсе алтмыш биш мең литр сыйдырышлы булса да сөялеп торырлык урыны юк, тимер салкыны пәлтә аркылы бик тиз үтеп керә. Ирексездән йөренергә туры килә. Дөресен генә әйткәндә, биек-биек коймалар, чәнечкеле тимер чыбыклар аркылы үтеп, бу тирәне белмәгән кемнәрнеңдер завод-фабрика милкәтен урлауларына ышанмый Ансар. Әгәр урлыйлар икән, бауның икенче очын, һичшиксез, завод-фабриканың үзеннән эзләргә кирәк.

Ансар машина янына килде. Бу «Москвич»ның номеры таныш иде аңа. Бизәнү әйберләре сата торган кибет янында күргәне бар. Юрфак студентын төрле техника белән эш итәргә, йөртергә, хәтта сүтәргә өйрәтәләр, әз-мәзләп, әмма кирәгенчә... Ныклап өйрәнәсе килгәннәргә тормыш дигән мөгаллим үзе өйрәтер диләр.

Күпме азапланып кабина ишеген ача алмады Ансар—ачкыч белән бикләнгән (монысы өчен юрист белеме генә житми, машиналар чәллерүче булу кирәк.). Китәсе килми бит «Москвич» яныннан. Шөкер, кузовның ике яклы ишеге җиңел ачылды. Тыштан кечкенә шкаф кебек кенә күренсә дә эче ярыйсы ук биек икән тагы, бөкрәергә иренмәсәң йөреп тә була. Киң

*әдибебез Г. Исхакый әсәрләренең журналда басылуы аның киң халык массаларына яңадан кайтуы иде.*

*«Казан утлары»н яратуым юкка гына түгел. Журналның абруен күтәрүдә аның хезмәткәрләре армыйталмый эшләп киләләр.*

*Журналны яратуымның тагын бер сәбәбе бар. Университетта мин 40 елдан артык эшлим. Шул заман эчендә йөзләрчә студентны укытып, әдәбият дөньясына чыгарып җибәрүдә минем дә күпмедер өлешем бардыр дип уйлыйм. Аларның зур бер өлеше язучы, шагыйрь, журналист булып үсеп җиттеләр. Журналны алу белән, ашыга-ашыга, дулкынланып, шуларның исемнәре юк микән дип карап чыгам. Һәм шул ук көнне укырга утырам. Аларны укыткан еллар искә төшә, алар белән булган вакыйгалар хәтердә яңара... Фәнис Яруллин, Роберт Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Зөлфәт, Рашат Низами, Рәдиф Гаташ, Ркаил Зәйдуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Рафаил Сибат, Газинур Морат, Нурия Измайлова, Марсель Галиев, Фәүзия Бәйрәмова, Шамил Маннапов, Гәрәй Рәхим, Галимҗан Гыйльманов, Ринат Мөхәммәдиев, Шәмсия Җиһангирова, Харрас Әюпов, Радик Фәизов, Флүс Латыйфи, Эльмира Шәрифуллина, Наис Гамбәров, Гәрәй Рәхим, Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Флера Тарханова... Барысын санап чыгу мөмкин дә түгел...*

*Горурланып та куям. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә әдәбиятыбыз өчен күпме талантлар әзерләнгән икән... Горурланып яшибез сезнең өчен, шәкертләребез!*

*Журналда әдәбиятыбыз, мәдәниятебез тарихына багышланган мәкаләләр, күзәтүләр дә аның дәрәҗәсен күтәрә, халкыбыз өчен горурлык хисе тәрбияли.*

*Үзгәртеп кору чоры журналга да тәэсир итми калмады. Җәмгыятьтәге Демократик үзгәрешләр бер яктан, кыюлык, тәвәккәллек күрсәтү белән аерылып торсалар, икенче яктан, әдәби зәвыкның бераз кимүе дә күзәтелә кебек тоела.*

*Басманың бизәлеше дә үзгәрә бара. Ул да укучыга күп мәгълүмат бирә. Журнал тышында рәсем сәнгате үрнәкләре, күренекле әдип-шагыйрьләребезнең рәсемнәре, милли тарихы-*

ачылган ишек аша баганадагы көчле лампа нуры яктырып тора: артык нәрсә күренми, тузан да тузан гына. Тузан белән сөремләгән егерме литрлы канистраны абайлап алды Ансар. Запас бензин йөртәләр микән? Кызыксыну дигән нәрсә өметне куалап тора. Ансар канистраны күтәрде—буш. Бөкесен ачып иснәп карады... Уйга калды... тагын иснәде, тагын, тагын... Хушбуй исен бензин исеннән аерыр өчен дегустатор булу кирәкми. Әллә, Мирзин дигәннәре «Москвич»ка бензин урынына хушбуй гына саламы?.. Машинасы да ватык түгелдер әле, логика буенча шулаерак килеп чыга.

Ансар үзен бүгенге төннең хуҗасы итеп тойды. Ишек алдында башка кеше юк. Димәк, серле билгесезлек Ансарга буйсынырга тиешле... Ян тәрәзәнең кыек өлгесен каера торгач, тупсалы пыяла бигеннән ычкынды. Инде кулны тыгып кабина ишеген эчке яктан ачасы гына... Аккумуляторы янадырмы, суынып майлары куерса да двигатель тиз кабынды, бер-ике тапкыр төчкереп күрсәткәч, тигез, күнелле гөрелте белән эшләп китте... Артыгы кирәкми. Ансар двигательне сүндереп, ишекләрне элеккегечә бикләп калдырды. Димәк, цехларда беренче смена башланганчы, капка сакчысы постка басканчы Мирзин иртән иртүк килә... Аны монда беләләр, үз итәләр. Каравылчыбикә шикләнми үзеннән. Канистраны хушбуй белән ничек тутыра соң ул? Көндез үк цехтан алып чыгып яшереп куямы? Ә инде иртүк килгәч, канистрага бушатып—өйгә... Иртән цехлар ачык булмагач каравылчыбикә машинаны тикшереп чыгаруны кирәк дип тапмый... Юк, Мирзин канистраны иртән килгәч тутыра... Ачкыч ятатып цехка керә, бер тәнкә көмеш юанлыгы торбадан кирәгенчә агызып ала. Янәшәсендә генә «Консул», «Командор», «Геракл» кебек кыйммәтле хушбуйлар булыр. Ләкин Мирзин барыбер «Тройной»ны сайлап алыр. Ни өченме? Арзан товар үтемлерәк була. Кибетләрдә хушбуйны чүмечләп сатмыйлар, ул сыра түгел. «Исле гөл» фабрикасының капка төбендә теләсән күпме буш шешә әрҗәсе-

*бызга караган рәсемнәр журналны кулга алырга теләк уяталар.*

*Журнал әдәби телебезнең халыкчанлыгы юнәлешен саклап килде, аны үстерүдә, баетуда, яшәтүдә зур роль уйнады. Әдәби телебезгә багышланган махсус мәкаләләр бастырып, бәхәсле проблемалар күтәреп, хакыйкатьне яклап, проблемаларына игътибарны җәлеп итте. Бу затлы басмада берничә мәкаләм басылып чыгуны үзем өчен зур дәрәҗә дип саныйм.*

*Фәнни хезмәт язганда, сүзлекләр төзегәндә, мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр эшләгәндә, бу журнал минем өчен «тел лабораториясе» булды: яраткан журналым битләрендә дөнья күргән әсәрләрдән йөзләгән, меңләгән мисалларны язып алганымны хәтерлим...*

*«Казан утлары» хәзерге матбугатта беренче булып латин язуын кире кайтару юнәлешендә күп еллар инде эшләп килә. Моның белән ул журналның аерым өлешләрен чит илләрдәге милләттәшләребезгә дә укырга мөмкинлек бирә.*

*Журнал битләрендә соңгы дистә еллар эчендә хәтта безнең зыялыларыбызга да таныш булмаган күп санлы язучылар, аларның иҗаты, күп тарихи-мәдәни мәгълүматлар яктыртыла башлады. Сүз ирегә журналның абруен тагын да күтәрде.*

*«Казан утлары»нда язучыларны һәм киң катлам укучыларны борчыган фикер алышулар, дискуссияләр үткәрелү журнал белән укучы арасындагы бәйләнешләрне ныгытуда бер нәтиҗәле чара булгандыр дип уйлыйм.*

*Хәзерге авыр заманда да журналны халык ятатып укырлык дәрәҗәдә тоту җиңел эш түгел икәнлеге һәркемгә билгеле.*

*Журналның һәм аның хезмәткәрләрен бәйрәмнәре белән тәбрик итеп, әйтәсе сүзебез шундый: «Казан утлары» милләтебезнең яраткан журналы булып калсын! Анда иң затлы, иң мәгънәле әсәрләр генә урын алсын! Журнал телебезнең сагында торып, аның халыкчанлыгын үстерү, камилләштерү юлында армый-талмый хезмәт итсен! «Казан утлары» үзенең йөзьеллык, ике йөзьеллык, өч йөзьеллык бәйрәмнәрен дә, халкыбыз белән бергә яшәп, аңа хезмәт итеп үткәрсен иде.*

әрҗәсе белән аунап ята, кирәгенчә күтәреп кит, бушлай ул. Канистраны вак шешәләргә бүлеп салырга өйдәгеләр булыша ала. Вак эш әлбәттә, шырпы сыярлык кына гурласыннан тамызып ике йөз граммлы флаконны тутырып кара әле син!.. Ләкин, Мирзин кебекләр аның чарасын табар: аптекадан ике йөз грамм сыешлы шприц сатып алырлар да шешә саен кадарлар. Куен кесәсенә салып алып чыккан этикетка кәгазьләрен ябыштырсаң—эше бетте, тауарга әйләнә, кибетче дусларына илт тә бир...

Ансар әзер продукцияләр цехының ике канатлы зур ишегенә сокланып карап торды—бу кадәр авырлыкны тупсалары ничек күтәрә аладыр?! Ил нужасы ишекләрдә... Ишекләр тыгыз ябылган, идән белән ике арада күсе йөрерлек тә ярык юк. Ишек канатларын алкалы йозак тыеп тора. Мондый ярты потлы йозаклар сатылуда беткәннән бирле кибетләрдә ике-өч буын сатучы алышынгандыр инде.

Җентекләбрәк карый башлагач тагын бер нәрсә сизелде—йозакны җыеп торучы кендекләр заводта эшләнгәнчә түгел, кулдан чүкелгән. Димәк, бу йозак күптән түгел генә төзәтелгән. Ачкычын югалткач сүтеп янадан җыйганнар. Алкалы йозакларга ачкыч ясау өчен аны сүтеп җыярга туры килә. Ачкычы чынлап югалганмы? Ачкыч бервакытта да югалмый, җиргә төшсә төшәр, суга батар, яшергән җирдә онытылыр, мәгәр юкка чыкмас, кулдан-кулга гына күчәр. Югалган ачкыч—Мирзин кулында булыр!..

Ансар үз-үзеннән имтихан алгандай, вакыт-вакыт бер сорауга җавап эзләде: ике чиләк ислемай белән ярты капчык бүрек арасында, Байгушов белән Мирзин арасында уртаклык бармы? Бар! Алар икесе ике төрле җирдә эшләсәләр дә чынлыкта исә юллары бер. Димәк, Мирзинның эзенә төшү—ул Байгушовның сукмагына чыгу дигән сүз. Бүген инде аз гына нәрсәгә ирешәсе калды. «Исле гөл» капкасыннан чыккан чакта, инструкциягә туры китереп Мирзинның «Москвич»ын тикшерергә. Ул машинаны «төзәтергә» иртәнге дүртләрдә килеп житә диделәр, ә Ансарның әле эш сәгате сигезгә кадәр, вакыт житәрлек...

Төннең бер жирендә, теләсә нинди сакчыңны да егып салырлык йокы китергеч минутлар бар. Жылынып чыгыйм дип кергән чакта, каравылчыбикәнең күз алдында, көймә мичкә арка терәгән килеш Ансар йокыга изрәгәнен сизми калды. Хәер, йокы дип әйтү артык зурлау һәм чамасыз янгыравык булыр, бәлки саташу—уяна алмыйча интегү дип кенә әйтергәдер... Күзен йомганын көтеп тордылар да Мирзин машинасының калай әрҗәсенә бикләп алып киттеләр. Әй, баралар болар, әй алып баралар Ансарны... Ниһаять, туктатып агач авылның киртә капкасы янында төшерделәр. Урамдагы кешеләрнең һәммәсе Алпамша кеби икән...

Мирзин Ансарны авыл эченә алып керде дә:

—Менә, иптәш дипломсыз адвокат, без шушы авылда торабыз инде, йортларыбыз «Русский лес» белән буралап, түбәләре «Шипр» белән ябылган. Син безне якларга тиеш!

Әллә төшке аш вакыты житкән, авылныкылар кайтып киләләр. И Раббым, бу Алпамшаларны туйдырырга да... Нинди әзмәверләр!.. Пилорамнан кайтучыларның балта очына ияргән чумарасы бүрәнә хәтле! Печән өючеләренең сәнәк очына эләгеп кайткан печән өеме кибән чаклы. Ә амбардан икмәк җилләтеп кайтучы ханымнарның билләренә күтәреп бәйләнгән алъяпкыч итәкләре бер капчык бодай сыйдырган. Комбайннан бөртек ташучы машиналар автоүлчәүдән чыгуга туп-туры үз өйләренең имән капкасыннан кереп югалалар, имеш. Ансар кайсысының якасына барып ябышырга белмичә тик тора. Кычкыра башлаган иде, «сарыкмахерский»га алып керделәр. Чукмар беләкле, уклау бармаклы түткәң йон кыркый торган кайчы белән Ансарның чәчен алып атты. Шуннан, чәчтән котылган такыр башка бер чүмеч «Тройной» сиптеләр.

—Сипмәгез, кирәкми, мин «Исле гөл»дә бүген туйган хуш истән! Бүрегемне бирегез!..—дип кычкырган минутында аны каравылчыбикә уятты.

—Тор, йокы чүлмәге, күп яттың. Син бит эшкә килгән кеше!..

Ансар бәрелеп-сугылып дигәндәй, ишек алдына йөгереп чыкты.

Чыкса—мичкәле вагон урынында тора, ә менә Мирзин машинасыннан хуш исле җилләр искән... Нишләргә?! Сактагыларны бастырып әлеге «Москвич»ны эзләтергәме? Көләрләр... Ярый ла Мирзин бүген «чумара» алган булса... Әгәр, күңеле сизенеп, буш кул белән чыгып китсә?! Йокы, йокы! Иң арзан ризык!

Ансар ислемайлар тулы сумкасын күтәреп килеп кергәндә Райнур дежурга чыгар алдыннан соңгы сәгатьләрен йоклап ята иде. Алсу Ансарга ияреп кергән хуш искә аптырап инбашларын җыерып куйды.

—Одеколон эчтең мәллә, бөтенләй якын килерлек түгел?!

—Кондитер фабрикасыннан кайтсам конфет исе килә, дияр идегез әле... Уянган булсаң, тор, Райнур!—һәм Ансар сумкадагы байлыкны идәнгә бушатты.

Алсу «Аh!» итеп идәнгә утырды да ислемай шешәләренә үрелде. Юрган астыннан чыккан килеш басып торган Райнурга ишарәләп:

—Менә, кеше иртә таңнан мал таба белә. Ә син, йоклап ятасың!

—Райнур түгел, мин йоклап калдым әле монда. Кул астыннан шуып чыгып качты, инеш балыгы шикелле.

—Кем качты? Кем йоклаган? Кемнекеләр бу?

—Урланган нәрсәләр болар. Акт төзеп исәбен алыйк та кирәге чыкканчы саклап торыйк. Ә калганы турында юлда аңлатырмын, киен әйдә.

Кояш—кышкы ялкау кояш түгел, иртүк торып офыкның иреннәрен кызылга буяп куйган. Талларның сыек чыбыгына тезелгән тук бөреләр шул якка таба борылдылар. Сагынып кайткан кара каргалар тимер юл читендәге тупылларга сарылып иртәнге нәрәткә җыелганнар, үзләре, «кайтасыларыбыз кайтып бетте микән дигәндәй, станциягә иренеп килеп кергән һәр поездны күздән кичерәләр.

—Ислемай сипкән кешеләр очрамаса ярар иде,—дип тәгәлләде Ансар, төнге маҗаралар турындагы сүзен.

—Бәлки «Исле гөл»дә каравылчыларны кисәтеп куяргадыр? Мирзинның машинасын тикшергәләсеннәр...

—Каравылчыбикәләргә ышанмаска хакым бар. Атна үтәр, ай үтсә үтәр, әмма ул Мирзинның машинасын үзем эләктерермен.

—Бүгенге шикелләме?!.

## Яратырга вакыт юк

Ансар кайтып кергәндә Гадигали агай җиз самавырга кушылып, җырлап утыра иде. Ул үзенә генә билгеле эш сәгатен тәгәлләп, чәй эчә. Сөембикәсе өстәл артында, йокы аралаш, картның күңелен күрер өчен, теләсә-теләмәсә дә чәй чөмерә. Самавыр яңа кайнап чыккан, ахрысы, чынаяк тәлинкәсенә бик еш өрәләр.

Ансарны күрү белән Гадигали агай чынаяк тоткан кулын селкетми генә сыңар куллап яңа чәй агызды. Вак көмеш чыбыктан үрелгән кәрҗиннән бер шакмак шикәр алып бирде. Сөембикә карчык утыргыч шудырды. Бабайның кәефе юк, дип уйлап куйды Ансар, чәйне көлешә-көлешә эчә торганнарые.

—Гадигали агай...

—Әйт шуны.

—Әллә чирләбрәк торасың инде?

—Миңа дигән чирнең исемен белмиләр ди әле.

—Бабакаеннын шүрлегеен сүтә башлаганнар,—дип сүзгә кушылды әби кеше, үртәүле кеткелдәү белән. Үзе кеткелди, үзенең кулындагы чынаягында чәй дулкыннары леперддәшә.

—Авызыңны ерма, чәең түгелер,—дип кырт кисте хуҗа кеше,—әллә синеңчә урлау түгелме? Аякка бастырабыз дигән булып иске диварны сүттеләр дә яңа кирпечтән өйделәр. Ә үз кирпече—изге ташлар, чүп-чар

өеменә әверелде, чокырга илтеп саласылар ди. Йөнтәс бүреклеләр шуны авыз ерып карап тора.

—Таш урынына таш ярамаган тагы,—дип каршы дәште карчык.

—Акыллы сүзгә кушылмыйча, «әйе», дип кенә утырсаң, исәрлегенне күрсәтми калырсың шул.

—Берәү гомер буе кешегә акыл саткан да үзе акылсыз калган ди...

—Минем турыда түгел бу сүз. Манаралар тирәсендә йөрүемне гел юләрлеккә санадың. Өйдә эшсез ятсам, сугышып бетәр идек без синен белән. Көне-төне самавыр янында утырып... Пенсиягә чыкканыма биш ел—биш ел буе самавыр сыгам, инде буыннарымны мүк баса.

—Әнә, акчалы эшкә кер, ичмасам, бушлай йөргәнче...

—Нишлим артык акча белән, бары житкән?! Акча—урлашучыларның эшен жиңеләйтү өчен уйлап табылган зәхмәт ул. Күтәрә алмастай мөлкәтне акчага әйләндереп ташыйлар. Кулдан-кулга, кесәдән-кесәгә, илдән-илгә йөреп никадәр халыкны талап чыга ул акча!

—Акча бер тирәгә жыйнала торган нәрсә ул, күбәеп китсә кассага салырбыз. Яшьләрчә күкрәк кагып яшәрмен дисеңме? Картаерсың бер, пенсияңне даруга әйләндерер чак житәр, әйткәние диярсен.

Яшь дип үстереп әйтүен ошатты әле Гадигали агай, тиз күнде хәләлкәе сүзенә.

—Кем алсын мине эшкә?

—Мин сине «Исле гөл» фабрикасына урнаштырам, Гадигали агай, син анда бик кирәкле кеше.

—Кулыңнан килсә—рәхмәт!

—Мең рәхмәт!—дип тезеп китте Сөембикә карчык.—Ансар, улым, аргансыңдыр, төнге каравылдан кайткач. Әнә, ястыкны идәнгә ыргыт та рәхәтләнеп тәгәрә...

—Көпә-көндез урын өстендә аунасам килешерме соң?

—Төнлә генә йокларга дигән закон юк ул, йокы үз вакыты белән килә.

—Дөрес!—дип, җанашкаеның сүзләренә мөһер сукты Гадигали.

—Йокы алдыннан Венераны күрәсе бар, иртәнчәрәк кенә свиданиегә барып килермен, барыбер йокы качты.

Ансар белән Венера кебекләр нишләргә тиеш соң? Кыз, беренче сменада чагында, эштән кайтып бизәнеп-ясанып өлгергәнче кичке алты тула. Ләкин алтыда Ансарның каравылга китәсе бар. Ярый, Венераның икенче сменага чыгуын көттек ди. Көндезге өчтән төнге унбергә чаклы эштә ул. Ансар белән кайчан күрешәсе? Төнге унбердән кафе-рестораннар эчтән бикле, паркларда ут юк, урам әйләнер иден—арылган... Димәк, Венераны өченче сменага жибәрдек, төнге унбердән иртәнге жидегә чаклы аяк өстендә ул. Тизрәк кайтып мендәргә капланасың, юкса төнге смена хәзер килеп житә...

Аңлавыбызча, Ансарның хәле бик үк мактанырлык түгел.

Гашыйкларны иртән иртүк очрашудан тыйган кеше юк.

Егетләрнең паспорт эчтәлеген журналга теркәп торырга тиешле вахтер апа Ансарны күрмәде дә, ниһаять, төнне исән-имин үткәрү шатлыгыннан, өстәлгә башын куеп, утырган килеш, гырылдап йоклап ята.

Ишек шакыдылар. Баштагы мәлне бу тавыш Венерага күрше йорттан ишетелгән кебек тоелды. Аннан күрше бүлмәдән ишетелгәндәй булды. Соңрак, гүя караватны селкетәләр иде... Ишекне ачып, эчке күлмәктән килеш, Ансарга килеп бәрелгәч кенә уянып китте кызый.

—Абау!

Ишек янадан ябылды. Ләкин эчке яктан бикләнергә тиешле йозак кыймылдамады. Шулай итеп, ишекнең ике ягында ике йөрәк калды. Теге якта да, бу якта да тынлык. Мәхәббәттә күп кенә мөнәсәбәтләрне тынлык фаш итә, мизгелләр хәл итә. Әгәр, шушы тынлыкны кичекмәстән жиңеп, бусага аркылы атламасаң, Венераның юрган жылысы сеңгән тәненә язгы пәлтә бөркәләсе иде...

Бүлмә эчендә яз. Форточкадан бүлмәгә җитәрлек кенә язгы җил керәп тора. Өстәлдәге ашъяулыкка кояш бөгәрләнеп яткан. Тәрәзә төбендәге гөлләр чәчәк атарга әзер...

Шәһәр читендәге авылларның кайберләрендә егет белән кызның янәшә йоклау йоласы яшәгән, элегрәк әлбәттә... Ягъни, кавышасы кешенең тән җылысын, уяулыгын, тәрбияви ягын, сабырлыгын һәм шуның кебек аеруча кирәкле сыйфатларын сыныйсың. Мондый элеккеге йоланы бүгенге яшьләрнең кайберләре сынап карый каравын, әмма сынаталар шул...

Вахтер соңгы дүрт-биш сәгать эчендә тулай торактан чыгучы ирләрне күрмәде. Хәер, ул бит әле иртәнге йокы белән булышып, Ансарның килгәнен дә сизми калган иде.

### «Тот, машинаны!»

Көннәр кабатлана, айлар, еллар кабатлана, ләкин бер-берсенә охшап түгел, һәркайсы үзгә... Вакыйгалар да шулай...

Теге көнне «Исле гөл»дә мичкәле вагон саклап Ансар һич көтмәгәндә генә Мирзин машинасының күләгәсенә баскан иде. Инде менә айга якын вакыт узды, ә бу вакыйга һич кабатланырга теләми. Еш кына Ансарны башка объектларга җибәрделәр, бәлки шул арада Мирзин әллә ничә чиләк ислемай алып чыккандыр. Бервакыт, «Исле гөл»гә килеп, Мирзин машинасын кабат очраткан иде ул, тик теге канистра юк иде. Урланган малын озатып бетермичә көн саен канистра күтәреп килми, күрәсең... Язит Язилевич Ансарны күрүгә җайлы урын тәкъдим итте.

—Беләм инде, «Исле гөл»дәге кызың янына барасың килә... Ләкин, нишләмәк кирәк, өстәмә каравылчы сорамадылар, буш урын юк диләр. Түлке борыныңны салындырма, килешми. «Исле гөл» янындагы заводка җибәрәм мин сине, сакчылары ремонтка туктаган—больницага кергән. Капкалары кара-каршы гына, ислемайчы кызыңның хәлен белеп чыгарсың.

Язит Язилевич кешенең күзенә карап сөйләргә яратмый, шулай да аның тавышында Ансарга ярдәм итәргә теләү сизелә. Ничек дип аңларга моны? Эшне тизрәк тотарга иде дип, кафедрадан берәр педагог шылтыратканмы? Язит Язилевич Ансарның нинди студент икәнлеген белә ләбаса! Монда эшкә урнашкан чакта бик җентекләп тикшерәләр: пенсионер гынамы, студент кынамы?! Әгәр бүрек каракларын үзем тотам дигән уен белсәләрме... Юк-бар сәбәпләр табып, Ансарны якын китермәсләр иде. Каравылчы икәнсең—каравылла! Эзәрлекләүнең үз кешеләре бар...

—Хатынны бик авыр сайлыйсың, Ансар энем...

Язит Язилевичның шулай дип озатып калуы Ансарның күңелендәге сорауны сызып ташлады.

Ансар әлеге уйларыннан арынганчы ук «Исле гөл» каршындагы завод капкасына килеп басты.

Күршең бай булсын: «Мә!» дип күтәреп килмәсә дә «Бир!» дип сораныП кермәс... Бу ике капка арасында әрле-бирле килеп, тегене эшлә, монысын тап, дип йөренүчеләр юк. Ике капка—ике җәмгыятькә, ике бүреккә буйсына: «Исле гөл»—җинел, ә завод—авыр сәнәгатьнеке. «Исле гөл»нең житештергәне шулкадәр җинел, озаграк саклап ятсаң парга оча башлый. Ә завод чыгарган әйберләрне вакытында алып китмәсәләр капка төбендә күгәрепләр ятса да югаласы юк.

Ансарга йокларга ярамый бүген. Ул бер капкада торып, икенче капканы күзәтә.

Иң авыр эш—эшсез утыру икән...

Бер ноктага текәлеп, сигез сәгать буе тик утырасы бар, ялгызың гына, телевизор карамыйча, китап укымыйча. Ә уяулык кирәк. Эшсезлектән сүрелеп, вазифаларыңны онытып күңелсезлектән йокымсырасаң да сизгерлек сакта торырга тиеш.

Каравылчы йортының көл төсендәге бүлмәсендә утырып алҗыгач, Ансар завод ишегалдына чыкты, «Исле гөл» капкасына текәлде. Койма

ярыгыннан гел бер төрле генә сурәт күренсә дә Ансарда таң атканчы мавыгып күзәтерлек көч бар.

Йолдызлы тымызык төн. Чалт аяз күк йөзендә галәм төсе. Йолдызлары жемелдәгән күк капусының чиксезлеге алгысыта. Һәм шунысы кызык, ул чиксезлектә бер карак та, урларлык нәрсә дә юк...

Кешегә чир генә әйләнеп кайта, ә үткән вакыйга кире әйләнеп кайтмас, дисәләр, Ансар ышанмас иде. «Исле гөл» капкасыннан чыккан кеше Мирзин иде. Ике капка арасында машиналар кара-каршы узыша алырлык ара бар. Мирзинның йөзен таныр өчен бер карау да житә. Ул үзе генә, урамда көтеп торучысы юк, эшлекле кыяфәт белән трамвай тукталышына ашыкты. Ниһаять, менә ул Ансар көткән төн! Мирзинның машинасы «Исле гөл»нең ишек алдында, ул иртүк әйләнеп киләчәк. Бүген Ансарга йоклап калырга ярамый!

Ялгызлыктан интеккән тутый кошның кеше телендә сөйләшергә мәжбүр булганын белә Ансар. Ләкин ул бүгенге ялгызлыкның шушындый буш, борчулы һәм авыр тынлык белән килүен теләмәгән иде. Венерага шылтыратырга кирәк, икенче сменада ул, эшеннән чыгуга туп-туры монда килсен.

Венера белән чүкердәшеп утыра торгач эшсезлек икегә бүленде, сәгатьләр икеләтә кызу йөри башлады, ялгызлык уртак, сүзләр парлы, хисләр кайнар... Диплом практикасының әле тагын бер ай чамасы вакыты бар. Венераның да отпуска алырлык жае бар икән. Бактың исә, берберенең авылларына кайтып, туган-тумачаларга мәшәкать чыгарырга шәп мөмкинлек бу. Төне буе сөйләнгән сүзләр күбесенчә, әнә шул бер айлык ял тирәсендә бөтерелде.

Завод вакыты белән иртәнге бишләр тирәсендә капкага шакыдылар, житмәсә, аяк белән дөбердәтә үк башладылар. Ансар, Венераны кая яшерергә белмичә, дүрт квадрат метрлы каравыл йортында арлы-бирле йөренергә тотынды. Бары тик Венераның тыныч, сабыр һәм самими карашы белән күзгә-күз очрашкач кына, ниһаять, кыз алдында үзен-үзе кулга алырлык хәлгә килде.

Ансар капканы ачты, Венера Райнурга шылтыратыр өчен телефонга үрелде.

Бәрелеп-сугылып дигәндәй, буш погонлы бер милиционер килеп керде. Ана хатын-кыз ияргән иде.

Кеше ышанмаслык хәлләр: милиционер Ансардан сорау ала башлады.

—Менә бу кешене таныйсызмы?—диде ул ияртеп кергән хатынга күрсәтеп.

—Күргәнем юк—диде Ансар исе китмичә генә.

—Ә сез, гражданка, таныйсызмы?

Әлеге хатын милиционерның жиненнән тартты.

—Әйдә киттек, абый, бу кеше ул кеше түгел.

—Ашыкма, апаем, хәзер ачыкларбыз.

—Мәгънәсезлек күрсәм женем котыра, тизрәк аңлатып бирегез, ни булды?—диде Ансар тәмам сабырсызланып.

—Сөйләп бир!

Күрер күзгә генә олы күренә, болай бөтенләй яшь икән әле милиционерның сенелкәше. Тавышында балаларча яңгыравык бар. Өстендәге мамык курткасы кабарып олыгайтып тора. Башындагы куян бүреге, кайчандыр яңгыр астына эләгеп, үз жанвары төсенә кергән.

—Кичә генәк, төнлә эштән кайтып килгәндә, мин гел шушы урамнан йөрим, бер адәм туктатты. Буйга озын, озын буйлылар озынча яңаклы булалар иде, ә бу адәм түм-түгәрәк йөзле. Кызлар шикелле—түгәрәк йөз, йомыры ияк, хәтта үзенә килешми дә кебек... Вәт, ул каршыма килде дә: индийский чәй кирәкме, ике кило, ярты бәясенә ди. Кирәкмичә сон, сөенә-сөенә алдым, хәтта акчамнан сдача да кайтарып бирде. Миңа кеше өлеше кирәкми, ди. Шулкадәрле дә инсафлы, гадел, беркатлы кешегә охшаганые... Минәйтәм, туры килгәндә шулай саткала миңа, күбрәк тапсаң ишу да яхшы, авылга күчтәнәч итеп алып кайтырмын,

дим. Теге әйтә, теләсәң ящигы белән табып бирәм, ди. Мин әйтәм, кирәкмичә соң, әйдә... Теге әйтә, иртәгә эшеңнән кайтышлый шушында көт, төгәл мең тәңкәлек чәй китерәм ди... Сөйләшкән вакытка килсәм— чынлап та тора теге. Озак көттерден, ди. Товарны койма эченә яшердек, дуслар саклап тора, давай сумкаң белән акчаңны, ди. Бозау сыярдай сумкага өстәп мең тәңкәмне тоттырдым... Кереп китте бу коймадагы бер тактаны кубарып. Көтәм дә көтәм. Ике сәгать үткәч кычкырып та карадым... Аннан соң инде менә...

—Милиционер абыегызны алып килдегезме?

—Әйе.

—Аферист койма тактасын кубарып сезнең заводка кереп качкан. Ә сез, Субаев, каравылда торасыз, кемгә сылтарга соң тагы? Җитмәсә, сак торасы урында... хатын-кызлар белән кәеф-сафа корып ятасыз.

Венера бер Ансарга, бер милиционерга карап, ни әйтергә белмичә, телсез калды. Ансарның кәефе кырылды.

—Син, энекәш, кызлар алдында телеңне чамалап ач. Мундирың хакына булса да башкаларны хөрмәт итә бел.

Дөрес, Ансар әлеге егет белән якалашып маташмас иде анысы, алай да бу минутта Райнурның килеп керүе бик урынлы булды. Райнурга: «чыгып тор әле», дип әйтергә милиционер егетнең погоннары такыррак иде.

Хәлне сөйләп күрсәткәч, дүрт квадрат метрлы бүлмәдә тәгәритәгәри көлде Райнур:

—Диплом эшемне алданрак бетереп, калган вакытымны ял итәрмен, дигән идең. Күрәсеңме, Ансар, профессияң нинди—бер эше бетсә икенчесе туарга тора. Коллега,—дип, олылап дәште Райнур милиционерга,—сезнең алдыгызда юрфакның соңгы курсы студенты Субаев! Ул махсус эш белән йөри.

—Алайдыр да, тик менә фактны актлаштырасы иде.

Ансар кул селтәде:

> —Акты, дисвителни факты:
> Мамадыштан кайткан чакта,
> Бер шешә аракыбызны
> Ат типте дә ватты...

—Яз беркетмәңне, кул куям.

Беркетмә язылган арада тынлык урнашкан иде.

Кинәт, күршедәге «Исле гөл» капкасының тупсалары чыелдаган тавышка Ансар «үрә» катты:

—Райнур, чыгып бара теге машина. Тагын ычкына...—Соңгы «а» авазы әйтелеп беткәнче Райнур белән теге милиционер егет урамга чыгып басканнар иде инде.

Капка бөтенләй ачылып беткәнне дә көтмичә кызыл төстәге «Москвич» урам ягына ашыкты.

Каршысында пәйда булган Райнурны күргәч, Мирзин кисәк тормозга баскан булды. Моңа ышанып, Райнур кабина ишегенә таба килә башлады. Ләкин шул минутта машина бөтен булган көченә үкереп алга ыргылды. Ишек тоткасын эләктереп өлгергән Райнур, мәтәлеп дигәндәй, читкә атылды. Алай да өч сүз әйтеп өлгерде:

—Ансар, тот машинаны!

Каушабрак калгандыр инде, теге милиционер егет читтәрәк тора иде, Райнурның Ансарга эндәшүе аңа кискен адым ясарга этәргеч булды. Егет «Москвич»ның капот өстенә сикереп менде һәм менгән килешкә үк алгы тәрәзәгә китереп типте... Күзенә пыяла валчыклары керүдән шүрләптер, Мирзин ике кулы белән йөзен каплады. Милиционер егет, шул форсаттан файдаланып, ачкычны тартып алган иде инде. Машина, таугa каршы атылган тәгәрмәч төсле, озак баралмыйча туктап калды.

Сүз белән язып аңлаткач күпкә китте, ләкин чынбарлыкта исә, әлеге көрәш йолдыз атылган мизгелгә сыйды да бетте.

Венерадан алда теге кыз йөгереп килде.

—Абыем, алмам, берәр жирең имгәнмәдеме?!—диде ул өзгәләнеп.

—Юк, апаем, мондый шалапайлар өчен яраланып торырга. Бәрепсугып машина куган була бит әле. Урлый белмәгәненә без гаепле диярсең. Һәр карак машина белән милиционер таптата башласа фуражка кияргә кеше калмас.

Райнур белән Ансар килә килешкә үк кузов ишеген ачып карадылар: канистрадан гайре берни юк. Анысын Мирзинның үзеннән ачтырдылар. Мирзин, гадәтенчә, ике куллап чалбарын күтәреп куйды да капкачны каерды.

—«Тройной» гына икән,—диде егет канистрадагы сыеклыкны иснәгәч.

—Мондыйларга күбрәк ирек бирсәң вагонлап урлый башларлар...

—Ирекнең кадерен белә торган кеше түгел бу,—диде Ансар Райнурның сүзен җөпләп,—әзер продукция цехының икенче ачкычын бир монда...

Мирзин, уч төбенә чак сыярлык бер ачкыч сузды.

Закон кушканча, хәзер кичекмәстән Мирзинның өенә тентү ясарга кирәк иде.

Мирзинның күршесеннән ике агайны уятып, пүнәтәйләр исемлегенә теркәгәндә урамдагы лампалар, көн яктысыннан оялып, рәте-рәте белән сүнә башлаганнар иде инде. Пүнәтәйләр тәмле йокыларын бүлдерүчеләргә офтанмадылар һәм күршеләренә тентү килүгә һич аптырамадылар, киресенчә, пүнәтәй булып керергә әллә кайчан әзер инде без дигәндәй, йокламыйча көтеп ятканнар бугай.

Йокыннан уятып тентү килеп төшсә иң пошынмас җаннар да каушар. Мәгәр, Мирзинның хатыны такмаклый-такмаклый шашынып елаган икән— бу каушаудан түгел, ә ир өчен үзен гаепле санаудан гына иде:

—Әйттем, ахыры юньле бетмәс дидем. Тыңламадың! Дус, дип йөргән Байгуш кына харап итте сине... Ичмасам, өйдән куып чыгаргач та ташлап китәлмәдем, бу хурлыкны күрәсе кеше түгел идем мин. Әле ярый, сина ышанып бала тапмадым...

Бер бүлмәле булса да фатир биш стеналы иде: дүртесе, бетон белән тышланып эчтән чәчәкле кәгазь ябыштырылган. Ә бишенче стена «германский» дип телгә кергән көзгеле-көзгесез, ябылулы-ишексез, шифоньер, сервант, антресоль һәм сандыклардан өелгән чит ил җиһазы. «Кызганыч,— дип уйлап куйды Райнур, ә бит бу затлы җиһазны конфискацияләргә мөмкиннәр. Кем белә, бәлки әле хәләл акчага алынгандыр...» Бу «германский»ның тартмалары шулкадәр күп, хәтта аңа өйдәге әйберләр генә түгел, читтән кергәннәре дә сыйган. Берсеннән, өчәр литрлап тутырылган ике банка хушбуй чыкты. Райнур аларны пүнәтәйләргә иснәтеп карады.

—Боларын сатып өлгермәгән, тагын канистра күтәреп чыккансың?

—Күптәннән, кирәк-яракка дип тотам, иптәш сержант.—Мирзин күршеләренә туры карамаска тырышты.

—Әллә кырынгач башыңнан коясыңмы шулхәтле?!

Ансарның бу сөйләшүләргә исе китмәде. Ул башка нәрсә эзли— башка нәрсә! Мирзинның Хушбуй урлавы исбатланган инде. Ләкин аның «Каракүл» берләшмәсе белән элемтәсен исбатлар дәлилләр юк әле.

Тартмаларны капшый-кармалый торгач, зур целлофан капчыкка кулы тиюгә, Ансар күбәләк тоткан сабый төсле чак кычкырып җибәрмәде. Әлеге минутларның кем өчендер бик зур хәсрәт икәнен белгәнгә күрә генә тыелып калды ул. Үтә күренмәле капчыктагы бүрекләр: без бик күп дигәндәй, күзгә төртелеп торалар иде.

—Бүрекләр чөйдә торырга тиеш, Мирзин!—диде Ансар, тавышын көчкә тыеп.

—Сезон бетте бит инде, күя төшмәсен дип төреп куйдым.

—Мирзин,—диде Ансар, бишек янында әкият сөйләгән әтиләрдәй әкрен генә,—каян алдың боларны?

—Иптәш малай китерде, кирәк кеше табылса, сатарсың диде.

—Кем ул?

—Сез белмисез аны.

—Белербез.

—Мин дусларны исемләп сатмыйм.

—Сатмый имеш,—диде Райнур үртәлеп,—аның эше дусларны сату гына аз, аяк-кулларын бәйләп тапшырырга кирәк.

—Байгуш ул, Байгушов!—дип төзәтте Мирзинның хатыны.

—Беләбез, үз авызыннан әйттерәсе килгән иде,—Ансарның тавышында җинүчеләргә хас көрлек сизелә...

Мирзиннар өендәге соңгы сөйләшү аның хатыны белән Ансар арасында булды.

—Минекенең эше зурга китәме инде?

—Җинаятьнең зурысы, кечкенәсе юк. Законны бозган кешегә җәза тиеш.

—Ана карап илдә урлашу бетәр дисезме?

—Бераз тынып торырлар әле... Әгәр инде законның барлыгын шулай сиздереп тормасак, җәмгыятьне ике көндә өйләренә ташып бетерә болар...

## Бетте, дигәндә генә...

Сөембикә карчык сумкага ризык тутыра—Гадигалиен төнге каравылга әзерли.

—Ак бүрегеңне ки. Синең өчен яз җитмәгән әле.

—Карчык дим, мавыкма шул хәтле ашау әзерләп, армиягә китмим ич!

—Алай димә, карт, яңа урында беренче көнең айдан да озаграк тоелыр әле. Эчең пошкан саен тамак ялгарсың. Бәлки тәмле ризыкларымнан күңелең йомшарып, «Исле гөл»дән ярты гына шешә исләмәй алып кайтырсың, артык кыйммәтлесен димим, ярый миңа нинди дә...

—Чынлап мәллә?

—Ихластыр.

—Ансар, Ансар, чык әле...

—Нәрсә бар?—дип, күрше бүлмәдән Ансар йөгереп чыкты.

—Сөембикә түткәнә штраф сал, мине дәүләт милкен урларга котырта.

—Ярар, ярар, бүләк сораган өчен бинават такма...

—Бүләк дисәң, беренче получкадан, миннән калмас.

—Гадигали абый, мине көт, трамвайга хәтле бергә барабыз.

—Әллә Венера көтәме?

—Көтә. Эштән соң автовокзалга килә.

Ансар кулына юл сумкасы тотып чыгып басты.

—Венераны бозлы фонтан янында атналап көтәргә җыенмыйсыңдыр, сумкаң бик дәү күренә.

—Авылга кайтабыз, икәүләшеп. Безнең якка. Таныша торсын, минем әти-әни дә бар бит әле...

—Бардыр шул, әти-әниең булмаса юрфакларга укырга керә алмасыең... Ярый алайса, хәерле юл,—дип теләк теләүдән гайре эш калмады Сөембикә карчыкка.

Апрель киче. Кояш гөрләвекләргә алтын буяу булып кушылган. Дингез буеннан кайткан түрәләр сыман, ботак саен сыерчыклар кәпрәеп утыра. Урамда хуш ис—ислемай шешәләренә сыймаслык тупыл бөреләре исе. Урам себерүчеләр, кыштан тизрәк котылырга теләгәндәй, ашыгыпашыгып кар чәчә. Һәм ярмалы кар, гөрләвектә эреп киң Иделгә ашкына.

Шәһәр үсеп, яңа аэропорт салынгач, искесен якын-тирә авылларга йөрүче автобуслар өчен зур тукталыш иттеләр. Якташларыңны, сабакташларыңны бик сагынсаң шушында гына кил.

Ансар ике айдан бирле авылга кайта алмады. Венера белән икесен бергә күргәч, туган якларда күптәннән югалып торуын өйләнү мәшәкатенә юрарлар, борчуларың бар идеме, төнге эшкә урнашкан идең мени, дип, төпченеп тормаслар.

Җомга көн кичкә, гадәттәгечә, кайтырга теләүче кунаклар хәтсез күбәя. Венераны көткән арада Ансар инде чират кичеп ике билет алып

өлгерде. Ярты бәягә рөхсәт итә торган таныклыгын күрсәтергә хурланды егет. Беренчедән, күргән-белгәннәр алдында вакланып торасы килмәде, аннан соң шушы ике ай эчендә отыры олгаеп, инде студент итеп түгел, ә яшь белгеч итеп тойды ул үзен. Касса төбендәге этеш-төртешне уенга санап, Ансарның һәр фигылен энә күзеннән үткәргәндәй күзәтеп торучы авыл кызлары да сизә иде моны... Ансар ботинка үкчәсенә тиеп торырдай озын кара пәлтә кигән. Муенында юка ак шарф. Башында чәшке мехыннан тегелгән купшы бүрек. Сдачага тигән кәгазь акчаларны санап та тормыйча тышкы кесәсенә бөгәрләп салды. Атлаганда, авыр сумкасын читкә тотып, пәлтә чабуына тидермәскә тырыша. Үзе, әле сәгатькә карый, әле шәһәр ягыннан килгән троллейбусларны күздән кичерә.

Автобус кузгалырга ун минутлап кына калган иде инде. Венера, килә килешкә үк, Ансарны култыклап читкә алып китте. «Кайта алмый микән? Ник алайса, юл сумкасын дөмбәсләп тотырып чыккан?»—дип уйлап өлгерде Ансар.

—Сонга кала яздың бит, Венера!

—Мин синең фатирыңа сугылдым.

—Ник?! Шушында очрашабыз дип сөйләштек ләбаса...

—Сөембикә әбине күреп сөйләшкәч кенә эчемә җылы керде.— Һәм Венера, кесәсеннән чәчәкле ак кульяулыгын алып өлгермәде, керфекләре арасыннан күз яше саркып чыкты.

—Сине елатырлык нәрсә булды соң, Венера?! Тукта, зинһар, кешеләр әллә нәрсә уйлар...

—Кешедә минем эшем юк, үз хәлем хәл. Бүген теге Байгушовны күрдем. Берни булмагандай, складта эшләп йөри. Смена беткәнче башларыма уй капты, тизрәк синең хәлне беләсем килде.

—Менә бит инде мин, Венера, янында исән-сау килеш басып торам. Борчылырлык сәбәп күрмим.

—Минем күз алдымда кулларына богау салып озаттыгыз ич сез аларны. Ә бүген ул иректә йөри. Йөри генәме, шул ук бүрекләр складында эшләп йөри!.. Байгушовны яба алмагач син гаепле булып каласың түгелме?..

—Алай түгел ул, Венера. Байгушов белән Мирзинның гаебе расланды.

—Ник иректә соң алар?!

—Венера!—Ансар, дәресен өйрәнмичә килгән мәктәп баласы шикелле, күз карашларын төбәрдәй нокта эзләп, аяк очына текәлде.— Байгушовны яклап Ханкаланың бер йөнтәс бүреклесе шылтыраткан. Берләшмәгез мактап характеристика җибәргән.

—Байгушовның хатыны, ике баласын житәкләп, безнең ашханәдә имза җыеп йөрде. Әтиләренең эше зурга китсә бу хәерче ятимнәрне ничек үстерермен, дип, үкереп елый.

—Имза куйдыңмы соң?

—Кызганыч шул. Бөтен цех яклап кутәрелгәндә мин генә читтә калсам. Бер имза каян килеп кая китмәгән.

—Менә, күрденме? Хөкем карарын үзегез чыгарып та куйгансыз инде. Байгушовка күп дигәндә өч ел бирерләр, анысы да шартлы рәвештә генә. Син эштә яклаган, мин аны судта якларрмын...

—Син?!

—Мин түгел, минем кебек башка берәү... Барыбер шул ук мәрәкә инде ул.

—Урлый. Тотыла. Хөкем ителә. Котыла. Тагын урлый...

—Һәм бүтән тоттырмый... Ә син беләсеңме, Венера, караклыкка каршы бер генә чара бар.

—Нинди чара?..

—Урлатма!..

Ун минутка сузылган әлеге кискен сөйләшүне читтән күзәтеп торучы авылдашлар: «Болар әрләштеләр!»—дип, ялгыш нәтиҗә ясамасын өчен, Ансар белән Венерага юл буе елмаешып кайтырга туры килде...

*1985-2002 еллар*



## Рафис Корбан

### Мин бер генә яшим дөньяда

Безнең гомер үтеп бара икән!
Гаҗәп икән Вакыт—ни ара
Селтәп аткан күпме елларымны!
Тын алалмый ятам,—бичара.

Язлар булып Вакыт, көзләр булып
Сүтә икән гомер йомгагын.
Мәгънә эзләп кылган эшләремнән
Җавап сорый үткән елларым.

Юк, теләмим җавап тотарга мин.
Этлек эшләмәдем кемгә дә.
Явызлык юк минем күңелемдә
Тырнак очы кадәр генә дә.

А, бу дөнья! Нинди гаҗәп икән:
Бүлгән безне дуска, дошманга.
Дошманым юк,—үзем дошман икән
«Кеше бул!» дип дәшкән дусларга.

Нинди кырыс Вакыт, мәрхәмәтсез—
Күңел канатларын каерган:
Бала чактан аерган ул безне,
Яшьлекләрдән безне аерган.

---

Рафис КОРБАН *(1957)—шагыйрь, «Буран кайда йоклый», «Куркуын җиңгән куян» (балалар өчен пьесалар), «Уян, татар», «Җиде төстә кунакта» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Аерган ул безне сөйгән ярдан,
Туялмаган килеш сөешеп.
Аерган ул безне әнкәйләрдән—
Илгизәрләр иткән... Ни өчен?

Ә шулай да ерак әле безнең
Җавап тотар көннәр Ходайга.
Иләсерәк булыйк әле бераз,
Без бик җитди бугай болай да.

Күңел ачыйк—җырлыйк, көлик әле—
Без бу җирдә бары кунак бит.
Гашыйк булыйк әле чибәрләргә,
Тормыйк әле куркып гөнаһ дип.

Яшәргә дә өлгермәгән килеш
Соңгы көнең алыр якадан...
Сүкмәгез дә, гаепләмәгез дә—
Яшәүләр юк җирдә яңадан.

## Кырыкта

Япа-ялгыз дөнья уртасында.
Иблис тә юк янда, Алла да.
Киләчәгем—уйда—татлы газәл,
Үткән гомер—кырыс баллада.

Әле бар да, бар да алда кебек,
Кырыкка соң җиттем ни ара?
Барган юлым озыная бара,
Барасы юл һаман кыскара.

Юк бер тавыш, җиһан калган тынып,
Тик каләмем генә кыштырдый.
Ә каләмем миңа, синең гомер
Мәңгелек, дип гүя пышылдый.

## Яра

*Ш. Петефидән*

Бишегендә үксеп-үксеп
Елый бер бала.
Йоклап китсен дип әнисе
Җыр җырлый аңа.

Йөрәгемдә әрни күптән
Иске бер ярам.
Басылмасмы дип шул ярам,
Җырлар чыгарам.

*Ә бит таулар биек булса гына*
*Башларында эремәс кар ята.*

Н. Нәҗми

Әллә нишләп иртә агардым мин.
Тормады шул дөнья иркәләп.
Әллә картлык килде микән миңа
Яшьтәшләрдән күпкә иртәрәк.

Картлыктырмы, башка сәбәптерме
Башкаемны шулай агарткан.
Шуны беләм: биек тауның гына
Түбәсендә була ап-ак кар.

## Әни

Бөтен дөнья мине сөймәгәндә,
Мине күреп йөзен чытканда,
Яла ягып, өскә пычрак атып,
Һәр сүземә каршы чыкканда.

Ташлап китсә хәтта иң якын дус,
Йә сөйгән яр итсә хыянәт,
Кояш сүнеп, кара көнем килсә,
Тормышымда җитсә кыямәт.

Инде тәмам беткән кеше булып
Саналырга тиешменмени?!
Юк, барыбер, барыбер бар җирдә
Барып сыеныр кешем!
Ул—әни!

Юк, барыбер, барыбер бар мине
Кеше итеп күргән яклаучым,
Ярлыкаучым бөтен гөнаһлардан,
Барлык афәтләрдән саклаучым.

Юк, барыбер, барыбер бар җирдә
(Әйтсәләр дә шунда әллә ни)
Таянычым, табынганым минем,
Газиз Аллам минем, и Әни!

## Яңа ел

*Былтыр болай түгел идем,*
*Быел әллә нишләдем...*

Х. Туфан

Кими бара яңа еллар,
Кимегән саен кими.
Килгәне дә инде хәзер
Элекке кебек килми.

Бетте элекке уеннар,
Бетте элекке гамьнәр.

Инде язмыш шәмдәлемдә
Сүрелеп бара шәмнәр.

Югала, кими дуслар да
Еллар кук, берәм-берәм.
Яңа елларга да хәзер
Дусларсыз гына керәм.

Тагын бер ел үтеп бара,
Сүнеп бара бер шәмем.
Былтыр болай түгел идем,
Быел әллә нишләдем...

Искерә бара елларым,
Искерә барам үзем.
Искелек калдыгы булып
Карый дөньяга күзем.

Күнегеп булмый яңага,
Өйрәнеп булмый җырга,
Ияреп булмый вакытка,
Өлгереп булмый чорга.

Чорларны узып чабучы
Замана тизлегенә
Өлгерәме, юкмы бу, дип,
Исе дә китми генә,
Тетәм хәзер тетмәңне дип,
Якадан алган кебек
Гомеремә тагын да бер
Яңа ел килә кереп.

*Ф. Зөлкарнәй ядкяре*

Син Иделдә йөзгән кораб идең,
Океаннар гизгән Титаник.
Нигә икән зур кораб та бата?
Титаниклар төпкә китә ник?

Әллә Идел акчарлагымы Син?
Акчарлак шул түгел яр кошы.
Ник Кояшка биек күтәрелдең?—
Белмәдеңме Икар язмышын.

Йөзәр өчен дә шул юлы кирәк,—
Әллә соң Син Маяк идеңме?
Кораблары сайга утырмасмы?—
Бер Маягы сүнде Иделнең.



## Тәлгат Галиуллин

# ҖИР АЛМАСЫ

хикәя

Төне буе урынында боргаланып ятканнан соң, иртәнге якта гына Габделгазиз йокымсырап китте һәм соры, тозсыз тормышына кискен борылыш алып килгән гаҗәеп төш күрде. Аның янына ап-ак сакаллы, тездән түбән ап-ак күлмәкле, чандыр гәүдәле карт килде, ирнең колагына иелеп, кайнар сулышы белән сүзләрен бутый-бутый пышылдады:

—Газиз улым, ничә йөз еллар күнелемдә, канымда йөрткән серемне сина чишәм. Бу изге серемне бер тапкыр Аттилага, икенче кат Искәндәр Македонлыга әйткән идем. Ничек күтәрелделәр, дөньяны тетрәттеләр! Ә балалары, оныклары алар юлын дәвам иттерә алмады, чөнки серне югалттылар. Татар халкы минем ярдәмнән башка күтәрелә алмаячак...

Габделгазизнең тамагына әчкелтем-төчкелтем төер килеп тыгылды. Йөрәге читлектәге коштай талпынды. Сулыш алудан туктады. Соңгы җегәрен төйнәп, сорарга җөрьәт итте:

—Бабай, кем соң син?

—Мин авыр хәлдә адашып калган балаларыма алсу таңнарда юл күрсәтергә чыккан Хозыр Ильяс булам. Мине танымавың белән рәнҗеттең, бала!

Картның үпкәсен җитдигә алмыйча, ир үзеннән янә өч сүз кысып чыгара алды:

—Бабакай, әйтче сереңне!

—Җир алмасы булыр ул, яңача исемен белмим. Син шуны чәчеп, халкыңа ашатырга тиешсең. Бу—изге вә бөек бурычың... Таң ата, әтәчләр уяна. Миңа китәргә вакыт. Сакалымның очын сыйпап кал, шуннан сиңа көч вә акыл иңәр.

Габделгазиз, кулының калтыравын басарга тырышып, сакалга үрелде. Әмма:

—Кит әле моннан, исерекбаш,—дигән тавышка уянып китте. Бактың исә, ул хатынының юрганнан бүлтәеп чыккан иңбашын сыйпап ята икән.

Хәләл җефетенең пырдымсызлануы гына Габделгазизнең кәефен

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН *(1938)—әдәби тәнкыйтьче, прозаик, филология фәннәре докторы, академик. «Элмәк», «Тәүбә», «Гомер төлгәшләре», «Шигърият баскычлары» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

җимерә алмады. Иреннәрендә серле елмаю биеде, бөтен тәне, җаны, күз керфекләре яңа фикер, илһам белән тулы иде. Ул татар халкын янәдән бөек мәмләкәтләр белән бер рәткә куярлык әмәлне, милләтен артта калдырган сәбәпне белә. Ачкыч—аның ышанычлы кулларында.

Төшендә күргән серле хәлләр йогынтысында кәефе күтәрелгән Габделгазиз, сызгыра-сызгыра юынды, берничә чынаяк чәй эчеп, авыл хуҗалыгы буенча сүзлекләр, китаплар актарырга кереште. Алынган мәгълүматлардан канәгать калып, җаваплы очрашуга яисә яраткан кызы белән күрешүгә ашыккан егеттәй пөхтә итеп киенә башлады.

Бәләкәй генә хезмәт хакына өч бала белән беркайда эшләмәгән ыржыктай ирне ашатып торкан хуҗабикә Габделгазизнең күзге каршында көязләнеп торуын һич кенә дә хупламады.

—Соңгы кәчтүменне сатып эчәргә чыгып барышыңмы?

Җитдилектән ерак сорау белән генә Габделгазизнең кояштай балкулы, тулы айдай бәхетле йөзенә кара шәүлә төшереп булмый иде. Бичара хатынына астан-өскә карады да:

—Өлкәннәр сезнең турыда тикмәгә генә чәче озын, акылы кыска дип әйтмәгәннәрдер. Хәзер сөйрәп йөрерлек чәчегез дә калмады, кистереп бетердегез. Син миндәге үзгәрешне, янадан тууымны күрмисеңмени?

Иренең квадрат чыраена күтәрелеп тә карамыйча, хатын костюмның җиңенә килеп ябышты.

—Ничә ел ашатып ятканның рәхмәте шулмы? Мыскыл итәргә булдыңмы, оятсыз җан?! Синең яңадан тууларыңнан миңа болай гарык булган,—дип сөйләнә-сөйләнә, җиңне ычкындырып, тычкан артыннан сикергән җитез мәче кебек, аш-су бүлмәсенә атылып керде дә, әбисеннән калган агач саплы чуен табаны күтәреп чыгып, тегенең өстенә китте. Әзмәвердәй ир кечкенә буйлы, арык гәүдәле хатыныннан курыкмаса да, шундый илаһи ниятләр белән олы юлга чыгып барганда, хуҗабикә белән сугышуның үзен бизәмәгәнен чамалап, кулларын боксерларча өскә ташлап, тавышына ышандырырлык төсмер-аһәннәр өстәргә тырышып, аңлатма бирүне кирәк тапты:

—Хатын, кызма әле син! Минем бик зур планнар белән чыгып барыш. Тиздән син калабызның иң бай хатыннарыннан берсе булырсың! Алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәрдән бармакларың Агыйдел камышы кебек сыгылып торыр. Ашаганың бал, төкергәнең май булыр. Олы кызыбызны Америка телен өйрәнергә җибәрәм. Җитте аңа Болак сасысын иснәп ятарга!

Бу сүзләр хатынның аңы аша табага барып җитте. Пешерүдән башка бурычны үти алмый калган, күпне күргән чуен таба бот буена төште. Иң явыз хатынның да ялганга ышанасы килә. Кешене өмет нуры, киләчәк чаткысы яшәтә. Бәлки, шаяртмый торгандыр... Бик җитди күренә. Өметсез шайтан, ди.

Габделгазиз исә, булдыклы ефрейтор кеби, кара туфлиенең үкчәләрен шакы-шыкы китереп, бер-берсенә бәреп алды да, аркасын, уклау йоткан кешедәй катырып, эре генә чыгып китте. Ак сакалы биленә төшкән картның гозерен үтәү өчен аның җанын аңлардай миһербанлы, акчалы кеше кирәк. Габделгазизнең сәмән дип аталган төсле зәхмәтне күрмәгәненә биш былтыр. Заманында, олы кәнәфи биләгәндә, аякка басып калган туганнан туганы Сәйфидә шактый акчаның эшсез ятканы аңа мәгълүм. Ике бакчасын, гаражын, бер машинасын яхшы бәяләргә озата алды. Үзендә чит илдә ясалган җиңел «арба»сы калды. Мәсьәләләрне тиз хәл итү өчен автомобиль аларга бик тә ләзем аралашу чарасы булачак. Сәйфинең кысмырлыгы мәгълүм. Яңалыкны авыр кабул итә. Мие корыган. Милли хисләре башлангыч хәлендә калган, илаһилыктан ерак, бөеклеккә омтылмаган, җирдән шуышып йөрүдән канәгать ирнең туң йөрәген халык мәнфәгатьләре белән яшәүгә чакыру аша гына эретеп булмас. «Мин татарны болай да яратам» дип, акча капчыгын кочаклап, икенче ягына борылып, гырылдап йокыга китәр. Габделгазиз милләттәшләрен ике төргә генә бүлә. Беренчесе—хәерче, икенчесе, хәллерәге—кысмыр. Сәйфи икенче

төргә керә. Мәгәр агач корты кебек һәр адәми затның эчендә утырган комсызлык дип аталган иблискә каршы торырлык көч табып була. Әзли белергә генә кирәк.

Бәхете бар икән, Сәйфи гаҗәпләнүдән туймаган зур күзләрен челәйтеп өендә утыра. Габделгазизнең атналар буе салмыш йөрүеннән хәбәрдар хужа, бурычка акча сорап килгәндер, дип фараз кылып, йөзенә шатлыклы төсмерләр чыгарырга ашыкмады. Кунакның исе китмәде: «Акчаны күрәп ала башлагач, кәефе үзгәрер. Габделгазиз абый, гафу ит, сине бәяләп житкермәгәнмен»,—дип, үрмәләп килеп житәр.

Исәнлек-саулык турында сөйләшеп, һава торышын белешүгә вакытны сарыф итмичә, ул Сәйфине урамга чакырды.

—Бик житди сүз бар,—диде ул.

Сәйфи аны үзенчә аңлады:

—Мин бүген уразада. Шайтан суын тотмыйм.

Үзе турында әнә шулай үзенчә уйлаганы өчен ихластан рәнжеп, Габделгазиз кискен генә кулын селтәде.

—Юк ла. Вагайтма син мине.

Сәйфи буйдаклык программасын тулысынча үтәп, бик сонарып өйләнү сәбәпле, аның талчыбыгыдай нечкә билле, яшь хатыны ирга каршы әйтү, ярдәмгә чуен таба чакыру дәрәҗәсенә күтәрелмәгән иде әле. Хәер, анысы—якын киләчәк...

Кышкы ямьле көннәрнең берсе иде. Аккош мамыгыдай ак кар бөртекләре талпынып-талпынып биткә, иренгә, күзгә сылана, шунда юкка чыга. Алмашка башкалары очып килеп житә. Яшь агачлар утыртылган кечкенә бер бакчага кереп, арлы-бирле йөренә башладылар.

Габделгазиз сүзне ерактан башлады.

—Сәйфи туган, без—күп санлы, көчле, тиешле бәясен алмаган нәсел балалары. Һаман аякка баса алмыйбыз. Беребез дә пирамиданың түбәсенә, симез хөкүмәт калҗасы бүленә торган урынга менеп житә алмады. Юк кына йолкыш малайлар охранылы коттеджларда яши, мерседес, линкольн, джипларда чаба, иң чибәр кызлар белән үзе теләгән вакытта чит илләрдә, диңгез буйларында кәеф-сафа кора. Безнең гомер заяга узып бара. Күпме тырышып, маймыл кебек мәтәлчек атып та әлләни майтара алганыбыз юк. Яклау булмагач, син дә югары урынны озак бизи алмадың. Кәнәфиең олы түрәләргә якынрак кешегә кирәк булды. Бүген, менә шундый кышкы ямьле көндә, без кемнән ким соң?—дигән сорауны куясым килә.

Бу туры сүзләр Сәйфинең җанына барып тиде, авырткан сөяленә без булып кадалды.

—Дөрес әйтәсең, брат,—диде ул үпкәчел, моңсу тавыш белән.—Тик безгә янәдән күтәрелү булмас инде...

Сәйфи холкы-фигыле белән хыялый, нечкә күңелле, алдану өчен яратылган инсафлы, әтрафлы зат иде. Карт көнебездә азык-төлек мәсьәләсендә, бәлки, ярдәме тияр дип, үз мәнфәгатьләрен алга сөргән мәртәбәле һәм беркатлы абыйларын тыңлап кына авыл хужалыгы институтын тәмамлаган иде. Әүвәл эшләре гөрләп барды. Аягында нык басып торган колхоз белән житәкчелек итте, хакимият башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелде.

Арттан төртеп баручы терәк булмагач, көннәрдән бер көнне аны шәмнең яктылык иңми торган өлешенә—түбәнә төртеп төшерделәр. Югарыга үрмәләү юллары ябылды.

—Бизнеска кереп китәсе иде,—диде Сәйфи Габделгазизнең тәнкыйди пафосына бирелеп.—Янарак, тапталмаган юнәлеш кирәк.

Бу сүзләр өлкән туганның йөрәгенә сарымай кебек ятты, йөрәге узыштан кайткан атныкы кебек котырынып тибә башлады. Тимерне кызуында сугып калырга кирәк иде.

—Туганкаем, мин таптым бит аны. Син әйткән яңаны,—диде ул тавышына төпсез кое тирәнлеге салырга тырышып.

—Чынлапмы?! Әйтеп кара әле!

—Берәүнең дә башына килмәгән бик көчле идеям бар. Ул—саф татар бизнесы, безне, нәселне күтәрәчәк тармак булачак,—диде Габделгазиз, бу юлы аның тавышында тантаналы вә серле төсмерләр сизелде. Вәләкин күнелендәген ачып салырга ашыкмады ул. Тимерне суга тыгып, янәдән эссе күмердә куырып аласы итте.

—Эзләгән корт бал табар, эшләгән кул мал табар! Бу шулчаклы алыш-биреш булачак, без, тиз арада аякка басып, чит илләр белән сәүдә итү юлына чыгачакбыз,—дип, яскана-яскана сөйләде ул.

—Йә, көттермә! Фикереңне уртага сал!

Габделгазиз ашыкмады. Озын ак сакаллы карт калдырган жиде йозаклы сандыкны ачарга иртәрәк иде әле.

—Мин бу эшне әүвәл үзем генә башлап жибәрергә уйлаган идем. Тик, үзең беләсең, мин андый кеше түгел. Туганнар өчен йөрәгем һәрвакыт ачык. Нәсел күтәрелсен, токым шауласын!

—Габделгазиз абый, сузма, фикереңне уртага сал. Мин монда эшсезлектән үземне кая куярга белмичә интегәм, ә син...

—Мин нәселем, туган халкым өчен тырышам...

—Мине пайга ал! Булган акчамны кертәм.

Соңыннан бу вәгъдәне ашыгыбрак ычкындырганы өчен үкенсә дә, әйткән сүз—аткан ук иде.

—Әлбәттә, анысы да кирәк булыр,—дип, туганын жөпләп, Габделгазиз сүзен дәвам иттерде.—Акча иң мөһиме түгел. Юлга чыгып бер сызгырсам, бай, надан мафиозник малайлар мине әрсез көзге чебеннәр кебек сырып алачак, акчага күмәчәк. Безнең заманда иң кыйммәтле нәрсә—яңа идея. Әнә милләтләр уртак фикер эзләп, тыз-быз киләләр,ниләр генә кыйланмыйлар, үзара сугышып, талашып бетәләр...—дип, ул, Андромеда томанлыгына кереп китәргә ниятләгән иде, яңа кредиторы аны кискен бүлдерде:

—Житте сиңа, абзый, сафсата сатма. Нишлибез?

—Жир грушасы, фәнчә, топинамбур дигән, шалкан, чөгендер, кишер кебек туфракта, аста үсә торган ризык турында ишеткәнең бармы? Без аны жир алмасы дип атарбыз. Груша әллә ничек, татар сүзе түгел.

Сәйфи мондый сәер исемле үсемлек турында беренче кат ишетсә дә, сер бирәсе килмәде.

—Тәмләп караганым бар бугай. Соң? Причем монда жир алмасы—топинамбур.

—Дөньяда адәм баласы жиңеп чыга алмаган эш юк. Әнә, айга да мендек, Марска да сәлам бирдек. Без шул үсемлекне үстерә башлыйбыз! Малакаем, син андагы файдалы витаминнарның күплеген беләсең! Йөрәк авыруы, кан басымы, шикәр, бавыр ялкынсынуы кебек барча чирләргә дару ул. Бу әлегәчә берәүнең дә ике ятып бер төшенә кермәгән яңа, татар бизнесы булачак. Язын, күрше районнан утыз гектар жир алып, чәчеп жибәрәбез. Киләсе елга чәчү мәйданын йөз гектарга житкерәбез. Шуңа өр-яңа типтагы, XXI гасыр каласы, әйтик, Яңа Карамалы, Яңа Шәрбән салабыз, күпме ярлы-ябагага эш бирәбез. Тик бу фикерне берәр әрсезе эләктереп алмасын!

Габделгазиз, тирән хөкүмәт серен саклаучылар үрнәгендә, имән бармагын иреннәренә куйды:

—Чуваш кардәшләр әйтмешли, аңкышкыр.

Дөрес, Сәйфи күңеле белән чит илдән кайтарылган автомобильләр сату, Якутиядә урланган алтынны эшкәртү, һичьюгында, читтән бушлай кайткан даруларны кулга төшереп, яңа бәягә ычкындыру, Тажикстаннан килгән яфрак—тузаннар белән шаярып алу кебегрәк бизнесларны күз алдына китергән иде. Габделгазизнең тәкъдиме кызыклы, мәгәр күп хезмәт сорый торган шул. Байлыкны адәм баласына жирнең тирәндәрәк яткан катламнары гына бирә. Шулай да, абыйсының кайнар дингез дулкыныдай көчле йогынтысы, дәрте, аурасы аның миен агулап өлгергән иде.

—Эшне башлап жибәрергә шактый акча кирәк булыр. Берәр банктан кредит-мазар алып булмасмы?

Үзе уйлап тапкан рольгә тәмам кереп беткән Габделгазиз янында Саламторхан, барон Мюнхгаузен, Хлестаков, Остап Бендер кебек дөнья ялганчылары икенчел, чүп булып калырлар иде.

—Тәвәккәл таш ярган, күп уйлаган буш калган, ди торган иде минем әти. Беренче уныштан тегермән салабыз. Калада ике заправка ачып җибәрәбез...

Аннары, тавышын акрынайта барып, пышылдауга күчеп өстәде:

—Җир алмасының беренче уңышын җыр һәм бию ансамблена илтәбез.

—Аңламадым. Синең анда күз атып йөргән матур апаең бармы әллә?

—Юк ла. Тагын да шәбрәк биесеннәр, Мәхмүт Әсәнбаевтан югарырак сикерсеннәр. Президентыбызга да авыз иттерербез. Аның да кан басымы уйный, диләр.

—Башлап җибәрергә күпмерәк акча кирәк булыр?—дип, тәмам ихтыяры сынган Сәйфи сорарга җөрьәт итте.

—Ваклашмыйк, Сәйфи туган. Ни барын минем коңгырт папкага салырбыз да, кирәк кадәренчә генә туздырырбыз. Синең чыгымнарны тиз каплыйбыз. Миңа инде Әрмәнстаннан заявка килде. Ул халык файдалы ризыкның кадерен белә. Израиль белән элемтәдә торам.

Менә шул тарихи көннән башлап, гыйнвар карыдай ап-ак күлмәкләр кигән, ялтыравык галстуклар таккан, култык асларына калын папкалар кыстырган ике дусны төрле министрлыкларда, җаваплы оешмаларда, хакимият башлыкларында күрергә мөмкин булыр иде.

—Топинамбур... Безгә кредит кирәк.

—Топинамбур... XXI гасыр ашы... Татар милләтенең киләчәге.

—Сез артта калган кеше, берни аңламыйсыз.

Берәүнең дә «артта калган кешеләр» исемлеген бизисе килмәде, мыек астыннан елмаеп, ярдәм иткән булдылар, кәгазьләренә кул куйдылар, мөһер суктылар. Тик акча бирүчесе генә офыкта күренмәде. Сәйфинең яшь хатыны гына, «артта калганнар» рәтенә керүдән курыкмыйча, иренен юк эш белән шөгыльләнүенә җылый-җылый карышып карады.

—Бәйләнмә шул Габделгазиз белән. Тыныч кына биш-алты ел яшәрлек акчабыз бар. Ул абзыйның бер файдалы эш тә майтара алганы юк. Төрле дәрәҗәләр бирен карадыгыз, эчеп-тузып йөрүдән, булганны җилгә очырудан уза алмады.

Әмма миенә Габделгазиз ут үрләткән Сәйфине туктата алырдай көч юк иде дөньяда.

Каһәр суккан чыгымнар исә шактый булып чыкты. Әүвәл акчаны аз-азлап, жиз иләк аша гына үткәреп чыгарырга тырышса, бераздан Сәйфи топинамбурга, үз киләчәкләренә тирәнтен ышанып, акчаны кызганмый тота башлады.

Сыкранып, сагышланып карлар эреде, кителеп-кителеп бозлар акты. Күп тә үтми язгы гөрләвекләр, кояшлы тау битләрендә яшел тереклек иләре, урыны-урыны белән умырзая күренә башлады. Шундый көннәрнен берсендә гыйнвар кары кеби ап-ак күлмәк, көяз әтәч кикригедәй чуар галстук таккан ике дус бер вилаятьнең хакимият башлыгы кабинетында пәйда булдылар. Олы гәүдәле, зур башлы, коңгырт бөдрә чәчле бүлмә хуҗасы, каты холыклы, кырыс булса да, татар җанлы кеше икән.

—Егетләр, вакытым тар. Ни йомыш?

—Сездән арендага утыз гектар җир сорап килгәниек.

Колхозларны таратып, җирне теләсә кемгә, унга-сулга тарату сәясәте котырынган чор иде.

—Нет вопросов. Гариза язгыгыз. Тик сез ул җир белән нишләмәкче буласыз? Йорт салырга уйлыйсызмы? Авыл тирәсеннәнрәк кирәктер андый уегыз булса.

Габделгазиз, дулкынлануын басарга тырышып, йомшак келәмнән йөренеп алды.

—Без анда җир алмасы—топинамбур чәчәбез.

—Шалкан шикеллерәк бер нәмәстәкәйме?—дип сорады бүлмә

хуҗасы, ап-ак күлмәкле егетләргә сәерсенеп карап. Ул аз сүзле эш кешесе иде.

—Фарук Махмутович, бу бөтенләй яна юнәлеш, татар бизнесы булачак. Бу үсемлектәге файдалы матдәләр халкыбызга күтәрелергә, коллык богауларын алып ташларга ярдәм итәчәк, илаһи көч индерәчәк.

—Кызык,—дип кенә сүз кыстырып куюдан узмады хәйләкәр бүлмә хуҗасы.

—Ни өчен милләтебез һаман ангы-минге хәлендә йөри? Чеченнәр, Югославия мөселманнары, Косово албаннары, көрдләр күтәрелә, чаң суга. Ә татар һаман кушканны үтәп, башка халыклар кубызына биеп йөри бирә. Безнең бабаларыбыз бөек халык булган, Алып, Чура, Гали кебек батырларны биргән, Аттила, Кубрат хан кебек даһи оештыручыларны күтәргән. Алтын Урда атлары тоягыннан яшен ташыдай очып чыккан кантарлар Алып таулары итәгенә барып җиткән. Казанын югалтканнан соң, татар халкы тәки күтәрелә алмый. Ни өчен?

Габделгазиз, тавышын бизи төшеп, фикерен дәвам итте:

—Аңа көч, куәт индерерлек витамин җитми. Анын миен, буыннарын бәрәңге кәлҗемәсе сыегайткан. Халыкны бары тик җир алмасы—топинамбур гына күтәрә алачак. Үзләренә көчләп бәрәңге ашата башлаганчы, безнең бабаларыбыз нинди куәтле булган. Минем исәпләүләремә караганда, элек халкыбыз бәрәңге урынына җир алмасы чәчкән, шуннан бетмәс-төкәнмәс көч, дәрт алган...

Габделгазиз, үзе сөйләгәннәренә үзе ышана барып, янәдән халыкның зәңгәр томаннарга уралып еракта калган данлы тарихи үткәнен искә алып, француз, алман, һичьюгында чех, фин, швед халыклары белән бер рәттәге киләчәгенә кыю караш ташлады.

—Һәр татар кешесе канын яңарту, югалган пассионарлык җегәрен уяту өчен елына кимендә бер чиләк без үстергән җир алмасы ашарга тиеш. Әлегә без Татарстанда яшәүче ике миллионга якын татарны гына күздә тотабыз. Читтә яшәүче кардәшләргә ярдәм сонрак килер!

Габделгазизгә тәмам ышанып, гашыйк булып, дулкынланудан бер колагы кызып, икенчесе ак төскә кереп, иреннәре солы чүпләгән атныкы кебек сәер кыймылдый башлаган Сәйфи, күзеннән шартлап бәреп чыккан тозлы суны сөртеп алуны кирәк тапмыйча, өстәп куйды:

—Катнаш никахта торучыларны да ашатырга туры килер.

Тәрәзәгә карап утырган хакимият башлыгының ни, нәрсә турында уйлаганын ачыклавы кыен иде.

—Исеме бик сәер. Топинамбур. Ул яңа үсемлек бугай? Безнең бабаларыбызга мәгълүм булдымы икән? Мин аларга көч ат ите белән кымыздан килгән дип йөри идем. Карале син аны? Без бөтенләй надан икәнбез,—дигән булды бүлмә хуҗасы. Ул шаяртамы, ихластан сөйлиме, өздереп әйтә торган түгел иде.

—Сон, җир алмасы ат итенә килешеп, тач ятып тора. Иш янына куш. Топинамбур нигез тамыры белән татар сүзе булырга охшый. Тәпиләп бар. Ягъни көченне кая куярга белмичә, гел алга ашкын!

Хакимият башлыгы төерем иреннәрен җыеп, кычкырып көлеп җибәрде.

—Ярый, егетләр, сезгә җирнең иң яхшысын, кара туфраклысын, бала тапкан хатын-кыз күкрәге кебек үзеннән-үзе кабарып торганын бирәм. Уңган кеше кулында туфрак алтынга әйләнә, диләр. Тик сүздә генә калмагыз.

Шул көннән башлап, Сәйфинең күнеле аҗагандай ялтырап ачылды. Ул бар акчасын, мал-мөлкәтен, көчен шул изге гамәлгә юнәлтергә карар кылды. Элеккеге шик-шөбһәләре, акчаны кысып тотуы өчен аңа үз алдында оят иде.

Габделгазиз Мәскәүдә яңа башлангычларны, бигрәк тә экологик чиста азык-төлек эшләп чыгаруны яклаучы, бушлай ярдәм итүче үзәк барлыгын ачыклый. Шунда үзе барып кайтырга ниятли. Бүләк-күчтәнәчсез, буш кул белән сәфәр чыгу килешмәс. Мәскәүлеләр Татарстаннан чәшке

бүрек, Чистай сәгате, Яшел алан пыяласы, чәк-чәк, бал ише әйберләрне яратып алалар икән. Туннарын сонрак, жылы мөнәсәбәтләре ачыклангач алып барырга мөмкин булыр.

Сәйфи һәдияләрне тапты, сатып алды, әйбәтләп төреп, Татарстан поездына алып төште. Билеты арзанрак плацкарт вагонда бару фикерен Габделгазиз бусагадан кире какты:

—Мин, Сәйфи туган, вагон башында, тамбурда бара алам. Купеминем өчен аралашу үзәге. Күпме кеше белән танышасың, аралашасың. Безгә топинамбур яклы, изге ниятебезне аңлаган һәр кеше кадерле. Андыйлар, абзыкаем, плацкартта йөрми инде.

Сәйфигә саранлыгы өчен оялудан башка чара калмады. Габделгазиз Мәскәүдә, затлы кунакханәдә бер атнага якын яшәде. Заманында берничә ел башкалада укыган кеше өчен яшьлек хатирәләре, Кызыл мәйдан, хәтта Ленин бабай мавзолее—барысы да якын һәм газиз иде. Топинамбур орлыклары турында да белеште. «Баш катырып йөрмәгез әле, башка эшегез юкмыни?»—дип, аны тиз генә озату ягын карадылар. Ә чәшке бүрекнең, татар балына манчып ясалган, авызда эри торган чәк-чәкнең файдасы тимәдеме, дигән сорауның тууы табигый. Алары сөекле кызын Америкага укырга жибәрү хәстәренә китте. Чит илләр белән эшләүче министрлыкта да татар күчтәнәчләре уңай урнашты.

Сәйфи Габделгазизне поездан үзе каршы алды. Йөзеннән берни укып булмый, маска кигән фатир талаучы диярсең. Тәртип өчен тынлык саклап барганнан соң, Сәйфи түзмәде, йомшак, тулы иреннәреннән сорау кысып чыгарды:

—Ну, ничек анда? Уңышлар бармы?

Габделгазиз үз бәясен белеп, көттереп кенә жавап кайтарды.

—Бару бик файдалы булды. Селекция үзәгендә бер карт еврей белән якыннан таныштым. Орлык белән ярдәм итәрмен диде. Топинамбурның киләчәгенә ышандым. Орелдан бер мужик әлеге яһүдигә тун күтәреп килгән. Костромадан зур агач сәгать бүләк иттеләр. Конкуренция зур булачак. Алырмын дигән алдан кергән. Без—беренче.

—Барысы да топинамбур чәчәргә уйлыйлармы? Без өйләнгәч, төн кыска дип, юкка гына әйтмәгәннәрдер. Инде нишлибез?

—Хәзер ресторанга кереп, тәмләп ашап алыйк. Шунда барысын да бәйнә-бәйнә сөйләрмен. Бару файдалы булды. Пушкин фондында эшләүче Аделия Чикбизова дигән ярым шимбә, ярым татар хатыны белән таныштым. Мәдәният министрлыгыннан хат алып килегез, доллар белән ярдәм итәрмен, диде.

—Авыл хужалыгы министрлыгыннан түгелме?—дип, Сәйфи ачыкламыш кертергә булды.

—Каян да ярый. Яман эше ярты юлда калыр. Икенче атнада мина тагын Мәскәүгә барасы. Теге карт еврей янына. Аделия Чикбизовага шул хатны ирештерермен.

Ак күлмәкләренә асфальт тузаны иңә башлаган ике дус, тагын да ныграк бүлтәйгән папкаларын култык асларына кыстырып, оешмадан оешмага йөрүләрен дәвам иттеләр. Шул арада Габделгазиз, Сәйфи исәбенә, тагын да мулрак бүләкләр алып, ике тапкыр Мәскәүгә барып кайтты. Олы калага өченче зыярәтендә кызын ярты елга укырга Америкага озатуга иреште. Туганыннан топинамбур орлыгына дип алган акчалар шунда китте.

Сәйфи аны һәр кайтуында машинасы белән каршы алды, ресторанга алып кереп ашатты. Шуннан соң гына хәл-әхвәлләр турында сорарга жөрьәт итте:

—Ничек анда хәлләр? Тиздән чәчүгә төшәргә вакыт. Мин жирне сөрдереп кайттым.

—Жир сөрелер,—диде Габделгазиз төксе тавыш белән.—Теге татар маржасы Германиягә киткән. Ярты елдан соң гына кайта, ди. Карт еврей шулчаклы хәйләкәр булып чыкты, алдап йөртте-йөртте дә, быелга орлык булмый, диде.

—Инде нишлибез? Күпме акча түктек...

—Бәрәнге утыртып торырбыз. Үзең беләсең, татар шул ризыктан башка яши алмый. Киләсе елга ул орлыкны барыбер кулга төшерербез. Әйдә, миңа тагын йөз илле грамм салып җибәр әле.

Сәйфинең Габделгазизне соңгы күрүе булды. Бер атна баш күтәрми эчеп йөргән, диделәр. Шуннан соң ул суга төшкән балтадай бөтенләй юкка чыкты. Өй телефоны җавап бирми. Ишекләрен ачмыйлар.

Ике атнадан Сәйфиләргә түгәрәк сакаллы, күзлекле ир килеп керде.

—Исәнмесез!

—Хуш киләсез, ни йомыш?

—Йомыш дип, бурычны кайтарырга вакыт. Мин—банк вәкиле.

—Нинди бурыч ул тагын?—диде Сәйфи.

—Сезнең ширкәткә мин өч ай эчендә түләү шарты белән илле миллион, янача, мең акча биргән идем. Бирелә кул куелган, печать сезнеке.

—Минем кул юк. Габделгазиз Саубанов имзасы тора ич!

—Дөрес. Ширкәтнең рәисе сез. Печать сезнеке. Саубановны табып булмый. Рәхим итеп түләгез. Эшне судка җиткермик.

Икенче көнне дә шул ук тарих кабатланды. Ишекне шакып, заманында алыш-биреш итешкән, таныш склад мөдире килеп керде. Инә белән буе бер, судагы үрдәк төсле як-якка чайкалып йөри торган Әсмабикә—Асяның, һавадан акча ясап, баеп беткәне Сәйфигә мәгълүм иде. Тавышы тук күгәрченнеке шикелле, тамак төбеннән гүләп чыга.

—Фатирыгыз матур икән. Сөбханалла. Тигез гомер итегез. Ничә балагыз? Икәүме? Хуш. Сәйфи, үзеңне бик борчымаска идем дә, кызым икенчегә кияүгә чыга. Беренче туен акча җәлләп, ни ылтара, ни пылтара гына ясаган идем, тормадылар. Монысын гөрләтеп, шаулатып, затлы ресторанда уздырмасам, исемем Әсмабикә булмасын.

Хуҗа бу бай хатын, ниндидер мәкер белән бурычка акча сорарга килгән дип уйлап, кунакның күңелен рәнҗетмәскә тырышып, иплән кенә хәленең хөртиләнеп китүен аңлатырга тырышты.

—Энем, әллә мине әҗәткә акча сорап килгән дип уйлыйсыңмы? Аллам сакласын. Мыскыл итмә, мин андый көнгә калган хатын түгел. Алган бурычыңны бир!

Сәйфи аның сүзләрен шаяртуга, ялгышуга юрап, җитди кабул итмәде.

—Минем сине, Әсмабикә, җаным-ахирәт, ике-өч ел күргәнем юк. Нинди әҗәт турында сүз алып барасың? Усал итеп шаяртасыңмы? Кара юморлы ахырзаман җитәме әллә?

—Синең исемнән Габделгазиз Саубановның ун меңне алып китте. Ике ай элек. Сәйфи үзе кертеп бирер, диде. Көтәм юк, көтәм юк. Аптырагач, үзем килдем.

—Бурычыңны биргән кешеннән сора,—диде Сәйфи, бавырдан күтәрелгән ярсуын авырлык белән тыеп.

—Соң сез бит итәк белән җиң кебек гел бергә йөрдегез. Вәт, акчаны бурычка синең өчен алам дигән распискасы. Барысы да законлы. Миңа кайсыгыз түләсә дә ярый. Ул ата хөрәсәнне каян табасың? Әйдә, Сәйфи, куала ун меңне. Юкса, процент үрләтә башлыйм.

Сәйфинең җен ачулары чыкты.

—Чыгып кит минем өемнән. Бет ачуын туннан алмыйлар.

Ирнең җикеренүенә ханымның иягендәге йоны да селкенмәде.

—Их, Сәйфи, Сәйфи... Үзең акыллы адәмгә охшап торасың. Шалкан чәчеп баеган кешене күргәнең бармы? Башта киңәш-табыш итәргә кирәк иде. Җитә алмасны кума, дип дөрес әйткәннәр. Теге атнада акчага керермен. Әзерләп куй. Эшне судка җиткермик.

Көч-хәл белән бәйләнчек хатынны озатты. Ишекне тагын шакыдылар. Күзчәдән тышка карап, хуҗа имәнеп китте. Ишек төбендә кыска күн курткалардан өч таза ир-егет басып тора иде. Сәйфи бармакларын ике яклап чәченә батырып, «топинамбур» дип кычкырып, диванга ауды. Безнең сүз түгел икән шул. Нигезе «топи»—батыр булырга тиеш. Шуннан соң инде тәпиләп китәсең! Үзең бара алмасаң, тиешле җиргә озатып куярлар.



## Шәүкәт Гаделша

### СЕБЕР ЯГЫ—МОҢ ЯГЫ

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз ятканым бар.
Дулкыннардан, камышлардан, яфраклардан
Ишеттем мин бер үк ачы моң-зар.

Гарлегемнән туфрак чәйнәп, йөрәк кысып,
Ярларында корттай бөгәрләндем.
Куе томан эчләреннән олы көчме,
Нидер көтә-көтә юләрләндем.

Газиз халкым язмышының шаһите—Ай
Ник елмайсын шунда юри генә.
Боекланган, моңсуланган, буйсынып ул
Ачы хакыйкатьнең ирегенә.

Учагымның очкыннары югарыга
Талпына да менми—чыртлап сүнә.
Карый белсәң: күк йөзендә—акылсызлык!!!
Гөрли, ыжгыра ул—ничек кенә!

Моң-зарларны тыңлыйм да мин, күңел елый:
Ия түгелмен күк үз-үземә.
Дан җырларга гына кала Себер
Татарының мәэюс түземенә.

Тәүде, Тубыл, Тура, Иртеш ярларында
Учак ягып бераз ятканым бар.
Сүлпән булды, ахры, учакларым—
Өермәләр килеп капмадылар.

---

Шәүкәт ГАДЕЛША *(1949)—шагыйрь, «Ярык мөгез», «Сөмән кадыйм», «Ядрә тигән» исемле китаплар авторы. Журналыбызда беренче тапкыр басыла. Казанда яши.*

Сукмактагы кортны изсәң,
Җиңү хисе киләме?

Йоклап яткан этка типсәң,
Җиңү хисе киләме?

Себер татарым, кинаям
Җаныңа хуш киләме?

Урманнарың, күлләрең—син
Теләгән киңлектәме?

## Тартар

Иртә, кичен яра иде:
—Алла саклар!
Алла саклар!
Инде менә ишетелми,—
Нигә тынды безнең тартар?

Әллә бер үк авазларны
Кабатлаудан туйдымы ул?
Әллә мине юатырга
Яңа аваз уйлыймы ул?

Сирәгәя башлады бит
Дусларым, безнең дә сафлар.
Кайда тартар? Ник батмый:
—Алла саклар! Алла саклар!

Камышка камыш ышкыла,
Җилсез-нисез ышкыла.
Әйтерсең, яшеренеп яткан
Ат табуны пошкыра.

Шып туктый кайчак очкан кош—
Гүя укка сугыла.
Тозак кылыдай кылтырап
Кояш нуры суына.

Сизә күңелем, әйе, сизә:
Ята монда хәзинә.
Күчемнеңме? Кайсы ханның?
Әйтә алмыйм хәзергә.

Сизсәм дә кайда ятканын,
Теләмим кагылырга:
Иректән мәхрүм халыкның
Ирексез алтыны да.

## Корыган агач

Ботаксыз, чыбык-чабыксыз,
Кунмый кош-кара.
Авыр суламакчы булып
Көчәнеп тора.

Тоям да шул көчәнешне—
Тетрәнеп куям.
Кәүсәне каезлап, тырнап,
Череген коям.

Күктән каен тузыдай ак
Болытлар уза.
Гүя коргаксыган дөнья
Каплары туза.

❦

Башын чуртан судан сонган.
Шулчак бәке никтер туңган

Чуртан ярым чыгып калган,
Чуммый калган. Ник алданган?

Күгенә бак: анда кояш—
Нәкъ бер йотма инде, йотма.

Кемне кызыктырып, әйдәп,
Кемне алдап җирдә тота.

❦

Менә монда болан ауган—
Ята-ята усак булган.
Әнә анда куян яткан—
Ята-ята куак булган.

Үсә каен, нарат, балан,
Күрәм тагын эт шомыртын.
Агач кочып уйланамын:
«Мин, егылсам, ни булырмын?»

Кайчагында карурманда
Шундый татлы ингеримен:
Гүя оҗмах белән тәмут
Арасында мин йөримен.

## Балыкчы хатын

Яшь егет һәм яшь хатын—
Икәү без бер чанада.
Вак усаклык, яшь таллык
Бәсләнә ян-яннарда.

Көндә шундый яктылык!
Җирдә шундый саф аклык!
Язгы хисләр гыйнварга
Керде, ахры, адашып.

Кинәт хатын, дерелдәп,
Мине тартты үзенә.
Иреннәре ашыгып
Тыпырчынды йөземдә.

Шар ачты ул изүен:
—Кил курыкма, кечегәм...
Каты итеп коч мине,
Туңам, җаным, күшегәм...

Ике «ак кыр тавыгы»
Калкып чыкты изүдән;
И, Аллам, нинди сынау
Бәрдең минем йөземә!

Куркытты мөкатдәс сер,
Көтмәгәндә чишелеп,—
Дилбегәгә орынды
Йөрәгемнең тибеше.

Ыргылды ат: туң күлне
Барабанлап чабабыз.
Кайсыбызны үчекләп
Ыңгыраша чанабыз?

Яшь таллар—нәзек таллар
Оялгандай болгана.
Өстә очкан саескан
Кунмак була дугага.

Кал саескан, сәбәп юк
Гайбәтләр таратырга:
—Туң балык,—дип, яшь хатын
Каты төртте артыма.

... Инде менә картаям
Гаеп тоеп үземдә.
Карый алмыйм туп-туры
Хатын-кызлар күзенә.

## Бармы ирләр?

Күк томан эчендә «дөп» тә дөп»,
Тышаулы елкы-елгырлар килә күк.
Ятып та, басып та мин карыйм:
Күрмәмме аларның сыртларын?

Күрмәмме шунда мин берәр ат—
Иярле, кылычлы, чукмарлы...
Җилфердәп килмәсме соңгедә
Кучемнең ак кыллы бунчагы?

«Дөп» тә «дөп»—инде ул бик якын!
Чынлап та ат булса, нишләрмен?
Ничек мин, туктатып, тотармын?
Ничек мин тышавын чишәрмен?

Болгана каршымда күк томан.
Белмимен: артымы, алдымы?
Атларны чүктереп, атланыр
Берәр ир Себердә калдымы?



## Индус Сирматов

# БҮРЕ БАЛАСЫ

хикәя

Тулып килүче ай яктысында куак арасыннан ике күз ялтырады. Ул да булмады, туйра ботакларын чаштырдатып, сукмакка күз иясе үзе дә атылып килеп чыкты. Каушап калган Шәмсегали карт, кулындагы сәнәген селтәп сукранып куйды.

—Нәмә йөрисең тагын кеше куркытып? Бетмәде шул гадәтең, көне буе урык-сурык чабып йөрисең, тик торганда әллә каян пырылдап килеп басасың да йөрәкне аласың.

—Куркуыннан ыштанына җибәрдеңме әллә?

—Теленә салынма! Тот дилбегәңне, бор атыңны, диләр сиңа! Әйләндереп җибәргәнне көтәсеңме әллә?

—Бик батырайма, бабкай! Кайткач, әбекәй үзе дилбегәнне борыр әле—тагын бер бәбкәсе югалган. Бабаң гына куып төшерде күл буена, төшермәгән булса—югалмыйдырые, ди. Былтыр да берсен чуртаннан алдырганые, ди.

Быел да югалуы чын булса, бәбкәсе өчен карчыгыннан ишетәселәр турында уйлана-уйлана, Шәмсегали карт күбәдәге печәннәрне тавышсыз-тынсыз гына арбага төйи башлады. Эһе-һе, булды шул былтыр андый хәл. Каз бәбкәләренең берсен озын күлдә чуртан йотканые. Быел да шул нәләт харап иткәндер. Тотып ашамадылар да, ичмасам, шул чуртанны!

Көндез умарталыкта эше күп булганга Шәмсегали картка печәнне менә шулай төннәрен ашык-пошык кына кайтарырга туры килә. Ярдәмчесе дә юк, ичмасам. Карчыгы Рәхиләнең хуҗалыкта эше тавык чүпләп бетерә торган түгел. Оныгы әле бик кечкенә, көне буе бүре баласы төсле тегендә-монда чабып йөреп, зыян-зәүрәт китерүдән башканы белми. Ярдәмләшү түгел, аның үзе артыннан әби-бабасының күз-колак булып торуы кирәк әле.

---

Индус СИРМАТОВ *(1937)—язучы, журналист. «Еллар шаһит», «Әткәй сәгате», «Ике як иңсәмдә» һ.б. китаплар, иллелэп фильм һәм телеспектакль авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Бабай, печәнен тәяп бетергәч, бастырыгын бәйләмичә генә йөк уртасына ыргытты да оныгын күтәреп бастырык өстенә утыртты.

—Тот дилбегәнне.

Малай дилбегәсен кагуга, тыңлаучан алаша салмак кына урыныннан кузгалды.

—Кайчан югалган? Әбиеннең бәбкәсе дим?

—Бүген инде. Иртән үзен күлгә кугансың бит. Кич кайттылар. Берсе юк. Әбкәй әйтә, бабаңның иманын укытам әле, мал кадерен белми, ди. Үзен дә инде, бабкай, ничә әйттем күлдәге шул чуртанны тотаек, дип. Бәбкәләреңне генә түгел, казларыңны да ашап бетерер әле ул.

—Тот, нигә тотмыйсың соң?!

—Тотарсың, бар! Ничә кармагымны гына алып китте. Былтыр, оясыннан егылып үлгән чыпчык баласы белән салгач, кармак җебемне тәбе-тамыры белән өзеп качты.

—Тал тамырына эләктереп өздергән кармагыңны чуртанга сылтама.

—Чуртан инде, бабкай, чуртан. Җәтмә салырга кирәк аңа. Җәтмәсез пычак та эшләтәлмисең син аны.

Бабай белән оныгы Озын күлдәге шул чуртанны тотарга инде күпме кыҗрап йөрсәләр дә әлегә рәтле эш чыкканы юк иде. Дөресен әйткәндә, Шәмсегали картның чуртан артыннан чабасы килми, моңа вакыты да житми. Умарталыкта болай да эш муеннан. Авылдан биш чакрымнар ераклыктагы умарта аланына яз башында күчеп киләләр дә, көннәр суытып, умарталарны кышкылыкка җайлап урнаштырганчы шунда яшиләр. Умарталардан бушаган арада бабай утының, печәнен хәстәрли. Ә Рәхимә әбинең бөтен вакыты өй янында, мал-туар, кош-корт тирәсендә үтә. Оныклары Хәмиткә генә җәннәт—умарталык белән күл арасында трай тибә, балык каптыра, йомран аулый, җиләк-җимеш, чикләвек җыя, эшсез йөрисең, дип, бабасы тотып пешерсә генә, әбисенә ярдәм итешкән була.

—Бабкай, дим, арба ава бит!

Шәмсегали карт авып бара торган йөген аркасы белән терәтмәкче иде, өлгерми калды. Башта малай шуып төште, аның өстенә бастырык, аннары икесен бергә печән йөге күмеп ташлады. Быел югалган каз бәбкәсе өчен карчыгыннан былтыргыдан да яманрак эләгәсеннән шөлләп кайтучы бабайның хәзер инде башка уйдан коты алынды—бастырык оныгының башын ярмаганмы, билен сындырмаганмы. Ул, булдыра алганча тиз-тиз кыланып, печәнне актара башлады.

—Нәмә чокыйсың анда, бабкай, муен тамырың кычытамыни? Шулчаклы печәнне бастырыгын бәйләмичә алып кайталар димени! Бер эшеннең рәте юк!

—Һи, бүре баласы, син печән астында калмадыңмыни? Җикеренеп торган була бит әле тагын! Берәр җирең авыртмадымы, улым? Бастырык бәрмәдеме, дим?

—Бастырык астында калырга мине дуракка саныйсыңмы әллә. Үзеңне бел! Күрсәтер әле сиңа әбекәй югалган бәбкәң өчен!..—Алар шулай инде, читтән карап торган кешегә бер-берсенә авыр сүз әйтешеп сөйләшәләр кебек тоелса да, күңелләрендә усаллыкның әсәре дә юк. Бу юлы малай тукталып та тормастан бөтенләй икенче тавыш белән сүзен дәвам итте.—Бабкай, дим, әйдә иртәгә иртүк барып тотып кайтабыз шул чуртанны. Әбекәй уянганчы барып җәтмә салыйк та ул уянуга тотып кайтырбыз. Синең җәтмәләрең өчәү бит, өчесен дә салыйк.

Оныгының сүзендә хаклык бар инде анысы. Шәмсегали картның келәтендә өч җәтмә тәреп куелган. Тик алар председательнеке. Авылга олырак кунаклар кайтканда ул аларны умарталыкка алып килә. Күңелләре күтәрелгәч, җәтмә сөйрәп, күлне актарып чыгалар. Табан балыгы тоталар. Кайчакта вак-төяк чуртан, шамбы балалары да эләккәли. Җәтмәләре

ертылып, бер балыксыз калган чаклары да була. Ә жәтмәне ертучы–карт чуртан. Алай түгел дияр иден, аны үз күзләре белән күручеләр бар. Озынлыгы ярты бастырык буе булыр, диләр.

Күручеләр бар, тота алучылар гына юк. Авыл яшьләре мурда салып та карадылар, аулап та–барып чыкмады. Озын күл камышлары төбендә типтереп яши бирә чуртанын. Күлгә ул хужа. Табан балыкларының патшасы да ул. Хәтта күл читендәге тал куаклары, камышлар, түмгәләкләр арасында оя корып бала чыгарган бихисап кыр үрдәкләренең бәбкәләре суга төшкәч, алардан да авыз итә, дип сөйлиләр.

Булса да булыр–былтыр Рәхилә әбинең бәбкәсен шул гына харап итте бит. Шәмсегали карт, әрәмтамаклар өйдә ятмасыннар әле, дип, күлгә куып төшергән иде аларны. Әби, күнеленнән нидер сизенеп, Озын күл янына килсә, күз алдында бер бәбкәсе чырылдый-чырылдый су төбенә төшеп бара. Пырылдап караса да, ата каз коткара алмады бахырны. Ул, башкайларыгыз исән чакта моннан таегыз, дигән сыман муенын сузып, калган бәбкәләрне су читенә куалап чыгарды да юл буена каңгылдап, Шәмсегали картны сүгеп кайтты. Рәхилә әбидән исә ата каздан да ныграк эләкте. Быелгысы өчен инде әбиенә яңа бәбкәләр чыкканчы сүз ризыгы житәчәк.

Шәмсегали карт шуларны уйлый-уйлый печәнен яңадан төягәндә Хәмитнең дә түбәтәй астындагы сырлары кыймылдый иде. Бәлки аның уе барып чыгар әле. Бабасын күндерә алса, белмәссең, шул чуртанны тәүбәгә китерүләре бар. Былтырдан бирле Хәмитнең жанына тынгылык бирми бит инде ул Озын күл патшасы. Олылар аңа ялгызы гына күлдә кармак салырга рөхсәт итә башлагач былтырлы-быеллы ничә кармак кына әрәм итте инде Хәмит чуртан тотам дип. Төпкә эләккән кармагын чыгарам дип үзе суга бата язган чагы да булды. Берсендә баштанаяк ләмгә буялып кайтты. Шул көнне аңа бабасы, бөтен әрәмәне, күл буйларын, камыш араларын бер итеп заяга чабып йөрүләрен, көненә бер зыян эшләми калмавын да искә алып, киямел бүре баласы булдың, дип кушамат такты. Аңа карап кына чуртан барыбер эләкмәде. Хәмитнең дә уеннан китмәде.

Печәнне ишек алдына кайтарып бушаткач, Шәмсегали карт, жәтмәләрне тикшерәбез, дигән булып, оныгын туры келәткә алып керде. Чынында аның бу гамәле, өйгә кереп, Рәхилә әби теленә эләкмәскә тырышудан иде. Бераз күзенә чалынмыйрак йөрсән, эссесе сүрелер, янәсе.

—Әбиең уянганчы, дисенмени улым? Алайса, шушында гына ятып йоклаек та, иртүк торып китәрбез.

Бүре баласы бабасының сүзенә ышанды. Бабасының башында, малай уянганчы умарталыкка чыгып сызармын, төшкә чаклы әбисенен дә төтене сыегаер, дигән хыянәтчел уй барлыгын ул күнеленә дә китермәде.

Алар келәт идәнендәге иске юрган өстенә сузылып яттылар. Малай шунда ук бабасы кочагында эреп йокыга талды. Тик бер арада гына ул кичтән бабасы йөк өстенә ыргыткан бастырыкның печән бастырыгы булмыйча, Озын күлдәге чуртан булуын күреп гажәпләнде. Аны кем кайчан тоткан да печәнлеккә кем алып килгән–малай шунысын гына һич аңламады.

Келәт ишегеннән кергән салкынча һавадан уянып киткәндә Хәмит бабасының мыштым гына капкадан чыгып баруын күреп алды. Бабасы жәтмәләрне алмаган иде. Жәтмәләр өчесе дә үз урыннарында эленеп тора. Ул ихатадан шактый ераклашып баручы бабасын куып житте.

—Бабакай, күзен чыккыры, жәтмәләрне онытып калдыргансың бит!

—Бәй, улым, син дә уяндыңмыни? Без, улым, болай итик, бүгенгә тотмый торыйк әле ул чуртанны. Кортлар бик уйный торган чак, куч аерылып әрәм булмасын, дим. Бүтән вакытта иркенләп тотарбыз. Син бар, әбиең янына кереп ят. Уянгач умарталыкка килерсең. Син бер дә кайгырма, бүген булмаса иртәгә барыбер тотабыз ул чуртанны.

—Син гел шулай инде. Гел алдыйсың, гел мине бала-чага итәсен!

—Кит әле, алты яшьлек егет бала-чага буламыни! Аннан килеп, сине алдарга кем дип белдең мине! Тотабыз булгач тотабыз. Менә умарталыкта гына эшләр җинеләйсен дә.

—Чын, диген, валлаһи, диген. Күзем чыксын менә, диген.

—Кит әле, чуртан өчен ант итәргә монда...

Хәмит бабасына җаваптан бүтән сүз әйтмәде. Аның умарталыкта эш җиңеләйгәнен көтеп торасы да килми иде. Бабасы кузгалып киткәч, ул да кире борылды. Тик өйгә кермәде, күл буена төште.

Тып-тыныч күл өстендә сирәк-мирәк кенә вак балыклар сикерешеп уйнаклый иде. Алар сикереп чыккан урында бер дулкын боҗрасы, чумган җирдә икенче боҗра барлыкка килә дә, боҗралар бергә кушылгач, күл өсте тагын тынычланып кала. Бераздан шул күренеш янадан кабатлана. Тик башка урында.

Шуларны күзәтеп, Хәмит күл ярында озак кына басып торды. Нигә сикерешә икән бу балыклар? Күлдә урын җитми микәнни соң аларга?.. Бабасы әйтә, йөзеп барган җирләреннән күл өстендә очучы чебен-черки, күбәләк ише кортларны күрәләр дә шуны кабып йотарга сикерәләр алар, ди. Әллә малайлар кебек чумып уйнаулары микән?

Кинәт кенә Хәмитнең башына бөтенләй башка бер уй китереп сукты: теге чуртан куадыр аларны, шуннан качып сикерәләрдер вак балыклар. Димәк ки, чуртан да хәзер шушы тирәдә генә булырга тиеш. Тизрәк җәтмәләрне алып килергә дә күлгә батырырга!

Өч җәтмәне берьюлы күтәрә алмаганга Хәмиткә күл белән келәт арасын ике тапкыр урарга туры килде. Җәтмәләрне пар ишкәкле зур көймәгә тутырса, ишеп барырга көче җитмәсен белә иде Хәмит. Шуңа ул аларны юан бүрәнәдән чокып ясаган тагарак-көймәгә салды да, кулына ишкәк хезмәтен үтәүче иске ипи көрәгеп алып, күл уртасына таба кузгалды. Бара-барышлый су өстендә уйнаклаучы балыкларга да күз салгалады. Хәзер алар нигәдер монда түгел, күбрәк күлнең камышлар үсә торган ягында сикерешәләр иде. Чуртан да шунда икән, дип, малай көймәсен камышлар арасынарак борып кертте.

Хәмит җәтмәләрне чишеп зурысының бер канатын күлгә ыргытты. Җәтмәнең кирпеч боҗралар, тимер-томырлар бәйләнгән аскы ягы шунда ук чупырдап суга чумды, такта калкавычлар тагылган ягы күл өстенә йөзеп чыкты, калкавычлар белән бергә быгыр-быгыр килеп күл төбеннән күбекләр күтәрелде. Күлдә агым булмагач, көймә, кайда тукталсаң, шунда тик тора. Хәмит ишкәге белән уңлап-суллап бер-ике тапкыр ишеп ала да җайлап төрелгән җәтмәне суга төшерә бара. Шулай йөзә торгач, зур җәтмә күлдә үз урынын алды. Калкавычлар туп-туры буй булып сузылып ята иде.

Калкавычларга карап торганда Хәмит күл өстендә күк йөзенең көзгедәге кебек чагылышын күреп алды. Аның мондый да матур манзараны беренче генә күрүе түгел иде түгелен. Тик алары яр читеннән карап торганда була иде. Монда ул әллә ничек иркен, колач җитмәслек киң икән, дугаланып тора икән. Хәмит ишкәк очын аз гына суга тигерүгә, бөтен матурлык вак-вак дулкыннар арасына керде дә югалды. Күк йөзенең күл өстендә янадан дугаланып чагылышы килеп чыгуын аңа шактый озак көтәргә туры килде. Тик бу юлы күл көзгесендә ниндидер кара-кора буй-буй сызыклар да чагыла иде. Текәлебрәк карагач, Хәмит ул сызыкларның камыш шәүләләре икәнен аңлады. Һәр камыш шәүләсе кыйгачлап сузыла да күл төбенә төшеп китә иде. Юк, болары шәүлә түгел, камышларның су астындагы сабаклары икән. Көймә кырыеннан карасаң, күл төбе дә аерым-ачык күренә.

Монда шулай сай микәнни, дип уйлап алды Хәмит. Ай-һай, зур чуртан шушындый сай җиргә сыяр микән? Әллә соң җәтмәләрне тирәнгәрәк, күл уртасынарак салыргамы? Әнә бит, вак балыклар да уйнакламый башлады. Чуртан башка урынга күчмәгәндер бит, югыйсә?

Чуртан ул сиңа болын буйлап үлән умырып йөрүче сыер түгел.

Юктыр, ике кечкенә җәтмәне дә зурысы янына ташларга кирәк, аларын салу зурысы кебек мәшәкатьле булмас. Хәмит шундый карарга килсә дә барсы да син теләгәнчә генә барып чыкмый икән шул. Зурысын батырганда болары да чуалган. Хәмит, бер җәтмәнең кайсыдыр канатын көймә койрыгына кагылган агач чөйгә элеп, икенче канатын камыш арасына ыргытты да әкрен генә ишә башлады.

Малай ничаклы гына сак кыланырга тырышса да, җәтмәләрнең рәтенә чыга алмады, икесен берьюлы ташлый башлады. Суга төшкәч, алар үзләре үк рәтләнерләр төсле иде. Менә инде җәтмә канатын чөйдән ычкындырасы гына калды.

Хәмит чөйгә үрелгәндә көймә артыннан нindидер бер озын кара шәүлә выжылдап узгандай тоелды. Шул арада көймә дә кинәт тартылып куйды, йөзүеннән туктады. Хәмитнең коты очты. Чуртанмы әллә бу? Көймә тикле көймәне шып туктатырлык зур чуртан микәнни?! Малайның хәзер үк көймәсен ташлап йөгерәсе килде. Тик нишлисең—су өстеннән йөгереп буламыни! Аннан соң чуртаннан качарга килдемени ул монда, тотарга килде бит ул аны! Җәтмәне чуртаны-ние белән бергә яр буена сөйрәтергә кирәк. Анда күз күрер.

Хәмит ишкәге белән унлап-суллап ишә башлады. Тик көймә кузгалмады, җәтмә бавы гына тагын да ныграк тартылды! Ул да булмады, көймә койрыгы кинәт кенә борылды да, көтелмәгән бу хәлдән тигезлеген югалтып, малай чупылдап суга егылды. Аның белән бергә тагарак көймә дә капланды.

«Батам. Батам да үземне чуртан йота!» Куркудан малай куллары белән әллә нинди хәрәкәтләр ясый башлады, аның авыз-борынына су керде. Үләм икән, дигән куркыныч уйдан Хәмитнең күз аллары карангыланды. Ярый әле шунда бабасының киңәше исенә төште. Су буенда үскән егет батып үлүдән курыкмаска тиеш, андый чакта иң әйбәте—суга чуму, аннан соң калкып чыгасың да тын аласың, дип өйрәткән иде аны бабасы. Бер тапкыр күлнең сай гына җирендә шулай суга батырышып уйнаганнар да иде.

Чуртаннан курыкса да Хәмит күлгә чумды. Башын калкытуга, капланган көймәгә тотынып, аякларын алмаш-тилмәш чапылдата башлады. Көймәгә дә җан керде. Алар икәүләшеп йөзеп киттеләр.

Бераздан Хәмит ярга түгел, күл уртасына таба йөзүен аңлады. Көймәгә утырган булса, аны ишкәк белән боруы берни тормас иде дә, монда борып кара син! Көч житәме соң аңа? Тегеләй дә хәрәкәтләнеп карады Хәмит, болай да. Көймә генә аңа буйсынырга теләмәде, һаман күл уртасына таба йөзүен белде.

Инде, җәтмәләр дә артта калып, күл яры да ераклаша башлагач, Хәмит туктап ял итәргә булды. Их, ичмасам, көймәнең теге башында булсам, ярга чыгар идем, дип уйлады ул, бераз хәл кергәч. Күнеленә килгән яңа уйдан шунда ук үзен-үзе олыларча битәрләп ташлады. Вәт, дурак, көймә читенә ябышып кына теге башына барсам, ярга чыгам бит.

Кешене курку белән шатлык икесе бертөсле каушата. Хәмит тә, шатлыгыннан каударланып, чак кына көймә астына керми калды. Бу куркынычтан котылгач, ул саграк булырга тырышты. Ләкин ул инде бик нык арыган, кичәдән бирле берни ашамаганлыгы да сиздерә иде. Малай аяклары белән өч-дүрт тапкыр чапылдата да ял итә, кузгалып китә дә тагын туктап ял итә. Ул инде үзенең ярга таба йөзгәнен белә, тик, яр әле еракта дип, башын күтәреп карарга курка иде.

Бервакыт көймә лып итеп нәрсәгәдер килеп бәрелде. Бу юлы инде Хәмит башын судан күтәреп карамый булдыра алмады. Карагач күрде— аның көймәсе үзе салган җәтмәләргә килеп төртелгән икән.

Малай көймәне җәтмәләр белән бергә этәргә тырышып караса да, көймә урыннан кузгалмады. Аның ташлы-тимерле җәтмәләрне сөйрәтерлек хәле калмаган иде. Хәмит, көймә читенә тотынып, аның икенче башына

йөзеп килде дә җәтмәне ычкындырмакчы булды. Ләкин тимерләре, ташлары белән су төбендәге агач тамырына эләккән җәтмәне һич кенә дә ычкындыру җае юк иде. Малай үзенә таба тарткан саен җәтмә дә ныграк кирегә тартыла. Күрәсең, ул тамырга бик каты уралган иде.

Хәмит хәлсезләнгән бармаклары белән көймә читенә тотынып күзләрен йомды.

* * *

Шәмсегали карт, әбәткә кайтып оныгының өйдә юклыгын белгәч, келәткә керде. Җәтмәләр күренмәгәч, карчыгына да әйтеп тормыйча, күл буена ашыкты. Йөгерә-атлый барудан аның сулуы капты, аяклары тыңламас булды, йөрәге чабышкы атныкы кебек дөп-дөп тибә иде. Башында бер генә уй: харап иттем баланы, исән булса, бу вакытка чаклы кайтмый калмас иде. Бәйләп куйган урыннарында зур көймәне генә күргәч, аның шомлануы тагын да артты: тагарагы белән кереп баткан. И бала, бала, кайдан гына эзләргә инде синең гәүдәңне.

Бабай, көймә уртасына баскан килеш, сыңар ишкәк белән уңлап-суллап ишә-ишә, күл буйлап, капланган көймәне эзли китте. Капланган тагарак эченә су тулса да бата торган түгел, күренми калмас.

Аңа әллә ни озак барырга туры килмәде. Ул камышлык янында тагарак көймәнең ялтырап яткан төбен күреп алды, утыргычка утырып, ике ишкәкләп бер-ике селтәнүгә килеп тә җитте. Тагарак янында ук җәтмә калкавычлары да йөзә иде.

Су төбен бәгүр белән актарырга—малайны шунсыз табып булмас. Әбисен ярдәмгә чакырып авылга җибәрергә. Шәмсегали карт, шул уй белән су читенә чыккач, тораташ булып катып калды—кайнар комда онгы йоклап ята. Тик нигәдер малайның трусигы гына юк иде.

Җилкәсенә бабасының кулы тиюгә Хәмит уянып күзен ачты. Шәмсегали карт үзенең җебеп төшүен сиздермәскә, кырысрак күренергә тырышып, сүз югында сүз булсын, ата казың күкәй саламы, дигәндәй, сорап куйды.

—Ыштаның кая?

—Камышлыктан йөзеп чыкканда су төбенә төшеп калган бугай.


—«Бугай» белән «дыр» беләсеңме кайда? Алашаның койрык астында. Әйдә, анда әбиең ашарга көтә. Каз бәбкәсен чуртан алган, дигән була бит әле. Нигә алдадың?

—Үзең бармагач...

—И, Улым, синең белән миңа тоттыра торган булса, бозау чаклы булып үскәнче күл төбендә яшәми дә ул!

Ашап-эчеп бераз ял иткәч, бабай белән оныкң, бәгүр күтәреп, яңадан күл буена төпкә эләккән җәтмәләрне чыгарырга килделәр. Тамаша карарга Рәхимә әби дә аларга иярде.

Икәүләп башта зур җәтмәне яр буена тартып чыгардылар. Анда бармак буе гына алтынсу табан балыгы эләккән иде.



## Әдхәт Синугыл

### ТӨРКИ БОЛАКЛАР

**Кырым чишмәләре**

**Чатыр-Дагның түбәсен чалартып,**
**Ел артыннан еллар кичәләр...**
**Иске Кирмән, Кизләү, Учан-Судай**
**Күпме монда талир чишмәләр.**

**Учан-Суның чишмә суын эчеп,**
**Хан атлары ярсып кешнәгән,**
**Су алырга Җидегән чишмәләргә**
**Күпме килен-кызлар төшмәгән.**

**Күпме чишмә, фонтан булып атып,**
**Таулар күкрәкләрен тишмәгән,**
**Ничә йөз мең Тугай бәй[1] атлары**
**Улаклардан сулар эчмәгән.**

**Кырым чишмәләрен саный китсәң,**
**Шәл чуклары кебек чуклаган[2],**
**Кырымдагы моңлы чишмәләрнең**
**Җырын тыңлап, азмы сокланган!**

**Гәүр[3] кулларыннан юкка чыккан**
**Күз яшь түгеп күпме чишмәләр...**
**Бакчасарай чишмәләре дә юк,**
**Сагыш били, искә төшсәләр.**

---

Әдхәт СИНУГЫЛ *(1935)—шагыйрь, публицист; татар, кырымтатар һәм урыс телләрендә дөн[ья] күргән китаплар авторы. Тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Кырымда яши.*

[1]Тугай бәй—Кырым ханлыгы чорында атлы урданың (армиянен) баш командармы.
[2]Чуклаган (Кырым татар)—күпләгән.
[3]Гәүр—кяфер.

## Тере мәет

*(Кушма)*

*Юныс Кандымга тәкълид*

**Мин сәхрәдә җирләнгән мәет күрдем,**
**Аны тоеп чулый чүлдә капланнар,**
**Каберенә яшь яңгырын түктердем,**
**Җеназасын укып чыңлый шоңкарлар.**

**Йөрәк газабын аркылы-буй кичтем,**
**Кайгы-хәсрәт җилләре булып истем,**
**Мин дә мәет, тәмам өметем кистем,**
**Баш очымда ялт-йолт уйный балталар.**

**Кабер кыса, мин торырга омтылам,**
**Киң даламдай киерелергә тотынам,**
**Гүр иләндә дер калтырыйм салкыннан,**
**Күз яшьләрем туңып, боздай каталар.**

**Тәндә җан юк, сүнгән шәмдәй йөрәгем,**
**Кемгә хәзер минем бар соң кирәгем...**
**Таянычым булыр ауган терәгем,**
**Сарып алган дүрт тарафым шайтаннар.**

**Төпсез упкын төпсез уйлар тудыра,**
**Җан ачысы давыл-буран туздыра,**
**Ярсу дулкын Тау күчерер тоела.**
**Кабер ташым алып юлга атканнар!**

**Тел тотлыга, мием кайный и, Кандым,**
**Яшен уйнап, Ил күге түгә каным;**
**Мәет булма, кил ат чаптырып, Аңым,**
**Мәйданда чын ирләр канга батканнар!**

*Февраль, 1977*
*Акмәчет.*

## «Кайгы Анасы»

**Стәрлебаш авыл бакчасында**
**Һәйкәл булган «Кайгы Анасы»...**
**Сугышларда үлеп, һәлак булган**
**Бар корбаннар—аның баласы.**

---

(Кушма) азәрбайҗан телендә «гошма»)—«Әдәбият белеме сүзлеге»ндә (Казан, 1990) язылганча, «... Һәр юлы 11 иҗекле строфа формасы. Гошма 5 строфалы дүртьюллыклардан тора... Гошмада шигъри юллар саны 20 дән артмаска тиеш»,—диелгән. Ләкин, «Кушма»да шигъри юллар саны 40 ка кадәр дә җитүе мөмкин. Моны, мәсәлән, XVII гасыр азәрбайҗан поэзиясе классигы Молла Пәнаһ Вагиф иҗатыннан да күреп була. «Кушма»ларда кафияләр беренче строфада—а б а б, калганнарында исә—а а а б, г г г б, д д д б, с с с б һәм аннан соң да шул эзлеклелектә дәвам итә. *(Искәрмә: Урта гасыр азәрбайҗан шагыйре Ашыг Әләскар вә XVII йөз кырымтатар классигы Гашыйк Гомәр иҗаты мирасларына күз сал. Ә. С.).*

Бураннар да, койма яңгырлар да
Юа алмый кайгы ярасын,
Эче-тышы тоташ ялкын аның,
Хәсрәт баскан Кайгы Анасын.

Үз кайгысын эчтән генә йотып,
Өзгәләнә йөрәк пәрәсе,
Кайгыларын берни баса алмый,
Һич табылмый дәва чарасы.

Ел артыннан шаулап еллар үтәр,
Кайгы гына микән тик үтәр?..
Сугыш чәчкән матәм кайгылары
Күпме Ана йөрәген өтәр.

Өтәр! Өтәр! Кан коюлар җитәр!—
Дип әйтегез бердәм, Аналар!—
Яшәү белән Сугыш дуслашалмый,
Сугыш өчен тумый балалар!—

Дип әйтмисез ник, бар Аналар?!

Стәрлебаш авыл бакчасында
Бер һәйкәл бар: «Кайгы Анасы»,
Сугышлардан урап кайталмаган
Сугыш корбаннары—баласы.

Хәсрәт уты капкан йөрәгендә
Тоз сипкәндәй әрни ярасы,
Сугыш утын кабызучыларга
Ләгънәт укый солдат Анасы.

Күзгә карап бездән ялвара ул—
Кабынмавын сугыш, яңасы...
Сугыш кырларында һәлак булган
Бар корбаннар Аның баласы.

*Сентябрь, 2001*
*Стәрлебаш.*

Көне-төне көрәшеп, Сүз күпме эш эшли,
Кемдер сүзен кемнәр ега, кемнәрдер екмый...
Уй диңгезем шәрран ачык, нәкъ кәрвансарай,
Кемнәр генә кереп, аннан кемнәр тик чыкмый.

Әйт, кем әйтер начар дип тормышлар алай,
Майлагандай эш бара тәгәрәп уңай...
Күп урлап кем караклыкта тотылмаган,
Булды куйды хәзер инде иң бай, малай!

Татармы син—уклар булсаң атар миңа?
Якламаган татарын—җиде ят миңа.
Син атмасаң, кем җанатар татарыма?
Үз татарын сөйгән генә татар миңа.

Болгарда—Болгарны эзләп,
Азмыни адашканнар...
Ике татар бергә килеп,
Баш бирми талашканнар.

Тумыштан ук милләтеңнең
Исеме булса «татар»,
Татар өчен киң дөньялар
Ләхеттән дә хәтта тар!

*Май, 1997.*
*Ташкент.*

## Яралы былбыл

Ник син, былбыл, бу кадәр дә моңсу икәнсең,
Таң җилләре җилбер-җилбер җилеп искәндә.
Ник син минем күңел кылын чиртеп-чиртәсең,
Йөрәгемә тигән уклар телеп кискәндәй.

Әллә берәр зәһәр елан юкса уклары
Тәннәреңне рәнҗетеп синең чактымы?
Әллә берәр хыянәтче мордар актыгы
Үз ояңнан сине тышка йолып аттымы?

Әллә сине, гонаһсызга, күзен тондырып,
Кырагай бер ач җанвардай үлем көтәме?
Әллә бәллүр каның коеп карын туйдырып,
Кара козгын җаның тәслим синең итәме?

Күз яшь түкмә, җәсүр кошым, бераз сабыр бул,
Офык йөзен нурга манып ал таң атачак.
Киң мәйданга уктай беркөн атылып бер кул,
Кыргый җанның үзенең дә җанын алачак.

Менә шулчак көр авазга җырың җырларсың,
Азатлыкның, гаделлекнең шанлы җырларын...
Таң нурлары белән торып сазың сузарсың,
Туган якның мактап туймый болын-кырларын.

Төзәләчәк синең шулчак, беләм, яраң да,
Ишеләчәк тәхетләрнең золым ярлары.
Савыгачак иртә-соңмы былбыл, яраннар,
Йөрәк кенә булмасын тик, йөрәк—яралы.

*Октябрь, 1999*
*Кырым*

# Таңчулпан

## МӘҢГЕЛЕКНЕҢ ЙӨРӘГЕ

Бала табу йорты.
Төнне ярып
Аваз салды яңа туган сабый.
Шул сабыйның тәүге авазыннан
Тулган шатлык, минем җанга сыймый,
Бәреп чыга тозлы яшь булып...

Мин дә көтәм,
Керфек какмый көтәм
Сабыемның туар мизгелен.
Карынымда яткан нәниемнең
Һәрбер хәрәкәте сизелә.
И дулаган була...
Ашкынамы
Якты дөнья йөзен күрергә?—
Хыялымда
Ак бантиклы кызым
Яшел болын буйлап йөгерә...

И сабыем минем,
Бу дөньяга
Бәхетле җан булып тусаңчы.
Мәхәббәтле булып, өебезнең
Кояшы һәм ае булсаңчы.
И сабыем минем,
Көтелгәнем,
Ходаемның олуг бүләге...

Яңа туган сабый елавында
Икән
Мәңгелекнең йөрәге!

## Ана сөте

Шөкер, Аллам,
Сабыема
Ризык булды ана сөте.
Сөтем белән керсен аңа
Бу тормышта яшәү суты.
Тәнкәенә бирсен куәт,
Күңеленә игелек иңсен.
Акыл-зиһен иясе бул,
Саф җаныңа иман сеңсен.
Хәләл ризык иясе бул,
Эчәр суың булсын илдә,

Мәхәббәт һәм мәрхәмәт тә
Керсен сиңа сөтем илә.
Ана сөте ризык булды—
Ана теле булсын телең,
Ата-бабалардан калган
Мөселманлык булсын динең.
Күкрәк сөтем хәләл булсын,
Үс син, балам, татлы алмам.
Синнән туар сабыйга да
Ана сөте булсын тәгам.

---

ТАҢЧУЛПАН— *шагыйрә, «Кыргый чәчәк» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Җиде ятлар «иң кадерле» була,
Иң кадерле кала ят булып...
Бер җаныма таба алмыйм урын,
Алып китсәң иде, ак болыт.

Җиде ятлар «иң кадерле» була,
Сөйгән кешең була, табынган.
Җүләрмендер, фәкать сөю ага
Кан йөрергә тиеш тамырда.

Мин генәме икән исәр заттан
Һәм табынган чит-ят берәүгә?
Йә, бер Аллам, кичер хаталансам,
Сөям кебек аны—биләүдән.

Шул җиде ят «иң кадерле» миңа,
Үткәннәрем калды ят булып.
Ак бәхете булып килим аңа—
Коендырчы мине, ак болыт.
Җаным-тәнем калсын пакь булып.

## Рәсем

Ир асылы—табынганым,
Шашып-шашып сагынганым,
Язмышымны урап үткән,
Ялгызыма языйганым.

Гаярь җанлы арысланым,
Ярсып билен алышканым,
Әле кырыс, әле уйчан—
Мәңге чишмәс табышмагым.

## Дусларым

*Йөз сум акчаң булганчы,*
*Йөз дустың булсачы.*

Халык мәкале

Озак очтым, талды канатым,
Тау-ташларга бәреп канаттым.
Дуслар шул чак канат булдылар,
Хыялыма илтеп куйдылар.

Диңгез уртасында ялгызым,
Дулкыннарга елап ялындым.
Килде көймә туган җирләрдән—
Дуслар миңа җилкән җибәргән.

Сахра кебек иде күңелем,
Кайнар комга беттем күмелеп.

Тамды тамчы җанга дым булып—
Атап миңа килде бер болыт.

Күзге җилдә торам күшегеп,
Ямьсез сүздән рухым төшереп.
Дуслар янә терәк булдылар—
Минем җырны җырлап уздылар.

Йөзгә тулмаса да саннары,
Дусларымны тормыш сынады...
Булмасам да үзем әлләкем—
Дусларымны сайлый белгәнмен!

# Афзал Шамов

# ГОМЕРЕМ ТАҢЫНДА

АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬ

## I

Көз кереп, салкыннар башлану белән өйдә мине сабакка бирү турында сөйләштергәли башладылар. Кечкенә идем әле: алтыда гына. Укысын, белем алсын дип түгел, ә өйдә, аяк астында буталып йөрмәсен, колагыбыз бераз тынып торсын дип кенә бирергә теләделәр булса кирәк.

Белмим, мине сабакка биреп кенә өйдәгеләрнең колаклары тынармы икән? Чөнки өйдә миннән башка да бала-чага житәрлек. Икесе бишектә: берсе сеңлем, икенчесе дәү абый улы. Алар нигәдер алмаш-тилмәш елыйлар. Берсе туктаса, икенчесе шундук, авызын бөрештереп, кычкырып елап жибәрә. Аларны имезлек каптырып кына туктатырга була, башка берничек тә тынычландыра алмыйлар. Елыйлар да, елыйлар. Хәер, алмаш-тилмәш кенә түгел, кайчак икәү бергә кычкырып елап жибәрәләр. Андый чакларда әбиебез, куллары белән колакларын томалап, ак якка, бабай янына чыгып китә. Без дә, аннан күреп, колакларыбызны томалаган булабыз, имеш, елаган тавышларына түзә алмыйбыз.

«Без» дигәнем—ике апам белән бер энем, бер сеңлем. Сеңлем әле тәпи йөри генә башлаган. Ул да бишектәге балалар хорына еш кына кушыла. Кайчак алар өчәүләп шундый тавыш күтәрәләр,—мондый вакытта инде әбием генә түгел, ян сәке буенда, тәрәзә каршында итек тегеп, итек ямап утыручы абыйлар да, бу тавышка түзә алмыйча, эшләрен ташлап өйдән чыгып китәләр. Кыскасы, минем сабакка йөрүем белән генә өй эче тынып торыр дип уйламыйм.

Кайчак бу «музыкантлар» аркасында әбиемнән әнигә дә, абжингигә[1] дә эләгә:

—Балаларыгызны нигә елатасыз?! Нигә карамыйсыз?!—ди ул аларга. Моны ул шундый ачуланып әйтә, әни белән абжинги телсез калалар. Әйтерсең, алар елата. Гажәп, әбиебез шуны да белми. Күреп тора лабаса. Елаклар ич алар. Шуңа елыйлар. Кайчакларда төнлә дә, көндез дә үзлексез

[1]Абжинги—абыз жиңги.

елыйлар. Берәү дә тимәгәндә, тик торганда да, чәрелдәп елап җибәрәләр. Елаклары бу кадәр каян чыга торгандыр!

Әни белән абҗингине кызганам мин. Бигрәк тә әнине кызганам. Мескеннәр, бала тавышын ишетсәләр, кайда гына булмасыннар—тышта, терлек-туар тирәсендә йөриләрме, әллә почмакта, казан тирәсендә маташалармы, барыбер шундук кулларындагы эшләрен ташлап, алар янына йөгереп киләләр, юешләнгән булса, чүпрәкләрен алыштыралар, йә коры ягына әйләндереп салалар, тирбәтәләр, авызларыннан төшкән имезлекләрен төкереп каптыралар. Алай да тынычландыра алмасалар, кулларына алалар, имезәләр, юаталар, ягымлы сүзләр әйтәләр.

Бу елак капчыклары өчен әбидән безгә дә эләккәли. «Нигә карамыйсыз, нигә тирбәтмисез?»—ди ул безгә. Без еламасыннар, тавышлары чыкмасын дип, кабык бишекләрне бик тырышып тирбәтәбез. Әни белән абҗинги күрмәгәндә шулкадәр тырышабыз, шулкадәр каты тирбәтәбез, мескен бәбиләр бишектән чак егылып төшмиләр. Бусы инде иң соңгы чиктә, тәмам аптырагач, йөдәгәч, урамга чыгасыбыз бик килгәч. Еламасыннар, нигә елыйлар! Үзләре тәпи йөри белмиләр, урамга чыга алмыйлар икән, минем чыгасым, уйныйсым килмимени? Бу кадәр аңсыз да булырлар икән!

Ишегалдында инде мине әллә кайчаннан бирле Актырнак көтә.

Хәер, кайчакларда без бишектәге сеңелләребезне бик теләп тирбәтәбез. Моның өчен безгә абҗинги манный пешергән кружканы кырырга, яларга бирә. Чиратлап бирә ул аны безгә: бер көнне—бер апага, икенче көнне—икенче апага, ә өченче көнне—миңа. Манные әллә ни күп калмый калуын. Шулай да бик тырышып кырсаң, бер бал кашыгы чамасында чыга. Төбе, иң тәмлесе.

Манный боткасын казан астындагы учакта, калай кружкада пешерәләр. Ярмасын, бик кадерләп, кашык очы белән генә салалар. Бик кадерле ул манный ярмасы. Аны, акча биреп, сатып алырга кирәк. Кечкенә чакта миңа дөньяда манный боткасыннан да тәмле нәрсә юктыр шикелле тоела иде. Хәлле булсак та, безгә бала чагыбызда манный боткасын пешереп ашатканнарын хәтерләмим.

Сабакка мине, барыннан бигрәк, әбинең йөртәсе килә:

—Йөрсен, күнегә торсын,—ди.—Укырга иртә кергән бала тырыш була.

Бабайның ул чаклы рөхсәт бирәсе килми.

—Алтыда гына бит әле,—ди ул минем турыда.—Нигә шулкадәр иртә миен чертергә? Бераз үссен... Аннары да өлгерер...

Мин әле ми чертүнең ни икәнен аңламыйм. Ми дигән нәрсәне күргәнем юк.

Әни инде киндер кисәгеннән букча да тегеп куйды. Дөрес, яңа киндердән түгел, иске киндердән. Элек алъяпкыч булганмы шунда, сөлгеме—белмим. Кыскасы, тотылган киндердән. Миңа дигән букчаны иске киндердән теккәнгә бераз чәбәләнеп, тыпырчынып карасам да, үпкәләвемнең урынсыз икәнен бик тиз төшендем. Әни миңа букчамны бик мактады:

—Иске киндердән теккән букча белән йөргән бала сабагын яхшы белә,—диде.—Аны хәлфәсе дә ярата. Суктырмый да, кыйнамый да.

Әнинең сүзе дөрес булса кирәк. Безнең әни беркайчан ялганламый, һәрвакыт дөресен сөйли.

Әтинең иң кече энесе Галәтдин абыйга, ягъни Кечкенә абыйга, һәр елны яңа киндердән букча тегәләр. Шуңа күрә ул сабагын белми. Зурлар аны еш кына орышалар:

—Нигә бу кадәр миңгерәү булдың икән син?!—диләр.—Нигә сабагыңны белмисең, нигә тырышмыйсың икән?! Күрмисеңмени, яшьтәшләреңнән һәммәсе «Коръән»не су урынына эчәләр. Ә син «Ясин» белән «Тәбарәк» сүрәләрен дә ятлап бетерә алмыйсың. Ничә ел инде шулардан уза алмыйсың... Йә Алла, бу кадәр миңгерәү сарык булырсың икән!..

Сарык?.. Абый нигә сарык булсын. Кеше ич ул абый, кеше! Яхшы кеше!

Бигрәк тә аны табын янында, ашаганда орышалар. Белмим, нигә табын янында орыша торганнардыр?! Әллә инде аш белән бергә аңа акыл кертергә дә уйлыйлармы икән? Хәер, аның өчен түгелдер. Башка вакыт орышсалар, абый аларны тыңлап тормый, бишмәте белән бүреген ала да урамга чыгып китә. Моңа өйдәгеләрнең ачулары бик килә. Ул чыгып киткәч тә орышуларыннан туктамыйлар. Нихәтле орышсалар да, абый аларның сүзләрен ишетми, ишегалдында Актырнак белән уйный, аны төрле һөнәргә өйрәтә.

Табын янында орышканда исә абый урыныннан кузгала алмый. Ул, аякларын ипләп кенә бөкләп, түр башына, тәрәзә янына менеп утырган, кулында бизәге кырылган китек агач кашык, ә табын уртасында–зур аш табагы. Анардан бөркелеп, хуш ис таратып пар чыгып тора. Абый кулындагы кашыгын табак белән авызы арасында бик тиз йөртә, чумарның иң зурларын, тәмлеләрен эләктерә, табак төбе күренмичә, аш ашалып бетмичә, урыныннан кузгалмый. Кузгалса, табындагы чумардан бер нәрсә калмый. Башкалар аны шундук ашап бетерәләр. Менә шуңа күрә ул, ашны ташлап, ишегалдына чыгып китә алмый, бер сүз дә әйтмичә, карышмыйча, ашый бирә.

Кай көннәрдә абый мәдрәсәдән бик күңелсезләнеп кайта, беркем белән сөйләшми, кашларын җыерып тик йөри, хәтта мәче белән дә уйнамый. Шундый көннәрнең берендә ул әни янына почмакка керде дә, күк киндер күлмәген күтәреп, аркасын ачып күрсәтте. Аркасында камчы эзләре, кара янып, буй-буй сузылып ята иде. Әни, моны күреп, кызгануыннан:

—Ай, Аллам! Нишләттеләр сине?!—дип кычкырып җибәрде, кулындагы эшен дә куйды.—Баланы шулай суктырырга ярыймыни?! Әй, аларны... Кансыз да булырлар икән!..

Аны сабагын белмәгән өчен дә, намазга бармаган өчен дә суктырганнар икән. Ул көнне хәлфәнең нигәдер кәефе киткән булган, шуна күрә җомга намазына бармаган әллә никадәр баланы яткырып камчы белән суктырган. Әни тыштан каз мае алып керде дә, башкалар ишетмәсен дип, авыз эченнән генә пышылдап юата-юата, аның ярасына сөртте. Әни кызгана аны, бик кызгана. Һәрвакыт яклый, аңа сүз әйттермәскә тырыша. Кызганмаса, абый аңа аркасын ачып күрсәтмәс иде. Башкаларга күрсәтми ул, хәтта әбигә дә.

Бу юлы да аркасы турында абый берәүгә дә әйтмәскә кушты.

Камчы эзләрен күргәч, минем дә йөрәгем «жу» итеп китте, хәтта аркам да сызлый башлады кебек. Мин дә бит тиздән шул мәдрәсәгә барасы малай. Кем белә, бәлки, мине дә шулай суктырырлар.

Әни мине тынычландыра:

—Сине суктырмаслар,—ди.—Хәтта сиңа чәнчә бармак белән дә чиртмәсләр, сабагыңны белерсең син, яхшы укырсың,—ди.

Белермен шул. Әни бит миңа букчаны иске киндердән текте. Иске киндердән теккән букча белән йөрүче балалар сабакларын яхшы укыйлар.

Әни абыйны да юата, тынычландырырга тели:

—Хәлфә суккан җир тәмугта янмый,—ди.

Димәк, абыйның аркасы тәмуг утында беркайчан янмаячак! Моны белми идем әле мин. Алайса, суктырсалар да ярый икән. Шулай да суктыртасым килми, берәүдән дә—мулладан да, әтидән дә суктырасым килми минем. Тәмуг әле ул еракта, әллә кайда, теге дөньяда, ә аркам монда, күлмәк астында гына. Тәмуг әллә бар, әллә юк. Әти шулай, ди.

Сабагын белмәсә дә, абыемның кулыннан эш килә. Уенчыклар ясарга оста ул. Кулына берәр такта кисәге эләксә, шуннан хәзер бер уенчык ясап ташлый: сука да, чана да, арба да ясый. Әмма миңа барыннан да бигрәк, ул ясаган җил тегермәне ошый. Андый-мондый гына түгел, әкәмәт тегермән. Такта яручылары да бар. Җил чыгып, тегермән канатлары

әйләнә башлау белән үк,бүрекле-чикмәнле ике кеше хәрәкәткә килә: кулларын бер күтәреп, бер төшереп, аркылы пычкы белән такта ярырга тотыналар, жил көчәйгән саен, кызурак эшлиләр.

Шундый тегермәннең берсе—капка башында. Аңа узган-барганнар кызыксынып карыйлар:

—Тәмам кеше сыман бит,—диләр,—бүрекләре дә, чикмәннәре дә бар. Әкәмәт!..

Җәй көннәрендә ул миңа да жил тегермәне ясап бирә. Такта яручылары булган тегермән түгел,—мондыйны гына, кечкенәне генә. Аны күтәреп, йә ишегалдында, йә урамда чабып йөрим. Чабам, ә таяк башындагы тегермән канатлары шылтыр-шылтыр килә, әйләнә, бөтерелә, тоташ бер түгәрәккә әверелә.

Абый мәче белән этне дә төрле һөнәргә өйрәтә.

Актырнак атлы этебез бар безнең. Ялтырап торган куе кара йонлы, чыннан да, ак тырнаклы эт. Абый аны бик ярата. Ишегалдына чыкса, гел шуның белән уйный. Эт, аны күрү белән атылып, чабып килә дә аның янында бөтерелергә, сикергәләргә тотына, кулын ялаштыргалап ала, ә кайчак, алгы аякларын абый күкрәгенә куеп, битен дә ялый. Абый ачуланмый, көлә генә. Аннары абый, башыннан мескен бүреген салып, каерылып, аны бер читкә ыргыта. Актырнак шундук, атылып барып, бүрекне алып килеп бирә. Шуннан соң абый кулын кесәсенә тыга, нәрсәдер эзләгән сыман була. Эт, моны күргәч, алгы аякларын күтәреп, арткы аякларына баса, колакларын торгыза, күзләре уттай яна. Шатлыгыннан бер-ике тапкыр өреп тә куя. Абый аңа ипи кисәге яисә бирәр сөяк бирә. Ипине эт шундук чәйнәп йота да, тагын бирмәсме икән дип, койрыгын селкеп, карап тора, ә сөякне, бер читкә алып китеп кимерә. Кыш көннәрендә абый аны жигеп тә йөри. Тау шуа торган чанага жигә ул аны. Актырнак, абыйны тартып, ишек алдының бер башыннан икенче башына чаба. Без дә, бала-чагалар, аның артыннан калышмаска тырышып, йөгерәбез. Яхшы ул безнең абый, утырта, чанасын кызганмый.

Эт жигелгән чанага утырып йөрүдән дә кызык, рәхәт нәрсә бармы икән дөньяда! Чанага сузылып ятасың да, кулларың белән үрәчәгә чатырдатып ябышасың. Абый эткә сызгырып жибәрә. Актырнак, аның сүзен тыңлап, сөяк яисә ипи бирер дип өметләнеп, чананы тарткан килеш ишек алдының аргы башыннан чабып әйләнеп кайта. Шулкадәр каты чаба ул, юл өстендә жим эзләп, актарынып йөргән тавыклар, куркып, пырылдашып, бер читкә очалар, канат жилләре биткә килеп бәрелә. Сарыклар бер өемгә тупланып, башларын күтәргән килеш сиңа гаҗәпләнеп карап калалар, хәтта акбаш тана да гаҗәпләнеп карый, тик сыерның гына исе китми, салам өстенә яткан килеш күшәвен белә. Актырнак исә, бернәрсәгә карамыйча, сине жилдәй очыртып алып бара.

Рәхәт тә соң этле чанага утырып йөрүе!

Сабактан кайтканнан соң, абый кайчак өйдә мәче белән уйный, аны бергә кушырып тоткан ике кул аша да, идәннән берничә карыш югары күтәреп тоткан таяк аша да сикереп чыгарга өйрәтә. Сикермәсә, колагына чиртә. Мәченең бер дә колагына чирттерәсе килми, абый сүзен тыңлый, таяк өстеннән дә, кыршау сыман итеп кушырып тоткан куллары өстеннән дә сикереп чыга.

Миңа барыннан да бигрәк, мәчебезнең «кар күрәргә чыгуы» ошый. Мин аның бу һөнәрен һәр юлы бик кызыксынып карап торам, көләм.

Абый шүрлектән ипи пычагын ала да теп-текә итеп идәнгә кадый. Шуннан соң, мәчене тотып килеп, пычак янына бастыра, аңа ачуланып бармак яный. Мәче, куркып, бик шикләнеп, абыйга карап ала да, аның кыйнамый, ә бары яный гына икәнен күргәч, ярар инде алайса, синеңчә булсын дигән сыман, алгы аякларының берсен пычак киртенә, икенчесен пычак сабы өстенә куеп, тынып кала, ияге белән таяна, берникадәр вакыт шулай урыныннан кузгалмый тора.

Абый, аңа көлеп карап:

—Гапсаттар абзый кар күрәргә чыккан,—ди.

Без дә аның артыннан бу сүзне кабатлыйбыз, көләбез.

Чыннан да, ул нәрсәсе беләндер Гапсаттар абзыйны хәтерләтә, дөресрәге, без абый әйткән сүзгә ышанып, бала акылыбыз белән аны шулай итеп күзалдына китерәбез.

Гапсаттар абзый—безнең күрше, Насыйх исемле дустымның әтисе, абыйларның әйтүләренә караганда, авылдагы иң аз сүзле кешеләрнең берсе. Кыш көннәрендә ул кар яуса да, яумаса да һәр көнне иртән, көрәге белән себеркесен күтәреп, урамга чыга да капка төбен бик пөхтәләп себерә, ә кар яуган булса, ашыкмыйча гына көри, бер читкә тау шикелле итеп өеп куя, аннары, эшен тәмамлагач, арып булса кирәк, ике кулы белән көрәгенә таянып, ияген куллары өстенә куеп, уйланып басып тора. Узган-барганнар аңа сәлам бирәләр, эндәшеп китәләр, ул барысының да сәламен ала, берсен дә алмый калдырмый. Кычкырып түгел, ә чал кергән сакалын селкетеп кенә ала.

Мәчебезнең пычакка таянып, уйланып басып торышы да аңа охшый кебек. Бәлки, охшамый да торгандыр, бәлки, безгә генә шулай тоеладыр. Ничек кенә булмасын, безгә кызык, без чыркылдашып көләбез.

Авылыбыздагы мәдрәсә көз көне, аяк асты каткач, салкыннар башлангач ачыла. Аңа кадәр ул тәрәзәләре кадакланган, ишеге бикләнгән килеш мулла абзыйлар тыкрыгында япа-ялгыз моңсу гына, күңелсез генә булып утыра. Коймасы-фәләне юк, болдыры туп-туры тыкрыкка чыга. Әйләнә-тирәсендәге алабуталар, кычытканнар, тигәнәкләр арасында тирә-күрше тавыклары чүпләнеп йөри, басмалары җимерелгән, чалшайган болдырында кояшлы көннәрдә хәйләкәр кәҗәләр кабыргаларын җылытып яталар, ашыкмый гына, эре генә нәрсәдер күшиләр, узган-барганнарга күз кырыйлары белән генә карап калалар. Урыннары тыныч. Мәдрәсә ачылганчы, болдырга алар хуҗа, алар баш. Берәү дә аларны аннан кумый, тик хуҗалары куып кайтырга килгәч кенә, яисә инде үзләре: «житәр инде, күп яттык, өйгә кайтып күренергә дә кирәк ләбаса»,—дигән шикелле урыннарыннан ялкау гына торалар, киереләләр һәм, болдыр идәненә кара «чикләвекләрен» сибеп калдырып, тоякларын шыртлатып баса-баса тыкрык буйлап горур гына китәләр.

Мәдрәсә ишеге ачылганчы укучы балалар иректә. Зурлары йорт һәм ындыр тирәсендә әти-әниләренә булышалар, ә кечкенәләре иртәдән алып кичкә кадәр урамда уйнап йөриләр... Хәер, кечкенәләргә дә эш житәрлек, йомышка йөгерү, бала тирбәтү, терлекләрне, тавык-чебешләрне караганда булышу, йә тегесен, йә бусын алып килү, кул астына керү... Барысы да эш.

Хәзергә әле абый мәдрәсәгә үзе генә йөри. Мине кар яугач үзе белән бергә алып барачак. Шуңа күрә мин һәр көнне кар яуганны көтәм, йокымнан уяну белән үк тәрәзә янына барам, урамга карыйм. Инде жир каткан, көннәр салкынайган: яфракларын койган шәрә агачлар, ачы жилләргә түзә алмыйча, сыгылалар, бөгеләләр, аннары, гайрәтләнеп, көч жыеп, янадан үз хәлләренә кайталар. Җил ыжгырып, сызгырып, янадан килеп бәрелә, янадан сыга... Ә кар һаман яумый. Мин әнине дә, абыйны да аптыратам:

—Кайчан кар ява инде?!. Нигә яумый ул?.. Әллә быел бөтенләй яумаска булганмы?..—дим.

Минем дә дәү малайлар шикелле букча күтәреп, мәдрәсәгә йөрисем, шәкерт буласым килә. Шәкерт булу—зур булу белән бер иде мина. Ә минем зур буласым бик килә иде.

## II

Ниһаять, бер көнне мин йокыдан уянганда кар яуган, бөтен дөньяны каплаган иде. Урам да, ишек алды да, өй түбәләре дә, каралты башлары да ап-ак.

Моны күреп, мин шатлыгымнан кычкырып җибәрдем:

—Кар яуган, кар!.. Мәдрәсәгә барам!..

Өстемә киенеп тормыйча, башыма кәлләне[1] эләктереп, шунда ук ишек алдына яланаяк йөгереп чыгып киттем, шатлыгымнан кычкыра-кычкыра, кар ерып, чабып йөгерергә, сикерергә, биергә тотындым. Ишек алдында шулай туйганчы чабып йөргәннән соң, урамга чыгып, тиз генә мәдрәсә яныннан да әйләнеп кайтырга уйлаган идем, шул ният белән бәләкәй капканы да ача башлаган идем, ләкин, кызганычка каршы, ак өйдән бабай карап тора икән. Ул, бик ачуланып, тәрәзәне шакылдатты, нәрсәдер әйтеп, бармак янады. Бабайны яхшы беләм мин. Аның сүзен тыңламыйча ярамый! Сүз тыңламаганны бер дә яратмый ул... Кесәсендә пәкесе бар аның. Ак сөяк саплы, үткен пәке. Ә урамда, капка төбендә, яшь өянкеләр үсеп тора. Һәр өянкедә әллә никадәр ботак, әллә никадәр чыбык. Бабай кесәсеннән әлеге ак саплы, үткен пәкесен чыгара да шул чыбыкларның берсен, бик иплесен кисеп ала... Юк, бабайның сүзен тыңламыйча ярамый. Һич тә ярамый!.. Мин тиз генә өйгә кердем дә, берәүгә бер сүз әйтмичә, эндәшмичә, мәче шикелле, шыпырт кына мич башына менеп киттем, киптерергә куйган итекләр, утын пүләннәре артына постым. Бабай күрмәсен!

Мич башы җылы, рәхәт. Аякларым ут кебек яна.

Кечкенә абый мине шул көнне үк мәдрәсәгә алып китте.

Мәдрәсәгә минем беренче баруым түгел. Моңа чаклы анда Кечкенә абый белән дә, күрше малайлары белән дә барганым бар. Әмма сабак укырга баруым беренче тапкыр.

Авылыбызда ике мәхәллә иде безнең: карт мулла һәм яшь мулла мәхәлләсе. Икесендә дә мәдрәсә бар. Икесендә дә кадимчә укыталар.

Безнең йорт карт мулла мәхәлләсендә. Шулай булгач, мин дә карт мулла мәхәлләсендә укырга тиеш.

Безнең мулла—Вафа Минкин—кырык яшенә кадәр Бохарада укыган, ул заман теле белән әйткәндә, гыйлем тәхсил иткән. Тирә-якта бик атаклы мулла, авыл халкының әйтүенә караганда, гарәпчәне дә, фарсычаны да су урынына эчә. Мулла гына түгел, ишан[2] да. Утыз-кырык мөрите[3] бар. Күбесе читтән, Кыр ягыннан. Авылыбыздан берничә генә кеше мөрит.

Мөритләр һәр кече атна көнне авылыбызга хәтемгә[3] җыелалар, ишан хәзрәткә сәдака төяп киләләр: бодай оны, ит, ярма, май, сарык, бозау һәм башка шуның кебек әйберләр. Кыш көннәрендә мөритләр аеруча күп җыела, бөтен мәчет әйләнәсе атлы чаналар белән тула.

Мин менә шул хәзрәт мәдрәсәсендә укырга тиеш булам.

Мәдрәсәгә мине бик тырышып әзерләделәр. Комган янына алып барып, битемне җылы су белән сабынлап юарга, борынымны яхшылап сөртергә куштылар, өстемә шул елны гына тегелгән бишмәт, башыма Кечкенә абыйның иске кырпулы бүреген кидерттеләр. Иске булса да, җылы иде ул, мех эчле иде.

Кайчакларда мин, аның эчен әйләндереп киеп, йә почмактан, йә сәке астыннан мүкәләп чыгып, энемне куркыта идем. Куркынычрак булсын өчен, тавышымны мөмкин чаклы калынрак чыгарырга тырышып, улаган, ырылдаган була идем. Энем, куркып, елап җибәрә иде. Моның өчен миңа кайчак апалардан шактый эләгә иде.

Менә шул бүрекне минем өчен сәндерәдән махсус алып төштеләр дә, тузанын, эчендәге чүп-чарларын бик әйбәтләп кагып, чистартып, бөтенләйгә миңа бирделәр, кидертеп караганнан соң, үзенә тегелгән

---

[1]Кәллә—кәләпүш.

[2]Ишан—үзен Алланың җирдәге вәкиле итеп санаучы дин башлыгы.

[3]Мөрит—ишанга кул биргән, ягъни, гомере буе аңа буйсынырга, ул кушканча яшәргә ант иткән кеше.

[4]Хәтем—Коръән уку, ишанның вәгазь-нәсихәтләрен ишетү өчен җыелган гыйбадәт мәҗлесе.

шикелле таман, шунын өстенә, бик килешә дә икән дип, мактап та алдылар. Тик Кечкенә абый гына, аларга карап, нигәдер көлемсерәп куйды, әбием дә нигәдер аңа күз кысты һәм йодрык күрсәтте. Нигә көлемсерәделәр дә, нигә күз кыстылар? Берсе белән дә кызыксынмадым, вакытым юк иде, мәдрәсәгә ашыга идем, аннары әни, бик матур итеп елмаеп карап, аркамнан сөя-сөя, мине киендерә, мәктәпкә әзерли иде.

Бу бүрекнең үзенә күрә кечкенә генә тарихы бар иде. Башта аны, яңа чакта, әти кигән. Аннары ул, бераз туза төшкәч, калыпсызлангач, бабайга калган. Бабайдан соң аны Кечкенә абый киеп йөргән. Бабай күпме кигәндер, белмим, әмма әнинең әйтүенә караганда, абый аны бары ике ел гына кигән икән. Хәзер инде ул миңа булды. Иске булган өчен түгел, ә бик зур булганга кимәскә чәбәләнеп караган идем дә, мине бик тиз күндерделәр, оялттылар:

—Ничек инде ул, әтиең кигән бүрекне кияргә теләмисең? Әтиеңә яраган, ә сиңа ярамый, имеш! Оят түгелме, кеп-кечкенә бит әле син, борын астың да кибеп җитмәгән,—диделәр. Мин шундук борынымны җиң очым белән тиз генә сөртеп алдым да бүрегемне басып кидем, карышмадым.

Бүрегем бик «таман» иде, ахры, мин аңа колакларым белән генә түгел, борыным белән дә кереп чумдым.

Нигә чәбәләнергә, нигә борчылырга? Зур булса, кышкы салкыннарда, бураннарда җылы булыр, борыныма хәтле батырып, рәхәтләнеп киеп йөрермен, бөтен малайлар кызыгыр. Аннары, башым да бит әле гел бер килеш тормас, үсәр, зураер, бүрегем бөтенләй кеп-кечкенә булып калыр.

Төрле эшкә ярый торган чыдам бүрек иде ул. Кыш көннәрендә генә түгел, соңгы елларда, абый киеп ташлаганнан соң, җәй көне дә хезмәт итә иде. Аңа әле генә йомыркадан чыккан чебиләрне салып асрыйлар. Эче мехлы, җылы. Чебиләргә рәхәт анда. Туңмыйлар. Дөрес, бераз пычраталар пычратуын, нәҗеслиләр, әмма угач, каккач, сабынлап югач бернәрсәсе калмый, яна шикелле чип-чиста була. Аннары, чебешләр гөнаһсыз мәхлуклар алар, нигә алардан чирканырга? Бүрекне кидерткәндә әни шулай диде, моны бик ышандырырлык итеп әйтте. Әни дөрес әйтә безнең. Мин аңа ышанам, ышанмыйча булдыра алмыйм.

Кулыма «Иман шарты»н тыккан букчаны бирделәр. Мин аны, олы шәкертләрчә, күкрәгемә кысып тотып, чыгып киттем. Капка төбенә кадәр озата чыккан әни артымнан кычкырып калды:

—Онытма аны, мәдрәсә бусагасыннан, әгузе-бисмилланы әйтеп, уң аягың белән атлап кер! Аны кара, сул аягың белән атлыйсы булма!

Мин әнигә бертөрле дә җавап бирмәдем, хәтта борылып та карамадым. Борылсам, «таман» бүрегем шундук башымнан атылып төшәр шикелле иде. Болай да башымда чак тора: йә күземне томалый, йә бөтенләй артка китә, һич тә бер килеш тормый.

Абый мине юл буе үгетләп, батыр булырга, бернәрсәдән дә курыкмаска өйрәтеп барды:

—Мәдрәсәгә укырга килгән малайны беренче көнне сынап карыйлар,—диде.—Сынауны үтсәң, мәдрәсәгә алалар, үтмәсәң—алмыйлар.

Бу турыда ишеткәнем юк иде әле. Мин, бик кызыксынып, сораша башладым:

—Ничек сыныйлар?

—Ничек дип, төрлечә сыныйлар. Үзең кебек малайлар белән көрәштереп, сугыштырып карыйлар. Сөзештерәләр дә.

Болар миңа әллә ни куркыныч булып тоелмады. Көрәшергә дә, сугышырга да була. Көрәшмәгән, сугышмаганмыни! Сөзешергә дә мөмкин. Тик маңгай гына чыдасын.

—Тагын ничек сыныйлар?

---

[1]«Иман шарты»—мәктәптә укучы балага «Әлифба» урынына бирелә торган беренче китап, беренче дәреслек. Ул 1875 елда Казанда, Кукубин матбагасында басылган.

—Бәлки, нәләт камыты кидертеп, мичне бер урыннан икенче урынга күчертерләр.

Нәләт камыты? Мондый камытның дөньяда барлыгын ишеткәнем юк иде әле. Тай камыты, сука камыты, бурлы алаша камытларының барлыгын беләм, әмма нәләт камытының нинди икәнен белмим. Абый да аңлатып бирмәде:

—Баргач, күрерсең,—дию белән генә чикләнде.—Тик шуны онытма, ни кушсалар да эшлә. Бернәрсәдән дә курыкма. Курыкмаган малай барысын да булдыра.

Куркалар диме соң! Нигә куркырга!

Мулла абзыйлар тыкрыгына борылу белән ук, мәдрәсәдәге тавышлар гөрләп ишетелә башлады.

—Кечкенәләр генә калган икән. Зур шәкертләр ашарга кайтып киткәннәр булса кирәк,—диде абый.

Мин аңа гаҗәпләнеп карадым:

—Күрмичә торып, каян беләсең?

—Ник белмәскә? Күрәсең ич, ул кадәр шауламыйлар. Зурлар булса, шау-шу болай гына булыр идемени.

Белмим тагы, башка вакытларда ничектер. Ләкин бүген мәдрәсә, бөтен тыкрыкны тутырып, шау килеп, гөрләп тора. Алты ташлы тегермән диярсең!

Мәдрәсәбез иске һәм кечкенә. Такта башлы, алты тәрәзәле, тәбәнәк, шыксыз. Нигез бүрәнәләре чери төшкән булса кирәк, бер ягы белән сәждәгә китеп бара.

Болдырына менгәч, җилләр уйнап торган чоланга керәсең, аннары чыпталы шалама ишекне шыгырдатып ачасың. Бусаганы атлап керү белән ук әчелек[1]. Идәне һәрвакыт кара, чүпле, ярыклары шомлы булып ыржаеп тора. Бөтен җирендә шәкертләрнең салып ташлаган чабаталары, киез каталары, башмаклары тәртипсез сибелеп ята. Шунда ук стенадагы чөйләргә бишмәтләре, сары туннары эленгән.

Мәдрәсәгә килеп керү белән борынга нindидер авыр, әче ис килеп бәрелә. Мондый авыр, тынчу ис авылыбызның бер өендә дә юк.

Әчелекнең уң ягында кайчандыр агартылган, инде акбуры кырылып, кызыл кирпечләре чыккан, шуның аркасында шалама ала сыер төсенә кергән, авызы төтенләнеп, каралып беткән зур мич. Аңа әйләнә-тирәли кызыл башлы, кижеле сөлгеләр, шакмаклы тастымаллар, сөлгегә охшашлы тагын нindидер киндер чүпрәкләр эленгән. Шәкертләр аларны юынганнан, тәһарәт алганнан соң киптерергә элгәннәр.

Шунда ук, идәндә, калҗайган зур ләгән белән бик күп дөнья күргән, шуның аркасында бәрелеп, сугылып, яньчелеп беткән, капкачсыз бакыр комган тора.

Түрне әчелектән калын имән такта белән бүлгәннәр. Такта, кабыргасы белән куелганлыктан, аның аша, бусаганы атлап үткән шикелле аякны күтәреп, атлап үтәргә кирәк. Берәүнең дә, аяк киеме салмыйча торып, бу тактаны атлап үтәргә хакы юк. Чөнки тактаның аргы ягы—түр, мәдрәсә түре. Анда шәкертләр тезләнеп утыралар, сабак укыйлар, сабак тыңлаталар. Мәдрәсәгә кереп, сабак биргән чакларда хәзрәт тә, хәлфә дә шунда утыра. Дөрес, алар, шәкертләр кебек, коры идәнгә утырмыйлар, ә мендәр өстенә утыралар. Мендәрне аларның дәрәҗәләренә карап салалар: муллага өч-дүрт мендәр, ә хәлфәгә—бер, яисә ике.

Түрдә, бүгенге мәктәпләрдәге шикелле, кара такта да, парталар да, өстәлләр дә, урындыклар да, хәтта эскәмияләр дә юк. Түр шәп-шәрә диярлек. Анда бары тәрәзәләр өстендә сәндерә сыман киң шүрлекләр бар да, аннары стена буйлап тезелгән, төрле зурлыктагы, төрле төстәге кечкенә сандыклар бар.

Шүрлекләрдә тыгызлап тутырылган мендәрләр, киезләр, юрганнар,

---

[1]Әчелек—мәдрәсәләрдә аяк киемнәрен салып керә торган урын.

ябынып ятыр өчен алып килгән иске чикмәннәр, бишмәтләр. Болар барысы да мәдрәсәдә кунып укучы шәкертләрнеке, аларның урын-җирләре. Төнлә алар аны идәнгә җәеп, тезелешеп яталар, ә көндез җыеп, шул киң шүрлекләргә тыгызлап тутырып куялар.

Сандыкларда шәкертләрнен китаплары. Кара шешәләре, карандашлары һәм каурый каләмнәре.

Сандыклар йозаклы. Шәкертләр аларны ычкырларына таккан ачкыч белән ачалар, кирәк әйберләрен алганнан соң, яңадан бикләп куялар. Бу сандыклар мәдрәсәдә кунып-ятып укучы өлкәнрәк шәкертләрнеке.

Кечкенә абыемның да сандыгы бар анда. Яшел сандык. Быел җәй ул аны үзе ясады, каяндыр буяу табып, бик тырышып буяды, кояшта киптерде. Сандыгы башта котсыз гына иде, буягач, шундый матурланып китте, аның кебек матур сандык берәүдә дә юктыр. Хәер, белмим тагы.

Кечкенә абый сандыгының эче дә бик матур. Ул аңа бөртекле чәй, кәнфит һәм исле сабын кәгазьләре ябыштырды. Алар сандык капкачын ачу белән үк ялтырап күренәләр. Бу кәгазьләрне карарга бик яратам мин. Андый сурәтләрне беренче тапкыр күрәм. Анда әллә нинди озын чәчле, озын мыеклы, зонтиклы кеше сурәтләре дә, эт, мәче, арыслан сурәтләре дә бар. Хәтта ике кыз сурәте дә бар. Берсенең башын гына ясаганнар, икенчесен биленә хәтле. Икесе дә яланбаш, икесе дә чәчләрен, бүрек сыман итеп, башларына өйгәннәр. Икесе дә абыйга елмаеп карап тора. Хәер, мин карасам, миңа да елмаеп карый алар. Елмайган итеп ясаганнар аларны. Берсе дә безнең авыл кызларына охшамый...

Кызлардан бигрәк, мине озын мыеклы кешеләр гаҗәпләндерә. Үзләре мыеклы, үзләре чәчләрен хатын-кызлар кебек үргәннәр. Абый әйтә: кытайлар алар, ди, кытайлар чәчләрен шулай үреп йөриләр икән, ди. Кытай дигән кешеләрне әле мин беренче тапкыр ишетәм. Менә бит ул ничек! Дөньяда әлләниләр, әллә нинди кешеләр бар!

Тик, нигәдер, Кечкенә абый, сандыгын мәдрәсәгә алып китәр алдыннан, ул сурәтләрне ак кәгазь белән бик тырышып каплап, ябыштырып куйды. Ябыштырды дигәч тә, сурәтләргә зарар килмәслек итеп ябыштырды. Теләсә, абый ак кәгазьне ертып алачак та, әлеге кешеләр, этләр, мәчеләр яңадан күренәчәк.

Абый сындыгындагы ак кәгазь астында шундый сурәтләр барлыгын берәү дә белми. Тик абый үзе белә дә, мин беләм. Белсәм дә, бу турыда берәүгә дә, хәтта әнигә дә әйтмим. Абый аны берәүгә дә әйтмәскә кушты.

Сурәтләрне каплаганнан соң, сандык күңелсезләнеп, котсызланып китте. Башта мин аның сурәтләр өстенә ак кәгазь ябыштыруына, аларны кеше күрмәслек итүенә гаҗәпләнгән идем. Соңыннан аңладым: мәдрәсәгә, мәдрәсәгә генә түгел, өйгә дә сурәтле кәгазьләр алып керергә ярамый икән. Андый сурәтләр кыямәт көнне җаныңны сорыйлар икән.

Кечкенә абый кыямәт көнне аларга җанын бирүдән курыкмый булса кирәк. Курыкса, сандыгына ябыштырмас иде. Ул бары мулла абзыйдан гына курка. Чөнки мулла абзый мәдрәсәгә сурәтле кәгазьләр алып керергә рөхсәт итми. Әгәр белсә, моның өчен суктырачак аны... Абый камчыны бер дә яратмый. Хәер, кем яратсын аны! Күлмәгеңне салдырып, идәнгә сузып салсыннар да, каеш камчы белән чаж-чож каезласыннар әле. Яратырсың, бар!

Абый сандыгы эчендә кечкенә генә ике бүлем бар. Берсе унда, икенчесе сулда. Абый аның берсенә карандашы белән каурый каләмен салса, икенчесенә кара шешәсен бик шәпләп ныгытып куя. Үзе юк чакта кайберәүләр, үч итеп, аның сандыгын никадәр типкәләп йөртсәләр дә, карасы түгелерлек түгел. Аныкы кебек яхшы, ялтыравык кара башка шәкертләрдә бармы икән? Юктыр, мөгаен. Чөнки караны ул теш карасыннан үзе ясый, аңа чеметеп кенә шикәр сала, сәмих[1] сала, аннары

---

[1]Сәмих—кайбер агачлардан, мәсәлән, чия-слива ишеләрнең ярылган кабыкларыннан агып чыгып каткан сок.

шешәсен утта, мич алдында тотып жылыта, тагын нәрсәдер эшли һәм ялтырап торган кара килеп чыга.

Китапларын да, кәгазьләрен дә, өйдә тотарга теләмәгән әйберләрен дә, хәтта ашарга алып килгән ипиен дә сандыгында саклый ул. Ачкычы ычкырында. Аны беркайчан да үзеннән калдырмый, бик саклап йөртә.

Мәдрәсә түрендә тагын бер нәрсә бар: өч җәпле каеш камчы. Гади камчы түгел, тимер очлы камчы. Мәдрәсә бусагасын атлап керү белән үк күзеңә ташлана,—ике тәрәзә арасында агулы елан сыман эленеп тора. Беренче тапкыр күргән чакта, мин бер мәлгә катып калдым, котым очты: «Укырга йөри башлагач, мине дә шуның белән суктырырлармы икән?»—дип уйладым, йөрәгем «жу» итеп китте.

Юк, бер дә суктырыласым килми.

### III

Без, мәдрәсәнең чыпталы ишеген шыгырдатып ачып, барып кергәндә, анда өлкән яшьтәге шәкертләр, иртәнге сабакларын бетереп өйләренә ашарга кайтып киткәннәр, бары сабаклары сонрак башланырга тиешле кече яшьтәге малайлар һәм аларны укытучы берничә олы шәкерт кенә калган иде. Шуна карамастан, мәдрәсә, тынгысыз корт оясы кебек, шаулап, гөрләп тора. Идәнгә, төрлесе төрле урынга тезләнеп утырган балалар сабакларын бар хәлләренә кычкырып укыйлар. Аларга карап идән уртасында басып торган күк күлмәкле, алача ыштанлы, тула оеклы, унбиш-уналты яшьләрендәге бер малай, Җиһанша Керпе Гарифулласы, безнең кебек кечкенә малайлар әйткәнчә, Гарый абый, ачуланып, бармак янап, нәрсәдер әйтә иде: кычкырыбрак укырга куша иде булса кирәк.

Балалар, ишек ачылу белән үк, безгә таба борылып карадылар һәм нигәдер шундук укуларыннан шып туктадылар, Гарый абый да бармагы белән янаган хәлдә тынып калды.

Гарый абыйны беләм мин, өйләре бездән ерак түгел. Салам түбәле өй. Капка төпләрендә өч өянке үсеп тора. Юан, карт өянкеләр. Берсенә дә колач житәрлек түгел, хәтта зурлар колачы да җитми. Өянке башларында карга оялары бик күп.

Гарый абый—зур шәкерт. Ул үзе дә укый, кечкенә малайларны да укыта. Шулай да көрәшкәндә Кечкенә абыйны җинә алмый. Абый аны бөтереп кенә сала.

Гарый абый безгә таба борылды, яныбызга килде, бер Кечкенә абыйга, бер миңа таба караштыргалап торгач, нигәдер елмаеп:

—Йә, нихәл, Әбзәлтин?—диде.—Укыргамы әллә?

Минем өчен Кечкенә абый җавап бирде:

—Әйе, укырга.

—«Иман шарты»ң бармы соң?

Мин күкрәгемә кысып тоткан букчамны күрсәттем.

—Алайса, бик шәп!—диде Гарый абый.—Әйдә, өстеңне сал, әчелектә басып торма. Чын шәкерт бул.

Мин чын шәкерт булырга, алар кебек кычкырып укырга бик тели идем.

Гарый абый, нигәдер, тагын елмаеп, Кечкенә абыйдан сорады:

—Ничек уйлыйсың, Галәттин, Әбзәлтинне сынарга кирәктер бит?

Кечкенә абыйның дәрәҗәсе минем каршыда тагын да күтәрелә төште: монда аның белән киңәшмичә берни эшләмиләр икән. Менә нинди ул минем абый!

Кечкенә абый башта миңа көлемсерәп карап алды, тик шуннан соң гына җавап бирде:

—Сынамыйча булмый торгандыр. Гадәте шундый ич.

Мин гадәткә каршы түгел идем.

Гарый абый кисеп әйтеп куйды:

—Сынауны узмаган малай—малай түгел! Шәкерт була алмый ул!

Укырга керсә дә, сабагын белмәячәк... Әлифне таяк дип тә белмәячәк.

Болай булгач, теләсә нинди сынауны узарга әзер идем мин. Сабакны белерлек кенә булсын!

Ул арада безнең янга бөтен малайлар җыелды. Алар Гарый абый белән Кечкенә абыйның сөйләшкәнен кызыксынып тыңлап тора башладылар. Берсе, кызыл күлмәкле, алача ыштанлы, миннән бераз зуррак малай, Кечкенә абый күрмәгәндә миңа йодрыгын күрсәтеп алды. Мин дә күрсәткән булыр идем дә аңа, бурычлы булып калмас идем, тик кулларым буш түгел иде шул, букчамны күкрәгемә кысып тоткан идем. Әбием дә, әни дә шулай кушты: «Букчаны кендектән түбән төшереп тотма, гөнаһы була»,—диделәр. Бик зур гөнаһы була икән. Ә минем бер дә гөнаһлы буласым, тәмугта янасым килми.

Әлеге кызыл күлмәкле малай миңа һаман күзләрен акайтып карап тора. Мин аның янына килүен, башымнан бүрегемне алып чөюен сизми дә калдым. Мескен бүрегем башта түшәмгә барып бәрелде, аннары атылып, стена буендагы вак сандыклар артына барып төште. Малай аны тагын алып ыргытырга, һавага чөеп, уйнарга теләде, бүрегемә таба козгын шикелле ташланды. Мин тиз генә Кечкенә абыйга карап алдым. Ул, юньсез малайга ишарә итеп, миңа күзен кысты: «Нигә авыз ачып торасың? Бир үзенә кирәген!»—диюе иде аның.

Шундук мин, букчамны ташлап, әлеге малай артыннан йөгердем. Күз ачып йомганчы янына атылып барып җиттем. Бик җайлы туры килде, сандыклар артыннан бүрегемне алырга маташканда өстенә мендем дә яттым, кыймылдарлык хәле калмады. Кайсыдыр шунда, колак төбемдә, әллә инде Гарый абый, әллә үземнең абый:

—Икмәк шүрлегенә менеп төш берне! Кеше бүрегенә сузылмасын,—диде.

Мин, үзем дә сизмичә, алар сүзен тыңлап, тегенең чигәсенә икеөч тапкыр менеп төштем. Бүреккә кагылмасын! Нигә кагыла? Әти кигән бүрек ич ул. Андый-мондый бүрек булса иде.

Безне аердылар, сугышырга ирек бирмәделәр. Кечкенә абый инбашымнан тартып торгызды, Гарый абый теге малайны эләктереп алды. Кулымнан тотмаган булсалар, билләһи, бирәдер идем бит мин ул салма авызга. Бәхете!

Мин торганда инде бөтен шәкертләр яныма җыелганнар, шаулашалар, көлешәләр, мине дә, әлеге кызыл күлмәкне дә сугышырга дәртләндерәләр, котырталар иде. Гарый абый орышмады, шулай да шелтәләп алды:

—Сабаклы букчаны идәнгә ташларга ярамый. Гөнаһы була. Алла сүзе язылган анда. «Иман шарты»нда.

Нинди Алла сүзе булсын анда?! Әкәмәт тә инде бу Гарый абый! Балаларны укытам дигәч тә, әллә ниләр сөйли.

Шелтәсе бетмәгән икән әле аның:

—Аннары,—диде ул,—итегеңне әчелеккә салып калдырырга кирәк иде. Түргә аяк киеме белән узарга ярамый. Мәдрәсә бит бу! Идәне пакь булырга тиеш аның. Намаз укыйлар анда.

Укысалар соң? Укый бирсеннәр. Анда минем ни эшем бар? Әйтмәгәч, итекне салырга икәнен каян белим мин? Аннары башыннан бүрегеңне алып ыргытсын да, сине мыскыл итсен дә, син башта итегеңне сал, имеш, аннары гына артыннан йөгер. Кетәмени ул сине? Итегеңне салганчы бүрегеңне эт итәр, киярлеген калдырмас. Өйгә кайткач, әнигә ни әйтермен мин? Кара син аны, Керпене, итегеңне сал, дигән була.

Чишенгәннән, букчамны бер кырыйга куйганнан соң, мине сынарга керештеләр. Күнелем күтәренке иде. Ни әйтсәң дә, әлеге кызыл күлмәкне җиңдем.

—Ничек сыныйбыз?—диде Гарый абый, зуррак малайларга карап.

Малайлар бераз уйга калдылар. Ниһаять, арадан берсе мичне түргә, тәрәзә янынарак күчереп куярга кирәк тапты. Авызы караңгы якта икән, аны яктыга, тәрәзәгә каратырга кирәк икән.

Мин әлеге, бик күптән акбур күрмәгән, тотенләп каралып беткән мичкә куркып карап алдым. Күчереп булырмы икән? Бик дәү бит. Айһай, көчем житәр микән?

Кечкенә абыем карашымны сиздe булса кирәк, шундук мине дәртләндерә башлады:

—Күчерәсең син аны. Берни түгел! Былтыр әле синнән дә кечерәк малай аны ишекле-түрле тартып йөрде.

—Кем малае?

—Кем малае дип... Нигъмәт Тукранбаш малае. Кәримулла. Беләсендер бит?

Белмәгән кая, беләм. Бездән ерак түгел алар. Һи, ул күчергәнне мин күчермимме соң! Алайса, берни түгел ул миңа!

Гарый абый идән астыннан нәләт камытын алып чыгарга кушты.

Малайларның берсе, бик житезе, ике әйттереп тормады, идән асты капкачын ачып, түбәнгә сикерде, бары ялангач кара тәпиләре генә күренеп калды.

Нәләт камыты дигәннәре—ярып-ярып та, ярылып бетмәгән, чыннан да камытка охшаган ике япьле карама пүлән калдыгы булып чыкты. Мин аны тагы чын камыт дип торам. Түгел икән.

Нәләт камытын муеныма кидерделәр. Бераз авыррак булса да, чыдарлык. Үзе бер дә камыттан ким түгел, муенда яхшы утыра, тиз генә салып булмый.

Шәкертләр дә, олылар да, кечеләре дә, бик рухланып, чамадан тыш күңелләнеп китеп, көлешеп, кижеле сөлгеләр белән мине мичкә жиктеләр. Ике сөлгене дилбегә итеп тактылар. Жиккән ат дилбегәсез буламыни соң, диделәр. Чыннан да, жигелгән атның дилбегәсез булуын күргәнем юк минем. Гарый абый шул ук мич тирәли эленеп торган сөлгеләр арасыннан бер таррагын сайлап алды да чыбыркы кебек итеп иште.

Кечкенә абыем колагыма пышылдавыннан туктамады:

—Курыкма, курыкма, черәшебрәк тарт... Черәшсәң, күчерәсең аны... Берни түгел!.. Нигъмәтжан Тукранбаш малае күчерде... Шундый жинел күчерде, «эһ» тә итмәде...

Гарый абый, ишкән сөлгесен һавада болгап:

—На, малкай!—дип, атка чөңгергән шикелле, миңа чөңгереп жибәрде, «дилбегәмне» дә жинелчә генә тартып куйды.

Мин, бөтен көчем белән тырышып, тырышсам күчерә алам дип чын күңелемнән ышанып, килбәтсез мичне тәрәзәгә таба өстери башладым. Шулкадәр тырышып тарттым, нәләт камыты белән бергә муеным өзелеп чыга дип торам, сулуым капты, хәтта телем салынды.

Балалар, шаулашып көлешә-көлешә, бердәм кычкырып жибәрделәр.

—Кузгалды, кузгалды!.. Бара, бара... Тырышыбрак тарт!..

Бармыйча соң! Бу кадәр көчәнеп тарткач, нигә кузгалмасын! Тукранбаш малаеннан киммени мин! Мин аны бөтереп кенә салам.

Гарый абый кулындагы сөлгесе белән аркама да тамызып алды:

—На, малкай! На! Яле, тагын бераз!.. Дүрт аякланып, дүрт аякланып! Абаланып тарт! Алай жинелрәк...

Башка вакыт булса, аркамның сызлавыннан елаган да булыр идем, ләкин хәзер, мич урыныннан кузгалгач, шуның өстенә тагы бөтен малайлар көч биреп торгач, кайберләре куллары, иңбашлары белән мичне этешеп, булышып та торгач, елауны кирәк тапмадым. Авыр булса да, ике-өч адым алга киттем. Күчерәм, тәрәзәгә күп калмады инде...

Малайлар да, хәтта Кечкенә абый да:

—Китте, китте!.. Бара, бара, тәрәзәгә күп калмады,—дип кычкыралар, шаулашалар, көлешәләр, ә мин бөтен көчем белән тырышам, абаланып тартам... Абалангач, жиңелрәк бара икән. Инде тәрәзәгә күп калмады. Күп дисәң, ике адым. Шуннан артык булмас...

Бервакыт йөгем бөтенләй жиңеләеп китте, үзем стенага барып бәрелдем. Артыма әйләнеп карасам, ни күрим, каһәр төшкән мич һаман

урынында, бер карыш та кузгалмаган! Тик шәкертләр генә шаркылдап көләләр. Нигә көләләр, нигә авызларын ералар? Көләрлек нәрсә бар?.. Кузгалды дигән булдылар. Ялганчылар!

Гарый абыйга рәхмәт! Эчен тотып шаркылдап көлсә дә, мактап алды:

—Сөлгеләр чыдамады, өзелде. Чыдаса, билләһи, күчерә иден. Маладис, Әбзәлтин!

Көлешеп туйганнан соң, көрәш башланды. Шәкертләр идәнгә тирәли тезелешеп утырдылар. Мәдрәсәдәге иң кечкенә малайларның берсе мәйданга чыгып басты, киндер күлмәк итәген ыштан бөрмәсе эченә җыеп кыстырды да кырыйлары сүтелә башлаган, коймактай җәлпәк кәлләсен басыбрак киде, учларына бер-ике тапкыр төкерде. Гәрчә бу малай миннән берничә яшькә олы һәм зур булса да, сыналасы булгач, артык киреләнеп тормадым, чыгарга, көрәшергә булдым. Хәзергә мәдрәсәдә шуннан да кечерәк малай юк, диделәр. Булмагач, каян аласың аны! Сынауны үтмәсәң, укырга алмыйлар. Шуның өстенә Кечкенә абый да, аркама төрткәләп:

—Чык, чык, җиңәсең аны, җиңәсең,—дип котыртып тора.

Чыктым, учларымны төкереклəп, малайның ыштан бөрмәсеннән чатырдатып тоттым. Ул да билемнән кысып алды. Мондыйларны күрмәгәнмени мин! Җәй буе көрәшәм. Кечкенә абый мине үзем кебек малайлар белән һаман көрәштерә, көрәшергә өйрәтә.

Мәйданда, ярыклары ыржаеп торган идәндә, күпмедер вакыт әйләнгәләп йөрдек... Һәм бервакыт, идәнгә чалкан килеп төшкәнемне сизми дә калдым. Мин малай астыннан чыгарга теләп тыпырчынганда, балалар шаулашалар, көлешәләр, ә түшәмгә эленгән унлы лампа әллә шәкертләр шаулаганга, әллә инде болай гына селкенә, тирбәлә иде.

Гарый абыйга тагын бер кат рәхмәт! Егылсам да, мактады:

—Көрәшә беләсең икән. Сынауның бусын да үттең,—диде.

Белмәскә соң! Көрәшә дә белмәгәч, ни була ул! Әгәр минем белән көрәшкән малай аяк чалмаган булса, мин аны...

Кечкенә абый да егылуымны гаеп итеп санамады, хәтта сәбәбен дә тапты:

—Бүген бәрәңгене аз ашады ул. Күбрәк ашаса, җиңми калмый иде,—диде.

—Ничәне ашадың соң?—дип сорады Гарый абый миннән.

—Икене. Берсе кечкенә генә иде.

—Әй, Әбзәлтин, Әбзәлтин, күбрәк ашыйлар аны. Кимендә дүртне ашарга кирәк иде. Җиңгән булыр иден.

Белгән булсам, дүртне генә түгел, бишне, алтыны, хәтта табактагы бөтен бәрәңгене ашап бетергән булыр идем. Каян беләсең бит аны!

Сынауның соңгысы итеп, мине Зариф исемле малай белән сөзештереп карадылар. Тубал башлы бу малай да миннән зуррак, олырак иде.

Сөзешә белә идем мин. Дүрт аякланып басасың да, усал үгез шикелле муеныңны бөгеп, тамак төбе белән куркынычлы үкереп, сөзәргә килүче малайга каршы барасың, аякларыңны, кулларыңны җиргә каты итеп терәп, мангаеңны мангайга китереп сөзәсең. Тик ерактан йөгереп килеп сөзәргә генә ярамый, алай сөзешсәң, күздән утлар чәчри, маңгай авырта.

Абый мине җәй көннәрендә, капка төбендә җыелышып утырганда, күрше-тирәдәге үз ишләрем белән еш кына сөзештерә иде. Җиңә идем мин аларны. Шуңа күрә мине көлеп, мактап, Шиһабетдин үгезе дип атыйлар иде (әтием Шиһабетдин исемле булганга шулай атыйлâр).

Зариф миннән олы булса да, зур булса да, сөзешә белми икән. Каян белсен соң ул! Аның минеке кебек абые бармыни! Каян килсен ана андый абый!

Ул, мин сөзә башлаганны көтмичә, ашыгып, дүрт аякланып йөгереп килде дә тубалдай башы белән маңгаема шундый каты килеп бәрелде, сөзмәде, ә бәрелде, күзләремнән утлар чәчелде, маңгаем ярылды, күзләрем

атылып чыкты дип торам. Шөкер, берни булмаган икән әле, тик елак капчыгы гына, үзем дә сизмәстән, чишелеп китә язды. Тиз генә әчелеккә йөгереп барып, итегемне кидем дә, бүрегемне, бишмәтемне, букчамны кочаклап, урамга атылып чыгып киттем. Артымнан Гарый абый нәрсәдер кычкырып калды, ләкин аңа әйләнеп та карамадым.

Нигә карыйм? Сөзешә белмәгән малайны нигә чыгара? Шулай сөзештерәләрмени? Керпе шул, керпе! Кеше булса иде!

Ана да, Кечкенә абыйга да әрнүем, үпкәм чамасыз иде. Елыйсым килә иде. Тик урамда елавы оят. Малайлар күрсәләр, көләрләр, күзенне ачтырмаслар.

Чатны борылгач кына, бишмәтемне, бүрегемне кидем. Кечкенә абый артымнан куып җитте, кулында—кәләпүш. Карасам, минем кәләпүш.

—Нигә ташлап калдырдың?—ди. Кем ташласын аны? Кәләпүш ташлап калдырырга җүләрмени мин? Үзе төшеп калган. Кечкенә абый кулыннан аны бер сүз дәшмичә генә тартып алдым.

—Нигә үпкәлисең миңа?—диде абый.—Мин сөзмәдем ич...

Шул гына җитмәгән! Син сөзәр идең тагы. Бар, мир үгезе белән сөзеш. Мөгезләре белән күзләреңне актарып чыгарсын!

Бераз баргач ул, үз-үзенә эндәшкәндәй, авыз эченнән генә мыгырдап куйды:

—Зарифның, мескеннең, маңгаена йодрык хәтле шеш чыккан. Бик каты сөзгәнсең үзең дә, ул чаклы кирәкмәс иде... Үкереп елап калды...

Чынны әйтәме икән, алдамыймы икән дип, Кечкенә абыйга күтәрелеп карадым. Чынны әйтә булса кирәк, көлми дә, елмаймый да. Эчемә җылы кергәндәй булды, маңгаем да ул кадәр сызламый башлады: «Шул кирәк аңа, тубал башка! Әллә каян, ерактан йөгереп килеп сөзмәсен». Шулай да Кечкенә абый белән сөйләшергә теләмәдем.

Өйгә кайтып, әнине күргәч кенә, күзләремнән яшь атылып чыкты. Ни булгандыр миңа, үзем дә белмим. Берәр җирдә кыерсытсалар, кыйнасалар, суксалар, күз яшьләрем ул кадәр чыкмый, бары бер-ике тамчы гына тама. Ләкин өйгә кайткач, әнине күргәч... Йә, нигә сөйләп торыйм аны.

Мәдрәсә бусагасын уң аягым белән атлап кермәвем, бисмилла әйтмәвем кич белән йокларга яткач кына исемә төште. Менә бит ул! Хәер, барыбер мичне урыныннан кузгата алмас идем. Бик зур шул!

Әни әйтте:

—Мәдрәсәдә малайлар синең белән шаярганнар гына, мичне юри тарттырып караганнар,—ди.—Аны син түгел, әтиең кебек зурлар да урыныннан кузгата алмый, ун кеше дә кузгата алмый,—ди.

Кара син аларны! Мине кызык итмәкче булганнар икән. Әх, белгән булсам... Юк, анда мине генә түгел, беренче килгән бөтен малайларны шулай кызык итәләр икән. Гадәт шундый.

Гадәт шундый булгач, нишлисең! Буйсынмыйча булмый.

Иртәгесен мине Кечкенә абый белән бергә мәдрәсәгә җибәрергә никадәр тырышсалар да, бармадым.

Берничә көннән соң Гарый абый мине урамда очратты, малайлар белән куышып уйнап йөргәндә, көтмәгәндә, уйламаганда мәдрәсә тыкрыгыннан килеп чыкты да, көлеп, шаярып, тотып алды. Әгәр аны алданрак күргән булсам, өйгә йөгергән, качкан булыр идем, чөнки үпкәм бетмәгән иде әле. Маңгаемның сызлавы бетсә дә, үпкәм саклана иде.

—Нигә мәдрәсәгә килмисең?—диде ул миңа.—Сынауны үттең ич. Бик яхшы үттең. Башкалар елап чыгып качалар. Ә син еламадың, бернәрсәдән дә курыкмадың, әйткәнне берен эшләдең. Маладис малай икәнсең. Кил, үзем укытырмын. Берәүдән дә кыйнатмам, тырнак белән дә чирттермәм,—диде.

Шундук аңа булган үпкәм каядыр китте, бетте. Бер уйласаң, Гарый абый яхшы малай ул. Нигә үпкәләргә аңа? Аны мин «Керпе» дип тә атамас идем. Бер дә керпегә охшамаган.

Шулай да мин ул елны мәдрәсәгә бармадым. Апаларыма ияреп, сабакка мәзин өенә йөри башладым. Анда рәхәт, ичмаса. Мичне дә күчертмиләр, сөзештермиләр дә, көрәштермиләр дә. Хәер, көрәштерсәләр, шәп булыр иде. Кызлар көрәшә белмиләр. Батыр калыр идем.

## IV

Мәзин өенә сабакка көненә ике тапкыр бара идек. Берсе иртә белән, яктырып килгәндә, икенчесе—кич белән, кояш батар алдыннан.

Иртә белән дә, кич тә, укуга караганда, хезмәт «дәресләре» күбрәк була иде. Апаларым һәм алар яшендәге кызлар тышта эшлиләр: ишек алдындагы, капка төбендәге карны көриләр, себерәләр, терлек асларын җыештыралар, аларга ашарга салган саламнарны җыеп, көлтә итеп бәйлиләр, урам коесыннан су ташыйлар, мал-туар эчертәләр, өйгә дә су ташып куялар; ә мин, үзем шикелле кечкенә малайлар, кечкенә кызлар белән бергә, өйдә, җылыда, идәнгә тезләнеп утырып, казларга, тавыкларга ипи турыйм. Дөресрәге, зур кызлар кисеп биргән телемнәрне алдымдагы таш табакка чәйнәп салам. Казлар да, тавыклар да чәйнәп биргән ипине яратыбрак ашыйлар икән. Хәлфә апа шулай ди. Без, төкерекләребезне күбрәк, мулрак чыгарырга теләп, ярышып чәйнибез, бер-беребездән уздырырга тырышабыз.

Мәзиннен казлары күп. Эре казлар. Тамак аслары зур булып салынып торган кытай казлары, ә Кадер киче[1] ипиләре аннан да күбрәк. Келәттә, чормада тау кебек өелеп тора. Күптәнге ипиләр, таш кебек катып беткәннәр. Чәйнәве читен, тешләребез чак үтә, авызыбыз кибә, төкерекләребез җитми. Авызыбызны чылатыр өчен, яныбызда чүмеч белән су тора. Мәзин хатыны—безнен хәлфә апа—авызыбыз кипкәч, шушы суны эчәргә куша. Без исә, эчүгә караганда, кулыбыздагы телемнәрне суга манып алырга, тик шуннан соң гына чәйнәргә яратабыз. Хәлфә апа күрмәгәндә шулай итәбез дә. Хәйләбезне күрсә, ул безгә:

—Бик каткан телемнәрне суга манчытырга каршы булмас идем дә мин, бәпкәчләр,—ди ул бик ягымлы тел белән,—тик алай тураганны казларым өнәп бетермиләр шул.

Казлар өнәмәгәч, чыннан да, нигә суга манчырга? Без анын сүзенә ышанабыз һәм нәни кулларыбыздагы телемнәрне, коры, каты булса да, бик тырышып, хәтта ярсып кимерергә, чәйнәргә керешәбез. Тик казлар гына ашасын! Алар гына өнәсен!

Безне тагын да дәртләндерергә теләп, хәлфә апа эшебезне макташтыргалап ала. Хәер, мәзин үзе дә салпы ягыбызга салам кыстыра белә:

—Кара әле, сина әйтәм, бик тырыш шәкертләр булып чыктылар бит әле болар,—ди ул.—Нинди әйбәт турыйлар. Тагын да чәйнирәк төшсәләр, бөтенләй яхшы булачак бит бу.

Без чәйнирәк төшәбез, тырышабыз. Мактасыннар гына!

Мәзинне без, олылап, ихтирам итеп, хәлфә абый дибез, ә хатынын хәлфә апа дип тә, тәтәй дип тә атыйбыз. Икесенен дә исемнәре бар, билгеле. Хәлфә абый Шаһвәли Сәмитов, авылыбыздагыча гади итеп әйткәндә, Шәвәли мәзин, ә хәлфә апабыз—Гайникамал. Баласыз-чагасыз, картаеп бара торган кешеләр. Иген чәчәләр, урак уралар, мәзин вазифасын үтиләр, кыш көннәрендә мәхәлләбездәге кыз балаларны укыталар. Укытучылык итүләренә карамастан, икесенен дә белемнәре юк. Мәзин авылыбызда гына укыган, бабай сүзләре белән әйткәндә, шунда «ми черткән». Балалар кулында дәреслек булып йөри торган китапларны таный, «Коръән» сүрәләрен, төрле догаларны, ватып-җимереп булса да,

[1]Кадер киче—ураза аендагы дини бәйрәмнәрнен берсе. Ул көнне авыл халкы, сәдака итеп, мулла-мәзингә пешкән ипи илтә торган иде. Хәллерәк кешеләр, гаиләләрендә ничә җан булса, шунын санынча илтәләр иде.

күңеленнән белә, кирәк урында, бер дә тотлыкмыйча, туктамыйча кычкырып укый, биш вакыт намазны калдырмый, азанын бөтен мәхәллә халкы ишетерлек итеп, кычкырып әйтә. Шулай да тавышы икенче мәхәлләдәге Садри мәзиннекеннән калыша. Садри мәзиннең көчле һәм көр тавышы үз мәхәлләсенә генә түгел, безнең мәхәлләгә дә ишетелә, хәтта җәйге тын кичләрдә еракка, басуларга чаклы ишетелә икән. Халыкның әйтүенә караганда, күкрәге кин, тавышы моңлы. Аның азан әйтүен ишеткәч, кешеләр, туктап, тынып калалар, уйга чумалар. Шундый көчле, моңлы тавышлы ул. Тирә-якта андый көчле тавышлы мәзин бер авылда да юк икән.

Хәлфә абый да аңардан калышмаска тырыша, азанны бөтен көче белән әйтә, тик аңа ул кадәр каты кычкырырга ярамый, тамагы карлыга, шуннан соң ул атналар буе азан әйтми, манарага менми. Кайвакытларда хәлфә абыебызның тавышы шулкадәр карлыга, азан әйткәндә генә түгел, сөйләшкәндә дә кәҗә тавышы чыга башлый. Шуна күрәме, әллә башкагамы, авыл халкы аны Шәвәли Кәҗә дип атый.

Хәлфә абыебыз кәҗәне бер дә яратмый, хәтта кәҗә дигән сүзне дә яратмый. Әнием сабакка баруымның беренче көнендә үк колагыма бик нык тукыды:

—Кара аны, онытма, алар өендә кәҗә дигән сүзне әйтәсе булма,— диде.

—Ник?—дип сорадым мин аңардан, кызыксынып.

—Ник икәне сиңа кирәк түгел,—диде әни коры гына.—Колагын ишетсен: ул сүзне анда теленә аласы булма.

Әнинең сүзе кызыксынуымны гына арттырды. Нигә аларның өендә кәҗә дип әйтергә ярамый икән? Әгәр әйтсәм, кәҗә дисәм, ни була? Нишләтерләр икән? Түрдә эленеп торган камчы белән суктырырлармы икән?.. Юк, минем бер дә суктыртасым килми. Ул камчы болай да күңелемә шом салып тора.

Мин «Кәҗә такмагы»ның берничә юлын күңелемнән беләм. Үз ишләрем белән без аны, кәҗә күргән саен, бөтен урамны янгыратып такмаклыйбыз.

Кәҗә, кәҗә, Мәкәрҗә,
Кермә минем бакчага;
Керсәң минем бакчага,
Утыртырмын бүкәнгә,
Суктырырмын Иванга.

Иван—безнең авыл тимерчесе. Аның алачыгында сөремләнеп, каралып беткән зур имән бүкән бар. Аңа тимер сандал беркетелгән. Иван абзый учактан әле генә алган, уттай янган тимерне шул сандалга сала да кулындагы зур чүкеч белән бик каты кыйный, бөгә, нәрсәдер ясый, бөтен алачык эченә җемелдәвек утлар сибелә. Бакчага кергән кәҗәне, тотып, чәрелдәтеп өстерәп барып, менә шул бүкәнгә утырталар да Иван абзыйдан суктыралар шикелле тоела иде миңа.

Мин үз-үземне анламыйм, аларнын биш тәрәзәле, тар, кысан өйләренә, идәнне тутырып чабып йөргән бәрәннәр арасына барып керүем белән үк, нигәдер, «кәҗә, кәҗә, Мәкәрҗә...» дип такмаклыйсым килә. Алай гына да түгел, дүрт аякланып, бәрәннәр арасында кәҗә бәтие кебек кычкырып, ишекле-түрле чабып йөрисем дә килә.

Әгәр шулай чабып йөрсәң, кызык та булыр иде. Кызлар да, малайлар да туйганчы көләрләр иде. Ә хәлфә абый белән хәлфә апа нишләр иде икән?.. Кайчакларда үземне чак тыеп торам. Шулай да, түзмим, мич арасына кереп, берәүгә дә ишеттермичә, авыз эченнән генә «кәҗә, кәҗә, Мәкәрҗә» дип такмаклыйм.

Мәзинебезнең тавышы никадәр карлыкмасын, кайчакларда чәрелдәп чыкмасын, мәхәллә халкы аңардан канәгать. Нигә канәгать булмасын? Мәчет мичләрен яга, идәнен себерә, сукмактагы карны көри, мәетләрне

юа, көмешә, кирәк чакта «Ясин» чыга, Коръән укый, дога кыла, авыруларны өшкерә-төкерә, сулышы «шифалы», житмеш жиде чирне «юк итә» торган догалар белә, аларны тотлыкмыйча, уйлап тормыйча укый, эшкә йөри, чакырган жирдән калмый, кыз балаларны укыта, бераз яза-сыза белә, хат яздырырга килгән кешеләрне кире кайтармый, матчага кыстырган каурый каләмен ала да, тәрәзә төбендәге чебенле кара савытына мана-мана, шунда ук язып бирә. Кешеләрнең әйтүләренә караганда, аның боргалап-сырлап язган хатын башкалар чак укысалар да, үзе яхшы таный.

Тәлинкәләрен күтәреп килгән кешеләргә ул зәгъфран белән исмеәгъзам догасын[1] да язып бирә. Тәлинкәгә язылган бу «шифалы» доганы, жылы су белән юып, бисмилла әйтеп, авыруга эчерәләр. Шундый житмеш жиде төрле «һөнәре» булган мәзиннән мәхәллә халкы нигә канәгать булмасын икән? Канәгать булганнардыр дип уйлыйм.

Озын буйлы, какча гәүдәле, чал кереп барган коңгырт сакаллы мәзинебез дә үзенең хезмәтеннән канәгать иде булса кирәк. Килгән сәдакаларны бик кәефләнеп кабул итә, кулларын күтәреп, озаклап дога кыла. Догасын кылганнан соң, учларын тиз генә битеннән алмый, ә шәригатьчә жыйнак итеп алдырган, чал кереп барган коңгырт сакалын яратып сыйпап тора. Доганы ул бик матур, бик оста кыла. Кем белә, авылыбызда аның кебек оста дога кылучы кеше булмагандыр да.

Мәчеткә дә, ашка да, хәтта мәетләрне күмәргә дә бик риза булып йөри ул. Намазга тантаналы төс белән бик мәһабәт бара. Башында кызгылт кәләпүшкә ураган, зур да, кечкенә дә булмаган чалма, өстендә, жәй булса, шактый туза төшкән, терсәк тирәләре ямалган соры жилән, кыш көннәрендә кемнәндер фидияга килгән камалы тун, кулында яшел башлы озын таяк. Ул, зур-зур атлап, кулындагы таягын адым саен селтәп жибәрә-жибәрә, эре генә бара. Юлда очраган, үзеннән олырак яшьтә булган кешеләргә еактан ук сәлам бирә, аларның исәнлекләрен-саулыкларын сораша, хәлләрен белешә. Үзеннән кечерәкләрнең сәламнәрен дә бөтен кагыйдәсенә туры китереп ала. Гомумән, сәламне бирә дә, ала да белә ул. Кемгә ничек бирергә һәм аны ничек алырга кирәк икәнен тагын да яхшырак белә.

Без аның сәламне ничек бирүенә түгел, шулай ук аның зур-зур атлап баруына да түгел, ә яшел башлы таягына кызыгабыз. Безнең дә, шул таякны тотып, селтәп-селтәп жибәреп йөрисебез килә.

Хәлфә апага—тәтәйгә килгәндә, ул, киресенчә, кыска буйлы, тулы, йомры гәүдәле, ачык чырайлы, йомшак телле хатын иде. Үзеннән кечеләргә, бигрәк тә безгә, укучы балаларга «бәпкәч» дип кенә эндәшә. Эш кушканда яисә алып килгән сәдаканы кулыбыздан алганда, аеруча тәмле теллеләнә иде.

Ул авылда иң оста өшкерүчеләрнең берсе иде. Карчыкларның әйтүләренә караганда, сулышы бик шифалы икән.

Авыруларны өшкерергә барганда, аның беркайчан да үзеннән калдырмый торган куян тәпие бар иде. Шуның белән ул авырып ятучы кешенең сызлый торган жирен сыйпый-сыйпый өшкерә, авыз эченнән медер-медер килеп нәрсәдер укый, пышылдый, өшкерүен һәр юлы «бик авыртсын, тиз бетсен» дигән тылсымлы көчле сүзләр белән тәмамлый. Аннары, учларын кушырып, амин тота, күпереп торган йомшак иреннәрен еш-еш тибрәтеп, авыз эченнән генә тагын нәрсәдер укый, күзләрен ярым йомып, укуы жаена бөтен гәүдәсе белән бер алга, бер артка таба берникадәр вакыт чайкалып тора, тик шуннан соң гына битен сыйпый. Хәлфә абый кебек, колачларын киң итеп жәеп, шаулап, гөрләп амин итми, тыныч кына, ашыкмый гына битен сыйпый. Аның бөтен хәрәкәтендә, йөрешендә-торышында, хәтта вак-вак атлавында да ниндидер, күңелне тынычландыргыч

[1] Исме-әгъзам догасы—динчеләр фикеренчә, житмеш жиде төрле авыруны дәвалый торган дога.

ягымлылык, йомшаклык бар. Авырып, сызланып ятучылар аның өшкерү-төкренүләреннән генә түгел, ә җан эреткеч шул ягымлылыгыннан, мөлаемлегеннән дә шифа өмет иткәннәрдер дип уйлыйм.

Күпне күргән, кулда йөри-йөри, инде карала, йоннары кыршыла башлаган куян тәпие шифалы дәва булып чыкмаса, авыруны терелтмәсә, аны ятагыннан торгызмаса, хәлфә апабыз өметсезлеккә бирелми, үзенең «врачлык» багажындагы башка чараларны куллана. Йөгерек аяклы малайлар аңа койма башыннан яисә өй кыегыннан чыпчык тизәге җыеп төшеп бирәләр. Кырык данә чыпчык тизәге кирәк аңа. Тәтәй аларны, берәмләп санап (Алла үзе сакласын, кырыктан артмасын да, кимемәсен дә!), тәлинкәгә сала да эреп соргылт төскә кергән суны тондырганнан соң, хәлфә апабыз аны бик әйбәтләп өшкереп-төкереп, аның шифалы икәненә чын күңелдән ышанып, авыруга эчертә һәм, янадан иреннәрен кыймылдата-кыймылдата, бик озаклап дога кыла.

Беркатлы тәтәебез уенча, дөньяда чыпчык тизәгеннән дә шифалы, файдалы дәва юк. Җәен-кышын өй кыекларында, койма башларында, тәрәзә каршындагы агач ботакларында чыркылдашып, сикергәләп йөрүче чыпчыклар Алланың иң гөнаһсыз мәхлуклары икән һәм шуна күрә тизәкләре шифалы икән аларның.

Әгәр инде тәтәйнең күп мәртәбәләр «сыналган, тикшерелгән» бу «дәвасы» да авыруны терелтмәсә, ярдәм итмәсә, ул бик гаҗәпләнә һәм бераз аптырап кала, шулай да өметсезлеккә бирелми, өметсезлек аның холкына туры килми. Аның һәр авыруга үз догасы, үз «шифасы», үз «дәвасы» бар.

Берничә көннән соң ул авыруны яңача, иң соңгы, иң ышанычлы итеп дәваларга керешә. Иске чабатага өеп туфрак тутырып кирәргә куша. Боерыгын шунда ук үтиләр. Җәй булса, туфракны урамнан алып керәләр. Кыш көне исә, идән астыннан алып чыгалар. Идән асты туфрагы бигрәк тә яхшы. Өйдәге кешеләргә күнеккән туфрак! Шуннан соң тәтәй, әгузе-бисмилла әйтеп, лакан янындагы себеркедән кырык чыбык сындырып ала. Бу да кырык булырга тиеш. Артык та, ким дә булмасын! Чыбыклар озын түгел, һәркайсы бер карыш. Башта ул аларны, итәгенә салып, бик тырышып өшкерә-төкерә, күзен йомып, башын бераз югары күтәреп, аралаштыра. Шуннан соң ул чыбыкларны, берәм-берәм кулына алып, йомшак иреннәрен кыймылдатудан һәм өшкерүеннән туктамыйча, хастаның сызлый торган урынына берничә мәртәбә төртә дә туфракка кадый, төртә дә туфракка кадый, явыз чирне авырып ятучы кешедән туфракка, чабатага «күчерә».

Чыбыкларны туфракка кадап бетергәч, кайберләренә авырып ятучының иске күлмәгеннән ертып алган кечкенә-кечкенә чүпрәкләр дә таккач, ышанычлырак булсын өчен тагын бер кат өшкергәч, дога кылгач, чабатаны барлык туфрагы, чыбыклары, чүпрәкләре белән бергә авылдан алып чыгып китәләр дә җиде юл чатына илтеп куялар. Шунда ул, каһәр төшкән авыру, имеш, әледән-әле узгалап торучы юлчыларның берәрсенә ияреп китә икән. Шуннан соң хаста кеше «терелəчәк», үзен анадан туган кебек хис итәчәк.

Бу чара да авыруны аякка бастырмаса, тәтәебез бөтен гаепне җенгә-пәригә сылтый, җен зәхмәте булган аңа, ди. Моны бары Коръән чыгып кына «терелтеп» була икән. Кызганычка каршы, тәтәебез «Коръән»не укый белми. Белсә, Коръән чыгар, иренмәс иде, сәдакасы килер иде—корсакны тишмәс иде.

Миңа тел ачкычы бирергә тиеш булган беренче хәлфәмнең шундый һөнәрләре бар иде, тик белеме генә юк иде. Ул бары «Иман шарты» белән «Бәдәвам»[1] гына укыта иде.

---

[1]«Бәдәвам»—көйле, дини-әхлакый әсәр.

## V

Хәлфә апа минем шикелле борын аслары кибеп җитмәгән бала-чагаларны укыта. Аның «классы» почмакта.

Бөтен өйне тутырып торган ипи миче һәм такта белән бүленгән почмак тар, тыгыз. Савыт-саба, чүлмәкләр, чиләкләр, куна тактасы, кисәү, пумала һәм түр якка чыгарырга ярамаган башка шуның кебек әйберләр барысы да шунда: йә идәндә, йә сәкедә, йә киштәдә. Почмакта һәм мич арасында аз гына буш урын бар. Без менә шул бушлыкта, бишмәтләребезне, бүрекләребезне салмаган килеш (кызлар яулыктан, шәлдән), тыгызланып, бер-беребезгә төртелешеп басып торабыз. Кулларыбызда китап. Беребездән беребез уздырырга тырышып, кычкырып укыйбыз.

Почмакта без генә түгел, тынгысыз бәрәннәр дә бар. Язга таба, сыер бозаулагач, безгә «сабакташ» итеп бозауны да алып керәләр. Ул мич арасында, муенчакта яши. Безгә зур, матур һәм монсу күзләре белән гаҗәпләнеп карый. Яратабыз без бозауны, аның муенын, колак артын, мөгез урынын рәхәтләнеп кашыйбыз. Бозау да безне ярата, сыена, ышкына, кытыршы теле белән кулларыбызны, битләребезне ялаштыргалап ала. Яларга ирек бирсәк, бишмәтләребезне дә ялый, аеруча, борыныбызны сөртә-сөртә беләү сыман шомарган, ялтыраган җиңнәребезне яларга ярата.

Кайчакларда мин өйдән, әнигә күрсәтмичә генә кесәмә тыгып, бераз тоз алып киләм. Берәүгә дә сиздермичә (сизсәләр, эш харап! Тоз— изге ризык), аны төкрекле кулым белән сылап алам да бозауга сузам. Ул, ләззәтләнеп, койрыгын селки-селки, учымны бик тырышып, яратып ялый. Балалар гаҗәпләнәләр: «Нигә Әбзәлтин учын бу кадәр яратып ялый соң ул?!»—диләр.

Бәрәннәрне дә яратабыз без. Алар да безнең арада айкалалар. Кайчак аларны тотып, сәке астына ябып куялар. Шулай да аннан чыгу хәйләсен табалар.

Хәлфә апабыз гаҗәпләнә:

—Әле генә ипләп япкан идем бит. Ничек чыгалар соң алар?—ди.

Без, Насыйх исемле дус малай белән икәү, эчебездән генә көләбез, хәлфә апага күтәрелеп карарга куркабыз. Күтәрелеп карасак, сизәр кебек. Чөнки ул күрмәгән арада без сәке астын каплап куйган тактаны аякларыбыз белән төртеп ачабыз. Безгә бәрәннәр белән күңеллерәк. «Балалар нигә сабак укыйлар? Нигә бәрәннәр белән генә уйнап йөрмиләр икән?»—дип уйлыйбыз.

Бозаулаганнан бирле сыерны да көненә ике-өч тапкыр өйгә кертәләр. Ана, ишек төбендәге лаканга салып, күп итеп он сибеп, башак бутап бирәләр, ашаталар-эчертәләр, бозавын имезәләр, калган сөтен савалар.

Бозауны, бәрәннәрне яратабыз без, сыерны яратмыйбыз, аның белән дуслаша алмыйбыз, дуслашырга да теләмибез. Мөгезләре бик зур, шуның өстенә хәлфә апа да һаман әйткәләп тора:

—Бәпкәчләр, бәпкәчләр, сак булыгыз, якын бара күрмәгез! Мөгезе белән чөеп ыргытмасын. Бик усал ул...—ди.

Китапларны да аның тирәсендә калдырмаска куша ул. Хәлфә апаның әйтүенә караганда, китапны бик ярата икән. Хәер, без моны үзебез дә беләбез. Китап белән килеп тә, китапсыз елап кайтып киткән кызлар моны тагын да яхшырак беләләр.

Бер почмакка, сыер керә алмаслык җиргә кысылабыз, тик ул чыгып киткәч кенә түр ягына аяк атларга батырчылык итәбез. Кызлар ул калдырган эзләрне ашыгып-ашыгып сөртәләр, юалар.

Юк, сыерны яратмыйбыз без, ул безгә «сабакташ» була алмый.

Тыштагы һәм өйдәге эшләр беткәч кенә кызлар, кулларын юып, бисмилла әйтеп, букчаларыннан китапларын чыгаралар, сабакларын тынлаталар, яна сабак алалар. Өй эче язгы ташкын сыман шауларга, гөрләргә тотына...

Хәлфә абзый зуррак кызларны укыта. Алар «Һәфтияк», «Коръән»,

«Тәкый гаҗәп», «Сабит алма», «Фәзаилеш-шөһүр», «Йосыф китабы» кебек китаплар укыйлар.

...«Һәфтияк» дигәне «Коръән»нең бер кисәге, җиделән бер өлеше. Аны иҗекләп, көйләп тә укыйлар. Бу китапка керү өчен башта «Иман шарты» дигән дәреслекне укырга, хәреф танырга, иҗекне үзләштерергә кирәк. Шунсыз «Һәфтияк»кә керешмиләр.

Югарыда исемнәре телгә алынган китапларның өчесе «Тәкый гаҗәп», «Сабит алма», «Йосыф китабы» көйле китаплар. Шулай ук хәлфә апа укыта торган «Бәдәвам» да көйле китап. Аларны көйләп укыйлар, шуңа күрә көйле китап дип атыйлар да. «Фәзаилеш-шөһүр» исә кыска-кыска дини хикәяләрдән торган китап...

«Йосыф китабы» аерата якын миңа. Апаларым аны сагышлы, моңсу тавышлары белән көйләп укыганда, тыныч кына тынлый алмыйм. Йосыфны абыйлары, юмалап, иркәләп, без сине яратабыз, синә бик матур җирләрне күрсәтеп кайтыйк әле дигән булып, сәхрага күтәреп чыгып киткәннәр дә төпсез коега ташлаганнар. Бер дә яратмаганнар, әтисеннән көнләгәннәр аны, дошман күргәннәр. Дошман күрмәсәләр, нигә дип ул мескен кечкенә малайны, үзләренең энеләрен, ачы сулы коега, мыжлап торган еланнар, чаяннар, хәшәрәтләр янына ташларлар икән? Җитмәсә, үзләре, ялганлап, елагандай булып, әтиләре янына кайтканнар да:

—Йосыфны бүре ашады, менә күлмәге генә калды,—дип, аңа канлы күлмәк күрсәткәннәр. Күлмәкне юри кәҗә бәтие канына буяганнар.

Иртәгесен исә, шул ук явыз абыйлары аны, елатып, үкертеп, ялынуына, ялваруына карамастан, кәрван белән үтеп баручы чит-ят бер кешегә кол итеп сатып җибәргәннәр.

Апаларым көйләп укый торган «Йосыф китабы»н мин шулай аңлыйм, бала акылым белән шулай күз алдына китерәм. Шуның белән бергә, бу дәһшәтле вакыйга безнең авылда, яисә әти белән бергә баргач, күрергә туры килгән күрше авылларның берсендә булгандыр шикелле тоела иде. Сәхра да, төпсез кое да, хәтта кәрваннар узып йөри торган олы юл да әллә кайда түгел, ә шундадыр шикелле иде. Минем карашта әле дөньяның чиге дә әллә кайда еракта түгел, ә шул ук күрше авыллар артында, офык итәкләре янында иде.

Кол итеп сатылуның ни икәнен белми идем мин. Апаларым да белмәгәннәрдер дип уйлыйм. Шулай да инде мин, кешеләрне булмаса да, терлек-туарны сатуның ни икәнен беләидем.

Быел җәй көне безнең күрше Сөнгат абзый үзенең бик матур таен сатып җибәрде. Таен сатарга җыена икәнен ишеткәч, без бөтен тирә-күрше малайлар, алар капкасы төбенә җыелдык. Зуррак малайлар ишек алдына ук кереп киттеләр, мин бары капка ярыгыннан гына карап тордым. Ишек алды уртасында озын буйлы, җирән сакаллы, бик явыз кыяфәтле бер ят кеше, мескен тайны җиргә егып салып, бармак юанлыгындагы бау белән аның аякларын бәйләп маташа иде. Тайның бер дә бәйләтәсе килми, чәбәләнә, тыпырчына, урыныннан торырга азаплана, елагандай кешнәп, әнисен чакыра, башын җиргә бәреп-бәреп ала, Җирән сакал тайны үзе генә бәйли алмады, бер читтә моңсу гына басып торган Сөнгат абзыйга, нәрсәдер әйтеп, кычкырып салды. Сөнгат абзый, сискәнеп киткәндәй куркып, тай янына килеп иелде. Аннары алар аны әлеге кешенең арбасына күтәреп салдылар. Тай, арбага салгач та, тыпырчынуыннан туктамады.

Капканы ачтылар, мин бер читкә тайпылдым. Җирән сакаллы явыз кеше, аякларын салындырып, арбага менеп утырды да алашасына чөңгереп җибәрде, арба кузгалды. Мескен тай, нигә бәйләдегез мине, ни гаебем бар, дигәндәй, һаман тыпырчына, башын күтәрә, чәбәләнеп, зур кара күзләре белән кешеләргә карый, коткаруларын сорый, аннары, хәлсезләнеп, башын арбага сала һәм шунда ук, яңадан күтәреп, тыпырчынырга, каты кысып бәйләгән баудан ычкынырга, котылырга тели.

Арба урам буйлап китте. Без, күрше-тирә малайлары, бөтенебез бергә өерелеп, аның артыннан иярдек. Урамда чабып уйнап йөргән, яисә, бу хәбәрне ишетеп, өйләреннән йөгереп чыккан башка малайлар да безгә килеп кушылдылар. Сөнгат абзый да, таеннан аерылырга теләмичә, бер кулы белән арба үрәчәсенә тотынып, икенче кулын адымы жаена селкеп жибәрә-жибәрә, берәүгә бер сүз әйтмичә, тик ара-тирә күлмәк жине белән күз яшьләрен генә сөрткәләп алып, кыр капкасын чыкканчы озата барды. Капканы чыккач, Жирән сакалга нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, бер ана, бер тайга караштыргалап алды, ләкин бернәрсә әйтмәде, әйтеп ни файда дип уйлады булса кирәк, кулын гына селтәде, аннары, кинәт борылып, ындырлар арасына кереп китте. Сөнгат абзыйның бүгенгедәй башын түбән иеп, бөкресен чыгарып йөргәнен беркайчан да күргәнем юк иде. Тай артыннан өзлексез елап барган малайлары (ике малай, икесе дә миннән зур) аның ындырлар арасына кереп китүен күрсәләр дә, артыннан иярмәделәр, безнең белән баруларын дәвам иттеләр. Тайны саткан өчен алар әтиләренә бик каты үпкәләгәннәр иде. Ничек үпкәләмәскә! Мин дә үпкәләр идем. Шундый матур, шундый акыллы тайны күрмәгән-белмәгән кешегә сатып жибәрсен әле.

Сөнгат абзый ындырлар арасына кереп киткәч, әлеге жирән сакаллы кеше, безгә чыбыркысын селтәп, ачуланып:

—Нигә иярдегез сез?! Ни калган сезгә?.. Бар, кайтып китегез, маңкалар! Югыйсә, мин сезне!..—дип, берничә тапкыр янаса да, курыкмадык, чәпчүенә, орышуына карамадык, арбадан бераз калышып булса да, тай артыннан баруыбызда булдык. Гөбенә күперен чыгып, бераз баргач кына, туктадык. Туктагач та әле тиз генә борылып кайтып китмәдек, юл өстенә өелешеп баскан килеш мескен тайны күзләребез белән озатып калдык. Арба ераклашканнан-ераклашты, бераздан карамчык булып кына күренә башлады, аннары бөтенләй күздән югалды. Тик шуннан соң гына авылга таба борылдык.

Гөбенә елгасына житкәч, арабыздан кайсыдыр:

—Әйдәгез, су коенабыз,—диган иде дә, көн эссе булуга карамастан, берәү дә коенырга теләмәде, мин дә теләмәдем, чөнки кайгыбыз зур иде, күнелләребез һаман әрнеп, сыкрап тора, елыйсыбыз килә иде.

Житмәсә, кайсы малайдыр шунда:

—Ул кешене беләм мин, итче ул. Суярга алып китте ул аны,—дип әйтеп куйды.

Моны ишеткәч, котыбыз чыкты, катып калдык. Сөнгат абзыйның кече улы, Гарифулла абый, күз яшьләрен тыя алмыйча, юл буе шыншып килгән иде, бу сүзләрдән соң түзмәде, кычкырып елап, жиргә йөзтүбән капланды. Өлкәнрәк малайлар аны юатырга, көйләргә керештеләр, әлеге эт авызның сүзе дөрес түгеллеген, ялган икәнен әйттеләр. Гарифулла абыйны жирдән күтәреп торгызсалар да, тынычландыра алмадылар, сыгылып-сыгылып үксүен дәвам итте.

Малайларның теге эт авызга каннары бик кызды, кирәкмәгән сүз сөйләгән өчен, аны бик ачуланып, орышып, арабыздан куып жибәрделәр, хәтта кайберәүләр артыннан таш ыргытып та калдылар. Юкны сөйләмәсен, лыгырдамасын... Авызыннан жил алсын иде аның сүзләрен!.. Шундый матур, шундый акыллы тайны суялармыни! Ана ничек кул күтәрелсен. Әгәр суйса, жир йотар үзен, аяз көнне яшен сугар!

Малайның сүзенә ышануын ышанмадык, ялганлый торган гадәте бар иде аның, шулай да сүзе күңелебезгә шом салмыйча калмады, йөрәгебезне өтеп алды.

Бу кайгыны без тиз генә оныта алмадык. Мескен тай кайчак төшемә дә керә иде. Мин аны жирән сакалдан качып кайткан итеп күрә идем. Күрәсең, качып кайтуын бик теләгәнмен. Имеш, ул качып кайткан да, урамда, Сөнгат абзыйлар өе тирәсендә елагандай кешнәп, өтәләнеп чабып йөри, бер капкага килә, бер читкә китә. Тик нигәдер капканы ачмыйлар, ишегалдына кертмиләр... Яисә мин аны аларның ишегалдында итеп

күрәм. Аяклары бәйләнгән, җирдә ята, тыпырчына... Мин аны чишмәкче, коткармакчы булам. Чишә алмыйм, шулкадәр чиләп бәйләгәннәр, көчем җитми, тешләрем белән ябышам да, алай да булдыра алмыйм... Ишегалды буп-буш. Беркем юк. Урамнан малайлар тавышы ишетелә. Аларны ярдәмгә чакырам, кычкырам, кычкырам... ләкин тавышым чыкмый, хәтта үз тавышымны үзем дә ишетмим, бары гыжлыйм гына... Куркып, уянып китәм, як-ягыма гаҗәпсенеп карыйм: тай юк, Сөнгат абзыйлар ишегалдында да түгелмен, ә өйдә, идәндә, энем белән янәшә ятам, бөтен тәнем шабыр тир... Күңелем буш. Моңсу. Елыйсым килә...

Бик ияләшкән идем мин аңа, бик ярата идем мин аны. Ничек ияләшмәскә, ничек яратмаска кирәк аны? Бик матур иде ул. Күршетирә малайлары белән бергә мин, кайчакларда Сөнгат абзыйлар ишегалдына кереп, аның тирәсендә шактый вакыт әйләнгәләп йөри идем, кулымдагы ипи кисәген сузып, аны муеныннан да, аркасыннан да сыйпаштыргалый идем. Ипи алып кергән көннәрдә Сөнгат абзый малайлары миңа аның янына барырга, аны сыйпарга рөхсәт итәләр иде. Аны сыйпау, аңа кулым белән орыну бик күңелле, бик рәхәт иде. Атларыбыз булса да, таебыз юк иде безнен.

Кем белә, бәлки, аның кебек матур тай бөтен тирә-якта булмагандыр. Күзләре зур, кара, ялы тырпаеп тора, койрыгы кыска, бераз бөдрә. Хәер, ялы да бөдрә сыман. Аяклары нечкә, озын, бәкәлләре ак, ә үзе туры айгыр буласы. Кояшлы көннәрдә йоны җем-җем итә. Бер караганда кызгылтсу, икенче караганда көрәнрәк булып күренә. Кыскасы, әйтәсе юк, матур тай!

Тай кайгысы күңелемдә озак сакланды—бик кызганыч иде ул. Ләкин Йосыф аңа караганда да кызганычрак иде. Ни әйтсәң дә, кеше баласы ул. Абыйлары кол итеп сатканнан соң, аны да шулай, кулларын-аякларын бәйләп, елавына, тыпырчынуына карамастан, арбага салып алып киткәннәрдер шикелле тоела иде. Аны бәйләп алып китүчеләрне дә мин, нигәдер, әлеге җирән сакаллы кеше төсле котсыз, явыз кыяфәтле итеп күз алдына китерә идем. Апаларым Йосыфның кол ителеп сатылу турындагы юлларны укыганда күз яшемне тыя алмый идем.

...Без үскән елларда халык арасында бик таралган китап иде ул. Хатын-кызлар аның күп кенә сәхифәләрен яттан беләләр иде, иң кимендә, берничә юлын гына булса да яттан укыйлар иде. Әбием белән әнием дә укый иде ул китапны. Ул ипи шүрлегендә, бик кадерле урында саклана иде. Кайчакларда әнием, ир-зат өйдә булмаганда, кич белән без йокларга яткач, яныбызга килеп утырып, безгә аның кайбер урыннарын күңеленнән көйләп укый иде...

...Апаларым шигырь белән язылган китапларның барысын да көйләп укыйлар иде. Гәрчә андагы сүзләрнең күбесен аңламасам да, эчтәлеген төшенеп бетермәсәм дә, көйләп укуларын яратам. Моңлы да, сагышлы да итеп укыйлар. Бер тыңлаганда, кайгырып җырлаган шикелле, икенче тыңлаганда, әрнеп, көеп елаган шикелле тоела иде миңа. Бирелгән сабакларын укып бетергәннән соң, тирән сулап, көрсенеп куялар. Алар да Нөнкир-Мөнкирләрдән, зобаныйлардан, тәмугълардан, андагы җәзалардан, янулардан куркалар иде. Берәүнең дә янасы килми—аларның да, минем дә.

Тагын мин «Фәзаилеш-шөһүр»дәге әкиятләрне тыңларга яратам. Дөрес, аларның берсе дә моңача миңа урамда, капка төбендә җыелышып утырганда тыңларга, ишетергә туры килгән әкиятләргә охшамыйлар. Бу китапта хәйләкәр тазлар да, җиде башлы еланнар, аждаһалар белән сугышып, аларны җиңеп, патша кызларын коткарып кайтучы батыр егетләр дә юк, шулай да андагы әкиятләрне тыңлап утыру кызык һәм күңелле.

...Бер заман ач шайтан белән тук шайтан юлда очрашалар. Тук шайтан зур, таза гәүдәле, кызыл чырайлы. Ач шайтан исә, ябык, хәлсез, аягына чак басып тора. Тук шайтанны күргәч, ул бик гаҗәпләнә һәм аңардан сорый:

—Син әле күптән түгел генә минем кебек ябык иден. Бу кадәр тиз ничек тазардын? Нәрсә ашап торасын?—ди.

Тук шайтан үзенең нигә болай таза икәнен аңлатып бирә:

—Тамагым тук минем,—ди.—Хуҗам бисмилла әйтмичә ашый. Аның азыгын ашыйм, шуңа тазарам. Кешеләргә ул үзе ашаган булып күренә, ә дөресе, аның урынына мин ашыйм,—ди.

—Хуҗаң тазамы соң?—дип сорый аңардан ач шайтан.

—Нигә таза булсын ул, азыгын мин ашап баргач. Ябык. Көннән-көн ябыга,—дип җавап бирә тук шайтан һәм ач шайтаннан сорый:—Ә син нигә болай ябык?

—Нигә ябык булмыйм. Хуҗам табын янына утыру белән үк бисмилла әйтә, ашарга ирек бирми. Шуңа күрә һаман ач йөрим, ябыгам,—дип зарлана аңа ач шайтан...

...Шайтаннар барысы да усал алар. Кешеләрне бозарга, тугъры юлдан яздырырга гына торалар. Апалар укый торган китапларда шайтан мәлгуньнәр турында шулай язалар.

Мин, шайтаннар артыннан куып йөреп, бераз читкә киттем. Яңадан мәзин өенә, «мәктәбебезгә», бозаулар, тынгысыз бәрәннәр арасына кайтыйк.

Хәлфә абый түр ягында зуррак кызларны укыта. Зур дигәч тә монда унике-унөч яшьтән олы кыз юк. Бу унөч яшьтән узган кызлар, йә өйдә генә утыралар, йә, тагын да «белемнәрен» арттырырга теләп, мулла өенә йөри башлыйлар, остабикәдән сабак алалар. Анда да шундый ук китапларны укыталар. Тик аерма шунда: мулла абзыйларның өйләре зуррак та, матуррак та. Түбәсе дә, мәзиннеке кебек такта белән түгел, ә калай белән ябылган, яшел төскә буялган.

## VI

Минем урыным почмакта, бәрәннәр арасында. Кулымда «Иман шарты».

Халык телендә «Иман шарты» дип аталган бу «дәреслек»—уналты битле, кечкенә бер китап. Тышына гарәп хәрефләре белән «Шәриатыл-иман» дип язылган. Татарчага әйләндереп әйтсәң, «иман шартлары» дигән сүз...

...Иртә белән дә, кич тә кызлар, өй тулы бәрәннәрне имезергә дип, тыштан сарыкларны алып керәләр... Алар бөтен өйне тутыралар, безгә басып торырлык та урын калмый. Без стена буйларына кысылабыз, сәке өсләренә менәбез. Менә шул вакыт, дөньяңны онытып, хыялга бирелеп, китабыңны бер читкә куйсаң, хәлфә апа сүзе белән әйткәндә, авызыңны ачып торсаң, берәр явыз сарык шунда ук аны теле белән ялмап ала да чәйнәргә керешә, син еларга өлгергәнче, йотып та җибәрә. Бәрәннәр исә, һәрвакыт диярлек, нәни авызлары белән «Иман шарты»на үреләләр. Аларның бу гадәтләре безгә дә кызык. Без «Иман шарты» битләрен бәрәннәргә ялатабыз, аларны, кызыктырып, артыбыздан иярте йөрибез.

Сабакка озатканда әни һәрвакыт диярлек колагыма тукып җибәрә иде:

—Кара аны, китабыңны сарыклар, бәрәннәр ашый күрмәсен. Сарыкларны керткәч, сак бул, китабыңны кулыңнан төшермә,—ди иде. Әни бәгъре колагыма ничек тукыса да сак була алмадым. Беренче кышны каһәр төшкән сарыклар ике «Иман шарты»н харап иттеләр. Берсен ак сарык, сәке өстендә калдырган җирдән алып, күз ачып йомганчы чәйнәп йотты, кычкырырга да, еларга да өлгермәдем. Икенчесен кара сарык ашады.

Язгы кояшлы көннәрнең берсе иде. Тышта инде кар эри башлаган. Өй түбәсеннән тамчылар тама, тәрәзә каршындагы ялангач шомырт ботакларына кунган чыпчыклар канатларын кага-кага, чыркылдый-чыркылдый, нәрсә турындадыр сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Шунда ук

бик житез бер песнәк, ботактан ботакка оча-куна, нәрсәдер эзли, карана...

Мин, дөньямны онытып, тәрәзә янында шуларга кызыгып карап торганда, кызларның сарыкларны өйгә кертүләрен, бәрәннәрне имезә башлауларын сизми дә калганмын. Бары кулымдагы «Иман шарты»н янымдагы явыз кара сарык тартып алгач кына аңыма килдем. Ләкин югалып калмадым, шунда ук, елан чаккандай, чәрелдәп кычкырып, сарык өстенә ташландым, йонына ябыштым. Сарык, үз гаебен сизеп һәм китабымны бирмәскә теләп, мине почмактан түр ягына өстерәп алып чыгып китте. Аннары башка сарыкларны, бәрәннәрне өркетеп, айкалып бераз йөргәннән соң, яңадан почмакка килеп керде, шулай да авызыннан китабымны ычкындырмады, ашыгып-ашыгып чәйнәвендә булды.

Ул котылырга тели, кача, ә мин аның куе йонынннан кулларымны ычкындырмыйм, кычкырам, башкаларны ярдәмгә чакырам, китабымны аның авызыннан алырга азапланам. Әгәр шул вакыт олырак кызлар ярдәмгә килмәгән булсалар, почмаклы-түрле сәяхәтебез шактый дәвам иткән булыр иде. Сарык зур, көчле иде, мине җилтерәтеп кенә йөри иде.

Барыбыз бергә җыйнаулашып тартыша торгач, каһәр төшкән сарыкның авызыннан мескен «Иман шарты»н коткардык... Ләкин, кызганычка каршы, аның чиреге генә калган, ул да сарык селәгәе белән укмашып, изелеп беткән иде.

Китабымның бу калдыгы өстендә мин ул көнне күз яшемне аз түкмәдем. Шуннан соң, ике тапкыр авызым пешкәч, сак булдым, бер китабымны да ашатмадым. Аның каравы, үзем ике «Иман шарты»ның башына җиттем. Берсен югалттым, берсен, бик тырышып укый-укый, тетеп, туздырып бетердем...

...Бер көнне без, туңып, өшеп, үзебездән дә зуррак салкын ияртеп, мәзин өенә барып кергәндә, таң атып килә иде әле. Йокыбыз да туймаган, укыйсыбыз да килми иде. Хәлфәм безнең, бигрәк минем укыйсым, мәгънәсез ижекне кабатлыйсым килмәгәнне белми иде, билгеле. Апалар тышка, терлекләр карарга, ишегалдын себерергә, су ташырга чыгып киткәч, хәлфә апа мине:

—Кил әле, бәпкәч, кил әле,—дип, асылмалы лампа янына чакырып алды.—Сабагыңны тыңлатыйм әле. Ятлагансың инде, белә торгансың.

Мин, бишмәтемне дә, бүрегемне дә салмыйча, китабымны тотып, хәлфә апа янына барып бастым. Ул дөрес әйтә, чыннан да ятлаган идем мин. Хәтта, ятлый-ятлый туеп беткән идем. Чөнки ижегемнән бернәрсә аңлашылмый, ә минем аны аңлашырлык итәсе килә иде. Ятлый торгач, тырыша торгач, аңлашырлык булып чыкты шикелле.

—Йә әле, бәпкәч, укып кара әле,—диде хәлфә апам, бик ягымлы итеп. Кайчак ул шулай бик ягымлы эндәшә иде. Баласыз хатын иде ул һәм безне, кечкенәләрне ярата, ире өйдә булмаган чакларда, янына утыртып, «бәпкәч» дип әйтә-әйтә, аркабыздан сөя, башыбыздан сыйпый иде...

Мин инде ижегемнең «кәлимәтен таййибәтен» дигән ике сүзен беләм. Бу миңа җитә калды. Бер нәрсә аңлатмый торган мәгънәсез ижекне кабатлый-кабатлый тәмам туйгач, шул заманда балалар арасында таралган такмакны бик рәхәтләнеп, яратып такылдый башладым:

Кәлимәтен таебәтен,  
Минем әни бай хатын;  
Изүе тулы тәңкә,  
Борыны тулы маңка.

Моның икенче варианты да бар. Аның өченче-дүртенче юллары:

Маңгаенда ука-чук,  
Сандыгында б.. та юк,

дигән сүзләр белән тәмамлана.

Әни турында мондый сүзләрне такмаклавы яхшы булмаса да, мин аны күңелемнән үз әнием итеп түгел, ә башка, мин белмәгән малайның

әнисе итеп күз алдына китерә идем, шуның белән күнелемне тынычландыра идем. Бөтен өйне тутырып торган шау-гөр арасында такмагым янымдагы иптәшләремә генә ишетелә иде. Хәлфә апам исә, авызым кыймылдаганны күреп, мине укый дип уйлый иде...

## VII

...Ул көннәрдә, «Иман шарты» күтәреп сабакка йөргәндә, миңа дөньяда хәлфә апамнан да галим, аңардан да зуррак укыган кеше юктыр шикелле булып тоела иде. Мин аңа, аның галимлегенә чын күңелдән ышана идем.

Кайчак абыйларым өйдә хәлфә апам турында үзара бик гаҗәпләнеп сөйләшәләр иде.

—Ничек укыта икән ул? Чеп-чи надан бит. Әлифне таяктан аера белми,—диләр иде.

Мин әлифне таяктан аеруның ни икәнен белмәсәм дә, аларның минем кадерле хәлфә апамнан көлүләрен, аны хурлауларын төшенеп, чын күңелдән әрни идем, хәтта күз яшьләремне дә кызганмый идем.

Хәлфә апамның «күзе шәйләмәве» өчен кайгырмый идем мин, бары шатлана гына идем. Чөнки соңрак, берәр сүзләп иҗекли-иҗекли, китапның уртасына җиткәч, сабагымны белмәгән чакларда мин, аның күзләре «шәйләмәвеннән» файдаланып, ул төртеп күрсәткән сүз урынына бөтенләй икенче сүзне иҗекли идем. Ансатрак иҗекләсәм, телем-телгә йокмаса, ышана иде ул. Шулай итеп, мин аны, мескен карчыкны, күрәләтә алдалый идем. Рәхмәт яусын аңа, шуның өстенә ул мине мактап та куя, башымнан да сыйпаштыргалый иде. Яшерми әйтәм: кайчакларда ул, алдавымны сизеп:

—Тукта, тукта әле, бәпкәч, дөрес укымыйсың шикелле. Алдыйсың бугай,—дип, колагымнан эләктереп ала иде.

Миһербанлы хәлфә апам колагымнан тотса да, йолкымый, бормый, тик бераз тарткалый гына иде. Мондый тартуларга үпкәләми идек без. Сабый бала булсак та, колакларыбыз күпне күргән иде инде. Мескен колакка тынгылык юк иде ул заманда. Аны тиешлегә дә, тиешсезгә дә тотып боралар, йолкыйлар, тарталар, хәтта кайберәүләрне, усал малайларны, билгеле, колагыннан тотып, типкәләп, өстерәп тә йөриләр иде. Кайчакларда колакларыбызның кып-кызыл булып, ут шикелле янып торуына берәү дә гаҗәпләнми иде.

Шулай да колакларыбызны һәр нәрсәдән кадерләбрәк саклый идек без. Урамда берәрсе колакка үрелсә яисә, колагыңны кисим әле дип, кесәсендәге пәкесен капшый башласа, шундук бер читкә сыза идек. Барыннан да бигрәк, бабачыдан, аның күпне күргән чалгы пәкесеннән курка идек без. Андый чакларда өйгә таба үкчә күтәрүне, капка астыннан җәлт итеп кереп китеп, берәр аулаграк урында посып утыруны яхшырак саный идек. Башка вакытларда эт белән кусалар да, капка астыннан болай ансат һәм тиз шуып керә алмас идек.

Өйгә кайткач, сабагымны ара-тирә тыңлаталар яисә тыңлатырга тырышалар иде. Шуңа күрә мин хәлфә апамнан алган бер авыз иҗекне бөтен күңелем белән бирелеп ятларга тырыша идем. Шулай да өйдә сабагымны тыңлатасы килми иде. Апаларым тыңлатсалар, иҗегемнән һәр юлы хата табалар, хата тапкан саен, йә чеметәләр, йә колагымны эләктереп алалар иде. Чеметкәч тә, колакны да йолкыгач, нигә тыңлатыйм мин аларга! Әнием сукмый, кыйнамый, рәнҗетми, бары яхшырак укырга гына үгетли иде.

Әтием сабагымны сирәк тыңлата иде—вакыты юк иде. Ул, базардан-базарга йөреп, сату итә, өйгә төн урталарында гына туңып кайтып керә һәм без йокыдан торганчы яңадан чыгып китә—атнага бер-ике генә көн өйдә була иде. Шулай да ул беркөнне сабагымны тыңлатмакчы булды һәм таң белән «мәктәпкә» чыгып китәр алдыннан әйтеп куйды:

—Сабагыңны белеп кайт, тыңлатам,—диде.

Ул көнне миңа хәлфә апам «вәләктебе» дигән сүзне иҗекләргә бирде. Бу сүзне бик ошаттым мин. Аның татарчага тартымы бар иде. Алла сүзен бозмыйча, аны, шаярып, вәләк төбе дип тә, яңак төбе дип тә әйтеп була. Әтигә тыңлатасы көнне шундый ансат сүзнең туры килүенә бик шатландым һәм аны чын күңелдән бирелеп ятларга керештем, мич арасында кысылып басып торган килеш өзлексез кабатладым. Бәрәннәр белән дә, бозау белән дә уйнамадым. Нигә вакыт әрәм итәргә! Әтигә сабагымны тыңлатасы бар...

...Иҗекнең «вәләк, вәләкте, вәләктөбе» дигән өлешләрен бик ансат ятладым. Чөнки ул миңа «бәләк» булып ишетелә иде. Өйдә бәләгебез бар иде. Сабагымны кабатлаганда ул һаман күз алдымда торды. Кер чаба-чаба ашалып, шомарып беткән имән бәләк иде ул. Еш кына аяк астында аунап йөргән, моңарчы игътибарымны берничек тә җәлеп итмәгән менә шул авыр, салмак бәләк бүген, алган сабагым белән бергә уралып, җанланып, нурланып китте, алтын сыман ялтырап торган саргылтсу төсе, очып барган үрдәккә охшаган килбәте белән күңелем күгендә йөзә башлады. Ниһаять, китабымнан татарча сүз чыкканга шатланып, рухланып, иҗегемнең ахырын йә «вәләктөбе», йә «яңак төбе» дип кычкырып-кычкырып, хәтта ашкынып тәмамлавымда дәвам иттем.

Бик яхшы ятладым, өйрәнеп җиттем дип уйлагач, өйгә иртәрәк кайтырга булдым, апаларымның ишек алдында эшләре беткәнен көтмәдем. Нигә көтим? Әтигә сабагымны тыңлатасы бар. Онытылганчы кайтып җитим.

Сабагымны яхшы өйрәндем, беләм, әти мактамый калмас дигән уйда идем мин. Яшермим, макталырга тели идем.

Көн кояшлы, салкын. Шулай да борынны өшетерлек түгел. Салкын булса да, туңмыйм. Өстемдә бишмәт, аягымда үкчәсенә күн салган киез итек (миңа кадәр аны апаларым киеп-киеп тә туздыра алмаганнар), башымда әлеге, күпне күргән, бабамнан калган тирән эчле, кырпулы бүрек. Аңа мин борыным, колакларым белән кереп чумганмын. Кулларымда киндер тышлы зур бияләй. Әллә ни зур түгел, учлап тотсаң, кулдан төшми.

Рәхәт. Күңелем күтәренке. Нигә күтәренке булмасын? Сабагымны беләм, әтигә тыңлатырга кайтам. Кеше кебек, юлдан түгел, ә кичә яуган йомшак карны сөреп кайтам, бернәрсәгә дә, койма башларындагы чәүкәләргә дә, чыпчыкларга да карамыйм, аларны санап та тормыйм, сабагымны кабатлыйм. Онытыла күрмәсен!

—Ваусенвә, ләмсенвәлә, кәпкәсәкен вәләк...

Шулай бик тырышып, бөтен күңелем белән бирелеп, иҗекли-иҗекли өйгә кайтып барганда, көтмәгәндә каяндыр, Камалулла капка астыннан булса кирәк, шалама бер этнең, атылып чыгып, сикерә-сикерә миңа өрә башлавын сизми дә калдым һәм, куркуымнан чәрелдәп кычкырып җибәреп, йөгерергә тотындым. Биш-алты адым да атлый алмадым, тирән көрткә йөзтүбән капландым.

Безнең тирәдә мондый явыз, мондый шалама эт юк иде бит! Каян килеп чыкты соң бу каһәр төшкере.

Әле рәхмәт, урамнан узып баручы Камалулла бабай кулындагы таягы белән этне куып җибәрде дә мине, юатып, иркәләп күтәреп торгызды, көрт өстенә сибелгән итегемне, бүрегемне, бияләйләремне җыеп бирде, хәтта букчамны да кулыма тоттырды. Букчамны тоттыруын тоттырды, юлга да чыгарды, өс-башымны да какты, еламасын дип, җылы сүзләр дә әйтте, ләкин шулай да хәтеремнән чыгып качкан иҗекне табып бирә алмады. Егылган җиремнән торганда инде сабагымның бары «вәләк, вәләк төбе» дигән сүзләре генә исемдә иде. Хәер, «яңак төбе» дип шаярып әйткән сүз дә күңелемдә сакланган икән.

Бик күңелсезләнеп, куркып, өйгә кайтып кердем. Әле ярый әти өйдә булмады. Шулай да, кайтып кереп, сабагымны тыңлата күрмәсен дип, тиз генә мич башына менеп постым. Чөнки иҗегемне инде оныткан

идем, ә «вәләк төбе, янак төбе» дигән сүзләрне тыңлатасым килми иде. Сабый чагыбызда янакларыбызга болай да, кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә эләккәли иде.

## VIII

Ярты кыш үтеп бара.

«Мәктәпкә» тәмам күнегеп життем, сарыклар, бәрәннәр белән дуслаштым, гадәтләрен беләм: китабымны ашатмыйм.

Зәһәр салкыннарда да сабагыбызны калдырмыйбыз, иртә белән дә, кич белән дә барабыз. Бармыйча калырга ярамый,—мәзиннең терлекләрен, казларын, тавыкларын карарга, ашатырга-эчертергә, асларын чистартырга, аннан чыккан тиресне өеп куярга, яисә бакчага чыгарып түгәргә кирәк. Ишек алдын да жыештырасы, себерәсе бар. Кар-бураннар әледән-әле булгалап тора, кайбер көннәрне авылыбызның кечерәк өйләрен күмеп китә. Мәзиннең дә өе зур түгел. Житмәсә, авыл читендәрәк. Буран аны да, мәзин дип, балалар укыта, хәлфә дип, кызганып тормый, күмә. Андый көннәрдә без таң белән алар ишек алдына көч-хәл белән кар ерып керәбез. Апаларым һәм алар яшендәге кызлар букчаларын өйгә кертеп чыгалар да кулларына көрәк белән себерке алалар. Кар бик күп булып, хәлфә абый ат белән тарттырса, аңа булышалар, тарттырмаса, үзләре көрәп, төяп, чана белән урамга чыгарып аударалар, ишек алдын да, капка төбен дә себерәләр, ялт иттерәләр.

Апаларга өйдә дә эш бетмәгән: идән юалар, тузан сөртәләр, кер уалар, аны Гөбенәгә алып барып, чайкап кайталар, хәтта йон да эрлиләр, оек та бәйлиләр, бәйләмәсләр иде, хәлфә апаның күзе «шәйләп» бетерми.

Безнең кебек кечкенәләргә дә эш житәрлек—Кадер киче ипиләре әле бетмәгән. Гәрчә инде казлар суелган, каз өмәләре күптән узган булса да, асрарга калдырганнары бар, аннары тавыклары да аз түгел. Башмак танага да кирәк. Аларның да без чәйнәгән ипине ашыйсылары килә.

Мин сабакка йөрим, иртә белән дә, кич белән дә барам, ә менә Кечкенә абыйга нәрсәдер булды, соңгы көннәрдә ул мәдрәсәгә теләр-теләмәс кенә йөри башлады. Көндез баргаласа да, төнлә анда кунмый. Әй, мин Кечкенә абый кебек зур булсам, гел шунда кунар идем! Рәхәт анда. Төнгә каршы шәкертләр үзләре генә калалар, туйганчы уйныйлар, көрәшәләр, мендәр белән сугышалар, тычкан тоталар, тотканын-берен тәрәзә арасына ябалар, йә, коерыкларына тегәр жеп бәйләп, туйганчы уйныйлар. Төн уртасында урам егетләре жылынырга керәләр, төрле кызык нәрсәләр сөйлиләр,—әкият дисеңме, башларыннан үткән әкәмәт вакыйгалар дисеңме,—барысын да сөйлиләр... Юк, Кечкенә абый урынында булсам, мин бер дә мәдрәсәдән кайтмас идем. Өйдә аңардан:

—Әйт, нигә мәдрәсәдә кунарга теләмисең? Ни булды?—дигән сорауга каршы ул, башын иеп, мыгырдап кына жавап бирә:

—Ни булсын?.. Берни булмады. Анда кунасым килми, бары шул гына...

Бик төпченә, йөдәтә торгач, кунарга бармавының сәбәбен болай аңлатты:

—Ватык тәрәзә янында ятам мин, туңам. Шуңа күрә анда кунасым килми...—диде.

Кечкенә абый дөрес әйтә. Тәрәзәдән жил өреп торгач, кар бөртекләре дә кергәч, тундыргач, нигә кунсын ул анда. Юләрмени ул! Андый урында мин дә кунмас идем. Тәрәзә пыяласын куйгач, барыр, кунар, куганны көтеп тормас.

Монда, сәндерәдә, урыны жылы аның. Дөрес, сәндерә аның өчен кыскарагын бераз кыскарак та, шулай да аяк бөкләп яткач, сыярлык.

Кечкенә абый мәдрәсәгә кунарга бармаса да, сабакка йөри, иртә белән дә, кич белән дә, букчасын күтәреп чыгып китә. Тик, нигәдер, ул

хәзер сабактан иртәрәк кайта. Мин моны әнидән ишетеп әйтәм. Әни шулай ди. Аннары ул соңгы көннәрдә бик туңып кайта. Моны да әни әйтә. Аның каравы, хәзер ул бабайның да, әбинең дә, әнинең дә сүзен тыңлый, хәтта абҗингинең дә сүзен тыңлый. Элек ул, үтерсәң дә, абҗинги сүзен тыңламый иде. Хәзер ана эш кушып өлгерә алмыйлар, барысына да чаба. Эш дигән булып, кайчак сабакка да бармый кала. Әллә инде юри бармый кала?

Әни әйтә:

—Ни булды бу Галәтдингә?—ди.—Бик тә эш тыңлаучан булып китте,—ди.—Андый-мондый хәл юкмы икән?—ди, шикләнә.

Нәрсә булсын? Тыңлый. Бары шул гына. Мин дә үскәч, аның кебек сүз тыңлаучан булырмын әле. Хәер, мин хәзер дә тыңлыйм. Тик кайчак, нигәдер, кушканны бер дә эшлисем килми, ирендерә. Шундый чакларда мин зурларга гаҗәпләнәм: каян йомыш табып бетерәләр алар? Тегендә бар да, монда бар! Тегене эшлә дә, моны эшлә! Эшләмәсәң, ярамый. Ялкау, диләр. Ә минем бер дә ялкау исемен күтәрәсем килми.

Кечкенә абыйны әйтәм әле, мәдрәсәгә бөтенләй йөрмәгән икән ләбаса. Кунарга гына түгел, хәтта көндезләрен дә бармаган. Укырга барам дип, букчасын күтәреп чыгып китүе алдау гына булган икән. Мәдрәсәгә барырга теләмәгән үзе кебек башка малайлар белән бергә эт куып йөргән икән. Бабай шулай ди, йә төрле аулак урыннарда, суынып бетмәгән мунчаларда посып яткан икән. Ялганы тиз ачылды.

Әй, Кечкенә абый, Кечкенә абый, үзең шундый зур малай, ә үзең алдыйсың! Алдарга, ялганларга ярыймыни соң! Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр ич. Беленде, беленми калмады. Кырык ел түгел, кырык көн дә үтмәде хәтта.

Бер көнне кич белән, өйдәге бөтен бала-чага бергә җыелып, түрдә сәкедә уйнап утыра идек. Әни белән абҗинги дә шунда. Берсе җеп эрли, икенчесе бияләй тышлый.

Кечкенә абый сәндерәдә ята. Ул, төрле кыяфәткә кереп, сәндерә рәшәткәсе арасыннан башын чыгара да безне көлдерә: йә бүреген тиреле ягы белән әйләндереп кия, авызын-борынын чалшайта, күзләрен акайта, тешләрен ыржайта, әллә нинди тавышлар чыгара; йә, битенә корым белән сызып, сакал-мыек ясый да шамакай булып кылана... Ә без эчебез катканчы шыркылдап көләбез. Безгә көлке. Хәтта әни белән абҗинги дә түзә алмыйлар, алар да көләләр...

Шундый минутларның берендә чолан ишегенең ачылып ябылганы ишетелде,—бабай ястү намазыннан кайтып килә иде. Гадәттә бабай, мәчеттән кайткач, яшел башлы таягын чоланда калдырып, ак өйгә—үзе тора торган якка кереп китә иде. Өстен-башын салып, бераз җылынгач кына, безнең якка чыга иде. Бу юлы ул, нигәдер, аш ишеге янына туптуры килде һәм, керәчәген белдереп, ике тапкыр тамак кырды. Әни белән абҗингигә сигнал иде бу: «Мин керәм. Киленнәр, түрдә булсагыз, почмакка кереп китегез»,—дигән сүзе иде аның. Гадәте буенча ул, тамагын кырганнан соң, ишекне бераз ачмый торырга, киленнәргә почмакка кереп качарга мөмкинлек бирергә тиеш иде. Бу юлы ул гадәтен сакламады, шундук ишекне зур итеп ачып җибәрде. Әни белән абҗинги, урыннарыннан торып, тиз генә аңа аркалары белән борылдылар, яулыклары белән йөзләрен каплап, мескенләнеп, бераз бөгелә төшеп, баскан җирләрендә катып калдылар. Бабай ишектән кереп килгәндә, алар инде почмакка кереп китә алмыйлар иде. Юл «ябык». Тик бабай, тыштан алып кергән салкынны бөркеп, түргә узгач кына, алар йөзләрен һаман да каплаган килеш, кыерсытылган кешеләрдәй, бераз иннәрен җыера төшеп, почмакка кереп киттеләр. Бабайдан алар тел яшерәләр, аңа беркайчан да йөзләрен күрсәтмиләр.

Без бабайның ачулы икәнен бик тиз сизеп алдык. Чөнки ул ачулы чакта гына ишекне шулай тупсасына хәтле каерып ача да каты итеп яба.

Андый чакта без генә түгел, түшәмдәге жиделе лампа да куркуыннан калтыранып куя. Бу юлы да ул ишекне каты япты, лампа да куркуыннан булса кирәк, сүнәм, сүнәм дигәндәй, ике-өч тапкыр күзен йомып алды. Без тынып калдык.

Бабай түргә узды һәм, як-ягына каранып:

—Галәтдин кайда?—дип сорады.

Аңа җавап бирүче булмады, абый да эндәшмәде. Ул, бабайның тамак кырганын ишеткәч үк, сәндерәгә чумган иде. Ә без куркып калдык, чөнки бабай ачуланса, курка идек. Әни белән абҗинги исә, аңардан тел яшергәнгә, җавап бирмиләр иде. Тел ачып, җавап бирсәләр, бик зур әдәпсезлек булыр иде.

Бераз җавап көткәннән соң, бабай апалардан кайтарып сорады:

—Нигә әйтмисез? Теге җирбит кайда? Почмактамы, әллә урамда эт куып йөриме?—диде.

Бу инде бабайның бик ачулы икәнен күрсәтә иде, чөнки ул шундый чакта гына кешене «җирбит» дип атый. Димәк, Кечкенә абый хәзер аның күзенә чалынса, аңа чыбыктан яисә чыбыркыдан котылмак юк. Хәер, абый моны бездән яхшырак белә, шуңа күрә сәндерәдә тынын да чыгармый.

Билгеле, Кечкенә абый почмактамы икән, юкмы икән дип, бабай үзе дә кереп карый алыр иде дә, хәзер аңа анда керергә ярамый—анда киленнәре утыра. Әгәр керсә, бабай тарафыннан бу да зур әдәпсезлек эшләнгән була. Безнең бабай андый түгел.

Апалар җавап биреп өлгергәнче, энем, мәми авыз, юмаланган булып, сәлпе теле белән лыгырдап ташлады:

—Баба, баба, ул әнә анда... тәндерәдә ята...

Сәндерәдә ятамы? Бабай гына чыгып китсен, Кечкенә абый күрсәтер әле сиңа сәндерәне, яңакларыңнан ут чыгарыр.

Ул арада әнинең почмактан пышылдап кына әйткән сүзләре ишетелде:

—Кызым, Һаҗәр, әткәйгә әйт: Кечкенә абыең өйдә. Йоклый.

Бабай бу сүзләрне ишетсә дә, апа аларны шундук кабатлады:

—Бабай, әни әйтә: Кечкенә абый өйдә, ди. Йоклаган, ди.

Чыннан да, Кечкенә абыйның тавышы-тыны ишетелми,—юри йоклаган булып ята булса кирәк.

Энем бабайга тагын нәрсәдер әйтергә маташа иде,—беләм мин аны, Кечкенә абыйның йокламаган икәнен әйтмәкче була ул. Шуңа ачуым килеп, тиз генә ботыннан каты итеп чеметеп алдым. Тик кенә торсын, аннан сорамыйлар! Шундук ул, чәрелдәп, елак капчыгын чишеп җибәрде. Еларга дисәң, булдыра инде ул!

Бабай күреп торган икән ләбаса, башымнан түбәтәемне шап иттереп бәреп төшерде:

—Нигә тиясең аңа?! Мин сиңе!..

Елыйсым килсә дә, еламадым. Шул булыр инде—бабай һаман энемне яклый. Нигә яклый торгандыр аны? Тукта әле, бабай гына чыгып китсен, күрсәтермен әле мин аңа. Елакны! Чебен тими чер иткән нәрсә!..

Бабайның яхшы гадәте бар, беркайчан да ул безнең алда әтинең яисә әнинең сүзен аска калдырмый. Бу юлы да ул әнинең сүзен дөрескә чыгарды: әгәр әни: «Кечкенә абыегыз йоклаган»,—ди икән, димәк, йоклаган булып чыга.

Бабай ишеккә таба борылды.

—Уянгач, ул җирбиткә әйтегез, иртәгә иртүк мәдрәсәгә барсын,—диде.—Бармаса, миннән шәфкать көтмәсен. Күлмәген салдырып, ярырмын.

Бабай чыгып китте, өй эче яңадан тынып калды.

Әни белән абҗинги дә почмактан түргә чыктылар, абыйның да сәндерәдән башы күренде. Мин аны сикереп төшәр дә энемне янаклар дип көткән идем. Янакламады, хәтта орышмады да. Мин дә аңа тимәскә булдым. Йә тагын черелди башлар. Зурлар нигәдер гел аны яклыйлар.

—Сабакка йөрмисеңмени син?—дип сорады әни абыйдан.—Нигә йөрмисең?

Кечкенә абый җавап бирмәде.

—Нигә йөрмисең соң? Нигә әйтмисең?.. Әллә тагын суктырдылармы?

—Юк,—диде абый борын астыннан гына.—Суктырмакчы булганнар иде дә... качып чыгып киттем.

—Нигә суктырмакчылар иде соң?

Нигә икәнен әйтәсе килми иде Кечкенә абыйның. Әни төпченеп, йөдәтеп интектермәде, бары кинәш кенә итте:

—Сабагыңа йөр син, Галәтдин. Йөрергә кирәк, укырга кирәк. Укымавың өчен соңыннан бик үкенерсең. Вакыт узган булыр.

Кечкенә абый яхшы иткән, суктыртмаган. Нигә суктыртырга? Анда бит, күлмәкне салдырып, идәнгә яткырып, бик каты суктыралар. Кечкенә абый моны яхшы белә, аркасындагы кутыр әле дә бетмәгән. Шулай да нигә суктырырга теләгәннәр икән аны? Беләсе иде.

Иртәгесен барысы да мәгълүм булды.

Бер көнне Кечкенә абый мәдрәсәдән өйгә ашарга кайтып киткәч, хәлфә, ачкыч яратып, аның сандыгын ачкан, нәрсә бар икән дип актарган. Сандык эченнән кеше башлары чыккан. Берничә кеше башы! Бабай шулай диде, кеше башлары, диде.

Моны ишеткәч, башта мин аптырап калдым: «Шундый кечкенә сандыкка берничә кеше башы ничек сыйды икән?—дип уйладым.—Каян алды икән ул кеше башларын?»

Моны уйлагач, йөрәгем «жу» итеп китте. Алла сакласын!.. Шулай да кеше башларын күрми калуым өчен бик үкендем. Вакытында әйтмәделәр бит. Әйткән булсалар, барып караган булыр идем... Аннары кылт итеп исемә төште: кеше башлары түгел бит, ә рәсемнәр генә! Шулай да хәлфә аны яткырып суктырмакчы булган. Гаҗәп, сурәтле кәгазь өчен нигә суктыралар икән? Башта аларның үзләрен суктырып карарга иде. Камчының нинди «татлы» икәнен белерләр иде!

Ясту намазында хәзрәт безнең бабайга әйткән: кеше сурәтен өйгә дә, мәдрәсәгә дә кертергә ярамый, дигән, кыямәт көнне ул җан сорый, дигән. Имеш, әлеге сурәтләр Кечкенә абый җанын сораячаклар. Сорасыннар, бирер абый аларга җан! Тотсыннар!

Әти көлә:

—Кәгазь генә бит алар. Ничек җан сорасыннар?—ди.—Аннары, кыямәт дигән нәрсә бармы икән әле? Күргән кеше юк бит аны,—ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, әни куркып китте:

—Телеңнән җил алсын! Тәүбә, тәүбә, әстәгъфирулла дип әйт,—диде.

Әти елмайды гына, тәүбә дип әйтергә теләмәде:

—Теге дөньядан кайткан кеше юк бит әле. Терелеп кайтып, сөйләсәләр, кем белә, бәлки, ышанып да идем,—дип кенә җавап бирде.

Әни кыямәтнең барлыгына ышанса да, кәнфит кәгазьләрендәге сурәтләрнең кыямәт көнне җан сораячакларына ышанмый.

Әти шул көнне үк, мәдрәсәгә барып, мулла белән дә, хәлфә белән дә сөйләшеп кайтты: Кечкенә абыйны суктырмаска булганнар, гафу иткәннәр. Шулай да мәдрәсәгә икенче тапкыр сурәтле кәгазь алып килмәскә кушканнар.

Әти Кечкенә абыйга әйтте:

—Андый кәгазьләрең булса, өйдә генә сакла. Мәдрәсәгә алып барасы булма,—диде.—Белмәссең ул чалмалы башларны, суктырырлар, оялмаслар...

Кечкенә абый инде белә, башка алып бармас.

Гаҗәп, мулла абзый белән мәдрәсәдәге хәлфә кеше сурәтеннән нигә бу кадәр куркалар икән?

Икенче көнне Кечкенә абый мине ишек алдында туктатты да бик төпченеп сорашты:

—Син миңа дөресен әйт: сандыгымда сурәтле кәгазьләр барлыгын берәр малайга әйтмәдеңме?—диде.

—Әйтмәдем.

—Берәүгә дәме?

—Берәүгә дә.

Абый ышанмады, ант итәргә кушты. Мин, җирдә яткан саламны алып, бугазыма куеп китереп өздем дә:

—Менә!—дидем.—Әйткән булсам, ипи йөзен күрмим!

Шуннан соң ышанды. Ялганларга, юләрмени мин!

Абый уйга калды. Миннән тагын сорады:

—Синеңчә, ничек: сандыгымда сурәтле кәгазьләр барлыгын хәлфәгә кем әйтте икән?

Мин дә, кызыксынып, аның үзеннән сорадым:

—Нигә соң ул сиңа?

—Белсәм, бәреп үтерер идем мин аны,—диде.

Мин куркып киттем: кеше үтерергә ярыймыни соң! Абый да курыкканымны сизде булса кирәк, төзәтеп әйтеп куйды:

—Үтерүен үтермәс идем, шулай да муенын борыр идем мин аның... Гомергә кәкре муенлы итеп калдырыр идем...

«Бусы ярый,—дип уйладым мин эчемнән.—Әләкләп йөрмәсен! Шул кирәк аңа!»

Шуннан соң мин урамда булсын, мәдрәсә яныннан узганда булсын, кәкре муенлы берәр малай очрамасмы икән дип, кызыксынып караштыргалый башладым. Абый әләкчене тапмаган булса кирәк—кәкре муенлы бер малайны да очратмадым.

## IX

...Утыздан артык укучының берсеннән дә ак кәгазь кисәге, карандаш сыныгы таба алмассың. Аның каравы, мәзиннең түр сәкесе янында, стенада безнең нәни йөрәкләребезне шомландырып, куркытып, каеш камчы эленеп тора. Почмак якта, өйнең хәлфә апа дәрес бирә торган өлешендә, камчы түгел, ә бары тал чыбык кына.

...Алар кайчакларда дәрәҗәләрен күтәрү, яисә хәлфә икәнлекләрен белдерү өчен генә, кырыс чырай күрсәтсәләр дә, бервакытта да мине һәм башка балаларны камчы белән суктырмадылар, рәхмәт аларга, бары селкетеп, ачулы кыяфәт белән минем һәм минем кебек сабыйларның баш очларыннан чыжылдатып, сызгыртып алу белән генә чикләнделәр. Бу да җитә иде безгә, каһәр төшкән камчыны яисә чыбыкны хәлфәләребезнең кулында күрү белән үк коелып төшә идек. Иләнгә сеңә идек, йөрәкләребез, күкрәгебезгә сыеша алмыйча, тыпырчына, атылып чыгарга җитә иде. Соңыннан аны тынычландыра алмыйча азаплана идек.

Без утырып түгел, ә аяк өстендә баскан килеш укый идек. Өсләребезне салмыйбыз, бары итекләребезне, чабаталарыбызны гына салабыз.

Барыбыз да кычкырып укыйбыз, дәресләребезне ятлыйбыз, өй эче яңгырап, шаулап тора, кайчак тәрәзәләр зыңлый.

Эчтән генә уку—укуга саналмый. Сабагыңны белсәң дә, белмәсәң дә, кычкырып укы. Кабатла. Ике-өч кат кына түгел, ун кат, йөз кат кабатла.

Укымавыңны, тик кенә басып торуыңны хәлфә абый да, хәлфә апа да, казый вазыйфасын үтәүче кыз да бик тиз күреп ала. Казыеннан курыкмыйбыз, ул бернәрсә эшләтә алмый, колактан тарта, ә менә хәлфә абыйның кулы шундук камчыга сузыла, яисә ул бармагы белән аңа ишарә итә. Бу ишарәне яхшы аңлыйбыз һәм шундук кинәт бөтен көчебез белән кычкырып укый башлыйбыз.

Мондый шау-шуда, бака күлендә, кемнең нәрсә укуын, нинди

сүзләрне кабатлавын бирәү дә белми, төшенми, төшенерлек, ишетелерлек түгел.

Кайчакларда мин сабак итеп бирелгән бер авыз сүзне ижекли-ижекли туеп бетәм, мәгънәсезлегеннән, мина бернәрсә дә аңлашылмавыннан туям, өй эчендәге шау-шудан, гөрләшүдән файдаланып, үзем белгән, телемә килгән такмазаларын кабатларга тотынам.

Ясин, такта чиләк ясыйм,
Бүген бетерәм,
Иртәгә китерәм.

«Ясин»—Коръән сүрәсе. Апаларым уку башлаганнан бирле шуны кабатлыйлар, яттан өйрәнәләр, ә мин шундый сүзләр белән аларны үчеклим. Моның өчен алар мина суккалап та алалар, хәлфә абыйга әйтү белән дә куркыталар, шулай да мин такмаклавымнан туктамыйм, үч итеп такмаклыйм. Бусыннан туйсам, икенчесенә күчәм.

Әби бара мунчага,
Бер кулында мунчала;
Барып керсә мунчага,
Ике пәри кул чаба.

Болар сабакка караганда, кызыграк та, күңеллерәк тә. Мәгънәле дә. Андый такмазаларым күп минем.

Безгә ник шундый такмазалар гына укытмыйлар икән? Ансат та, кызык та, ятлавы җиңел.

Такмазалар әйтүемне хәлфәм ишетми, белми. Иреннәрем кыймылдыймы?—Кыймылдый. Шул җиткән! Димәк, укыйм. Аннары хәлфәләребез ул кадәр күзәтеп тә тормыйлар. Үз эшләре дә муеннан. Хәлфә апа безнең кебек сабыйларга сабак бирә, үзе казан янында, мич тирәсендә маташа, аш-су әзерли, тик ара-тирә генә, безнең якка борылгалап карап:

—Нигә тынып калдыгыз?.. Укыгыз, укыгыз!—дип әйткәләп ала.

Без кычкырыбрак укыйбыз, урамнан узып баручылар укыганыбызны ишетсеннәр дип укыйбыз. Ишетсәләр, хәлфә апаның күңеле була: ни әйтсәң дә, тикмәгә генә мәзин хатыны булып тормый, нинди кычкыртып укыта!

Хәлфә абыйның да эше күп. Укучыларның сабакларын берәм-берәм тыңлатып, аларга яңа сабак биргәч, үз эшенә китә. Аның биш вакыт намазга барасы, азан әйтәсе, мәчет сукмакларындагы карны көрисе, идәнен себерәсе, мичләренә ягасы, лампаларына керосин саласы, куыкларын чистартасы бар... Бетмәгәнмени эш! Балалар укытам дип, өйдә генә тормас тагы! Аның атнага бер булса да базарга, төрле йомыш белән күрше авылларга да барасы бар. Аннары авылыбызда үлем-җитем дә булгалый. Бу кайгылы, күз яшьле эш беркайчан да мәзинсез башкарылмый. Шуның өстенә хәлфә абыегыз чакырылган җиргә ашка барырга да тиештер бит? Нигә бармасын ул анда? Аннан калырга ярыймыни! Тамагын туеп кайту дисеңме, аз булса да, кесәнә кереп торган сәдакасы дисеңме,—барысы да ярып тора хәлфә абыйга. Күрәсез, эше нинди күп. Муеннан, бугаздан. Балаларны укытырга вакыты да калмый. Шуңа күрә кай атналарда без хәлфә абыебызны бер-ике генә күрә идек.

Аның өйдә булуына, булмавына, ягъни укытмавына, сабак бирмәвенә карамастан, апаларым «сабакка» тәртипле рәвештә йөриләр, көненә ике тапкыр баралар. Мин дә, букчамны түшемә кысып тотып, алар белән бергә барам, бергә кайтам. Бармыйча ярамый, хәлфә абыйларга булышырга кирәк. Хәлфә бит!..

Шулай да хәлфә абыебыз кече атна көнне өйдә булмыйча калмый. Ул көнне без аңа сәдака бирәбез. Һәркем хәле-хәленчә, ягъни, әти-әниләре күпме бирсә, шуны алып килә: бер тиен, ике тиен, өч тиен, хәтта хәллерәкләр биш тиен дә алып киләләр. Хәлфә абыебыз сәдаканың күләменә, бәясенә карап дога кыла. Бер тиен өчен ике кулын агарып

барган сакалы тирәсендә иренеп кенә селкеп ала, борынын жыерып, иреннәрен дә кыймылдатмый. Ике тиен бирсәк, иреннәре бераз кыймылдый, амин итәргә дип, кулларын авызына кадәр күтәрә. Әгәр инде сәдакабыз өч тиен, бигрәк тә биш тиен булса, ул чакта хәлфә абыебыз доганы кызганмый, иреннәрен тиз-тиз кыймылдатып, кулларын киң итеп җәеп, шаулап, гөрләп дога кыла, битен маңгаеннан алып иягенә кадәр сыйпый, хәтта, бик канәгатьләнеп, сакалын да учлап тора.

Моннан тыш, әниләребез дә аларга, безне укыткан, шулкадәр «гыйлем» биргән өчен чын күңелләреннән риза булып, рәхмәтләр әйтеп, сәдака китергәлиләр: он, ярма, яңа пешкән тәмле әйберләр, сугым суйган чакларда—ит. Шуның өстенә хәлфә абый белән хәлфә апаның икесен бергә, парлап ашка чакыргалыйлар, кайчакларда мунча ягып та чакыралар. Хәлфә абый да, хәлфә апа да канәгать: барысы да бер кесәгә, бер корсакка керә.

Бу «мәктәп»тә берәүне дә язарга өйрәтмиләр. Кызларның каләм тота, язу яза белүләреннән Алла сакласын! Яза белсәләр, буйга җиткәч, егетләргә хат язулары мөмкин дип уйлыйлар. Аннары, имеш, хатын-кызларга язу-сызу белү нигә кирәк? Мин дә, бу «мәктәп»кә эләккән мескен малай, баш исәбеннән санаганда, кызлар белән бер рәттән йөрим. Шулай булгач, минем дә язу яза белүем мәҗбүри түгел. Хәер, мәҗбүри булса да, мине язуга өйрәтерлек кеше юк иде монда. Хәлфә апам үзе яза белми, ә хәлфә абыйга килгәндә, ул минем кебек кечкенәләрне укытмый. Әгәр укытса да, язу язарга өйрәтмәс иде ул. Үзе дә чак тырнаштыргалый.

...Яз житте, өй кырпуларыннан, сарай түбәләреннән тамчылар тама, койма буйларында, урамнарда, тыкрыкларда беренче гөрләвекләр күренә башлады, кара каргалар, сыерчыклар килде...

Ниһаять, ачык урыннарда калын кар астыннан анда-санда кара жир чыкты. Чирәмле жир, хуш исле жир! Шуның белән бергә ялан тәпиләребез исәпсез-хисапсыз чебиләр белән чуарланды. Әни мескен кичләрен, безне юата-юата, иркәли-иркәли, кайчакларда орышкалап, тирги-тирги, язгы пычрак белән каралып, катып, ярылып беткән аякларыбызны, сыйракларыбызны ачы катык белән уа.

Каргалар, сыерчыклар килгәч, тыкрыкларда, урамнарда чирәмле жир күренә башлагач, ничек итеп «мәктәпкә» йөрергә, укырга кирәк?

«Иман шарты»м укылып бетми калды, никадәр тырышсам да, чит-ят телдә язылган, бер сүзе дә аңлашылмый торган бу китапның соңгы битләренә житә алмадым, бер хәрефен дә үзләштермәдем. Чөнки мина хәреф күрсәтүче, бу фәлән хәреф, бу төгән хәреф дип өйрәтүче, кулыма каләм тоттыручы кеше булмады. Хәлфәм яза белмәгәч, нишлисең! Хәреф танымасам да, күңелемнән ятлаган алфавитны су урынына эчә идем, төнлә уятып сорасалар, төнлә дә, кулыма китабымны тотмыйча, битләрен ачып карамыйча, шартлатып укып бирә алыр идем.

Киләсе кыш бу китапны укырмынмы, юкмы,—белмим. Укысам да аның керләнгән, нәни бармакларым белән өзлексез уганга тишелеп, ертылып беткән, күз яшьләрем белән сугарылган алдагы битләрен, андагы сүзләрне танырлык түгел иде. Кем белә, бу китапны хәзер әлеге, явыз кара сарыкка бирсәң, бәлки, ул да ашамас. Шундый мескен хәлдә иде ул.

*1972 ел.*

**Редакциядән:** А. Шамовның (1901-1990) архивында сакланып калган бу әсәрен безгә аның кызы **Әлфия ШАМОВА** әзерләп китерде. Әсәр кайбер кыскартулар белән басылды.

## КОДРӘТЛЕ УЛ ШИГЫРЬ ДИГӘНЕҢ...

*Әкәмәт инде бу фани дөнья: ханнар вә шаһлар, корольләр вә императорлар борын-борыннан зиннәтле сарайлар, коллар һәм кәнизәкләр белән генә канәгатьләнмичә, янәшәләрендә үзләренең чын һәм ялган батырлыкларын, иксез-чиксез хәзинә-байлыкларын, гадел һәм мәрхәмәтле булуларын илаһи сүз белән әйтеп бирердәй шагыйрьләр дә тотканнар. Гап-гади иҗатчыларның дан-шөһрәте тынгылык бирмәгәнме аларга, әллә ниндидер эчке тылсымлы омтылыш күңел кылларына чиерткәнме, әллә инде төче мактаулар гына аз тоелганмы, еш кына алар үзләре дә кулларына каләм алганнар. Араларында исеме бөек Рудаки, Хафиз, Хәйям, Җами, Сәгъдиләр белән янәшә аталырлык, чын мәгънәсендә шигъри энҗеләр иҗат иткән кыю яугир—Һиндстанда бөек моголлар династиясенә нигез салган Бабур кебекләре дә булган.*

*Ни әйтерең бар—шигъри сүзнең кодрәте әлмисактан бирле уклардан, таш балталардан, сөңгеләрдән, мылтыклардан һәм туплардан да көчлерәк тоелган шул. Бөтен-бөтен империяләрне дер селкетеп торткан тиран хакимнәр генә түгел, кешелекнең әллә никадәр өлешен үз артларыннан ияртерлек тәгълиматлар тудырган пәйгамбәрләр һәм бөек акыл ияләре дә, иҗтимагый тормышның сәясәт, икътисад, мәдәният, фән кебек өлкәләрендә тирән эз калдырган шәхесләр дә шигърияткә күк капусы артыннан иңгән тылсым итеп караганнар.*

*Гадел җәмгыять турында хыялланган утопистлар Томмазо Кампанелла һәм Томас Мор, Дәһшәтле Иван, Әби патша Екатерина Икенче, Наполеон, Карл Маркс, Фридрих Энгельс, Җәвәхарлал Неру, Хо Ши Мин, Мао Цзедун, Леонид Брежнев, Патрис Лумумба, Юрий Андропов, әсәрләрен Осенев псевдонимы белән бастыручы Анатолий Лукьянов кебек уннарча, йөзләрчә шәхесләрнең күңел мөнбәрләрен нинди хисләр биләгәнен, аларның иҗади куәсе ни дәрәҗәдә икәнен ачык кына әйтүе дә кыен. Ахыр чиктә алар шигърият бакчасына вакытлыча һәм очраклы гына кереп чыккан кешеләр. Әйтик, яшел яшьлек елларында Иосиф Джугашвили (Сталин) хәтта грузин әдәбияты классигы Илья Чавчавадзе игътибарына лаек булган. 12-13 яшьлек «Бәләкәй Сосо» шигырьләре ул вакытта ук антологияләрдә, хрестоматияләрдә урын алган. Күрәсең, яшь иҗатчы төшеп калганнардан булмагандыр. Аның Ленин үлгәннән соң сөйләгән мәшһүр ант-чыгышы да югары шигъри сәләт турында сөйли. Ләкин ул дөньяга иҗатчы буларак түгел, канлы диктатор буларак танылa шул! Шуны ук Гитлерның «тел бистәсе» Йозеф Геббельс турында да әйтергә мөмкин. Узган елның 16 нчы октябрендә «Комсомольская правда» газетасы аның бер шигырен бастырып, иҗаты турында мәгълүматлар биргән иде. Бу шәхес безнең өчен никадәр генә җирәнгеч булмасын, бер дәреслекне танырга туры килә. Егерме биш яшендә аңа немец драматургиясе тарихы буенча тикшеренүләре өчен филология докторы дәрәҗәсе бирелгән, лирик шигырьләре дөнья күргән, «Михель» дигән романы басылып чыккан.*

*Бу шигъри бәйләмне әзерләгәндә мин «бусы ак—бусы кара», «бусы дус—бусы дошман», «бусы коммунист—бусы фашист» дигән принциплар куймадым. Бары дөнья хакимнәренең шигърияткә битараф булмаганнарын ассызыклап, ниндидер кызыксынуларны канәгатьләндерү максатын гына күз алдында тоттым. Шигырьләр нигездә лирик характерда—алар теге яки бу идеологияне алга сөрүне максат итми. Андый*

*фикерләр азмы-күпме Мао Цзедун һәм Хо Ши Мин әсәрләрендә генә чагыла торгандыр.*

*Заман чиреме ул, әллә Россия җирлеге белән генә бәйләнгәнме—без еш кына бер чиктән икенче чиккә ташланабыз. Әле ничә еллар элек кенә тырыша-тырмаша өйрәнгән «Капитал» һәм «Коммунистлар партиясе манифесты» кебек хезмәтләрнең авторлары Карл Маркс һәм Фридрих Энгельсне эттән алып эткә салабыз. Изге китабыбыз Корьән Кәримдә әйтелгән монафыйкларга әйләнәбез түгелме соң?!*

*Үткәннәрне кире кайтару да, булган вакыйгаларны яңадан кабатлау да мөмкин түгел. Тарих шартлы фигыль белән язганны кабул итми. Бар булганы булган инде... Киләчәге ничек булыр?!*

**Әхмәт РӘШИТ**

# Карл Маркс

## Скрипкачы

Скрипка ярсый, шаша, көлә,
Бөдрәләре төшкән күзләренә.
Бер ягында кылыч, бер ягына
Аткан бөкләп кара плащын да.

«Ни көйлисең вәхши скрипкаңда,
Сагышлы күз ташлап тирә-юньгә?
Ярсу каннанмы бу ут ярчыгы?
Тукта! Түзмәс моңа смычогың».

«Ни көйлимме? Кыяларга—кара!—
Дулкын арты дулкын чабып бара!
Күкрәк читлегемне ачар өчен,
Җәһәннәмгә җанны ташлар өчен».

«Гөнаһланма, көлмә, җырчы кеше
Алланың ул һәрчак сөеклесе.
Күтәрел син шул җыр канатында
Йолдызларга, зәңгәр күк катына».

«Ни сөйлисең? Җәннәт җыры, димсең,
Кылыч белән китерермен исең.
Алла җырлар белми—ул ачулы,
Җыр ул—җәһәннәмнәр саташуы.

Җан акылдан язган бер чагында
Иблис әйтте моны колагыма,
Ул һәр көйне алай-болай итә,
Минем смычоклы кулны йөртә.

Йөрәк, кыллар, смычок—бик аздан!
Шартлап үлү—анысы сезгә язган».

Скрипка ярсый, шаша, көлә,
Бөдрәләре төшкән күзләренә,
Бер ягында кылыч, бер ягында
Бөгәрләнгән кара плащ кына.

## Фридрих Энгельс

### Кич

*Иртәгә дә көн булыр!*

Шелли

Мин—бакчада. Үткән көн кояшы
Кинәт кенә чумды дулкыннарга,
Фәкать соңгы чаткылары гына
Шатланышып бии болыт барга.

Ямансулап күзен йомды гөлләр—
Көндезгә нур сүнде алар өчен;
Куаклыкта гамьсез кошлар гына
Шат җыр суза ямен мактап кичнең.

Океан кичеп килгән пароходлар
Сиртмәсендә суның туктап калган;
Җәяүлеләр арган—күпер чыгып
Югалалар кереп томаннарга.

Бокалымда шәраб күбекләнгән,
Алда—Кальдеронның[1] шигъри хисе;
Ә мин шәраб вә сүз кодрәтеннән
Үземә көч-куәт табам төсле.

## Иосиф Джугашвили (Сталин)

Ак балкышы белән кинәттән ай
Бар җир йөзен нурга төргәндә,
Һәм яктысы ерак тарафларда
Тонык зәңгәр төскә кергәндә,
Зәңгәрләнгән урман өсләренә
Сандугачлар моңнар сипкәндә,
Назлы авазларын саламури[2]

[1] Кальдерон, Серафин-Эстебан (1801—1867)—испан язучысы.
[2] Курайның бер төре

Бар хәяткә бүләк иткәндә,
Бер мизгелгә тынып, өр-яңадан
Чишмәләре тауның чыңласа,
Һәм уянып төнге кара урман
Назлы җилләр сүзен тыңласа,
Аяк басса качкын янә бер кат
Хәсрәт тулы туган илләргә,
Дөм караңгы көннәр артта калып,
Кинәт кенә кояш күргәндә,
Күңелдәге кара болытлар да
Таралгандай була як-якка,
Көчле аваз булып өмет шул чак
Йөрәгемне кабат уята.
Шагыйрь җаны ыргый биеклеккә—
Кем соң тыяр ашкын йөрәкне;
Беләм, беләм: өмет минем өчен
Игелекле, изге теләкле.

## Анатолий Луначарский

Гомер азагында килә сырхау,
Шыр сөякле үлем шәүләсе күк.
Йөрәк тибә туктыйм-туктыйм диеп—
Үткәннәр юк гүя, киләчәк юк.
Ә нәрсәгә? Билгеле ич инде—
Тузган машинадай какшау нигез.
Офык димсез?—ә ул күптән аста—
Биеклек һәм үзән бердәй тигез.
Коточкыч ул шәүлә—кискен, катгый,
Һәм бәяли гел үзенчә сине:
Учакларга аз-маз җылындыңмы,
Шәрабларга ирен тидерденме—
Һәм китәсең... Кая? Юк дөньяга,
Синең арттан китәр башкалар да,
Җан буш хыял белән көн күргән ич—
Нигә алдау?—соң бит инде бары да.
Ләкин менә үлем кире чигә—
Нигә диеп бу мәгънәсез шөгыль?
Нуль кебек буш, колга кебек коры,
Карусыз һәм хәтта явыз түгел.
Кинәт җанда, җәннәттәге кебек,
Соңгы көз гөлләре чәчәк ата,
«Үлем берни түгел, яшәү көчен
Ни җиңсен?!»—дип җырлар яңгырата.
Таша-таша чыңлый көмеш аваз,
Таша яшәү көче шома гына,
Изге эшләр, балкып, уралалар
Мәңгелекнең серле йомгагына.
«Яшәлмәгән» сыман көннәреңдә

Үлем белән яшәү сыный сине.
Дөньялыкның асыл мәгънәсе дә
Шушы ике сүздә түгелмени?!

## Юрий Андропов

Дөнья—фани, яшәү—фәкать мизгел,
Мәңге түгел—чери бәдәннәр.
Тәгәри Җир шары галәм буйлап—
Яши... һәм юк була адәмнәр.

Ә асылы, гәрчә караңгыда
Туса да, таң эзли юлында.
Эстафета итеп яшәешне
Алга илтә һәммә буын да.

## Мао Цзедун

### Уналтышар сүзле өч шигырь

Таулар!
Мин иярдә, камчы кулда, атым чаба куган җайдан.
Өскә карап—
Зәңгәр киңлекләрне күзләп калам хәйран.

Таулар!
Диңгез дулкыннары сыман ул дулкыннар катлам-катлам.
Ә киртләчләр—
Яулардан соң гүя атлар туктап калган.

Таулар!
Түбәләре зәңгәр күккә ашкач, шундый гүзәл икән!
Күк егылыр иде,
Ләкин ул тауларга таянасы иткән.

### Люпаньшань

Анда—ак бәстәй болыттан өстә
Казлар каңгылдап көньякка китә.
Егерме мең ли—безнең үткән юл—
Бөек Стенага кем алдан җитә,
Батырлар данын яулар бары шул.

Күккә баш сузган очлы Люпаньшань,
Безнең байраклар яна ялкындай.
Уйлар да бер үк, сүзләр дә бер үк—
Гыйфритнең башын өзү хакында.

# Хо Ши Мин

## «ТӨРМӘ КӨНДӘЛЕГЕ» КИТАБЫННАН

Төрмәдә тән газап чиксә чиксен,
Җаным очсын азат киңлек аша;
Максат ачык, юлым туры минем—
Мин ир булып калам ахыргача.

### Эңгер-меңгердә

Урманына кайткан арыган кош,
Болыт инде офык читен кочкан,
Авылда бер кызый ваклый маис,
Уйнап оча мичтән алсу очкын.

### Ирен күрергә килгәч...

Хатын һәм ир янәшәләр дә бит—
Корыч рәшәткәлә ике ара;
Өстән күзлимени җир йөзен күк—
Очрашу юк хәтта карашларга.
Ул карашлар нидер әйтмәкче дә,
Мөлдерәмә ләкин яшьле күзләр—
Күреп хатын хәлен, кем соң түзәр?!

*Әхмәт Рәшит тәрҗемәләре.*

Tarix
Тарих

## Солтан Шәмси

# НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

### АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

## Идегәй планы белән

«Мичкәле балны бозарга бер кашык дегет тә җитә»,—дип халык юкка гына әйтмәгән. Тимер бәкнең җиңү тантанасында «дегет» булырдай шундый бер хәл килеп чыга. Эш шунда ки, җиһангир Кондырча сугышын уңышлы тәмамлап, явын кайту юлына борганчы гаскәрдәге берничә Алтын Урда шаһзадәсе ана үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Бу шаһзадәләрнен Идел-Җаек буенда үз олыслары, ул олысларда үз ырулары булганга, алар Тимер бәк белән кире Мәвараэннәһергә кайтып киткәнче олысларына барып, андагы халыкны җиһангир карамагына китерергә теләк белдерәләр. Шуның өчен яудан аерылып торырга Тимер бәктән рөхсәт сорыйлар. Шаһзадәләр арасында Тимер бәк алдында зур абруй казанган Идегәй мирзадан тыш Тимер Котлык, Күнче углан, Кыерчык углан да була.

Табигый, Тимер бәк бу тәкъдимне бик сөенеп каршы ала, аның гаскәре әлеге шаһзадәләрнең ыруларына зыян салмасын өчен, махсус ярлыклар яздырып, тегеләрнең кулларына тоттыра. Шулай шаһзадәләр үз олысларына китәләр, тик шактый вакыт үтүгә дә карамастан кире әйләнеп кайтырга ашыкмыйлар. Аларны шактый вакыт көткәннән соң Тимер бәк, ниһаять, үзенең алданганлыгын аңлый. Шулай итеп, Алтын Урда шаһзадәләре Тимер бәкне төп башына утырталар. Шик юк, бу тәвәккәл адым Идегәй мирза планы буенча, аның турыдан-туры катнашы белән ясала. Билгеле, качып китүчеләр мондый юлга баскан өчен үзләренә дә, ыруларына да нинди хәвеф китерүләрен яхшы аңлыйлар. Шуна күрә бу хәлне алдан уйлаган Идегәй мирза саклык чаралары күрүне кирәк таба.

Әйтелгәнчә, Идегәй мирзаның мангыт (ак мангыт) ыруы Каспий дингезенең көнчыгышындагы далаларда яши. Туктамыш хан кул астында булганлыктан, бу ыру Кондырча сугышында Алтын Урда ягында орыша, Кондырча сугышының бик каты булачагын, зур корбаннар таләп итәчәген алдан белеп торган Идегәй мирза, үз олысындагы халыкны ничек тә булса саклап калу нияте белән, анда алдан ук кеше җибәреп, тегеләрне кисәтеп куя. Аларга сугышның иң кызган чагында, Туктамыш хан гаскәрен ташлап, ачык далага китәргә куша.

Мангытлар, чыннан да, шулай эшли, ханга хыянәт итеп, үзләрен саклап кала. Моның белән Идегәй мирза, беренчедән, Туктамыш ханнан үч кайтарса, икенчедән, Тимер бәккә эшне җиңеләйтә төшә—аңа җиңү яуларга ярдәм итә.

Алтын Урда гаскәре бу сугышта тар-мар ителеп, Туктамыш хан үзе качып киткәннән соң Идегәй мирза уйлаган планының икенче яртысын тормышка ашырырга керешә. Ул үз олысына барырга җиһангирдан рөхсәт сораганда:

Ахыры. Башы 1-5 саннарда.

—Мангытлар минем киңәшемне тотып сугышта Туктамышны ташлап киттеләр. Мондый хыянәт өчен хан аларны беркайчан да кичермәячәк, кайчан да булса бер үчен кайтарачак. Аларны хәвефтән йолып калу өчен мина үз олысыма кайтырга, халкымны синең хозурыңа алып килергә ризалык бирүеңне сорыйм,- ди ул.

Идегәй мирзаның кире әйләнеп кайтмавы аркасында мангытлар өстенә кабат гаеп төшә. Әмма Кондырча елгасы белән (хәзерге Саратов өлкәсендә) Мангышлак арасында иксез-чиксез дала—күчеп йөрүче аерым бер ыруны эзләп табып кара син. Шулай да Идегәй мирза ыруын алдан кисәтеп куйган була. Ул аларга:

—Сез бер урында гына тормагыз, туктаусыз күченеп йөрегез. Торган жирләрегездән мөмкин кадәр ераграк китегез. Үтеп керүе кыенрак жирләр булса, тагын да яхшырак. Бер жирдә бер төннән артык кунмагыз, юкса Тимер сезне эзләп табачак, кылычтан үткәрәчәк,—ди.

Бу эше белән Идегәй мирза ыруын гына саклап калмый, үзе өчен бик кадерле булган яшь Тимер Котлык угланны да Тимер бәк кулыннан тартып ала. Бу вакытта ул, агасы Идегәй мирзаның яшерен ниятләрен белмичә, үз кешеләрен чынлап торып Сәмәркand әмиренә китереп тапшырырга жыенып йөри. Шунда гына агасы аның күзләрен ача:

—Менә син кешеләреңне Тимер ягына күчерергә йөрисең. Уйлап кара әле, ыруынны анда алып китүдән сиңа ни файда? Тимер бит аларны Сәмәркand якларына озатачак, төрле жирләргә таратып бетерәчәк. Ә син үзең элеккечә аның нөгәре булып калачаксың. Аңлыйсыңмы эшләр кая бара...

Шушы сөйләшүдән соң гына яшь Тимер Котлык ниятеннән баш тарта, жинел уйлап, ыруына нинди авыр язмыш әзерләвен аңлап ала. Чыннан да, килмешәк-илбасар Аксак Тимер күчерелгән халыкның кадерен белмәячәк бит, аны кайсын кая таратып, әрәм итеп бетерәчәк.

Тимер Котлык ырудашларын жыя да:

—Тимер бәк сезне кылычтан үткәрергә жыена. Бала-чагаларыгызны, туган-тумачаларыгызны әсир итеп таратып бетерәчәк,—ди.

Билгеле, моны ишеткән халык урыныннан кузгалмаска карар кыла:

—Без синең белән калабыз, ә Тимер бәкне танымыйбыз,—дип жавап бирә.

Тимер Котлык, агасы Идегәй мирзаның киңәшен тотып, халыкка гел күченеп йөрергә куша.

Аерылып киткән шаһзадәләрдән Тимер бәк янына бары тик Күнче углан гына әйләнеп кайта.

Тимер бәк, шаһзадәләрне кулдан ычкындыруына бик үкенсә дә, берни дә эшли алмый. Эшнең башында куркусыз, нык ихтыярлы, мөстәкыйльлек яратучы Идегәй мирза торганны ул бик тиз аңлап ала. Тарихчылар теркәп калдырганча, күпмедер вакыт үткәч, Тимер бәк Идегәйне ятьмәгә эләктерү өчен бер талпыныш та ясап карый. Фәлән эш буенча утырып бер сөйләшәсе бар иде, килеп чыксын әле дип, аның янына бер кешесен жибәрә. Идегәй мирзаны урдасына чакыра.

Идегәй мирза исә килгән кешегә болай дип жавап бирә:

—Сез инде моннан соң эшләрегезне минсез генә алып барыгыз. Хужаң янына әйләнеп кайткач, аның колларын үбеп, шушы сүзләрне тапшыр: «Шушы көннән минем аңа хезмәт итә торган вакытым төкәнде. Мин бүтән аның кешесе түгел, чөнки Аллаһы Тәгаләдән куркам»,—дип әйтергә кушты диген *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов...,—т. I.—С. 468-469).*

Идегәй мирзаның бу сүзләре сискәндереп жибәрә. Алар мирза күңелендә барган каршылыклы хисләр давылын, эчке көрәшне бик ачык күрсәтә кебек. Чыннан да, моның өчен житди сәбәпләр житәрлек. Сәмәркand әмирен үгетләп, коточкыч яу белән Идел-Йортка алып килүче Идегәй түгелмени? Кондырча сугышында инешләр булып аккан болгар-кыпчак канында аның гаебе юкмыни? Гүзәл Идел-Йортны чак кына харап итми калучы ул үзе түгелмени?

Әлбәттә, аны да аңлап була. Болар барысы да кан дошманы Туктамыш ханнан үч кайтару өчен эшләнде. Тик артык кыйммәткә төшмәдеме әлеге үч кайтару? Бу очракта ул беткә үч итеп, тунны утка якты түгелме?

«Аллаһы Тәгаләдән куркам!» Куркырлык та шул. Үз ватанына каршы шундый авыр эш башкаргач, ничек жаның тыныч була алсын... Гөнаһлары артык зур булганга авызыннан шундый сүз чыгуы аңлашыла булса кирәк.

Мәшһүр тарихчы Л. Н. Гумилев, Алтын Урда шаһзадәләренең Тимер бәктән качып китүенә мөнәсәбәтен белдереп, бу хәл Кондырча буендагы жиңүнең нәтиҗәсен юкка чыгарды («свело на нет успех похода») дип яза (Гумилев Л. Н. Древняя Русь и Великая степь.—С. 650). Ләкин бу фикер белән килешүе кыен. Шушы яу нәтиҗәсендә Сәмәрканд әмире бик күп мал кулга төшерә, хисапсыз жылкы, дөя, сыер, куй көтүләре куып алып китә. Алдарак әйтелгәнчә, баскыннар Идел-Йортның байтак халкын Мәвараэннәһергә коллыкка озата. Бу гамәлләр татар иленә зур зыян сала. Шуңа күрә яуның нәтиҗәләре юкка чыга дигән фикер белән һич тә килешеп булмый.

## Нәфес аты үзеңне егар...

Кондырча сугышыннан качып киткәннән соң Туктамыш ханның эзе беразга югалып тора. Күрәсең, тугры тарафдарлары белән анда-монда күченеп, эз югалтып, берәр аулаграк жирдә Тимер бәкнең Мәвараэннәһергә кайтып киткәнен көтеп яткандыр. Ләкин сугыш барышында ханга хыянәт иткән шаһзадәләр бер дә илдә тынычлык урнашканны көтеп ятмыйлар. Һәркайсы тимерне кызу чагында сугып калырга, абруе төшкән ханның юкка чыгуын үз файдаларына борырга тырыша. Аларның шушы айларда кылган эш-гамәлләрен, ничегрәк хәрәкәт итүләрен барлап чыгыйк әле.

Бу хәлләрнең төп сәбәпчесе булган Идегәй мирза олысына әйләнеп кайту белән үзен Мангыт олысының өлкән бәге—хуҗасы итеп белдерә. Чыңгыз нәселеннән булса, үзен хан дип тә игълан иткән булыр иде. Әмма ул, алдарак әйтелгәнчә, чыңгызый түгел. Шуңа күрә әлегә Мангыт олысы белән чикләнә. Ә яшь Тимер Котлыкны Сарай тәхетенә чыгару өчен запаста тота.

Укучы хәтерлидер, Кондырча сугышы барышында Бикбулат исемле шаһзадә үз сугышчылары белән Туктамыш ханны ташлап киткән иде, ягъни ул, шушы гамәле белән ханга хыянәт итеп, Тимер бәк ягына чыкты. Инде сугыш тынып, Туктамыш хан турында хәбәр-хәтер ишетелмәгәч, ул Дон елгасы буендагы биләмәләрендә үзен хан дип игълан итә. Әлбәттә, аның биләмәсен житди ханлык дип кабул итеп булмый. Моны Бикбулатның күкрәк киереп бер кәперәюе, нәфсен канәгатьләндерергә маташуы дип кенә аңларга кирәктер. Әмма Туктамыш хан офыкта күренмәгәч, Бикбулатның нәфсе тагын да үсеп китә, ул бара да иясез калган Сарайны кулга төшерә, анда тәхеткә утыра, Туктамыш ханның мал-мөлкәтен, хатыннарын үзенеке итә. *(Тизенгаузен В. Г. Сборник материалов... т.I. С. 393.)* Шик юк, Сарай халкы аның тәхеттә озак утыра алмаячагын белеп торган, чөнки андый узгынчы ханнарны үз гомерендә күп күргән.

Бикбулатның Сарайдагы кыланмышлары тиз арада Туктамыш ханга барып ирешкән булса кирәк, чөнки шушы хәлләрдән соң ул кинәт үзенең барлыгын сиздерә. Тиз-тиз гаскәр туплый башлый. Дөресен генә әйткәндә, аңа гаскәр туплар өчен артык тырышырга да туры килми—дала баһадирлары законлы ханның кабат пәйда булуын ишетүгә аның урдасына ашыгалар. Шулай тиз арада гаскәр туплана, һәм Туктамыш хан Сарайдан Бикбулат шаһзадәне бәреп чыгара. Тегесе качып китә дә Кырымга барып урнаша. Туктамыш исә асыл тәхеткә утырып үз исемен пычраткан, мал-мөлкәтен тартып алган, хатыннарын кочкан шаһзадәне дөмектерү өчен тегенең артыннан Кырымга юнәлә. Бикбулат исә андагы Солхат каласына кереп бикләнә.

Каланы килгән шәпкә генә алу мөмкин булмаган, күрәсең. Бу мәшәкать озаккарак сузыла. Һәм... Туктамыш хан белән Бикбулатның үзара көрәшен читтән генә күзәтеп торган Идегәй мирза форсаттан файдаланып калмакчы була. Ул Сарайга бәреп керә дә запаста тоткан Тимер Котлык угланны хан тәхетенә утырта. Бу хәл шул ук 1391 елның көзендә була.

Тимер Котлыкның Сарай тәхетенә чыгуын ишетеп алган Күнче углан да (көнчелек белән хөсетлек шул дәрәҗәгә житә ки), түзеп тора алмыйча, Тимер

бәкне ташлап кача да Идел буена әйләнеп кайта. Тимер Котлыкка үч итеп, Туктамыш ханга хезмәткә керә.

Шулай итеп, Идегәй мирза күптән уйлап йөргән ниятен тормышка ашыруга ирешә. Әмма озаккамы? Башкала халкы, түрәләр, аксөякләр аның ягына чыгармы, хәлләр авыраеп китсә, ярдәм кулы сузарлармы? Ә Туктамыш ханны кая куярга? Ул бит законлы хан, әллә кая китеп югалмады, бары тик Кырымда дошманы Бикбулаттан үч кайтару белән генә шөгыльләнә.

Табигый, Туктамыш хан Сарайның Идегәй мирза кешесе Тимер Котлык кулына төшүенә битараф калмый. Солхат каласын камауны туктатып торып, зур ашыгычлык белән кире Идел буена әйләнеп кайта һәм әле мыек кына чыгып килгән Тимер Котлыкны Сарайдан куып җибәрә. Шулай Идегәй мирзаның планы кабат чуала. Аларга кабат Җаек буйларында, мангыт-нугай даласында форсат чыкканны көтеп яшәргә кала. Әйтергә кирәк, нәкъ шушы далада соңрак чорда Нугай урдасы барлыкка килә. Бу очракта нугайларның төркиләшкән монгол ыруларыннан барлыкка килүен әйтеп китү дә, бәлки, артык булмас.

Укучының: «Туктамыш хан Бикбулат шаһзададән үч алмый каламыни?» дип, урынлы сорау биреп куюы да бар. Юк, бу очракта Туктамыш хан ихтыяр ныклыгы күрсәтә. Тимер Котлыкны Сарайдан куып җибәрү белән кире Кырымга әйләнеп кайта, Солхат каласын кабат камап ала. Бу юлы ул каланы штурмлап-нитеп азапланмый—хәйлә юлына баса. Кырым аксөякләренә тарханлык ярлыклары өләшеп, тиз арада каланы ала да Бикбулат шаһзаданең башын кистерә.

Мәсьәләгә ачыклык кертеп узыйк: тарханлык ярлыгы бирелгән аксөяк ханга түләнә торган барлык салымнардан да азат ителә. Шуңа күрә Кырым аксөякләренең Бикбулат шаһзадәне үзләре үк тотып ханга биргән булулары бик ихтимал. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев бу хәл 1392 елның көзендә булган дип яза.

Кырымда жирле идарәче-әмир итеп Котлык Буга дигән берәүне билгеләгәннән соң, Туктамыш хан Сарайга әйләнеп кайта. Шулай Кондырча сугышы нәтиҗәсендә болганып алган илдә кабат тынычлык урнаша. Тик озаккамы? Без һаман саен әлеге «озаккамы?» дигән сорауны куярга тиеш булабыз, чөнки Идел-Йортның бу чорда гаять тотрыксыз хәлдә яшәвен вакыйгалар безгә гел күрсәтеп тора.

Бу тынлык давыл алдыннан була торган шомлы тынлык түгелме?

## Ике сугыш арасында

Кондырча сугышыннан соң илдә кузгалган низагларны бастыргач, Сарай өчен барган көрәштә җиңеп чыккач, Туктамыш хан җиңел сулап куя. Ул олысларны кабат бер йодрыкка тупларга керешә. Шуңа да карамастан ул белә—бу әле Тимер бәк белән соңгы бәрелеш түгел. Үзен шундый авыр хәлгә куйган, ил алдында рисвай иткән, тәхетенә янаган илбасардан Туктамышның әле үч аласы бар. Һәм ул аны алачак та! Үчен кайтармаса, исеме Туктамыш хан булмасын... Ерак бабасы Чыңгыз хан рухы белән ант итә—бу чатан козгынга ул гомере буе тынгылык бирмәячәк...

Ялгыз калганда шундый ярсу уйларга бирелеп киткәләсә дә, ниятне тормышка ашыру өчен тиешле шартларның булуы кирәк. Дөресрәге, аларны әзерләргә кирәк. Һәм Туктамыш хан шушы юнәлештә акрынлап эш йөртергә тотына.

1393 елның май урталарында ул Кырымда яңа гына әмир итеп куелган Котлыг Буга белән Хәсән мирзаны әле генә тәхеткә чыккан Литва кенәзе Витовт хозурына илче итеп озата.

Илчелек юлга чыгып китәр алдыннан олуг кенәз Витовтка тапшырасы ярлыктагы иң әһәмиятле сүзләрне аларның исенә тагын бер кат төшерүне кирәк таба: «Ата-бабаларыбыз бер-берсенә ярдәм итешеп гомер иткәннәр, диген. Ике яктан да илчеләр алмашканнар, без дә шулай яшәргә телибез, диген. Сез берәр хәл эчендә калып, безнең яктан берәр ярдәм кирәк булса, без бар булган көчебез белән дошманыгыз өстенә ташланырга әзер—хәбәр генә итегез. Без кыен хәлдә

калсак, сез дә шуны ук эшләрсез,—дип әйтерсен»,—дип илчелек башы Котлыг Буганы кисәтеп куя.

Әлбәттә, илчеләр җибәрүнең асыл мәгънәсе Тимер бәккә каршы алып барылачак сугышларда дуслар-аркадашлар булдыруга кайтып кала.

Туктамыш хан илчеләрне Литвага озату белән генә чикләнми, бер елдан Мисыр солтаны хозурына да шундый ук максатлар белән илчелек озата. Бу җәһәттән тарихчы М. Г. Сәфәргалиев бер кызыклы факт китерә. Нәкъ шушы вакытта Мисырда Сәмәрканд әмире Тимер бәктән килгән илчеләрне үтереп ташлыйлар. Илчеләрне үтерү бик сирәк була торган хәл. Алар үтерелгән икән, бу бары тик солтан кушуы яки рөхсәте белән генә башкарыла ала. Димәк, Мисыр солтаны белән Сәмәрканд әмире арасында зур каршылыклар булган. Бу исә Мисырның Алтын Урда белән бер сүздә булуы хакында сөйли.

Шулай итеп, Туктамыш хан астыртын эш йөртә-йөртә киләчәк бәрелешләрдә ярдәм итәрлек дусларын барларга керешә. Сарай хөкүмәте шулай ук Грузия патшасы белән дә элемтәгә керә, сөйләшүләр алып бара. Тимер бәк шымчылары моны җиһангиргә җиткерү белән ул Грузиягә яу оештыра. Туктамыш хан исә бу хәлдән файдаланып калырга тырыша. Тимер бәк Грузия өстенә ябырылган арада Тимер капу (Дербент) аша аның артына төшә—Ширван өлкәсенә бәреп керә. Бәлки бу адым Грузиядә сугышны туктату, аларга ярдәм итү максатыннан ясалгандыр. Ничек кенә булмасын; Туктамыш хан бу юлы үз дигәненә ирешә—җиһангирны Грузиядә сугыш хәрәкәтләрен туктатырга мәҗбүр итә. Тимер бәк Алтын Урда явының гайрәтен сизеп алып, эшне тизрәк солых төзүгә таба бора. Бу исә аның дәвамлы бәрелешләр алып барырга тиешле әзерлеге булмавы турында сөйли.

## Һәлакәт (1395 ел)

*«Үзләрен саклап калу белән бергә,*
*татарлар уйлавы да хәтәр*
*язмыштан Русьне коткарып калдылар...»*

Л. Н. Гумилев

Тарихта халыклар язмышына нык тәэсир иткән, аны башка юлга алып кереп киткән вакыйгалар була. Табигый, анда катнашучылар вакыйгаларның эчке логикасын, мәгънәләрен күрүдән, аңлаудан бик ерак торалар. Аларның асыл мәгънәсе бары тик байтак заманнар үткәч, зур тарихи перспективада гына ачыклана башлый. Алтын Урда дәүләте тарихындагы 1395 елгы сугыш шундый әһәмияткә ия вакыйгалар рәтенә керә. Бу сугышта үзеге Идел-Йортта урнашкан Алтын Урда белән Урта Азиядә, дөресрәге, Мәвараэннәһердә ныгып киткән, яңа җирләр яулау аппетите торган саен ачыла барган Тимер бәкнең (Аксак Тимернең) яшь һәм гайрәтле мәмләкәте бил алыша. Бер якта, Ислам диненә күптән күчүгә дә карамастан, дала йоласы һаман әле көчле булган Алтын Урда, икенче якта, нигезендә Шәрекъ мәдәнияте яткан, утрак тормышка көйләнгән мөселман традицияләре. Дөньяны кабул итүдә зур аерма, хәзергечә әйтсәк, ике төрле менталитет. Ике мәмләкәт арасындагы каршылыклар Туктамыш хан белән Тимер бәкнең аралары бозылу, шәхси конфликтка гына кайтып калмый, ә ике төрле яшәү рәвеше, идеалларның үзгәлегенә дә бәйле булса кирәк. Шул сәбәпле—бер-береңне өнәмәү, каршылыклар һәм сугыш...

### Ике сугыш арасында

Кондырча сугышыннан соң илдә булып алган низагларны бастыргач һәм Сарай өчен барган көрәштә җиңеп чыккач, Туктамыш хан җиңел сулап куйды. Ул олысларны кабат бер йодрыкка тупларга керешә. Шуңа да карамастан ул белә иде—бу әле Тимер бәк белән соңгы бәрелеш түгел. Үзен шундый авыр хәлдә калдырган, бөтен ил-көн алдында рисвай иткән, тәхетенә янаган илбасардан аның әле үч кайтарасы бар. Һәм ул аны кайтарачак та! Үчен кайтармаса, исеме

Туктамыш хан булмасын... Ерак бабасы Чыңгыз хан рухы белән ант итә—бу чатан козгынга ул гомере буе тынгылык бирмәячәк...

Ялгызы калган чакта шундый ярсу хисләргә бирелеп киткәләсә дә, ниятне тормышка ашыру өчен билгеле шартларның булуы кирәк. Дөресрәге, аларны әзерләргә кирәк. Һәм Туктамыш хан шушы юнәлештә эш йөртергә тотынды.

1393 елның май урталарында Туктамыш хан Кырымда әмир итеп куелган Котлык Буга белән Хәсән мирзаны яңа гына Литва тәхетенә чыккан кенәз Витовт хозурына озатты. Илчеләр юлга чыгып китәр алдыннан:

—Анда баргач, безнең ата-бабаларыбыз бер-берсенә ярдәм итешеп гомер иткәннәр, ике яктан да илчеләр алмашканнар, без дә шулай яшәргә телибез, дип әйтергә онытмагыз. Хәл эчендә калып, безнең яктан берәр төрле ярдәм кирәк булса, без бар көчебез белән дошманыгыз өстенә ташланырга әзер—хәбәр генә итегез. Без кыен хәлдә калсак, сез дә шулай эш итегез, дип әйтерсез,—дип әйтеләсе төп сүзләрне тагын бер кат тегеләрнең исләренә төшерде.

Әлбәттә, илчеләр озатуның асыл мәгънәсе Тимер бәккә каршы алып барылачак сугышларда дус-аркадаш булдыруга кайтып кала иде.

Туктамыш хан Литва белән генә чикләнмичә, бер елдан Мисыр солтаны хозурына да шундый ук максатлар белән илчелек озатты. Бу җәһәттән тарихчы М. Г. Сәфәргалиев бер кызыклы факт китерә. Нәкъ шушы вакытта Мисырга Сәмәрканд әмире Тимер бәктән килгән илчеләрне үтереп ташлыйлар. Илчене үтерү—сирәк була торган хәл. Бу бары тик солтан рөхсәте яки әмере белән генә башкарыла ала. Димәк, Мисыр солтаны белән Сәмәрканд әмире арасында зур каршылыклар булган. Ә бу исә Мисырның Атын Урда белән бер сүздә булуы хакында сөйли.

Шулай итеп, Туктамыш хан астыртын эш йөртә, киләчәк бәрелешләрдә ярдәм кулы сузардай дуслар барларга керешә. Сарай хөкүмәте Грузия патшасы белән дә элемтәгә керә, сөйләшүләр алып бара. Тимер бәк шымчылары моны җиһангиргә житкерү белән ул Грузиягә яу оештыра. Туктамыш хан исә бу хәлдән файдаланып калырга тырыша һәм Тимер бәк Грузия өстенә йөргән арада Тимер Капу (Дербент үткеле) аша аның артына төшә—Ширван өлкәсенә бәреп керә. Ничек кенә булмасын, Туктамыш хан бу юлы үз дигәненә ирешә—кан дошманын Грузиядәге сугыш хәрәкәтләрен туктатырга мәҗбүр итә. Тимер бәк, Алтын Урда явының гайрәтен вакытында сизеп алып, эшне тизрәк солых төзүгә таба бора. Бу исә аның дәвамлы сугыш алып барырга әзерлеге житешмәү турында сөйли.

## Тупас җавап

Тимер бәк гаскәрен тиз арада Грузиядән чыгара да Туктамыш ханның хәрәкәтләрен туктатуга ирешә. Алтын Урда явы кире Тимер Капуга чигенә, үз биләмәләренә әйләнеп кайта. Кыш житә. Тимер бәк вакытны сузу өчен сөйләшүләр башлап жибәрергә була. Ул Туктамыш ханга илчеләр озата, илчелек житәкчесе итеп иң тәҗрибәле дипломаты Шәмсетдин Алмалыкый дигән адәмне билгели. Зирәклеге һәм сөйләү осталыгы белән дан тоткан бу кешенең нотыгы Туктамыш ханга бик нык тәэсир итә. Өстәвенә Тимер бәк Туктамышка юллаган хатында мәсьәләне кабыргасы белән куя:

«Аллаһы Тәгалә исеме белән сорыймын: ни өчен син, шайтан коткысына бирелгән кыпчак ханы, кулыңа тагын корал алдың? Син безнең соңгы сугышны (1391) оныттың да мыни, синең гайрәтеңне, мал-мөлкәтеңне, тәхетеңне минем кулым юкка чыгарды түгелме соң? Игелегемне онытма, акылыңа кил! Миңа нинди зур бурычлы икәнеңне исеңә төшер! Җәзадан котылып калырга әле вакыт бар. Ни телисең—тынычлыкмы, сугышмы? Үзең сайла. Мин икесенә дә әзер. Әмма шуны белеп тор: бу юлы сиңа рәхим-шәфкать булмаячак» *(Грум-Гржимайло Г. Е. Джучиды.—35 б.)*.

Туктамыш хан илченең сүзләре һәм хатта язылганнар тәэсирендә сугыштан баш тарту ягына авыша башлый, сөйләшүләр шундыйрак юнәлеш ала. Ләкин аның тирәсендәге бәкләр, мирзалар моңа каршы төшә, аны солых төземәскә үгетлиләр һәм йомшак холыклы, йогынтыга тиз бирелүчән хан кире уйлый, үз

фикереннән баш тарта. Өстәвенә, Тимер бәктән кайтарылмаган үче дә кабат күнеләндә канат җәйгән булса кирәк. Ахыр чиктә ул сугышны дәвам иттерергә дигән карарга килә, шушы фикер анын җавап хатында да чагыла.Тарихчылар теркәп калдырганча, анын җиһангирга язган җавап хаты гаять тупас эчтәлекле булган.

Шушы җавап мәсьәләне хәл итә дә куя—үзе үстергән, үзе кеше иткән, аны тәхеткә утырту өчен күп көч һәм акча түккән Тимер бәк ни өчен әле шушы мәдәниятсез һәм мәгънәсез бәндәне гафу итәргә тиеш ди? Ул бит анын алдында малай гына! Җитмәсә, гомергә бурычлы! Туктамыш ханның бу тупаслыгы анын ярасына тоз гына сала һәм... Тимер бәк, язлар житеп, үләннәр күтәрелгәч, Туктамыш хөкем сөргән Идел-Йорт өстенә яуга кузгала.

## Терек суы буенда

Әле дүрт ел гына элек Кондырча буенда кыйналган, аннан соң көч-хәл белән эчке низагларны бастырган Туктамыш ханга, Сәмәрканд әмиренә булган үчен йотып, мыштым гына Сараенда ятасы, илне тәртипкә китерәсе, сәүдәне рәткә саласы, ныгыйсы, көч туплыйсы иде дә бит. Юк шул, хисләрен тышаулый алмады, шул сәбәпле менә тагын Тимер бәк белән әчелешле булды хан. Ә Сәмәрканд әмире җавапны озак көттерә торганнардан түгел. Менә анын өстенә килә...

Тимер бәк явы анын биләмәләренә килү хәбәрен ишеткәч, Туктамыш хан каушап калды—ул монда әзер түгел иде. Тегенең эшне болай тиз тотасын ул һич башына китермәде. Менә бит ничек унайсыз килеп чыкты.

Ул мәсьәләне солых белән хәл итәр өчен якынлашып килүче Тимер бәккә каршы илчесе Уракны җибәрде.Тик илче Тимер Капудан анын әмерен үти алмыйча әйләнеп кайтты. Зур яу кузгатып юлга чыккан җиһангирнын солыхка риза булмаслыгын илче анлый иде. Шуна күрә анын белән очрашмауны хәерлерәк күрде. Кем белә аны, «илчегә үлем юк», дип әйтелә әйтелүен дә, тик ачуы чыккан Тимер бәк янында әйләнеп кайтмавын да бик ихтимал. Кем әйтмешли, бәладән башаяк...

Шулай да Туктамыш хан янына бөтенләй буш кул белән кайтып кермәс өчен, бераз акча тотып, дошманнын нindirәк көчләр белән килүен ачыклый алды илче Урак. Сәмәрканд әмире зур көч туплаган, гаскәрнең маңгае белән урта кулы да гаять ишле икән. Димәк, калганнары да шуннан ким түгел.

Бу хәбәрне ишеткәннән соң Туктамыш хан әмир Казанчы җитәкләгән маңгайны (авангард) алга чыгарып куйды. Тик Тимер бәк, килгән шәпкә үк, маңгайга китереп сукты да аны таратып ташлады. Туктамыш ханга артта сузылып яткан Терек суына чигенергә туры килде. Елганы тиз кичтеләр. Андагы бердәнбер кичүне ныклап ныгытырга, канаулар казырга, атлы гаскәргә каршы очлы казыклар утыртырга, читән үреп, җәяүлеләрне шунын артына бастырырга кирәк булды.

Кичүдә орыш өч көн барды, дүртенче көнгә киткәч, Тимер бәк яугирләре, төнге караңгылыктан файдаланып, татар гаскәренә кабат һөҗүм итте, елганың бу ягына чыкты. Шулай дошман төрле хәрәкәт-маневр ясап булырлык, иркенләп орышырлык ачык җиргә аяк басты. Ә ачык җирдә Сәмәрканд әмиренең яу белән ничек идарә итүе билгеле. Ул монда да Кондырча буенда уныш китергән ысулны кулланды: гаскәрне жиде өлешкә бүлде, бер өлешен үз янында резервта тотты. Анысы, хәл бик кискенләшеп китеп, бәхет ана арты белән борылса гына сугышка кертеләчәк иде. Ходай ул көнгә калдырмасын...

Шулай дәһшәтле, күп корбаннар сораган сугыш башланды. Туктамыш хан ерак бабасы Чыңгыздан калган гадәт буенча, дошманнын ике канатына чыгып, аны ян-яктан китереп кысмакчы иде, унышка шулай ирешергә уйлады. Тик бу нияте барып чыкмады. Икенче көнне, ә бу 1395 елның 15 апрель көне иде, ханның атаклы гаскәр башлыклары Күнче углан, Бәк-Ярлык углан, Актау Давыт-суфи белән Утыргылар Тимер бәкнең сул канатына һөҗүм иттеләр. Уң канат белән орышуны Туктамыш хан әмирләре Иса бәк белән Бакыш хаҗига тапшырды. Тик бу очракта да Сәмәрканд әмиренең орыш ысулы отышлырак булып чыкты—

ул, үзенең резервтагы яугирләрен сугышка кертеп, әмир Иса бәк өстенә шундый итеп ябырылды ки, тегенә артка чигенергә, качып котылырга гына калды.

Ике көн дәвам иткән каты орышта күп кеше кырылды, ләкин ике якның берсе дә сизелерлек уңышка ирешә алмады. Күп югалтулар аркасында сул кулның хәлсезләнә баруын күреп торган Туктамыш хан уң кулда орышкан Яглыбәй баһадир яугирләрен сул кулга күчерде, шулай хәлне бераз җиңеләйтергә теләде. Тик бу чара да ярдәм итмәде. Иртәгесен татарларның сул кулы бик авыр хәлдә калды, ә Яглыбәй баһадир үзе дошман кулыннан һәлак булды.

Бәла ялгызы гына йөрми дигәндәй, әле Яглыбәй баһадирны сул канатка күчергән чакта ук, уң кулдагы әмирләр арасында көтелмәгән низаг килеп чыкты. Арадан берсе—әмир Актау, күптән үч тотып йөргән бер әмир белән талашып китеп, Туктамыш ханнан аны үтерергә ризалык таләп итте. Табигый, сугыш кызган чакта шундый низаг килеп чыгу ханны авыр хәлдә калдырды. Алда көчле дошман торганда, әмир түгел, һәр сугышчы исәптә чакта үзара мөнәсәбәт ачыклау башка сыймаслык нәрсә иде. Әмма Туктамыш ханга фәкать шундый шартларда идарә итәргә, сугышны шундый башбаштак-йөгәнсез адәмнәр белән алып барырга туры килә иде. Әгәр дә ул әмир Актауга бу эшне катгый тыйса, теге дулап китеп, ике дә уйламыйча яу кырын ташлап китәчәк бит. Һәм ул моны хыянәт иту дип тә уйламаячак. Шуңа күрә Туктамыш хан аңа:

—Мин синең теләгеңә каршы килә алмыйм, теләгәнеңне эшләрсең. Ләкин үзең күреп торасың, хәлләр шәптән түгел. Шуңа әлегә бу эшне кузгатма, вакыты ул түгел. Үченне сугыш беткәч кайтарырсың, мин каршы килмәм,—диде.

Әмир Актау исә моңа риза булмады. Ул:

—Юк, ул миңа хәзер кирәк. Аны миңа тапшырмасаң, дүрт ягым кыйбла—синең кул астыннан чыгачакмын, ташлап китәчәкмен,—дип янады, шулай мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Туктамыш хан аны тагын үгетләп карады—файдасы тимәде. Ахыр чиктә әмир Актау хан яныннан нык гарьләнеп, кара көеп китеп барды.

Шулай итеп, татар гаскәренең сул канаты бик нык имгәнде, әйтелгәнчә, анда күчерелгән Яглыбәй баһадир орышта һәлак булды. Сул канатның имгәнүен күреп торган уң кул ни өчендер ярдәмгә ашыкмады. Хәер, монда «ни өчендер» дигән сорау да бәлки артыктыр, чөнки анда орышкан әмир Актау Бәк-Ярлык углан белән Таштимер угланны дошманга каршылык күрсәтмичә Туктамыш ханны ташлап китәргә күндерде, һәм алар бергәләшеп Азак тарафына чигенделәр. Бу хәл гаскәрнең башка кулларына да тәэсир итте. Башкача була да алмый—сугыш кызганда берәүләрнең табан ялтыратуы, гадәттә, башкалар өчен дә үрнәк булып хезмәт итә—паника тудыра. Бу юлы да шулайрак килеп чыккан булса кирәк.

## Качкын хан артыннан

Туктамыш ханга да тугры калган тарафдарлары белән качып котылырга гына калды. Тарихчылар күрсәтүенчә, ул Идел буйлап төньякка юнәлгән. Дошман исә Кура елгасын да кичә, тигезлеккә чыга, тизлеген тагын да арттыра төшеп, Идел тамагына үк килеп житә. Монда тагын бәрелешләр булып ала, тик алар инде хәлне үзгәртә алмый. Туктамыш хан Иделне кичеп, елганың сул ярына чыга һәм урманлы Болгар җирләренә ашыга.

Тимер бәк тә, Туктамыш эзеннән барып, Иделне кичте, үзенә таныш Кондырча буйларына күтәрелде. Әлбәттә, дошман Идел буендагы күзгә чалынган һәр авылны, кальганы, каланы кара күмергә әйләндереп бара. Күпчелек тарихчылар болгар калаларыннан Үкәкнең, Болгарның, Җукәтауның, Кирмәнчекнең шушы 1395 елгы яу көннәрендә җимерелүен әйтәләр. Шулай булмый хәле юк, чөнки моннан дүрт ел элек, Кондырча сугышында күп көч югалтуы аркасында һәм дә салкын көзләр житкәнче өенә, Мәвараэннәһергә кайтып житәргә кирәк булганга Тимер бәк, жиңү яуласа да, Идел буен теләгәнчә талый алмый калган иде бит. Менә язмыш аңа, ниһаять, андый мөмкинлекне бирде—инде Идел-Йорт тулысынча аның хөкемендә: кыпчак ханы Туктамыш мәмләкәтен ул бүтән аякка баса алмаслык

итеп талаячак, яндырачак, тәмам юк иткәнче жимерәчәк—кара күмергә әйләндерәчәк.

Совет хакимияте елларында, тарихта төп рольне һәрвакыт халык уйный, дигән фикер алга сөрелеп килде, шуңа ышандырырга тырыштылар. Бер үк вакытта совет дәүләте, анда яшәгән халыклар, милләтләр язмышы белән аерым шәхесләр уйнады. Бер кешенең теләге белән халыклар башка төбәккә күчерелде, бер кешенең теләге белән төрле кануннар кабул ителде. Бу очракта да шәхеснең тарихтагы роле дигән мәсьәлә калкып чыга түгелме? Без, укучы белән бергәләп, татар мәмләкәте тарихын барлаганда, ирексездән, вакыйгаларның асыл сәбәбе хакимият башында утыручы шәхесләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләргә кайтып калуын күреп торабыз.

Әгәр дә Туктамыш хан, Тимер бәкнең изгелекләрен онытмыйча, аңа тиешле кадер-хөрмәт күрсәтсә, үзен шулай тупас һәм дорфа тотмаса, остазына каршы мәгънәсез-мәкерле яулар оештырмаса, Идел-Йортны кара күмергә әйләндергән, татар дәүләтенә һәлакәт китергән бу яу булыр иде микән? Уртак ватаныбыз Идел-Йорт мондый ачы язмышка дучар булыр иде микән? Тарихта аерым шәхестән дә күп нәрсә тора шул. Халык, халык дип лаф орулар ул—хакимият тәгәрмәченең әйләнү серләрен яшерү өчен генә эшләнә, ягъни, күз буяу өчен генә әйтелә сыман...

Хәер, вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк.

Туктамыш ханны болгар калаларына хәтле куа барып та эзенә төшә алмагач һәм бер уңайдан болгар-татар илен җимерү буенча байтак эшләр башкаргач, Тимер бәк, ниһаять, кире борыла, мәмләкәтнең мәркәзе Сарай шәһәренә әйләнеп кайта. Монда ул үзенә тугры хезмәт иткән Кыерчык угланны (Күк Урданың мәрхүм Ырыс хан улы) хан тәхетенә утырта. Бу эше белән Тимер бәк Идел-Йортны үз сүзеннән чыкмый торган бер олыска әйләндерергә теләгәндер, күрәсең. Кыерчык углан мәгънәсез-мәдәниятсез Туктамыш түгел, изгелеккә яманлык белән җавап бирмәс, дип фикер йөрткән булса кирәк җиһангир. Кем әйтмешли, авызы пешкән суны да өреп йотар...

Ә бу вакытта ханлыгын, йортын, мал-мөлкәтен ташлап качкан Туктамыш хан берничә тугры кешесе белән болгар урманнарында яткан.

## Ә башкалар?..

Сугышлар туктап торудан файдаланып, Туктамыш ханны ташлап киткән уң канат әмирләре дилбегәне үз кулларына алу өчен кайбер адымнар да ясап өлгерәләр. Алар, үзара киңәшкәннән соң, качкын хан урынына Җанак углы Таштимер угланны сайлап куялар. Алар уенча, Туктамышны тар-мар иткәннән соң Тимер бәк кире үз йортына, Мәвараэннәһергә кайтып китәчәк. Дәүләт исә боларга калачак.

Ә Тимер бәкнең нәфсе моның белән генә канәгатьләнми. Ул Идел-Йортта үзе куйган Кыерчык угланга көндәш булырдай яңа хан пәйда булганны ишетү белән яуны Иделнең уңъяк ярына күчерә һәм яңа һөҗүмнәр башлап җибәрә. Шулай итеп, сугыш хәрәкәтләре Азак-Дон, Днепр буйларына, Кырым тирәсенә күчә.

## Уң канатта...

Шулай Тимер бәк явының әмир Госман идарә иткән маңгай өлеше көнбатышка юнәлә. Әмма Алтын Урданың уң канаты дошманга алай тиз генә бирелергә җыенмый. Монда шуны да әйтеп үтәргә кирәк. Ул чакта Иделдән көнбатышка таба сузылып киткән далаларда тулысынча безнең төрки бабаларыбыз хөкем сөргән, шуна күрә андагы һәр инеш, елга, үзән, калкулыкның төрки-татарча үз атамасы булган. Бу далада атамаларның күпчелеге төркичә яңгыраган. Соңгы гасырларда әлеге җирләрнең урыслар кулына төшүе аркасында гына төрки атамалар кысрыклап чыгарыла башлады. Шулай да күп нәрсә барыбер элекке исемен саклап калган. Урыслар Воркслa дип йөрткән елганың чын исеме, мәсәлән,

Бурсыклы, Днепрны бабаларыбыз Узу елгасы дип йөрткән, Дон—Тын елга, Азов —Азак һ. б.

Дошман Узу (Днепр) елгасына килеп житкәнче далада нинди бәрелешләр булуы билгесез. Узуда исә әмир Госманның маңгай чирүе татарлар өстенә килеп чыга. Һөҗүм көтмәгәндә ясалган булса кирәк, чөнки татарлар бик күп кеше югалтты. Орышта Кондырча һәм Терек суы буйларында гайрәт күрсәткән Бәк-Ярлык углан да катнаша. Шулай ук безгә билгеле әмир Актау белән яңа күтәрелгән Таштимер хан да шунда орыша. Димәк, әмир Госман чирүе хан урдасына һөҗүм иткән, ә Туктамыш хан качып йөргәндә оешкан бу урда Узу буенда урнашкан була. Бәрелеш дошман файдасына тәмамлана, татар гаскәре кайсы кая таралып бетә. Бәк-Ярлык углан үзе Дон тамагына качып котыла.

Дошман Алтын Урданың уң канатындагы олысларны тар-мар иткәч, чират Кырымга житә. Кырым да тиз басып алына, калалар талана, бары тик Кәфә (Феодосия) каласында гына кыенлык килеп чыга—18 көн буена камап торганнан соң Тимер бәк аны да басып ала.

Кырымны айкап чыккач, Тимер бәк явы Узу буенда качып котылган татар төркемнәрен эзәрлекләргә, табылганнарын юк итәргә керешә. Көннәрдән бер көнне Азак-Дон тарафына качып киткән чирү дошманның игътибарын җәлеп итә. Бу Бәк-Ярлык углан чирүе була. Аны тиз эзләп табалар, өстенә ябырылып, тәмам таратып бетерәләр. Бәк-Ярлык углан үзе, гаиләсен, мал-мөлкәтен, хатыннарын дошман кулына калдырып, улы белән чолганыштан чыгып өлгерә.

Аннан Тимер бәк гаскәре атларын урыс җирләренә бора. Гадәттә, даладан урыслар өстенә килүче яу иң элек чиктә урнашкан Рязань кенәзлегенә аяк баса торган була. Бу очракта да җиһангир кылычын беренче булып Рязань кенәзлеге татый. Карасу каласын (Елец) алганнан соң яу Рязаньның үзенә килеп җитә. Кенәз үзе качып китәргә өлгерә алмый кала, дошман кулына төшә, кала талана, яндырыла, бик күп чибәр марҗа кызлары-хатыннары җыеп алына, халык күп җәбер-золым күрә.

Аннан соң Мәскәү чираты җитә. Тимер бәк анда бармакчы була. Ләкин, ни хикмәт, ике атна буе Рязань кенәзлегендә торып, кире борыла. Урыс фольклорында моның сәбәбе Тимер бәкнең яман төш күрүе белән аңлатылса да, тарихчыларда бу мәсьәләгә төрле караш яши. Л. Н. Гумилев, мәсәлән, Тимер бәк Мәскәүгә барырга курыккан, чөнки Алтын Урда далаларында аңа каршы торырлык көчләр әле шактый булган, дип аңлата. Җиһангир Мәскәүне алып маташкан арада татарның таралышкан көчләре тупланып, дошманга каршы күтәрелү мөмкинлеге аны өркеткән, ди. Ни дисәң дә, татар үз йортында, үз даласында сугыша бит—аңа көч туплавы да, хәрәкәт итүе дә уңайрак. Кыскасы, Тимер бәк татар гаскәренең арттан китереп сугуыннан курыккан булса кирәк.

Тимер бәк Рязань кенәзлегендә торган чакта улы Мираншаһ идарәсендәге гаскәр Азак каласы һәм аның тирәсендә сугышлар алып бара. Азак—италияле сәүдә әһелләре нык тамыр җәйгән кала, алар монда диңгез сәүдәсен үз кулларында тота, калын диварлы ныгытмаларда чын хуҗаларча яши. Мираншаһ бу ныгытмаларны да басып ала, мөселман булмаган халыкларны аса-кисә, каланы талата, яндырып көлгә очыра. Төньяк Кавказда урнашкан Мажар каласы да шундый ук язмышка дучар була. Монда яшәгән төрки ырулар (яслар, черкаслар) коры дала үләненә ут төртәләр дә өлешчә тау араларына кереп яшеренәләр. Калганнарын Мираншаһ углан җәзага тарта. Шулай сугыш Дәшти Кыпчак даласыннан Кавказ тауларына килеп җитә. Тимер бәк бөтен Алтын Урданы үзенә буйсындыра, аннан, чират тау халыкларына җитә—Дагстанда авыллар талана, ныгытмалар алына. Кан исен сизгән тау бүреләре айлы төннәрдә сузып-сузып улый, тирә-юньгә шом сала.

Буйсындырылган ил-мәмләкәт ихтыярсыз Туктамыш хан аркасында җиһангир аяк астында вәйран булып ята. Аннан Тимер бәк үз кул астындагы халыкларны идарә итү өчен олыслар башына калгайлар (наместник) билгеләү эшенә керешә.

Әстерханда калгай итеп Гомәр Табаный дигән әмир куела. Тик халык аны яратмый. Шәһәр каландары (старшина) Мөхәммәтнең үзенә карата начар мөнәсәбәттә булуын күреп, Гомәр Табаный бу хакта Тимер бәккә килеп зарлана.

Тимер бәк—тәвәккәл адәм, эшне тиз тота: Әстерхан халкын акылга утырту өчен, көннәр буранлап торуга да карамастан, юлга чыга. Моны белеп алган Әстерхан халкы да кул кушырып утырмый—боздан биек диварлар коя, аларны су сибеп катыра-ныгыта, кулга корал тотып Тимер бәкне каршыларга әзерләнә.

Тимер бәк калага килеп җитү белән, янына каландар Мөхәммәтне чакырта, теге йөрәксезлек күрсәтеп буйсына—каладан чыга, җиһангир хозурына килеп баса. Тимер бәк башта аннан сорау ала, аннан каландарны кулга алырга боера һәм калгайга буйсынмаган өчен бәкегә ташларга куша. Эш моның белән генә чикләнсә, Тимер бәк кансыз җиһангир да булмас иде. Ул баш күтәргән өчен Әстерхан халкына авыр салымнар сала, аннан яугирләренә каланы таларга рөхсәт итә. Эш моның белән генә бетми—кала халкы кышкы бураннар ыжгырып торган ачык далага куып чыгарыла, Ә Әстерханнын үзен яндырып кара күмергә әйләндерә.

Тимер бәк китеп барганнан соң Әстерхан каласы Тимер Котлык (Идегәй мирза кешесе) кулына төшә. Иске урында каланы торгызу мөмкин булмаганга, Тимер Котлык каланы яна урында—Иделнең сул ярында торгыза. Сәяхәтчеләр теркәп калдырганча, ул инде зур кала булып үсеп китә алмаган. 1556 елда Явыз Иван гаскәре аны басып алгач, кала кабат яна җиргә күчерелә. Патша әмере буенча воевода П. Оболенский, иске каланы ташлап чыгып, татарларны Иделнең каршы ярына күчерә. Ә үзе өчен беренче Әстерханнан бераз түбәнрәк урында урнашкан ныгытма-крепость төзи. Хәзерге Әстерхан шуннан үсеп чыккан кала инде.

Бу вакытта Сарай шәһәре дә шундый ук ачы язмышка дучар була. Тимер бәкнең оныгы Пирмөхәммәт углан белән Җиһаншаһ баһадир житәкләгән гаскәр башта Сарайны тулысынча яндыра, аннан җир белән тигезләү эшләре алып барыла. Башкала тирәсендәге далада яшәүче ырулар да зур зыян күрә, мал-мөлкәтләре, терлек көтүләре тартып алына, үзләре әсирлеккә төшә—Тимер бәк урдасына куып китерелә. Аларны нинди язмыш көткәнне күзаллау кыен түгел.

Шушының белән яулар тәмамлана дияргә мөмкин. Мәвараэннәһергә кайтып китәр алдыннан Тимер бәк Идел-Йорттагы барлык калаларны системалы рәвештә җимерү эшен төгәлләргә керешә. Җимерелеп бетмәгәннәрен юк итү башлана—башка беркайчан да күтәрелә алмасыннар, киләчәктә татар дигән кавем аңа сүз белән дә, гамәл белән дә каршы төшә алмасын! Шулай Сарай Бату, Сарай Бәркә, Әстерхан, Бәлҗәмин, Мажар, Азак, Кырым калаларыннан Солхат, Кәфә, Болгар илендәге Үкәк, Кирмәнчек, Җүкәтау, Болгар үзе, бихисап авыллар, кәрван сарайлар, гыйбадәтханәләр, төрбәләр, зиратлар юк ителә. Дошман олы калаларны юк итүгә аеруча нык игътибар бирә, чөнки алар кәрван сәүдәсен тотып торучылар. Ә кәрван сәүдәсе Алтын Урда икътисадының зур өлешен тәшкил итә. Зур калаларны җимерү—татар мәмләкәтенең тамырына балта чабу белән бер. Сәмәрканд әмире моны анлы рәвештә башкара.

Әлбәттә, бу вәхшилекнең җиле далада яшәүче ыруларны да әйләнеп үтми, алар коллар рәвешендә Тимер бәкнең сөекле ватаны Мәвараэннәһергә озатыла. Анда бит бушлай эшләүче куллар, туктаусыз яулар вакытында кара эшне башкаручы таза ирләр кирәк. Идел-Йорттан куып алып кителгән хисапсыз халыкны фәкать шундый язмыш көткән—хокуксыз килеш чит илдә эт тормышында яшәү, көнен-төнен эшләү, теләсә кемгә кол итеп бирелгән гаилә әгъзаларыннан аерылу, аларны тәмам югалту, дөньяда берьялгызын торып калу.

1395—1396 елның кышын Тимер бәк кыпчак даласында уздыра. Булып узган коточкыч сугыш нәтиҗәсендә Идел-Йортта ачлык башлана. Җирле халык кына түгел, дошман үзе дә авыр хәлдә кала. Күпсанлы гаскәрне туендыру торган саен кыенлаша, сугыш атларына, терлекләргә азык җитми. Талап җыйган байлыкның байтак өлеше ач гаскәр белән терлекләрне саклап калуга китә. Тарихчы Шәрәфетдин Йәзди ул вакыттагы хәлләрне менә ничек бәян итә: «Көчле суыклар аркасында Тимер явы бик нык көчсезләнде һәм рухы төште, терлекләрнең күбесе һәлак булды...»

1396 елның язын көч-хәл белән котеп алган дошман, көннәр җылына төшү белән, Иран аша туган якларына кайтып китә. Шулай кышның үтә дә зәһәр килүе дошманның җинү нәтиҗәсен бөтенләй үк юкка чыгара алмаса да, аның тәэсир көчен шактый киметә. Тимер бәккә иленә тантана нурларында

коенган хәлдә күтәренке күнел белән кайтып китәргә туры килми. Татар мәмләкәтенә коточкыч зур зыян салуына карамастан, ул аны бөтенләй үк юк итә алмый. Шулай да 1395 елгы яу Алтын Урда өчен чын һәлакәткә әверелә. Анын тәэсире, сөяккә үткән кышкы суык кебек, дәүләтнең үзәгенә китереп суга, гөрләп яшәгән ил кинәт тынып, бушап кала. Шушы яунын шаһиты булган тарихчы Ибне Гарәпшаһ, дәүләтнең элекке тормышы белән хәзерге хәлен чагыштырып, менә нинди юллар язып калдырган: «Гадәттә, Хәрәземнән чыгып киткән кәрваннар тыныч кына, беркемнән курыкмыйча-шикләнмичә, Кырымга хәтле килеп житәләр иде. Ә бу юл—өч ай дәвам итә... Кәрваннар бернинди ризык-фәлән дә, терлек азыгы да алмыйлар, анда яшәүче халыкларның күплеге аркасында юл күрсәтүче дә ялламыйлар, чөнки бөтен җирдә иминлек, кешеләр гел очрап торганга ашау-эчү дә жинел хәл ителә иде. Ә хәзер Хәрәземнән Кырымга хәтле сузылган ул җирләрдә ыру-кабиләләрдән берсе дә яшәми, анда хәзер кыр кәжәләре белән дөяләрдән башка нәрсә күреп булмый». Дөрес, бу сүзләрдә бәлки бераз арттыру да бардыр. Шулай да 1395 елгы яудан соң Дәшти Кыпчак даласында тормышнын бик нык сүлпәнәеп калуын шаһит сүзләре дөрес чагылдыра сыман.

## Низаг дәвам итә...

1395 елдагы яулар вакытында Идегәй мирза белән Тимер Котлыкнын вакыйгаларда катнашмавы укучы игътибарыннан читтә калмагандыр. Чыннан да, Кыпчак даласында канлы бәрелешләр барган чакта Сарай тәхетен кулга төшерү өчен жай көтеп яшәүче бу ике зат кайларда булган? Ни өчен алар ватан өстенә Сәмәрканд афәте килгәндә, Туктамыш хан белән ике арада булган каршылыкларны бер якка куеп торып, көч берләштерә, кулга-кул тотынышып уртак дошманга каршы чыга алмаганнар?

Әлбәттә, мондый сорауларны без XX йөз логикасыннан чыгып бирәбез? Ул заманда идарәчеләр бөтенләй башкача фикер йөрткән. Уртак ватанны, туган-үскән жирне, халыкны саклап калу, матди һәм мәдәни байлыкларны исән-имин килеш киләчәк буыннарга тапшыру кебек гуманистик яссылыкта фикер йөртү ул чактагы түгел, бүгенге идарәчеләргә дә житенкерәми.

Безнен каһарманнарга әйләнеп кайтсак, аларнын хан тәхете өчен алып барган көрәшләре бары тик үз олысыннан тыш тагын берничә олыска, дәүләтнең байлыгына хужа булуга, дан-шөһрәт казануга кайтып кала. Шулай күпләрнен асыл хыялы булган хакимият адәм балаларын гасырлар буе төрле көрәшләргә этәргән. Бу хәзер дә шулай. Бары тик анын эш йөртү ысуллары гына нечкәрә бара, камилләшә төшә. Димәк, гасырлар дәвамында адәми затнын психологиясе әллә ни зур үзгәреш кичермәгән.

Идегәй мирза белән анын сүзеннән чыкмаган Тимер Котлыкнын әлеге яулардан читтә торып калуы табигый. Туктамыш хан белән аралары бозылышу, инде төзәтеп булмас дәрәжәгә тирәнгә киткән дошманлык аларга якынаерга мөмкинлек калдырмый. Бер үк вакытта Сәмәрканд әмиренә кире әйләнеп кайту юлы да ябык, чөнки анын каршында гаепләре зур—Кондырча сугышыннан сон жиһангирны бик шәп иттереп төп башына утырттылар. Шуңа күрә Идегәй мирза белән Тимер Котлык угланга, 1395 елда яу кузгалгач, Жаектан да арырак далаларда, бәлки, Тубыл буйларына ук китеп югалып торырга туры килгәндер. Алар кан-көч түкмичә генә көрәшне читтән күзәтеп торырга булалар. Яулар кем файдасына тәмамланыр, кем өстен чыгар? Барысы да ачыклангач, анда күз күрер, дип фикер йөрткән булсалар кирәк.

Шулай да Тимер бәк, Терек суы буенда (1395) Туктамыш ханны тукмап ташлап, чигенә барган хан артыннан Идел тамагына килеп житкәч, Идегәй мирзаны исенә төшерә, бу яуда аны үз ягына тарту өчен бер адым ясап карый. Дала бит ул беренче карашка гына буш кебек күренә, әмма мондый бушлыкка ышанып бетәргә ярамый. Далала хәбәр тиз йөри, шуна күрә Тимер бәк Идегәй белән Тимер Котлык урдасынын кайда икәнен белеп торгандыр. Төгәл белмәгән очракта да, сүзенне житкерүче кешене эзләп табу кыен эш түгел. Кыскасы,

көннәрдән бер көнне Идегәй мирзага Тимер бәктән чапкын килеп төшә. Җиһангир сүзләрен ул шушы рәвештә тапшыра:

—Тимер бәк сине элеккечә якын күрүен һәм ярлыкавын әйтергә кушты. Шулай ук, әгәр дә каршы килмәсән, оныгын синең кызына өйләндерергә тели.

Тик Идегәй мирза бу сүзләргә эреп китми, көлемсерәп кенә куя да болай дип җавап кайтара:

—Мин синең хуҗаңда егерме ел хезмәттә булдым, аның иң якын һәм ышанычлы кешеләреннән идем. Мин аның нинди ысуллар белән эш итүен яхшы беләм, шуңа күрә мине алай кулга төшерү мөмкин түгел. Әйләнеп кайткач, хуҗаңа әйт: мин аның тәкъдимен кире кагам. Киселгән икмәкне кире ялгап булмый...

Бу җавап Идегәй мирзаның ачык фикерле зирәк кеше булуын тагын бер кат раслый.

Яулар төгәлләнеп, Тимер бәк гаскәре Мәвараэннәһергә кайтып киткәннән соң сугыш вакытында төрле якларга таралган, кайсы кая качып беткән олыс башлары кабат хәрәкәткә килә. Хәрабә хәлендә яткан илгә акрынлап җан керә, тормышны торгызу, рәткә китерү башлана. Әлбәттә, хансыз калган илнең олысларына хуҗалар тиз табыла. Шулай итеп, 1396 елда Алтын Урда җирләрендә дүрт мөстәкыйль олыс барлыкка килә.

Җимерелгән Сарай шәһәре тирәсендә урнашкан төп олыста Тимер бәк үз кешесен—Кыерчык угланны хан итеп калдыра. Әгәр дә ил мондый һәлакәт кичермәсә, барлык олыслар да аңа буйсынган, аны хан итеп таныган булырлар иде. Ләкин тәхеткә дошман тарафыннан утыртылган Кыерчык угланның сүзен берәү дә тыңларга җыенмый, санга сукмый. Тимер бәк гаскәре Идел-Йорттан китеп бару белән аның кул астындагы ырулар кайсы кая таралып бетә. Ә аларны җыеп алырга ханның ни көче, ни абруе юк. Идел-Йортта ул чит кеше, килмешәк, таяныр ырулары да аз. Шуңа күрә бу марионетка яу китү белән кызганыч бер адәмгә әверелә дә кала.

Җай чыгудан файдаланып, Идегәй мирза белән Тимер Котлык та хәрәкәт итә башлый. Идегәй мирза Җаек даласын, Тимер Котлык Әстерханны үз кулына ала. Аннан соң, эшне озакка сузмыйча, таянычсыз калган Кыерчык угланны Сарай олысыннан куып җибәрәләр. Шулай итеп, алар күптәнге хыялларына ирешү өчен җитди адым ясыйлар—Тимер Котлык хан тәхетенә утыра, Идегәй мирза аның төп киңәшчесе рәвешендә дәүләт сәясәтен алып баручыга әверелә. Өстәвенә бөтен гаскәр белән дә ул идарә итә. Димәк, аларның байтактан бирле эзлекле алып барылган планы беренче җимешләрен бирә, тормышка аша башлый. Инде план тулысынча тормышка ашсын өчен Туктамыш ханның эшен бетерәсе генә кала. Ул Идел-Йортта чакта Сарайда тыныч хөкем сөрү мөмкин түгел.

Инде Туктамыш ханга әйләнеп кайтыйк. Бу вакыйгалар үз чираты белән барган чакта Болгар олысында качып яткан Туктамыш хан белән дә төрле хәлләр булып уза. Дошман явы илдән китү белән хан кире Сарайга кайту, кабат илне туплау турында кайгыртырга керешкәндер дип уйлау бик табигый булыр иде. Аның дөресе дә шуннан гыйбарәт. Хан бу ниятеннән баш тартмый. Хәбәргәрләре Идел-Йорттагы хәлләрне аңа җиткереп тора. Мондый чакта тәхеттән куылган затлар билгеле бер схема буенча хәрәкәт итәләр—беренчедән, үзе килеп урнашкан төбәкнең халкын буйсындырырга, үзен әле көч-куәте бетмәгән абруйлы зат итеп танытырга тырышалар. Икенчедән, шуны раслар өчен, хәрбиләре белән җирле халыктан җыйган сугышчыларны туплап, чиктәш өлкәләргә яу йөриләр, аны буйсындыра алмасалар да, биләмәләрен талап-яндырып кайтырга тырышалар. Шулай бераз гайрәт күрсәтеп алалар. Бу хәрәкәтләр тарафдарлары аңа ышанычын югалтып бетермәсен, хан тәхетен кире кайтарып алса, аларда безгә дә өлеш чыгар, дигән өмет сүнмәсен өчен башкарыла.

Билгеле, бер үк вакытта дипломатик адымнар да ясарга туры килә. Монысы инде күршеләренне капшап карау, мөнәсәбәтләрен ачыклау, тәхетне кайтару эшенә керешкәч, кемнән ярдәм көтәргә, кемнән көтмәскә икәнне чамалау өчен эшләнә.

Туктамыш ханның бу көннәрдәге хәл-әхвәлләре чыганакларда бик саран яктыртыла, шуңа да карамастан, аның гамәлләрендә шушы чараларның өчесен дә күреп була. Әйтик, урыс елъязмалары күрсәткәнчә, Туктамыш хан бу көннәрдә,

төрле якка чапкыннар җибәреп, халыкны үз урдасына чакыра, киләчәк көрәш өчен сугышчылар яллау ниятеннән җирле халыктан алтын-көмеш кебек нәрсәләр җыйдырта. Шулай ук шаһзадә Энтәк житәкчелегендәге бер төркем атлыларны Түбән Новгородны талап кайтырга озата. Нәкъ шушы вакытта Туктамыш ханның Рязань кенәзлегенә илче Тимер-хуҗаны җибәрүе дә билгеле. Әлбәттә, үткәрелгән чаралар моның белән генә чикләнмәгән, алар күп булган, ләкин теркәлеп калганнары менә шушылар. Аларга таянып та ханның ул көннәрдәге хәлен күз алдына китерүе кыен түгел.

Кыскасы, хәл эчендә калган Туктамыш хан хәрәкәт итә, тәхетен кайтару өчен чаралар күрә. Әмма Түбән Новгородка һөҗүм иткән өчен үчеккән урыс кенәзләренең Болгарга яу белән килүе ханның планнарын чуалтып ташлый. Болгарлар үзләре дә тәхеттән куылган ханны, аның кешеләрен туйдырып ятарга бик ашкынып тормаганнардыр дип уйларга кирәк. Ана каршы күтәрелгән булулары да бик ихтимал. Шушы хәлләрне исәпкә алган Туктамыш хан, бәладән баш-аяк дигәндәй, Болгар олысыннан китеп бара.

Ул кайсы якка юнәлгән? Сарайга әйләнеп кайтуы, аны кулга төшерүе билгеле түгел. Ул, бәлки, Идегәй мирзадан куркып, анда барып та тормагандыр. Ул чакта ул кая барырга, кайда сыену урыны табарга тиеш? Көнчыгышка китә алмый—анда дошманы Кыерчык углан бар, төньяккарак китсән—буш дала. Калаларга, рәхәт тормышка күнеккән Туктамышка анда ни калган ди? Димәк, Сарайдан тыш хан барып урнашырдай бердәнбер җир—Кырым олысы. Ләкин анда хәзер Таштимер углан хөкем сөрә. Сугыштан соң ул шунда төпләнеп кала. Әмма Туктамыштай хан дуадак каздай кангырып йөргәндә—ни ояты белән Кырым тәхетендә утырыр икән. Иң дөресе—аны куып җибәрү, Кырымга үзе барып утыру булыр.

Әйе, адәм баласы вәзгыятькә карап төрле планнар кора. Бу көннәрдә Туктамыш хан планнарын зурдан кубып төземәгән булса кирәк. Аның өчен иң мөһиме—вакытлыча яшәп тору урыны табу, шунда бераз ныгу, көч туплау була. Соңыннан күз күрер. Һәм ул тугры калган тарафдарлары белән, чыннан да, Кырымга юнәлә. Чыганакларның берсендә, мәсәлән, аның нигездә итальян-сәүдәгәрләр яшәгән Кәфә каласына һөҗүм итүе, аны урап алуы телгә алына.

Табигый, монда төпләнгән Таштимер углан да тәхетен саклап калырга тырышкан, каршылык күрсәткән. Ләкин Туктамыш хан белән Таштимер углан икесе ике категориядәге затлар шул. Шуна күрә күп тә үтми үлчәү Туктамыш хан ягына авыша. Кыскасы, хан Таштимерне куып җибәрә. Монда ул җирле аксөякләрне үз ягына тарту аркасында ирешә, ә моның бердәнбер юлы—тәхеткә утыргач, аларга төрле өстенлекләр бирәм дип ышандыру. Бу вакыйгаларда Туктамыш ханга атаклы Ширин ыруыннан Рухтимер бәй бигрәк тә ярдәм итә. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев китергән бер чыганакта, мәсәлән, Рухтимер бәй хакында мондый сүзләр китерелә: «Рухтимер бәй һәрвакыт Туктамыш хан хозурында булган, аның зур хезмәтләр күрсәтүе аркасында ханның тормышы, иминлеге белән мал-мөлкәте дә сакланып калган. Шуна күрә хан аны башка бәйләр һәм ырулардан өстен куйган. Хан диванында да ана иң абруйлы урын билгеләнгән, ул ханның уң кулында беренчеләрдән булып урнашкан».

Шушы бәрелешләрдә җинеп чыккач, Туктамыш хан тәхеткә утыра—Алтын Урда ханы сыйфатында түгел, Кырым идарәчесе рәвешендә. Монда хәтле Алтын Урданың бер олысы саналган Кырым 1396 елгы вакыйгалардан соң мөстәкыйль ханлык булып йөри. Күрсәткән хезмәтләре өчен хан Рухтимер бәйне үзенә тагын да якынайта—бертуган сеңлесе Җанәкә солтанны ана кияүгә биреп, бөтенләй туганлашып китә. Рухтимер бәйнең бу никахтан Тәкин бәй исемле улы да туа.

Туктамыш ханның Кырымда ныгып китүе Сарай белән Әстерханны кулга төшергән, Азак-Дон далаларын үз кулында тоткан Тимер Котлык белән Идегәй мирза өчен житди мәсьәләгә әверелә. Шулай илнең ике канатында ике мөстәкыйль көч барлыкка килә. Тәвәккәл һәм кыю, тимерне кызган чагында сугарга яратучы Идегәй мирза 1396 елның көзендә үк Кырымга каршы яу оештыра. Әлбәттә, ул Кырымга зур көч белән бара. Туктамыш хан Генуя сәүдәгәрләре тарафыннан әйбәтләп ныгытылган, калын-биек диварлары да булган Кәфә каласыннан торып сугыша. Тарихтан күренгәнчә, андагы чит ил сәүдәгәрләре гомер-гомергә, кем

көчле шуның ягына чыгып, мондагы бәрелешләр вакытында гел үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәгәннәр. Туктамыш хан Кырымда тупланганнан соң да, яңа хакимгә төрлечә ярдәм итеп, акчалар да биреп торып, аңа якынаерга тырышалар, һәм шушы якынаюдан, диңгез сәүдәсендә булсын, калада торткан урыннарын саклап калуда булсын, үзләренә аерым өстенлекләр алуга ирешәләр. Шуна күрә Идегәй мирза пәйда булу белән Туктамыш хан калага кереп бикләнә. Шәһәр камап алына, бәрелешләр башланып китә.

Әмма итальян сәүдәгәрләре җилнең юнәлеше үзгәрүне бик тиз сизеп алалар, шуна карап эш итәләр. Сарай тәхетенә яңа хан Тимер Котлык чыгу, бу ханның атагы бөтен Кыпчак даласына таралган Идегәй мирзага таянуы да вакыйгаларга билгеле бер төс бирми калмагандыр. Бер сүз белән әйткәндә, көчленеке заман дип, гел үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан Кырым аксөякләре тиздән Сарай ханы һәм аның сәясәтен алып баручы Идегәй мирза ягына авышалар. Итальян сәүдәгәрләре-җәнүизләр дә, Кырым бәйләре-мирзалары да Туктамыш ханга арт белән борыла һәм бу хәл аның Кырымдагы язмышын бөтенләй икенче юнәлешкә борып җибәрә. Җанын саклар өчен аңа Литва кенәзе Витовт хозурына качып китәргә генә кала. Ә Витовт бу вакытта Киев каласында була.

Кырым аксөякләренең нәкъ шушы елда (1397) Тимер Котлык ханнан тарханлык ярлыклары алуы, ярлыкларда бәйләрнең ясак, калан кебек күп төрле салымнардан азат ителүе әлеге бәрелешләрдә аларның яшь ханга ярдәм күрсәтүләре белән аңлатыла булса кирәк.

Кенәз Витовт исә Туктамыш ханны зурлап каршы ала, аңа олы хөрмәт күрсәтә. Хан белән килгән татар сугышчыларына Литва биләмәләре чигендә җирләр бирә. Ханның үзенә һәм күп санлы яраннарына, гомумән, тәхетеннән куылган галиҗәнаб мескенлектә яшәмәсен өчен, халкы-ние белән аңа Лида каласын бүләк итә. Туктамыш хан шушы җирләрдән җыела торган салымнар хисабына яшәргә тиеш була. Литва кенәзе алга карап эш итә—Туктамыш ханга ул үз сәясәтендә бик тә отышлы бер фигура итеп карый. Өстәвенә Туктамыш хан белән килгән татар гаскәриләреннән дә кирәк чакта файдаланып булачак.

## Рольләр алмашына

Туктамыш хан Литва кенәзе Витовт канаты астында яши башлау белән Алтын Урдада вәзгыять тулысынча үзгәрә дә куя. Икенче төрле итеп әйтсәк, Идегәй мирза белән Туктамыш хан, ике кан дошман, үзләре дә сизмәстән урыннарын гына түгел, тарих сәхнәсендә башкарган рольләрен дә алмашалар. Бу чыннан да гаять кызыклы хәл. Әйдәгез, аңа җентеклəбрәк күз салыйк әле.

Идегәй мирза, элегрәк Тимер бәккә качып китеп, аннан торып Туктамыш ханга каршы астыртын эш алып барганда һәм Сәмәрканд әмирен Алтын Урдага яу белән барырга үгетләгәндә бары тик шәхси мәнфәгатьләрдән чыгып кына эш итте, гади генә итеп әйткәндә, дошманыннан үч кайтару өчен тырышты. Ул заман гадәтләрен искә алсак, моны аңлап та, хәтта берникадәр аклап та була кебек. Әмма объектив яктан караганда, Идегәй мирза үз ватаны, туган җире, үз халкына каршы җимерү эше алып барды. Һәм аның максатчан эшчәнлеге Алтын Урда дәүләтенә, таррак масштабта алганда, Идел-Йортка ифрат зур зыян салды. Әлбәттә, аның мондый эшчәнлегенә берничек тә унай бәя биреп булмый. Идегәй мирза мәшһүр дастан каһарманы булган өчен генә аны күкләргә чиеп мактау, эшчәнлегенең күләгәле якларын күрмәмешкә салышу безне хакыйкатьтән читкә алып китәр иде.

Әмма кинәт барлыкка килгән вәзгыять, ягъни Туктамышның Литвага барып урнашуы, ханның үзен Идегәй мирза үткән шикле юлга чыгара да бастыра. Ә аның тарихи көндәше Идегәй мирза исә ил туплаучы, аны ныгытучы, тәртип һәм имин тормыш урнаштыручы ролен башкарырга керешә. Шулай итеп, кан дошманнар булган ике зат үзләре дә сизмәстән рольләрен алмашалар. Язмыш аларны икенче яктан сынарга тотына. Бу сынауларны алар ничек үтәр, нинди гамәлләр кылыр?

Вакыйгаларга күчкәнче Идегәй мирза үткән юл, аның рухи халәте үзгәрүгә кагылышлы бер фикер әйтеп узасы килә. Минемчә, шушы берничә елда Идегәй

мирзаның күңел дөньясында, карашларында, тормышка булган мөнәсәбәтендә зур үзгәрешләр булганга охшый.

1397 елда аңа илле ике яшь—ул инде дөньяны күп күргән, төрле сынаулар үткән, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган олуг зат. Туктамыш ханны Алтын Урдадан куып, илнең сәясәтен үзе теләгәнчә алып бара, гаскәр белән дә үзе идарә итә. Рәсми рәвештә тәхеттә утыручы Тимер Котлык исә көчле агасына каршы сүз әйтерлек шәхес түгел—гомере буе аның канаты астында яшәде, гамәлләрен аның киңәше белән башкара килде, һәм агасының зирәклеге, тырышлыгы аркасында тәхет иясе булды. Шул сәбәпле Тимер Котлыкның роле, чыңгызый буларак, бары тәхеттә утыруга гына кайтып кала. Агасы Идегәй мирзаның, Чыңгыз хан Ясасы буенча, моңа хакы булмый. Тимер Котлыкның исә дәүләт эшләрендә йогынтысы бөтенләй сизелми диярлек. Шуңа күрә без аны телгә алсак та, фәкать Идегәй мирзаның күләгәсе сыман гына кабул итәргә тиешбез. Моны Тимер Котлык ханның 1397—1398 елларда биргән бер ярлыгы да раслый. Анда, мәсәлән, мондый сүзләр бар: «Минем Тимер Котлык сүзем: уң кул һәм сул кул угланнарга, меңбашы, йөзбашы, унбашы бәкләргә аларга баш төмән Идегәй белән...»

Бу документ Идегәй мирзаның бөтен Алтын Урда гаскәрен үз кулында тотуын күрсәтә. Сер түгел, кемдә гаскәр—шул хаким. Кыскасы, 1397 елдан соң Алтын Урдада булган вакыйгаларда төп тарихи фигура Идегәй мирза булып кала. Барысы да аның катнашы белән башкарыла яисә турыдан-туры башлап йөрүенә бәйле.

Әлбәттә, хакимиятнең иң югары баскычына күтәрелү Идегәй мирзага үз йогынтысын ясагандыр. Шушы көннән аның өчен яңа дәвер башлана, хәзер ул зур мәмләкәт башында торучы ирке чикләнмәгән зат. Инде ил язмышы, иминлеге аның җаваплылыгында. Аның инде, элекке кебек, шәхси мәнфәгатьләрдән чыгып кына эш итәргә хакы юк. Һәм ул моны яхшы аңлый. Әгәр дә тарихи Идегәй мирза моны аңлап эш итмәгән булса, ул беркайчан да, халык күңелендә зур урын алып, аның хәтерендә сакланып калмас, дастанның төп каһарманына әверелмәс иде. Дастанда Идел-Йорт халкы Туктамыш ханга да, Идегәй мирзага да үзенең гадел бәясен биргән. Шуңа күрә без Идегәй мирзада, Туктамыш ханнан арынгач, зур рухи үзгәреш булган дип әйтә алабыз. Бу чорда ул, чыннан да, күптәнге хыялына ирешә, таркала барган татар дәүләтен, тинтәк ханнар кулыннан тартып алып, аны саклап калу, яшәтү өчен олуг хезмәткә керешә. Әмма Алтын Урда дәүләтенә язмыш инде үз хөкемен чыгарган була. Бу очракта хәтта Идегәй мирза кебек гаҗәеп көчле шәхес тә тарихи закончалыкларны үзгәртә алмый—бары тик аларның үтәлүен беразга тоткарлап торуга гына ирешә. Идегәй мирзаның титаник тырышлыгы аркасында Алтын Урданың гомере беразга озая төшә. Менә ни өчен халык бу шәхесне хәтерендә калдырган, аның вафатыннан соң, дәүләт тәмам сүнә барган бер дәвердә, атаклы мирза хөрмәтенә гүзәл җыру—мәшһүр «Идегәй» дастанын—татарның бөек дәүләтен сагыну җырын иҗат иткән.

## «Шөһрәтле качак» хәрәкәткә килде

Тарихи вакыйгаларның эчке логикасын аңлар өчен фактларны бер чылбырга тезеп чыгарга туры килә. Алар җитәрлек булганда, моны эшләү җиңел, ә җитмәсә? Ул чакта инде булганы белән канәгатьләнергә туры килә. Җитешмәгәннәрен вакыйгалар агышын, катнашкан каһарманнарның шәхси сыйфатларын, сәяси карашларын, кылган гамәлләрен исәпкә алып, гомумән, вакыйгалар чылбырының өзелгән бәҗраларын шуннан чыгып тулыландырырга кала.

Литвага качып китәргә мәҗбүр ителгән Туктамыш хан, әлбәттә инде, кенәз Витовка таянырга, шулай тәхетен кайтару эшенә керешергә, аның юлларын эзләргә тиеш иде. Бу—табигый. Аның белән байтак татар кучеп китә, шуңа күрә ул үзен һаман әле законлы хан кебек хис итә, шундый дәгъва белән яши, һәрхәлдә, эчендә пыскыган гарьлек һәм кимсенү утын ятларга сиздермәскә тырыша.

Тышкы яктан караганда, аның хәле ул кадәр үк начар да түгел кебек—кенәз Витовт аны хөрмәт итә. Менә туеныргa Лида каласын бирде, аның татарларын чик буена урнаштырды. Бу шартларда Туктамыш хан үзенең «шөһрәтле качак» булып яшәвен вакытлы бер хәл итеп күрсәтергә тырышкандыр. Дөнья бит,

һәркем андый хәлдә калырга мөмкин... Ә жанында нинди ут дөрләгәнен, эчтән аны нинди ялкын, нинди авыр хисләр кимергәнен үзе генә белгәндер.

Ә бит боларның барысы да Идегәй, каһәр суккан Идегәй мирза аркасында килеп чыкты, ул гаепле! Тәхеттә утырган Тимер Котлыкны ул житди кабул итә алмый. Идегәй булмаса, Тимер Котлыкны ул тәхеттән этеп кенә төшерер иде. Юк шул, бөтен хикмәт әлеге үткен-унган да, хәйләкәр-зирәк тә, куркусыз да, барысын алдан күреп эш итә белүче Идегәй мирзага бәйле. Тормышны шул фетнә бозды, барысын чәлпәрәмә китерде.

Туктамыш ханның Идегәй мирзаны ни дәрәжәдә күралмавын күз алдына китерүе кыен түгел.

Туктамыш хан үз хәлен жиңеләйтү, Идегәй мирзадан үч кайтару нияте белән кайбер адымнар ясарга керешә. Аның ни дәрәжәдә түземсезләнүен, яуга ничек ашкынуын да аңлап була кебек. Үгетли торгач, ул кенәз Витовтны кайбер сугыш хәрәкәтләре ясап карарга күндерә. Хәер, кенәзнең үз фикере дә күптән шул тирәдә әйләнә—Алтын Урда жирләренә күптән күзе кыза.

1397 елның жәй ахырларында, Идегәй мирзага жавап йөзеннән, пишальләр һәм туплар (яңа корал) белән ныгытылган литва-татар гаскәре Алтын Урданың әллә ни ишле булмаган көчләрен жиңүгә ирешә. Күрәсең, бу вакытта Идегәй мирзаның төп көчләре Азак далаларына, Идел-Йортка әйләнеп кайткан булгандыр. Шулай да дошман бу уңышны ныгытып өлгерә алмый. Идегәй мирза 1398 ел башларында литва-татар гаскәрен Кырымнан бәреп чыгара, Туктамыш ханга кабат кенәз Витовт хозурына әйләнеп кайтырга туры килә.

Яңача коралланган гаскәрнең шулай туздырылып ташлавы кенәз Витовтның мин-минлегенә тигән булса кирәк. Житмәсә, Туктамыш хан да аны гел яуга өнди, үч кайтарырга чакыра. Шул сәбәпле 1398 елда Витовт Дәшти Кыпчакка жавап явы белән бара. Идегәй мирза белән Тимер Котлыкка гайрәтен күрсәтеп ала. Шик юк, яуны Туктамыш хан татарлары таныш юллардан алып килгән, Алтын Урданың үзәгенә китереп сугу өчен тиешле киңәшләрен биреп торган. (Әйтерсең, чит дәүләт жирләрен талыйлар!)

Чыннан да, бу яу Идегәй мирза өчен көтелмәгәндә килеп чыга. Дошман дала буйлап Дон елгасына кадәр үтеп керә, ул чакта Төп Урда нәкъ шушы тирәдә урнашкан була. Шуңа күрә ырулар зур зыян күрә, бик күп халык әсирлеккә төшә, Литвага куып алып кителә. Шулай ук даладан бихисап терлек-туар көтүләре жыеп алына, ягъни илнең иктисадына да зыян килә.

Яу шуның белән тәмамлана. Аның нәтижәләреннән чыгып фикер йөртсәң, ул бер көч-гайрәт күрсәтү, Алтын Урданы капшап карау гына булган дигән тәэсир кала. Бәлки, Витовт үзенә киңрәк максатлар да куйган булгандыр, тик моңа көче житмәгән, шуңа бу юлы татарларны сынап карау белән генә чикләнергә туры килгән. Ләкин хәлне ике як та яхшы чамалый—эш әле моның белән генә бетмәячәк, төп бәрелеш әле алда. Ни өчен дигәндә, Туктамыш хан исән чакта—Идегәй мирза, Идегәй мирза яшәгәндә—Туктамыш хан күңел тынычлыгы тапмаячаклар. Бу каршылык, аяусыз көрәш алдагы елларда әле татар дәүләтен даими тетрәтеп торучы, аны торган саен хәлсезләндерә баручы төп факторга әйләнәчәк. Көрәш әле тагын егерме елга сузылачак. Туктамыш хан үлгәч, Идегәй мирзага каршы аның уллары көрәшәчәк. Шулай татар, бер-берсе белән сугышып, даими рәвештә үз дәүләтен какшатачак, үз-үзенә ачы язмыш әзерләячәк.

Татар акылы төштән соң, ди халык. Хак әйтә. Бер генә әйтем-мәкаль дә сәбәпсез барлыкка килмәгән.

## Бурсыклы сугышы (1399 ел)

### 1

Туктамыш ханның Литва кенәзе Витовт канаты астына кереп сыенуы, аның белән сүз берләшеп, Алтын Урдага каршы яулар оештыруы Идегәй мирза өчен житди бер мәсьәләгә әверелә. Бу вакытта илле дүртенче яше белән барган Идегәй мирза язмышының иң биек баскычына күтәрелә. Аның кискен

борылышлар, хәтәр эшләр, канкойгыч бәрелешләрдә узган гомере, максатына ирешү өчен тәхет тирәсендә фетнәләр оештыруы, кирәк чакта аркадашлар табып, кирәге беткәч, алар белән араны өзә белүе, күп еллар туган иленнән еракта, ят җирләрдә яшәве—барысы да хакимиятнең иң югары баскычына күтәрелү. Алтын Урда тәхетенә Тимермәлик хан белән апасының улы Тимер Котлыкны куеп, аның исеменнән ил белән идарә итү өчен эшләнә. Инде менә барысына да ирештем—татар дәүләтенә хуҗа булдым дигәндә генә—Литва кенәзе Витовт һәм тәхеттән куылган Туктамыш хан аның бәхетен тартып алмакчылар. Аңа бит хәзер сугыш-орышларсыз гына яшисе, имгәнгән татар дәүләтен җайга салу, ныгыту, тормышны көйләү белән шөгыльләнәсе иде. Ул үзе дә сугышлардан, кан коюлардан тәмам туйды, инде сакалы чаларды, алтмышны ваклап бара. Әмма, язмыштан узмыш юк, күрәсең. Адәм баласы тәкъдирендә язылганның барысын да кичерергә тиештер...

Туктамыш хан Идегәй мирзаның илне ныгыту буенча ясаган һәр адымын көнләшеп һәм үчегеп барлап тора иде. Туган һәр көн дошманының хакимиятен ныгыта баруын һәм, киресенчә, аның өчен тәхетне кайтарып алу ихтималын киметә төшүен ул эчтән кимерелеп, хафага төшеп күзәтә. Көннәрдән бер көнне, түземе төкәнеп, ул кенәз Витовт белән ныклап торып сөйләшү өчен Вильно каласына чыгып китә. Аның күңелендә мәгълүм бер уй-ният тәгаенләнеп, ул аны, күрешкәч, кенәз Витовтка ачып салырга була.

...—Бөек кенәз! Синең өчен сер түгелдер—Аллаһы Тәгаләнең һәр бирмеш көне Идегәйнең көчен-куәтен арттыра, хакимиятен ныгыта. Ул инде Урдада үзен чын хуҗаларча тота, иркенәеп китеп эш йөртә, гәрчә тәхетенә Тимер Котлыкны утырткан булып кыланса да... Әйдә берләшик, ярдәм ит миңа...

Туктамыш ханның йөзенә куксел тимгелләр бәреп чыкты. Моны кенәз Витовт та күреп алды, эчтән генә: «Тәхеттән куылган хан хәлендә калырга язмасын»,—дип уйлап куйды, тик йөзенә чыгармады.

—Кодрәтле хан!—диде ул, Туктамыш ханны юатырга тырышып.—Сиңа мәгълүмдер—бүгенге көндә тәре йөртүчеләр—Ливон ордены белән мөнәсәбәтем шактый катлаулы. Аннан соң Новгород белән Мәскәү мәсьәләсе дә хәл ителеп бетмәгән. Бу очракта ашыгу кирәк микән. Миңа ике тарафта сугыш алып бару авырга туры киләчәк.

—Узган ел бит Донга чаклы җиттек, күпме ганимәт малы, даладан терлек-туар куып алып кайттык. Берләшеп эш итсәк, безне беркем туктата да, җиңә дә алмаячак...

—Узган елгы яу бер җилләнеп кайту гына булды. Чынлап тотынсаң, сугыш озакка сузылачак, көч күп кирәк булачак.

Кенәз Витовт тынып калды. Туктамыш хан, аның икеләнеп торуыннан файдаланып, сонгы дәлилен китерергә булды, шуның белән Литва кенәзен ризалаштырырга өметләнде:

—Бөек кенәз!—дип кабатлады ул, аннан дусларча елмаеп, үз итеп:—Кадерле Витовт! Әйдә без синең белән шундый килешү төзик. Мин сиңа бик тә әйбәт шартлар тәкъдим итәм.

Кенәзнең кашлары өскә сикереп, дугаланып алды:

—Нинди?

—Әгәр дә миңа тәхетемне кайтарырга ярдәм итсәң, Урданы үзара бүлешербез. Мәскәү кенәзлеге, Новгород, Псков, шуңа өстәп Тверь белән Рязань синеке булыр. Ә инде Сарай белән Хаҗитарханны, Азакны, Болгарны, Иделдән көнчыгышта яткан далаларны мин үземә калдырырмын. Риза бул. Бәхетеңнән баш тартма...

Ачыктан-ачык әйткәндә, Туктамыш ханның тәкъдиме Витовт үзе уйлаганнан да кызыклырак һәм отышлырак булып чыга түгелме? Эш болайга киткәч, бәлки, чыннан да, бу зур уенны башларгадыр. Туктамыш тәхетеннән куылса да, аның хан исемен берәү дә тартып алмаган. Санап чыгылган олыслар, калалар барыбер аныкы санала, тарафдарлары күп. Зур көч туплап, сугышны уңышлы тәмамласалар—күпме җирләр Литва кенәзлегенә килеп кушылачак. Ә бу байлык, кодрәт, шөһрәт дигән сүз. Җавап бирмичә торган арада кенәз Витовт менә нәрсәләр турында уйлап алды.

—Ярый,—диде ул, Туктамыш ханга кулын сузып:—Тәкъдименне кабул итәм.

Әлеге карарны кабул итү кенәз Витовтның планнарын үзгәртеп җибәрә. Ул зур яуга әзерлек чаралары күрә башлый. Польша короленә һәм Ливон орденына мөрәҗәгать итә. Польша короле Ягайло, кенәз Витовт сораган күләмдә үк бирмәсә дә, аңа хәрби көч белән ярдәм итәргә була. Ливон рыцарьларын үз ягына аудару өчен, Витовт аларга жемудь кабиләләре җирләрен бүләк итә, шуның бәрабәренә булачак яуда тимердән киенгән рыцарьлар да катнашырга тиеш була.

Бу хәзерлекләрне Мәскәү кенәзе, кенәз Витовтның кияве Василий Дмитриевич та бик шомланып күзәтә. Әле 1395 елда ук кенәз Витовт кияреннән Смоленскины тартып алган була. Дөрес, Смоленскины турыдан-туры Мәскәү җирләренә керә дип әйтеп булмый, әмма барыбер Литваның һаман кинәя баруы аны нык борчый иде. Аннан каенатасының Новгородка күзе кызуы да аны бик нык борчый. Хатыны Софьядан ишетүенә караганда, узган ел (1398) Ливон рыцарьлары катнашында Новгород белән Псковка яу йөрергә килешкән булганнар. Яу уңышлы чыкса, Новгород—каенатасы Витовтка, Псков—немец рыцарьларына калачак икән.

Әмма Туктамыш хан белән килешү төзү Витовтның планнарын үзгәртә, аның каршында тагын да зуррак мөмкинлекләр ачыла.

Идегәй мирза да Литвада «шөһрәтле качак» рәвешендә яшәгән Туктамыш ханның хәрәкәтләрен борчылып күзәтә. Тәхетне кайтарып алу өчен аның Витовтны яуга тартырга омтылачагы Идегәй мирза өчен ачык. Әмма кайчан? Яу көтмәгәндә башланмасмы? Аны менә нәрсә борчый иде.

Якын арада зур сугыш алып барасы килми иде Идегәй мирзаның. Хәзер аңа илне ныгыту өчен тыныч еллар кирәк. Әмма теләсә-теләмәсә дә, гаскәр туплый башларга, яуга әзер торырга була ул. Шул ният белән тәхеткә утыртылган Тимер Котлык ханга урдасын Литва чикләренә, Днепр тирәсенәрәк күчерергә киңәш итә, чөнки дошман ил эченә үтеп керсә, көрәшү кыенга туры киләчәк.

Кенәз Витовтның зур яуга әзерләнүен белеп торса да, Идегәй мирза бер чара кулланып, аны сынап карарга була—аңа хат юллап, шул хатта Туктамыш ханны үзенә кайтаруны таләп итә. «Качкын Туктамышны миңа кайтар, ул минем дошманым. Аның исән-сау килеш синдә яшәп ятуы тормышымның ямен ала, кәефемне боза»,—диелгән була ул хатта.

Әлбәттә, Идегәй мирза бер каптырмалы затлардан түгел, кенәз Витовтның Туктамыш ханны бирмәячәген белеп тора, андый эшне үзе дә хупламаган булыр иде. Бу дошманны сынап карау гына иде. Кем белә, бәлки, күрше мәмләкәттән шундый хат килгәч, Литва кенәзе ханга ярдәм итүдән баш тартыр...

Бераз көттереп булса да, көннәрдән бер көнне Литвадан җавап килә. Аны китергән чапкынны тиз арада Идегәй мирза каршына китереп бастыралар. Ул түкми-чәчми кенәз Витовтның сүзләрен тапшыра:

—Мин сиңа Туктамыш ханны бирмәячәкмен, Тимер Котлык хан белән үзем күреп сөйләшергә телим.

Җавапның Идегәй мирзаны кимсетү өчен махсус җибәрелгәне ап-ачык. Татар дәүләтендә хан син түгел, Тимер Котлык, кая кысыласың, дигән фикер анда ярылып ята. Мондый тупас җавап сугыш игълан итүгә тиң. Шулай итеп, Литва кенәзе, Урдага китереп сугарга җыенуын сиздереп, Аксак Тимер яуларыннан соң һаман аякка баса алмаган мәмләкәтегездә миңа, Литваның олуг кенәзе, Кейстут углы Витовтка каршы торырлык көч табылырмы соң, дигән тәкәббер сорау да куя сыман. Дөрестән дә, булачак яуны кенәз Витовт алай ук кыен эш дип санамаган булса кирәк.

## 2

Кенәз Витовт яуга чынлап әзерләнә башлый. Аның үз гаскәренә Туктамыш хан татарлары, көньяк рус кенәзлекләре полклары, поляклар һәм тәре йөртүче Ливон ордены рыцарьлары да өстәлә. Шулай 100 меңгә якын гаскәр туплана. Заманның соңгы казанышлары кимәлендә коралланган бу гаскәрдә хәтта махсус тупчылар бүлеге дә була. Шуңа күрә кенәз Витовт сугышның җиңү белән тәмамланасына нык ышана, шушы көч белән татар илен яулап алырга җыена.

Менә яу татар даласына таба кузгала. Сугыш кирәк-ярагы, азык-төлек

төялгән олаулар үзләре үк ничә чакрымга сузыла. Алар тиз бара алмый, шуңа гаскәргә дә акрын хәрәкәт итәргә туры килә. Бераздан хәл ачыклана—татарлар Днепрның сул кушылдыгы саналган Бурсыклы елгасы буенда (рус чыганакларында бу елга бозып Ворскла дип атала) тора, Тимер Котлык хан урдасы шунда урнашкан. Тик дошман татарларның төп көчләре Идел-Азак буенда, Идегәй мирза кулында булуын, монда исә Тимер Котлык ханның берничә төмәне генә торуын белми. Белсә, бәлки, килә-килешкә орышка да кергән булыр иде.

Дошман явы якынлашкан саен Тимер Котлык хан урдасында хәвеф арта, төмән башларының да, гади сугышчыларның да йөзе караңгылана бара. Ни өчен дигәндә, хәбәргәрләр китереп торган хәбәрләр бер дә өметкә урын калдырмый—дошман бихисап зур көч белән килә, шушы көч күнелләргә шом сала. Менә кенәз Витовт явының маңгай полклары Бурсыклыга килеп үк туктый, ә арттан килүче гаскәрнең иге-чиге күренми.

Шулай өч көн Бурсыклы буена дошман явы агыла.Дүртенче көнгә киткәч, Тимер Котлык хан иртән иртүк, калкурак бер төшкә менеп, дошман ягына күз сала һәм шунда йөрәге «жу» итеп китә, тәне салкын тир белән каплана. Ул төмән башлары белән бәкләрне, әмирләрне ашыгыч киңәшмәгә жыярга боера.

Ярты сәгатьтән барысы да жыела, киеренке тынлыкта ханның сүзен көтә.

—Бисмилләхир-рахмәнир-рахим!—Яшь ханның тавышы каушабрак чыга, моны барысы да сизеп ала.—Алдыбызда торган дошман артык көчле һәм ишле. Аның кинәт һөҗүм итүе бар. Безнең көчләр исә аз, анысы үзегезгә мәгълүм. Бу очракта орышка керү акылсызлык булмасмы?—дип, Тимер Котлык хан жаваплылыкны өлешчә тынлаучылар өстенә салуны кирәк таба. Бераз тын торганнан соң сүзен дәвам иттерә:—Без үзебез тәхеткә тугры әмирләр белән баһадирларыбызның һәлак булуын теләмибез. Шул сәбәпле кенәз Витовт белән сөйләшү башлап жибәрергә, солых сорарга кирәк дигән уйда торабыз. Кем моңа каршы?

Хан жыелган гаскәр башларына күз йөртеп чыга. Кайтарып сүз әйтүче табылмагач, мәсьәләне үзе хәл итә:

—Аллаһ ярдәменнән ташламасын!

Берничә кеше, аның зирәклеген мактап сүз әйтсә дә, күпләрнең йөзе караңгы, күзләре ханга карамаска тырыша иде. Каршы дәшәргә бераү дә жөрьәт итми. Барысының да уенда Идегәй мирза. Тизрәк килеп житсен дә шушы куркак кулыннан идарәне тартып алсын иде. Мондый түбәнлеккә төшкәнче...

Әмма хан инде илчеләрне кенәз Витовтка солых теләнергә озату өчен соңгы күрсәтмәләр бирә иде.

### 3

—Олуг кенәз Витовт галиҗәнаблары! Кодрәтле Тимер Котлык хан сина сәлам юллый, үзенә һәм яраннарына саулык, иленә-көненә иминлек тели,—дип башлый сүзен татар илчесе.

Кенәз Витовт ягыннан, йола таләп иткәнчә, сәлам кабул ителгәч, илче төп сүзгә күчә:

—Тимер Котлык хан синнән, олуг кенәз: «Ни өчен жиремә аяк бастың? Мин синең жиреңне дә, калаларың белән авылларыңны да тартып алмадым?»—дип сорый. Ул синнән жавап көтә.

Илчегә жавап кайтарганчы кенәз Витовт башта зур чатыр эченә жыелган Литва һәм Польша аксөякләренә, немец рыцарьларына, рус кенәзләренә караш ташлап ала. Татар илчесенең сүзне болай мескен башлавы аны гажәпкә сала. Аның уенча, татар ханы аның өстенә ярсу әтәч кебек очып кунар, гаепләү сүзләре ташлап, куркыта башлар дип көткән иде ул. Димәк, Тимер Котлык хан илчесен солых сорар өчен жибәргән. Кенәзнең сөенече йөзенә бәреп чыга. Моны мәрасимдә (церемониядә) катнашучыларның барысы да күреп ала, кенәзгә канәгать көлемсерәү белән жавап бирәләр. Димәк, Урданың хәлләре чыннан да мөшкел икән. Яу кузгатып ул дөрес эшләгән. Бүгенге көндә аңа каршы торырлык көч юк. Сарайның биләмәләрен тартып алса, аннан да кодрәтле хаким булмаячак. Шуңа күрә кенәзнең жавабы катгый яңгырый:

—Аллаһы Тәгалә ярдәме белән мин күп жирләрне, халыкларны яуладым.

Син дә, Тимер Котлык хан, миңа угыл бул, ә мин сиңа ата булырмын. Миңа ясак түләп торырсың. Әгәр дә угыл буласың килмәсә, колым булырсың...

Бу сүзләрдән илченең йөзе, камчы белән сыдыргандай, тетрәнеп куя. Ул бераз югалып тора да, үзен кулга алып, кенәз алдында бил бөгә һәм чыгып китә. Арттан, чатыр эченнән, кенәз Витовтны котлап әйтелгән дәртле авазлар ишетелә.

Шулай ике арада илче йөрергә тотына. Күпмедер вакыттан соң татар илчесе солыхка ризалык алып килә. Әмма кенәз Витовт бу юлы Тимер Котлык хан алдына тагын да катгыйрак таләп куя. Ул болай ди:

—Урдада сугылган акчаларда минем исемем булырга тиеш!

Дошманның оятсыз таләбе белән илчегә кабат хан янына әйләнеп кайтырга туры килә.

### 4

Кенәз Витовтның яңа таләбе Тимер Котлык ханны, диварга терәп куйгандай, чарасыз итә. Аңа риза булсаң, Сарай Литва кенәзлегенең бер олысына әверелә дә куя. Бу—дәүләтенне, мөстәкыйльлегенне югалту дигән сүз. Әлбәттә, Тимер Котлык хан моңа бара алмый, шуңа күрә мәсьәлә, асып куйган чаң тимередәй, һавада асылынып кала. Ә кенәз Витовт җавап көтә, вакытны сузсаң, һөҗүмне башлавы да бик ихтимал.

Тимер Котлык хан түземсезләнеп агасы Идегәй мирзаның килеп җитүен көтә. Ул үзен белгәннән бирле агасы киңәше белән яшәде, һәр адымы аның ярдәме белән ясалды, Сарай тәхетенә дә абзасы ярдәме белән чыкты. Ул мәмләкәтнең үзәк өлкәләреннән җыелган зур гаскәр белән кичә үк килеп җитәргә тиеш иде. Нигәдер тоткарланды. Килеп өлгерсә, Тимер Котлыкның өстеннән тау төшкәндәй булыр иде.

Шулай да бәхете бар икән Тимер Котлык ханның! Чатырга килеп кергән чапкын Идегәй мирза түбәннәренең Урдага якынлашуын хәбәр итә.

Бу вакыт тышта:

—Идегәй килә!

—Ярдәм килә! Ярдәм...

—Бәкләрибәк ярдәмгә килә!—дигән дәртле авазлар яңгырый башлый.

Сугышчылар да, гади олаучылар, хезмәтчеләр дә, эшләрен ташлап, Алтын Урданың гаскәр башы—бәкләрибәк Идегәй мирзаны каршыларга ашыгалар. Аның турында гаҗәп сүзләр йөри иде. Имеш, ул Аксак Тимернең үзен җиңгән, хәйләсе белән аны төп башына утырткан...

Менә якынлашып килүче атлы гаскәрдән җир селкенә башлагандай була. Алда унлап гайярь егет тарафыннан ярым алка эченә алынган Идегәй мирза үзе бара. Озын аяклы җинел ат ияр өстендәге төз гәүдәле җайдакны сизми дә кебек. Идегәй мирза өстендә юка парчадан тегелгән затлы халат, кыска җиңле комзол, билендә зиннәтле аел белән бизәлгән кин каеш. Башында парчадан тегелеп, мех белән каймаланган җинел бүрек. Урта буйлы, нык бәдәнле иллене узган Идегәй мирза башкалардан кара тутлы йөзе, көчле күз карашы белән аерылып тора. Гомерендә даланың җил-давылларын, кар-бураннарын, канлы орышларын күп күргән, алардан исән чыккан, акылы, зирәклеге, һәр нәрсәне алдан күреп эш итә, кешеләргә йогынты ясый белүе аркасында хакимиятнең иң югары баскычына күтәрелгән чын баһадир, асыл зат иде ул. Дәүләт эшләрендә дә, тормыш-көнкүрештә дә, галим-голямә белән аралашканда да вәзгыять һәм шартлар таләп иткәнчә эш йөртә, кирәксә, кешеләрне үз ягына аудара белә иде Идегәй мирза. Аңа хас төп сыйфат—кирәк чакта дөрес карар кабул итә белү иде.

Ул атыннан төшмичә генә кешеләрне үз янына чакырып ала, аларга кыска-кыска боерыклар бирә. Тегеләр боерыкны алу белән аны үтәргә ашыга. Бу да аның абруен, аңа булган ышанычны, хөрмәтне күрсәтә иде. Зур гаскәр белән Идегәй мирзаның килеп җитүе хан урдасында кәефләрне күтәреп җибәрә, төрле яктан дәртле авазлар яңгырый, моңарчы хөкем сөргән билгесезлекнең эзе дә калмый.

Аңа хан тирмәсендә нинди карар кабул ителүен дә, аннан соң булган хәлләрне дә житкереп өлгерәләр. Ул, урданы саклаучылар янында туктап та

тормыйча, бер төркем әмирләр белән хан чатырына якынлаша. Атыннан төшеп, эчкә уза.

Бәкләр, әмирләр Идегәй мирзаны күптән көтсәләр дә, аның чатырга килеп керүе ничектер кинәтрәк килеп чыга. Билләр бөгелә. Идегәй мирза иелгән аркалар өстеннән тәхеттә утыручы Тимер Котлык ханга күз ташлап ала да аңа таба китә. Яшь хан нидер әйтмәкче булып авызын ача, тик абзасының ярсу йөзен күреп, катып кала, сүзе тамагына тыгыла.

Идегәй мирза бер сүз дә дәшмичә ханга арты белән борыла, тезелешеп баскан киңәшчеләргә, әмирләргә күз йөртеп чыга. Йөзе яшенле яңгыр алып килгән кара болыттай.

—Ишетүемчә, монда кайберәүләр колак ишетмәгән мәсхәрәлеккә төшәргә—дошманнан солых теләнергә әзерләнәләр икән,—дип башлый ул сүзен.—Мин моны «мәсхәрәлек» дип бәялим, чөнки орышмыйча солых теләнү—дала батырларын мескен хәлгә куя. Безгә ни булды? Кая азаматлыгыбыз, ирлегебез? Соңге очында татар данын йөртүчеләр без түгелме?—Бәкләрибәкнең һәр әйткән сүзе эрегән кургаштай тама, чаң тавышыдай, миләрдә яңгырый.—Мондый мескенлекне күрсә, бабаларыбыз ни әйтер—алар оятларыннан каберләрендә әйләнеп ятар иде! Туган жиребезне кара күмергә әйләндергән Аксак Тимер явы сезгә житмәдеме?

Чатырда үлем тынычлыгы урнаша. Идегәй мирза күрә: кешеләр аннан күзләрен яшерә, димәк, әле өмет бар...

—Жир йөзендә иң яманы ни-нәрсә?—дип чатырдагылар өстенә сорау ташлый ул һәм үзе үк жавап бирә:—Халык өчен иң яманы—дәүләтеңне югалту, ирекле халыкның ятлар колына әверелүе. Без мона бара алабызмы? Юк, бара алмыйбыз! Тәхетеннән сөрелгән оятсыз Туктамыш хан монда дошманнар ияртеп килде. Алар белән берләшеп ватаныбыз Идел-Йортны таларга жыена! Шуны читтән күзәтеп торыйкмы? Юк, тормабыз! Әллә туган-үскән, кендек каныбыз тамган шушы изге жирдә дошман хужа булуын телибезме? Юк, теләмибез! Ата-бабаларыбыздан мирас булып калган изге Идел-Йорт безнең бәхетебез түгелмени? Без бәхетебезне шушында таптык, абруй казандык. Дөньяда туган жирдән дә изге ни-нәрсә бар? Аны дошман кулына бирү мөмкинме?..

Бөек бәкләрибәк сөйләде дә сөйләде, әмирләрне, төмән башларын татар данына лаек булып калырга өндәде. Ур күрде: әмирләрнең, төмән башларының караңгы йөзләре акрынлап үзгәрә, аларда тәвәккәллек, өмет, ярсу, дәрт чаткылары арта бара иде.

—Дошманга баш биргәнче үлем артыграк!—дип тәмамлый ул сүзен.

Чатыр эчендәгеләр аны дәррәү күтәреп алалар.

—Яшәсен Идел-Йорт! Яшәсен Идегәй!

—Алып кер орышка, бәкләрибәк!

Аннан соң Идегәй мирза, бәрелешкә әзер булырга боерып, әмирләрне, төмән башларын үз сугышчыларына озата.

Татар урдасы, гөж килеп, хәлиткеч орышка әзерләнә башлый.

## 5

Бу көн тарихка урта гасырлар азагындагы иң аяусыз һәм канкойгыч сугышларның берсе буларак кереп кала. Ул 1399 елның 12 августында Днепрның сул кушылдыгы Бурсыклы буенда була. Бу сугыш кояшы байый баручы татар дәүләтенең гайрәтен дөньяга тагын бер күрсәтә.

Бөек бәкләрибәк Идегәй мирза, олуг кенәз Витовт белән шәхсән очрашырга теләк белдереп, аңа илче жибәрә. Берничә сәгатьтән алар сөзәк ярлы Бурсыклы елгасы ярында очрашалар. Бер-берсе турында күп ишетсәләр дә, бу аларның беренче күрешүе була. Бер ярда—озын буйлы, көяз киенгән кенәз, каршы ярда—уртача буйлы, горур кыяфәтле бәкләрибәк. Ниһаять, ачыктан-ачык сөйләшү башлана. Күп тә үтми эшне үзара килешеп төгәлләү мөмкин түгеллеге ачыклана. Кенәз Витовт үзен инде жиңүчегә саный, чөнки сөйләшү барышында татарлар ясаган һәр чигенеш аңа Алтын Урданың көче аз икәнне раслап тора. Хәлсез мәмләкәттән зуррак калжа әләктереп калырга кирәк, дигән фикер аңа тәкәбберлек өсти.

Идегәй мирза исә, киресенчә, мәмләкәтне Витовт белән Туктамыш талавыннан саклап калу, аны ныгыту, элекке тәртипләрне кайтаруны кайгырта. Ул гомере буе хакимияткә омтылды, инде аның иң югары баскычына күтәрелгәч

кенә кулыннан ычкындырсынмы? Кичә олуг кенәзнең Тимер Котлыкка «угыл» булырга тәкъдим итүен белгәнгә, бөек бәкләрибәк сүзне нәкъ шуннан башлады:

—Әйе, ханны үзеннең «угылын» дип атарга синең хакың бар, чөнки син аннан өлкән. Әмма уйлап кара: мин дә бит синнән өлкәнрәк, ә син миннән яшьрәк. Шулай булгач, мин дә сиңа «ата» тиешле, ә син миңа «угыл» булырга тиешсең. Кенәзлегеңә кергән барлык җирләрдән ел саен миңа ясак түләп торырсың. Тагын шуны бел—суктырган акчаларыңа исемемне дә төшерерсең!

Бөек бәкләрибәк олуг кенәз Витовт алдына кичә Тимер Котлык ханга куйган таләпләрне үк куя. Кенәз Витовт өчен бу—аның яңагына сугу белән бер була, ул бик нык гарьләнә. Аны, бөек Литва кенәзен, кемдер үзенең «угылы» дип атый, үзенә буйсынган хаким сыйфатында күрә. Һәм моны ул кемнән ишетә... Күптән түгел Туктамыш хан хезмәтендә йөрүчедән!

Кенәз Витовтның гарьләнүдән хәтта тыны кысыла, йөзе кызарып чыга. Ул, ярсыган йөрәген тыя алмыйча, атын кисәк бора да сафларга тезелгән гаскәренә таба чаба. Килеп җитү белән һөҗүмгә әзерләнергә боера.

## 6

Елганың бу ярында җәелеп яткан болында татар гаскәре тора. Каршы якта—дошман. Тимер туннарга, көбәләргә төренгән, кылыч-сөңгеләре тырпаешкан, үлемгә сусаган ике зур яу җаннарга шом сала. Ике бинигая көч бер-берсен бугазларга, күп каннар коярга әзерләнә.

Идегәй мирзаияр өстеннән гаскәрне барлый. Җинел, вак бөҗралы көбә күлмәктән булгангамы, ул бүген яшәреп, ыспайланып киткәндәй күренә. Хәрәкәтләрендә тәвәккәллек һәм үз-үзенә ышану. Ул гаскәрдәге кулларның ничек урнашуын, боерыкларның төгәл үтәлүен күзәтә, ара-тирә өстәмә боерыклар биргәли. Менә маңгайга ук җәя, кылычлар белән генә коралланган җинел атлылар кулы килеп баса. Алар артында урта кул, ике якта, пар канатлар кебек, сул һәм уң куллар урын ала. Һәр кулның башкаларныкыннан аерылып торган үз әләме җилферди. Орыш барышында сугышчылар, кояшка карап көн вакытын билгеләгәндәй, үз әләмнәрен гел күз уңында тотарга тырышалар, шулай гомуми хәлне белеп торалар. Ә уртада иң зурысы һәм затлысы—Тимер Котлык хан туты җилферди. Идегәй мирзаның сыналган, күп орышларда катнашкан үз төмәне елга борылышындагы таллык артына постырмага куелган—алар орышка иң хәтәр вакытта, хәлиткеч мизгелдә кертеләчәк, дошман һич көтмәгәндә китереп сугарга, аны сытып үтәргә әзер торачак. Сафларга тезелгән гаскәр, һавада ялтыраган сөңге очлары, дәртле җилфердәгән әләмнәр бөек бәкләрибәк Идегәй мирза күңелендә горурлык хисе уята. Бу аның үз гаскәре, бәкләрибәкнең һәр сүзен үтәргә атлыгып торучы гаскәр. «Шушындый көч-куәт була торып, солых төзергәме»—дип уйлап куя ул, тик уен уйлап бетерә алмый—вакыты ул түгел...

Аннан ул дошман ягына борыла. Кенәз Витовт уртага көньяк рус кенәзлекләреннән тупланган полклар белән немец рыцарьларын куйган. Соңгыларының ак җирлеккә кара тәре сугылган зур байраклары әллә каян күренеп тора. Ян-якта Туктамыш хан төмәннәре белән Литва атлылары урнашкан. Еракта, кенәз Витовтның үз әләме җилфердәгән җирдә Польша һәм Литва рыцарьлары тора. Күп кавемнәр берләшүеннән барлыкка килгән шушы коточкыч зур гаскәр алдында, авызларын татарларга ыржайтып, җинел туплар тора, туплар арасына озын мылтык—аркебуздан атучылар белән арбалетчылар баскан. Болары кенәз Витовтның горурлыгы—әлегә татарда булмаган корал белән эш итүчеләр.

Менә ике якта да барабаннар дөпелди, быргылар кычкырырга тотына. Башта, ташкындай җәелә барып, татарның җинел атлылары кузгала. Меңләгән уклар дошман өстенә оча. Сай сулы тар елганы җинел генә кичеп, татарлар алгы сызыктагы Литва полкын сытып үтәм генә дигәндә, дошман туплары, аркебузчылар телгә килә, һөҗүм итүчеләр өстенә ут бөрки, аннан арбелетчылар кушыла. Татар атлылары, сөртенеп куйгандай, тизлеген югалта, байтак кешесен калдырып, дуга сыман хәрәкәт белән уңга борыла, дошман сафларына туктаусыз ук яудыра-яудыра, елгага әйләнеп кайта. Аннан кире борыла, тагын бер һөҗүм ясый.

Атлылар һөҗүмен төгәлләп тә өлгерми, аларны арттан Туктамыш хан яугирләре бастыра, әзәрлекләргә керешә, бу исә урда атлыларын ахыр чиктә бүленергә, канатларда торучы кулларга килеп сыенырга мәҗбүр итә. Туктамыш

хан һөҗүменнән соң дошман явының төп көчләре хәрәкәткә килә. Рус, Литва полклары, су чәчрәтеп, сикереп дигәндәй, елганы кичә. Аларны татар төмәннәре каршылый. Ике як та үзенчә сөрән сала, тамак ертылганчы акыра, үз-үзен дәртләндереп, алга ашкына. Аннан ике гайрәтле гаскәр йөзгә-йөз бәрелешә. Шул мизгелдә йөзләгән сөңгеләрнең сынуы, тимер туннарның чатнавы, көбәләрнең тишелүе, яраланган меңнәрчә ат һәм адәмнәрнең җан өзгеч аваз белән кычкыруыннан тирә-юнь гөрселдәп, инрәп китә, гүя табигать үзе, бу мәхшәрдән таң калып, тетрәнеп куя. Шулай барысы буталыша, аяусыз орыш—адәмнәрнең бер-берсен кисүе, чабуы, үтәли тишүе, ерткычларча бугазлавы башлана. Куллар өстендәге туг-байраклардан гына кайсының кайда, ни хәлдә икәнен чамаларга мөмкин.

Атлылар гел хәрәкәттә булып, орышны бер ябырылып, бер артка чигенеп алып бара. Берәүләре дошманны күкрәк белән каршыласа, икенчеләре яннан китереп суга, өченчеләре яңа һөҗүм өчен көч туплый, сафларын тәртипкә китерә. Бу хәрәкәтләрнең барысы да дошманның сафларын аеру, бүлгәләү, хәлен алу яисә чигенергә, хәтта качарга мәҗбүр итү өчен башкарыла. Әмма ике якның берсе дә әлегә максатына ирешә алмый—өстенлек әле бер, әле икенче якка күчә. Бер көч каршы торучы икенче көчне ни җиңә, ни буйсындыра алмыйча азаплана. Бер якның ярсуы икенче якның ярсуына килеп бәрелә, шулай тигезләнә бара. Дошманның туры кылычын татарның кәкре кылычы, сөңгене калкан каршылый, сөрәнгә сөрән авазы җавап бирә.

... Аяусыз орыш инде берничә сәгать дәвам итә. Сугыш кырын тузан каплый, аннан ярсу авазлар, атлар пошкыруы, акыру-бакыру, тимер чыңы яңгырап тора. Кайнап торган адәмнәр дәрьясыннан ара-тирә атлар килеп чыга, кайберләре җайдаксыз, кайберләре яраланып ияр өстенә капланган хуҗаларын мәхшәр эченнән йолып алган. Дәһшәтле, исәпсез корбаннар таләп итүче орыш тегермәне буталышып беткән ике яуны үз ташында тарттыра да тарттыра. Янадан-яңа корбаннар сорый.

Идегәй мирза тәбәнәк калкулык өстеннән сугыш кырын күзәтә. Ара-тирә ул янына берәр бәкне яки әмирне чакырып ала да аның бүлекчәсен орышка кертә—алар хәл эчендә торып калучыларга ярдәмгә ташлана. Әмма төп көчне—үз төмәнен ул әлегә саклап килә, аны орышка кертми тора.

Хан тугы җилфердәгән урта кулның хәле бигрәк тә авыр. Тимер Котлык хан кулы күпмедер вакыт литва-рус дружинникларының кысрыклавын кире кагып торса да, аның да акрынлап хәле бетә, ул да бирешә, артка чигенә башлый. Ярдәм сорап берничә тапкыр Идегәй мирзага чапкын җибәрә, тик бәкләрибәк бер үк сүзне кабатлый:

—Орышыгыз, Аллаһ сезне ярдәменнән ташламас!

Шулай хәлсезләнә барган урта кулга тагын да көчәнергә, соңгы көчне туплап орышырга гына кала.

Урта кулның мескен хәлен каршы яктан кенәз Витовт та күреп ала һәм, хан байрагын кулга төшерү өчен, ул анда үзенең соңгы резервын—Польша, Литва, Левон рыцарьларыннан торган сайланма полкларны ташлый. Менә алар, байракларын җилфердәтеп, сөрән салып, татар гаскәренең үзәгенә бәреп керә, канатлардагы полклар да шунда ыргыла.

Шулай урта кул коточкыч яра ала, хәл эчендә кала. Йөзләрчә яугир һәлак була, калганнары үлем ярсуы белән орышны дәвам итә. Әмма көч инде төкәнеп килә. Чигенә башлыйлар. Менә-менә сафлары өзелеп китәчәк, чылбыр аерым боҗраларга таралачак...

Әмма Идегәй мирзаның урта кулга ярдәм итмәвендә сугышны алып баруның төп хәйләсе ята иде. Кенәз Витовт татарларның хәле төкәнеп килә дип уйлап, урта кул өстенә соңгы көчен ташлый. Кенәз Витовтның атлылары татарлар белән буталышып орыша башлау белән Идегәй миза алар өстенә үзенең тәҗрибәле баһадирлардан торган төмәнен ыргыта. Сөңге белән коралланган, тимер туннарга төренгән бу атлыларның тиңе юк. Алар сугышка бик сирәк керә, әмма аны очлап куя беләләр. Менә алар, ач бүреләр кебек, кенәз Витовт рыцарьларын ботарларга тотына.

Авыр коралланган татар атлыларының һөҗүме шулкадәр көтелмәгәндә була, алар дошманның ике канаттагы полкларын сытып узалар, исән калганнарын таратып бетерәләр. Аннан дошманның артына төшә башлыйлар. Шул вакыт кенәз Витовт рыцарьлары каушап кала, чолганыштан чыгып өлгерү өчен чигенү

ягын карыйлар. Бу сафларның буталуына, максаттан тайпылуга китерә. Рыцарьларның бер өлеше, татарларны туктатырга тырышып караса да, күнелләренә хәвеф кереп өлгергән, анда инде курку тамыр җәйгән. Ул һаман үсә, арта бара, сафларны бүлгәли, өзә, тарката тора.

Шул вакыт ярдәм килүдән рухланган Тимер Котлык хан төмәннәре дә янабаштан эшкә керешә. Аларның дәррәү күтәрелеп орышка ташлануы дошман сафларын тагын да бүлгәли. Шулай дошман гаскәре идарәсез кала, анда тыеп-туктатып булмаслык буталыш башлана. Күнеленә җан саклау кайгысы килеп кергән, шул уй барысын да күмеп киткән гаскәрне инде бернинди әмер-фәрман да туктата алмый. Коралларын, олауларын ташлап, яралыларын сугыш кырында калдырып, дошман качарга тотына. Сугыш кырын беренчеләрдән булып Туктамыш хан ташлап китә, чөнки Идегәй мирзаның кем икәнен, ничек орышуын ул бик әйбәт белә. Аннан яраннары белән кенәз Витовт үзе табан ялтырата. Татарлар дошманның артыннан бастырып бара, качучыларны рәхимсез турый, әсир итә тора. Эш барысына да житә, эзәрлекләү дәвам итә...

## 7

Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, бу сугышта егермедән артык рус-литва кенәзе һәлак була. Идегәй мирза дошманны биш йөз чакрымлап куа бара, шулай Киев каласына килеп житә. Аның капкалары каршында үзенең зур чатырын кора. Киевтән 3000 сум йолым акчасы түләттерә. Татарлар бөтен Киев, Подолия жирләренә тарала, аннан зур байлык, меңнәрчә әсирләр жыеп кайта. Әле 1363 елда Литва кенәзе Ольгерд, Буг елгасының түбән агымын яулап алып, үзенә Кара дингезгә чыгу юлын тәэмин итүгә ирешкән була. Утыз алты елдан соң Бурсыклы сугышында жинеп чыгу нәтиҗәсендә бу жирләр кабат Алтын Урдага кайтарыла, далалар кабат татар атлары утлап йөри торган көтүлекләргә әверелә. Шулай итеп, Идегәй мирза тырышлыгы аркасында Алтын Урданың чикләре киңәя, дәүләт үзе ныгый, бер йодрыкка туплана башлый.

Бурсыклы сугышы, күпме низаглардан, өч-дүрт дистә ел буе барган тарткалашулардан соң да татар дәүләтенең әле һаман көчле, гайрәтле булып калуын бик ачык күрсәтә. Идегәй мирза язмышының иң биек ноктасына күтәрелә. Ул теләгәненә тулысынча ирешә, хыяллары тормышка аша. Хәзер аның алдында татар дәүләтен ныгыту, аның элекке данын кайтару максаты тора. Әмма ул шушы изге эшкә керештем дигәндә генә дәүләттә тагын низаглар башланып китә— бәкләр, әмирләр, угланнар баш күтәрә, һәркайсы тәхет дауларга тотына. Аларның нәфесен бастыру өчен Идегәй мирзага кабат кулына корал алырга туры килә.

Бурсыклы сугышында тар-мар ителеп, шактый жирләрен югалткан һәм хәлсезләнеп калган Литва кенәзлегендә яшәүнең инде мәгънәсе беткәнгә, Туктамыш хан үз тарафдарлары белән Себергә барып урнаша, анда үзенә яңа олыс төзи. Алай гына да түгел, хәтта Сәмәрканд әмире Аксак Тимер белән элемтәгә дә керә, уртак дошманнары Идегәй мирзага каршы көрәшү өчен аның белән сүз дә берләшә. Әмма 1405 елда Аксак Тимер, яу белән Кытайга барырга чыккач, үлеп китә. Туктамыш ялгызы торып кала.

Идегәй мирзаны дошманын тыныч тота торган затлардан дип әйтүе кыен. Ул Туктамыш ханның кайда, ни хәлдә икәнен даими белешеп тора, еш кына үзара бәрелешләр дә булгалый. Бер бәрелештә Идегәй мирза, уңышсызлыкка очрап, далага качып китә. Тарихчылар күрсәткәнчә, бу алар арасындагы унбишенче бәрелеш булган! Туктамыш хан үзен кабат Алтын Урданың төп хуҗасына әвереләдем дип уйлап тынычланып кала, уяулыгын югалта. Шулай гамьсез рәвештә кәеф-сафа корып ятканда кинәт яу белән Идегәй мирза килеп чыкмасынмы? Шунда ул кан дошманы Туктамыш ханның башына житә. Тарихчылар фикеренчә, бу хәл 1405 елда Төмән каласы тирәсендә булган. Күрәсең, Туктамыш хан Аксак Тимер үлеменнән соң үтерелгәндер. Томск каласы тирәсендә «Туктамыш курганнары» дип йөртелүче курганнар да бар икән. Гомумән, ул тирәләр «Туктамыш йорты» дип атап йөртелгәннәр. Литвадан киткәч, ул шушында килеп урнашкан, үзенә яңа «йорт» корган. Туктамыш ханның үлемен рус елъязмалары да теркәп куйган. Мәсәлән, Аргангелогорски елъязмасында 1406 елда Туктамыш ханның Себер жирендә, Төмән тирәсендә үтерелүе турында теркәп куелган.

Туктамыш ханнан котылганнан соң да Идегәй мирза тәхеткә үзе теләгән

чыңгызыйларны утыртып, татар дәүләтен саклап калырга тырыша. Шулай тәхеткә бер-бер артлы Шадыйбәк, Булат, Тимер ханнар утыртыла. Соңгысы 1399 елда, Бурсыклы сугышыннан соң үлеп киткән Тимер Котлык ханның улы була.

1411 елда яшь Тимер хан белән абзасы Идегәй мирза арасында зур низаг чыга, бәрелешләр була. Әлбәттә, Тимер хан артында башка кешеләр торган, яшь хан алар кулында уенчык кына булган. Алар үзара көрәшкән арада Сарай каласын Туктамыш хан улы Җәләлетдин тартып ала, тәхеткә чыга. Күп тә үтми Тимер хан Җәләлетдин тарафыннан үтерелә (1411).

Шулай тагын да аяусызрак көрәш башланып китә. Бу юлы инде Идегәй мирзага каршы Туктамыш хан уллары күтәрелә. Җиңелгән саен алар йә Кырымга, йә Литва кенәзе Витовтка барып сыеналар. Бераз көч туплагач, бәрелешләр дәвам итә. 1417 елда Идегәй мирза, ниһаять, Туктамыш улларын Алтын Урдадан куып чыгара. Әмма 1420 елда Туктамыш хан улы Кадыйрбирде кенәз Витовт ярдәме белән Кырым тәхетенә утыра. Шул ук елны Кадыйрбирде Кырымда тупланган зур гаскәр белән Иделгә кайта, аннан Җаек буена юнәлә. Сарайчык каласы янында (соңрак Нугай йортының башкаласы) Идегәй мирза белән Кадыйрбирде арасында каты бәрелеш була, бик күп кан коела. Кадыйрбирде үзе үтерелә, аның кешеләре кайсы кая качып бетә. Идегәй мирза да күп яралар ала. Сугыш шундый каты була ки, хәтта кайсы як җиңгәнне дә белә алмыйлар. Ике гаскәр дә таралып бетә.

Яраланган Идегәй мирза бер аулак урында туктап, яраларын бәйләмәкче, хәл алмакчы була. Бераздан бер нөгәрен хәл-әхвәлне белешер өчен разведкага җибәрә:

—Бар әле, хәлләрне белешеп кайт. Безнекеләрдән берәрсен очратсаң, монда җибәр,—ди.

Теге сугышчы юлда бер татар әмирен очрата да, аның Туктамыш ханда әмир булганлыгын белмичә, Идегәй мирзаның яралы килеш кайда ятуын сөйләп бирә.

Әмир сугышчылары белән Идегәй мирзаны эзләп таба. Идегәй мирза аны күреп алу белән сүгәргә тотына. Теге исә:

—Көн безнең файдага төгәлләнде. Без үз эшебезне башкардык. Син хәзер берни дә майтара алмыйсың,—дип, сугышчыларына Идегәй мирзага һөҗүм итәргә боера. Тегеләр карт мирзаны тураклап ташлыйлар. Шулай итеп, гомере дәһшәтле көрәшләрдә узган Идегәй мирза 63 яшендә сугыш кырында һәлак була. Бу хәл 1420 елда Җаек тирәсендә булган, диләр.

* * *

Идегәй мирза татар тарихында аерым урын алып торучы атаклы шәхес. Ул бик катлаулы тормыш юлы уза, үз гомерендә дәүләткүләм әһәмиятле бик күп вакыйгаларда катнаша, еш кына аларны теге яки бу якка борып җибәрүчеләрдән була. Шуңа күрә аның язмышы гаять катлаулы, бик тә каршылыклы. Гомеренең бер дәверендә ул, кан дошманы Туктамыш ханнан үч алу белән мавыгып китеп, татар дәүләте Алтын Урданы хәлсезләндерү, аны җимерү эше белән шөгыльләнсә, картаймыш көнендә исә, хакимиятнең иң биек баскычына күтәрелеп, олуг мәмләкәтнең бәкләрибәге (асылда—ханнарны тәхеткә утыртучы) дәрәҗәсенә ирешә, таркалуга йөз тоткан татар дәүләтен бер йодрыкка туплау, хөкүмәтне ныгыту, дәүләтнең элекке данын, абруен кайтару өчен көрәшә. Бу эштә ул зур тырышлык күрсәтә, күп көч түгә, әмма күпме генә тырышмасын, хәтта бөек бәкләрибәк Идегәй мирза да таркалуга барган дәүләтне коткарып кала алмый. Тарихта башланган процессны туктатырга әллә нинди гайрәтле шәхеснең дә кодрәтеннән килми. Андый шәхес бу процессны бары тик беразга тоткарлый гына ала. Идегәй мирзаның бу омтылышы, шәмнең сүнәр алдыннан балкып куюы кебек, соңгы талпыну гына була. Бу вакытта тарихи үсешнең аяусыз кануннары татар дәүләтенә үз хөкемен инде чыгарган була. Сүнә-сүрелә барган Алтын Урда җирләрендә бераздан яна татар дәүләтләре—Кырым, Әстерхан, Казан, Касыйм, Себер ханлыклары барлыкка килә. Шулай халкыбыз үз тарихының башка дәверенә аяк баса.

*1996—1999 еллар,*
*Казан*



Марсель Зарипов

# САДРИЕВЧА СӨРҮ

АВЫЛ ХАЛКЫ телендәге «сөрү» сүзенең ике-өч төрле мәгънәсе бар. Беренчесе—сабан сөрү, җир эшкәртү булса, икенчесе—әйтергә дә куркыныч!—сөргенгә сөрү, ә өченчесе—язучылар телендә һәм башка очракларда да әйтелә торганы—«менә, сөреп чыктым әле», ягъни ниндидер эшне майтардым дигән мәгънәдәрәк булыр.

Әлбәттә, борын-борыннан авыл халкы җир сөргән-чәчкән, иген үстергән һәм «Садриевча сөрү»нең бер яңалыгы да юк кебек. Әмма Буа районындагы иң беренче фермерларның берсе Фәрит Садриев яз-көздә генә җир сөреп калмый, ә, маңгай тирен түгеп, елның өч йөз алтмыш биш көнен «сөреп»-эшләп тора. Менә инде ун ел буена шулай: ял көннәре дә, санаторий-курортларга барулары да юк аның. Ирекле фермерның өлешенә тигән көмеше шул—син ял итүдән азат! Эш хәтта хезмәткә сарыф ителгән вакытта да түгел, алай булса, борынгы грек мифларындагы Сизифның гомере буе бер үк ташны тау башына тәгәрәтеп менгерүе шикелле, файдасыз гамәл генә булыр иде ул.

Ярар, җир кешесе—авыл халкының хезмәтләре турында соңрак тәфсилләп язарбыз. Ә хәзер илдә фермерлык хәрәкәте турында бераз сүз йөртеп алыйк. Кайдан килеп керде соң бу «фермер» сүзе безгә? Алар Рәсәйдә ничек барлыкка килде дә, аларның тир түккән хезмәтеннән халыкка файда бармы? Ил-халыкны фермерлар гына икмәккә-иткә-сөткә һ. б. туйдыра алырмы?

Фермер—капиталистик илләрдә, иң беренче чиратта, Америкада—шул ук крестьян инде ул. Колхозлашмаган ялгызак крестьян. Совет елларында алар «аерым хуҗалык» дип, «ялгызак» дип бик каһәрләнеп йөртелгән, берән-сәрән генә була иделәр.

Бер унбиш-унҗиде еллар элек, Рәсәй дәүләте—юк ла!—ул вакытта әле СССР дәүләте башына Михаил Горбачев килеп, илдә «үзгәртеп кору чоры» башланганнан соң, авыл халкының иң эшчән, иң кыю ир-атлары, колхозлардан аерылып чыгып, шушы фермерлык эшенә алынды. Бик сирәкләр генә алынды! Шуннан китте инде: кем күпме гектар җир алып (бушлай!), күпме эшкәртә ала—рәхим итсен! Әмма шул ук елларда кичәге дус-күршеләре андыйларны күрәлмый, аларга зыян сала башлады: йә

каралты-курасына ут төртәләр, йә трактор-фәләнен урлап китәләр, йә үзен үк үтереп ташлыйлар...

Әйе, хуш... СССР дигән ил дә, аның беренче президенты М. Горбачев та юкка чыкты. Ә иң үҗәт, булдыклы фермерлар җиргә ябышып калды!

Җир турында, аны кемгә ничек бирү турында кайнар бәхәсләр исә, инде ил буенча закон кабул ителүгә дә карамастан, һаман дәвам итә. Янәмәсе, җирне сатуга куйсаң, чит ил байлары безне ач-ялангач калдырачак. Бушлай бүлеп бирсәң, үзебездә «яңа кулаклар» барлыкка киләчәк h. б. h. б. Өч-дүрт ел буе Дәүләт думасы: «Крестьяннарга җирне арендага—ягъни файдаланып торырга биреп, үзеннән соң балалары-оныкларына да мирас итеп калдырыйк яки ирекле сатуга куйыйк»,—дип тарткалашканнан соң, ниһаять, «сатарга» дигән закон кабул итте. Әмма бу ике фикер дә шәһәр асфальтында үскән, авыл тормышын телевизор экраннарыннан гына күреп, «ак күмәчләр агачларда үсә, ә депутатлар буфетына бифштекс-котлет ишеләрне туп-туры шул әлеге дә баягы фермер хуҗалыкларыннан китерәләр» дип йөрүче депутатларыбыз фикере генә иде.

Аларны Ходай хөкеменә калдырыйк та, яңадан авылга—җир кешесе янына әйләнеп кайтыйк әле. Җир кешесе фермерлыкка ничек карый? Аны хуплыймы, әллә кире кагамы? Ялгызак, аерым хуҗалык хезмәте файдалыракмы, әллә күнегелгән колхозларныкымы? Аны хәзер, утызынчы еллар башындагы кебек, «күмәк хуҗалыклар» дип атыйлар. Ягъни «колхоз» түгел, ә «күмхуҗ»...

Буа районының фермер һәм крестьян хуҗалыклары берләшмәсе (ассоциациясе) рәисе Фатих Гаязов әйтүенчә, 1991 елда районда өч фермер булган, хәзер исә—утыз алты—күренеп тора: фермерлар саны унике мәртәбә арткан. Хәл-әхвәл болайрак икән: фермерлыкка керәүне дә көчләп куып кертмиләр (элекке заманнардагы колхоз түгел ул сиңа!), шул ук вакытта теләгәннәргә төрле каршылык-киртәләр дә куймыйлар! Әнә шул утыз алты фермер кулында дүрт мең сигез йөз гектар җир бар икән. Районның нибары дүрт процент чәчүлек җире. Ике меңенче елда җитмеш дүрт мең центнер иген җыеп алганнар, район буенча бу ике генә процент тәшкил итә. Әмма алар арасында бик елгыр вә өлгер кешеләр дә бар. Мәсәлән, Фәргать Ибәтулловның җире ике йөз ун гектар, Фәнил Кәримовныкы—йөз гектар, Расих Мифтахетдиновныкы—алты йөз гектар...

Бу фермер хуҗалыклары отышлымы-түгелме? Кәгазьгә язып күрсәткәндә, шактый отышлы шикелле, әмма чынбарлыкта бик алай куанырлык та түгел икән әле. Барысы да кешеләрнең үз тырышлыкларыннан тора. Җир алгансың икән—көне-төне эшлә! Йоклап ятма, уйлан, тегеге яки бу хәлләрдән ничек чыгарга икәнен исәплә. Ә бит үз җиреңдә үзең нәрсә игәргә ирекле булсаң да, заман кырыс, хәтта шәфкатьсез. Җир эше уен-муен гына түгел ул. Сиңа җир биргәннәр икән, димәк, югары уңыш, ахыр чиктә уртача уңыш булса да ал. Әгәр, ялкауланып, җиреңне чүп үлән басса, көт тә тор—аны синнән тартып алачаклар. Җир һәрвакыт эштә әйләнештә булырга тиеш. Авыл халкы шулай уйлый һәм шулай эшли дә. Мисалга, Харис Исмәгыйловның йөз гектарын да кире кайтарып алганнар, бик әтәчләнеп ике йөз кырык гектарга өметен сузган Шамил Җәлиловка да нибары алтмыш гектар гына калдырганнар. Әле тагын Равил Гатауллинның да йөз гектар җирен алырга җыеналар. Өстәл янында яки диванда кырын ятып кына хыяллану бер хәл, ә тормыш кануннары бөтенләй башкача—кырыс ул.

Шунысы кызык: тормышта булсын, фәндә-фәләндә булсын—мең кире нәтиҗәгә бер уңае булса да, соңгысына ышанасың. Әгәр дә беренче уңышсызлыктан соң ук диңгезчеләр Һиндстанга иң кыска юлны эзләүдән туктасалар, кем белә, кешелек әле һаман да Америка кыйтгасын ачмаган булыр иде... Монысы көлебрәк әйтелде, әлбәттә. Әмма шунысы хак: хәзерге заманда аерым хуҗалыклы фермер булып яшәве-эшләве карурманда сукмак таба алмыйча, адашып йөрү шикеллерәк бер гамәлдер. Аннан чыгар юлны да таба алмавың бик мөмкин. Шуңа күрә җир кешесе—

крестьянны буш вәгъдәләр, юк табышлар белән ымсындырмаска кирәктер. Хикмәт бит сиңа җир бирүдә түгел, аны ничек файдалана белүеңдә! Менә шунда килеп төртелә дә инде мәсьәлә. Сыйфатлы, арзанлы мул уңыш алу һәм аны әйбәтләп сату өчен фермер нәрсәләр эшләргә тиеш? Үз җирең булгач, көн үтсенгә генә йөри алмыйсың шул инде.

Өметләрен өзеп, җирдән баш тартучылар булса да, ике меңенче елда Буа районында тагын ун хуҗалык фермерлык эшенә алынган икән, димәк, моңа игътибар итәргә, аларның эш-хезмәтләрен күңелдә тотарга кирәктер.

Фермерлыктагы ун ел бик аз вакыт әле. Аның артында күпме ачылмаган мөмкинлекләр, район түрәләре тарафыннан күпме киртә-тоткарлыклар ясау ята! Ә бит, чынлыкта, фермерларга икътисади һәм әхлакый яктан да ярдәм итәргә кирәк. Монысы инде бу фидакарь хезмәтчәннәргә берәүнең язгы май аедай елмаеп карауларыннан, икенчеләренең, караңгы күз күнендәгечә, каш җыерып торуларыннан киләдер. Ә хакыйкать һәрвакыт уртада була: йә син фермер хуҗалыкларына хәерхаһ бул, йә, хөсетләнеп, аларны кире как. Кире кагасың икән—үзең яхшы итеп эшләп күрсәт.

Буа районында берсүзсез үрнәк итеп куярлык бердәнбер фермер Расих Мифтахетдиновтыр, мөгаен. Ул үзенең крестьян хуҗалыгын «Очкын» дип атаган. Расих җирдән файдалануның кызыклы ысулын да тапкан, нәтиҗәләре дә куандырырлык-өметле икән. Р. Мифтахетдинов җирле «Искра» колхозында агроном булып эшләгән, бердәнбер хуҗасына—колхоз рәисенә киңәшләрен биреп торган. Көннәрдән бер көнне токкан да ирекле крестьян хуҗалыгына алынган: үзе—баш, үзе—муен ул хәзер. Уңган кеше Р. Мифтахетдинов—аның һәр кишәрлек җире күз уңында, иң файдалы-уңдырышлы игеннәрне генә игә ул. Хуҗалык итү алымнарын үзе теләгәнчә башкарган, кайда, кайчан, нәрсә чәчәргә кирәклеген дә белә, аның башында әллә ничә яңа уй-ниятләр туа, ул шуларны тормышка ашырырга ашкына. Бүгенгесен төгәл исәпләп, иртәгәге көненә ышаныч белән караганга күрә, аның башлаган эшләрендә уңышсызлык юк дәрәҗәсендә, уңышлары күбрәк икән. Аның хуҗалыгы очын-очка ялгап кына яшәми, ә үсә-киңәя. Максаты—игеннәрне үстерү генә түгел, ә үстергәнен эшкәртеп, азык-төлек итү. Расих Мифтахетдинов җыеп алган уңышын үз тегермәнендә тарттыра да онга әйләндерә, ә онныннан, билгеле инде, икмәк пешертә. Ипиләрен авылда һәм район үзәгендә генә сатып калмый ул, Ульяновск базарларына да барып җитә. Кесәгә өстәмә табыш керәме—керә. Аның җирләрендә яшелчә бакчаларына да урын табылган: суган, кәбестә, кыяр, кишер, помидорлар белән янәшә буй-буй кабыклы карбызлары да, сап-сары кавыннары да гөрләп үсә. Басуларында безгә таныш арыш-бодай, солы-борчак кына түгел, рапс һәм карабодай да игелә. Бу соңгы икесенең уңышы яхшы серкәләндерүгә бәйле. Шуңа күрә алар янәшәсендә төрле төскә буялган умарталар тезелеп тора, бал кортларының гөжләве көннең көнендә тынмый. Фермер гектарыннан егермешәр центнер орлык ала. Алтын бәясенә торырлык орлык! Ә балы тагын? Һәммәсе дә акча, табыш бит.

Әйтәм ич, Расихның башында әллә нинди уйлар кайный. Хәтта кеше ышанмаслыклары да була аларның. Бервакыт Мифтахетдинов кайдандыр әкияти-могҗизаи үсемлек турында укый—расторопша. Исегездә калдырыгыз: рас-то-роп-ша! Менә шул әкәмәт үсемлекнең орлыклары гаҗәеп сәләтләргә ия икән—бавырны да дәвалый, үт куыгын да, хәтта махмырдан да файдасы бар, имеш. Кайдандыр юнәтә моны Мифтахетдинов: «Әй, булса—булыр, булмаса—юк!»—дип, ун гектар җиргә чәчеп тә куя. Чәчәр алдыннан расторопша орлыкларын кемгә сатарга икәнен дә чамалый. Эзләнә торгач, үзебезнең Татарстанда алучы табылмаса да, күрше Ульяновск өлкәсендә табыла. Көзен егерме тонна шул дару-дәва орлыгын һәр тоннасын егермешәр меңнән сатып та җибәрә. Бу бит бодайга караганда ун тапкыр кыйммәтрәк дигән сүз!

Расих Мифтахетдинов үзе трактор-комбайннарны сирәк йөртә, аның эше—гомуми җитәкчелек итү, алдагы бурычларны ачыклау, аларны үтәү алымнарының иң нәтиҗәлеләрен сайлау. Ә гадәти крестьян эшен даими

рөвештә унике кеше башкара. Алар яхшы белә: айга биш мең сум хезмәт хакы күктән төшми, ул сыйфатлы эшләп, мул уңыш җыеп алуга бәйле. Шуннан инде дәртләнеп-тырышып эшли алар. Нәтиҗәсе дә күз алдында: корылык булган елларда уңыш гектарыннан утыз центнер җыеп алынса, ел уңай-әйбәт килгәндә—җитмешәр центнер. Мондый уңыш белән күп гасырлар фермерлык иткән көнбатыш крестьяннары алдында да йөз кызарырлык түгел.

Фермер Расих Мифтахетдинов эшен бер йөз гектар җир алып башлый. Елдан-ел эш нәтиҗәләре яхшыра барган саен ул җирен дә арттыра бара—хәзер аның алты йөз гектар кыр-басулары бар. Бу инде аерым хуҗалыклы ялгызак кына түгел, ә иң югары сыйфатлы авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә торырлык хезмәт.

Ә менә фермер Фәрит Садриев, дөньяда ашарга яраклы нинди үсемлек бар—һәммәсен дә үстереп карарга атлыгып тора торган Расих Мифтахетдиновтан аермалы буларак, берне генә сөючән шәхес. Аның кыр-басуларында төп урынны язгы һәм көзге бодай алып тора. Ул инде җир эшкәртүнең бөтен алымнарын әнәсеннән җебенә кадәр белә, техниканың барлык төрләрен—комбайнын, тракторын, автомобилен, чәчкечен, электр двигательләрен, эретеп ябыштыру аппаратларын, металл эшкәртү станокларын биш бармагы белән капшап үзләштергән.

Фәрит Садриевның хуҗалыгы гадәти гаиләнеке: каникул вакытларында әтисе белән бергә аның улы—авыл хуҗалыгы академиясе студенты Рөстәм эшли, бухгалтер хезмәтен район хастаханәсендә экономист булып эшләүче хатыны Венера башкарып килә. Бухгалтерияләрдәге кәгазь тауларын күргәнегез бардыр, аларны махсус әзерлексез ерып чыгышлы да түгел. Минемчә, күп кенә фермерлар әнә шул тау-тау кәгазьләр тутырудан куркып та үз эшләреннән баш тарталар булса кирәк. Һәртөрле салым җыючылар, финанс хезмәткәрләре, конторларда өстәл биләп утыручы эреле-ваклы башка түрәләр крестьяннар-фермерлар аларны туйдыру өчен генә яшиләр-эшлиләр дип уйлый шикелле килеп чыга. Түрәләр теләсә кайсы режимда да үрчегәннәр, һаман да үрчи торалар—алар нәкъ кандала-тараканнар кебек!

Фәрит Садриев хуҗалыгында бер генә «кимчелек» күзгә ташлана—аның аты юк. Ә атсыз крестьян нинди крестьян инде ул, бер аксөяктер шунда, дип фикерләргә безне Россия телевизион каналлары өйрәтте. Аларда фермерны парлап җигелгән атта йөри, йә фермасында сәнәк белән тирес чистарта, малларга чиләк-чиләк фураж ташый итеп күрсәтәләр. Шуны истә тотып, мин дә Садриевтан: «Нишләп атларың юк?»—дип сорадым.

Минем соравым аңа гаҗәбрәк тоелды шикелле, фермер шулай да сер бирмәде. Бармакларын бөгә-бөгә санап китте: «Атларым юк, ат эшен минем ике җиңел автомобилем башкара, бүтән эшләрне дә машиналар көче белән алып барабыз. Атлар белән, көрәк-сәнәк белән генә бик күп майтара алмассың, андый ысуллар фермерлар өчен оят булырга тиеш—ул бит үзеңә зыянга эшләү генә булып чыга, димәк, мәгънәсезлек»,—дип сүзен тәмамлады Фәрит Садриев.

Аның хуҗалыгындагы ике йөз гектар җирдә ике «Дон» комбайны, өч трактор, бензинын-соляркасын салып торучы станция, махсус трансформатор подстанциясе һәм тагын әле әллә ничәмә-ничә төрле техника эшли. Станоклары гына да биш-алты, орлык җилгәрү комплексы «петкус»ны да электр эшләтә. Орлык склады да элекке крестьян амбары түгел. Һәммәсе механикалаштырылган, ул склад капкасыннан КамАЗ машиналары кереп йөри, агач ларлар урынына вентиляцияле биек-биек тугыз бункер тора. Басудан кайткан икмәкне әнә шул бункерларга бушаталар, шундук компрессор эшли башлый, һава агымы орлыкларның дымлылыгын тиешле унике процентка кадәр киптереп-җиләтеп тә бирә. Шуның белән—вәссәлам! Сатар вакыт килеп җитмичә, уңышка башка кагылдым юк. Ә Фәрит Садриевның «сатар вакыты» икмәк бәяләре төшкән август-сентябрь айларында булмас, бары тик алдагы яз-җәй айларында—бәяләрне инде товарның үз хуҗасы билгеләгән вакытта булыр. Садриевның товары югары сыйфатлы, калибрланган, иң яхшы орлыклар гына чәчеп үстереп

алынган һәм зур генетик мөмкинлекле бодай бит—сатып алучылар аңа чират тора. Аның бодаен фуражга алмыйлар, юк, күмәч-калачлар пешерү өчен дә түгел, ә орлыкка, ягъни, авылча әйтсәк, «симәнәгә» алалар.

Дөрес, Фәрит Садриевның да хуҗалыгында һәммәсе дә ал да гөл түгел әле. Шактый төзисе бар. Мәшәкатьләр муеннан, кирәкнең чиге юк. Техникасын саклар өчен җылытылган, түбәле бина кирәк. Садриевлар гаиләсе әле район үзәгендә яши, аңа ул квартирны Буа шикәр заводында баш инженер булып эшләгән чагында биргәннәр. Кырга-басуга эшләп кайтыр өчен генә килеп йөриләр. Үз сызым-проекты буенча бер юньлерәк йорт та салып керәсе иде дә бит, һаман акча җиткереп булмый, бар тапканы агымдагы чыгымнарга тотылып бетә бара. Әмма шунысы куанычлы: Садриевның хуҗалыгы мөстәкыйль яши ала.

Аның төп байлыгы хуҗалыгын торгызырга алган кредит акчасы да түгел, акча—чүп ул, аны эшләп табуга караганда җилгә очырту җиңелрәк тә. Бөтен техникаң булып та, аны эшләтә белмәсәң, анысы да тимер-томыр тавы гына булып калачак. Садриевның төп байлыгы—аның алтын куллары, уйлый-фикерли белә торган башы.

Сталин заманнарында крестьяннарны колхозга куып-көчләп бик тиз арада керткән булсалар, ул колхозларны әзерлексез, ашык-пошык тарату аннан да тизрәк эшләнде. Фермерлыкка кемнәр омтылды? Колхоз-совхозларның хәерчелегеннән җык күреп яшәгән җир сөючән эшчәннәр. Алар югарыдагы хакимиятнең алтын таулары вәгъдә итүенә, озакламый үзләре дә көнбатыштагыча яшәвенә ышанып алданды. Имеш, җир хуҗасы күрсәтмәләр биреп кенә яшәячәк: җиргә кайчан һәм күпме ашлама кертергә, кайчан сөрергә-чәчәргә, урып-җыеп алырга—һәммәсе дә нәкъ чуртан кушуынча булачак—гаризаңны гына бир, хезмәт күрсәтү оешмалары шундук килеп җитәчәк. Техникаң-фәлән ватылдымы, бер генә шылтырат—ремонтчылар да шундук килеп ремонтлаячак. Җыеп алган уңышыңны да икмәк биржаларында кочак җәеп көтеп торырлар, акчасын да сәгате-минуты белән түләрләр. Кыскасы, «о кей!» булачак.

Булды ди сиңа, тот капчыгыңны! Хыял бик татлы да бит, өметсез күз яшьләре бик әче...

Бүгенге Россия хакимияте башындагы түрәләр дә, элекке өстәл биләп утыручылар шикелле, эшлексез һәм буш куык булып чыкты. Алар вәгъдә иткән алтын таулары, чынлыкта, чеп-чи ялган, демагогия генә икән ул! Инде ничәнче кат крестьянны яңадан төп башына утыртып калдырдылар. Кечерге татлы хыялларыннан арынган фермерлар, түрәләрне һәм үз язмышларын каргый-каргый, җирләрен ташлап янә тарала-кача башлады.

Хәлбуки, безнең сүзебез фермер Фәрит Садриев турында иде. Ни өчен аны ирекле фермерлык кызыктырган соң? Шул мең төрле авырлыклар белән көрәшеп яшәр өченме? Һич юк. Хәтта байлык-муллык артыннан да кумаган ул: шикәр заводының баш инженеры хезмәт хакы тормыш алып барырга җитәрлек булган. Фәрит Садриевны җир тәме, ирекле крестьян хезмәте мавыктырган! Ул бит авыл баласы. Кечкенәдән кыр-басуда зурларга булышып йөргән, төнгелектә атлар көткән, печән чапкан, ә беренче мәртәбә тракторга утырып тәүге буразнаңны сызулар, комбайн штурвалын тотып, дулкынланып торган бодай басуын беренче мәртәбә урдырып түгәрәк әйләнүләр! Болар һәммәсе дә яшүсмер күңелендә мәңгай тирләре, кулга чыккан сөялләре белән түгел, ә файдалы авыл хезмәтеннән алган шатлык-куанычлары белән исендә калган. Шуңа күрә дә Фәрит Казан авыл хуҗалыгы институтының инженер-механик бүлегенә укырга барып кергән. Югары белем алып чыккач, колхозда үз һөнәре буенча эшләгән, тырыш егетне бик тиз шәйләп алганнар: район авыл хуҗалыгы идарәсенә эшкә чакырганнар. Димәк, аның җиргә әйләнеп кайтуы очраклы түгел, шикәр заводында ун ел эшләве генә очраклы бер хәл булып чыга.

Фәрит Садриевның фермерлык язмышы әнә шулай башлана. Үз жирендә үзең хуҗа булып яшәүгә нәрсә җитә! Бу бит инде кемгәдер ялланып эшләү түгел, бурычыңны һәм җаваплылыгыңны тоеп, чын ир-ат булып, җилкәңә шундый йөк күтәрү дигән сүз. Менә шуңа да ул җиргә ябышып ята, хуҗалыгын үстерә, үз хезмәтеннән тәм таба.

Фермерның вакыты бүген һәм иртәгә, язын һәм көзен, киләсе елга һәм аннан да алдагы елларда майтарып чыгасы эшләре белән хисаплана. Аннары, иң мөһиме шул—бер сумыңны да тиешле-тиешсез җилгә очырма, һәр тиенеңне кичектергесез хаҗәтләреңә тот! Фәрит Садриевның кулыннан килмәгән эш юк, дипломлы инженер-механик барысын да булдыра, һәр техниканы күз йомып та сүтеп-җыеп бирә ала—кыскасы, алтын куллы оста ул.

Хәзерге крестьян китмән-көрәккә, сабан-тырмага гына калмаган, аның хәзер трактор-комбайннары, машиналары, башка төрле техникасы бар. Ә техника дигәнең ватылмый тормый, әйтик, шул ук комбайнны гына ал—уттай кызу урак өстендә җимерелә дә куя, берәр сәгатькә генә ремонтчыларны ябыштыру аппаратлары-нилләре белән чакыртып кара әле (тиз генә килеп җитәрләрме-юкмы, анысы да бар)—бу сиңа ничә сумнарга төшәчәк, ә?! Башка фермерлар әнә шул «техник хезмәт күрсәтү» дигән нәрсәгә меңнәрен чыгарып салганда, Фәрит Садриев бер тиенен дә югалтмый. Ул төрле уйлап табуларга да бик һәвәс, кулына ни-нәрсә генә килеп кермәсен, иң әүвәл ул аңа шикләнебрәк карый: әйбәт ясалганмы, яхшыртып булмыймы? Сүзне озынга сузмый, шуны гына әйтергә мөмкин—Фәрит Садриев үз гомерендә меңләп төрле рационализаторлык тәкъдимнәре керткән, аларның кайберләренә, уйлап табучы буларак, авторлык патенты да алган.

Фермерлар хезмәтендә һәрнәрсә бер-берсе белән бәйләнгән, бер уңышлы эш икенчеләренә юл яра һәм киресенчә—бер уйланып җитмәгән очраклылык башка югалтуларга китерә. «Корал эшләр, кул мактаныр»,—дигән мәкаль бар халыкта. Уйлап таба белүе, теге яки бу әйберне камилләштерүе Фәрит Садриевка кыр эшләрен башкалардан иртәрәк бетерергә, күбрәк файда алырга мөмкинлек бирә. Тырышып-тырышып та уңышны вакытында җыеп ала алмаучы фермерлар да аз түгел. Ә Садриев беркайчан да соңламый. Юк, тырышу хикмәте генә була алмый аның хезмәте, ул башкача сөрә, башкача чәчә. Ничек?

Иң четереклесе дә менә шул «ничек?» инде аның.

Юкса, җир эшенең уйланмаган, хәл ителмәгән бер генә ысул-алымы калмагандыр кебек. Ничәмә-ничә галимнәр бу өлкәдә ни-нәрсәләр генә уйлап чыгармаган. Ел саен—берәр яңалык. Йә аркылыга-буйга чәчү, йә квадрат-оялап утырту, йә бәрәңгене бураэна өеменең төбәсенә үк күмеп үстерү, йә камылны күп калдырып җир сөрү... Ул бик отышлы культиваторлар, яңа тракторлар, «Дон» комбайннары дисеңме?! Өйрәнеп-үзләштереп кенә өлгер дә, инструкциясендә язылганнардан бер адым да тайпылма!

Әгәр дә кешеләр, көн саен бер үк эшне башкарып, бер дә уйланмыйча, кичәге көненнән канәгать булып яшәсә, гадәти-күнегелгән нәрсәләрне ничектер башкачарак, яхшырак итәргә тырышмаса, җәмгыятьнең алгарыш-тәрәккыят арбасы гасырдан-гасырга һаман шул бер салган юлдан тәгәри барыр иде. Әле кем белә, тәгәрәргә көпчәге дә булмас, сөйрәлеп кенә йөрер иде.

Мөстәкыйль, ирекле хуҗа буларак, фермер Фәрит Садриев беренче елында җирен сөреп, агротехник чараларны җиренә җиткереп үтәгәч, тиешле ашламаларын керткәч, тырмалап, чәчүен аркылыга-буйга үткәргәч, уйга кала: «Бу чәчкечне нинди кыек куллы конструкторлар эшләде икән, нинди кыек куллы осталар ясап, безгә саталар икән?»—ди. Аның уйлап табучыга хас сәләте тагын баш калкыта, нәрсәләрнедер үзгәртәсе, камилләштерәсе, башкача ясап карыйсы килә.

Фәрит Садриев—эш-гамәл кешесе. Гел генә яңалыкларга ашкынган тынгысыз холкы аны Казан авыл хуҗалыгы академиясе галимнәренең ишеген шакырга өнди. Бара фермер академиянең механизация кафедрасына һәм үзен борчыган сорауларын әйтеп сала: «Җирне бер дә башкача, яңарак ысуллар белән, тизрәк һәм файдалырак, мулрак уңыш алырлык итеп эшкәртеп булмыймы соң?»—ди. Әлбәттә, җавап билгеле: әйе, андый мәсьәлә көн тәртибендә тора, әмма фикер алышу-бәхәсләшү җиңел, ләкин аны чишүе бик авыр. Галимнәргә фермерның дәгъвасе бик урынлы, тик шунысы да бар—сәләте булган һәр кеше җир эшендә үзен сынап карый ала. Бернинди тыю-фәләннәр юк ич. Әгәр дә инде фермер Фәрит

Садриев шундый башлы икән, бирегә килеп дәгъва белдереп кенә йөрмәсен, үзе җигелеп тартып та карасын, бәлки, алгарыш-тәрәккыят арбасы аның да ярдәме белән тизрәк тәгәри башлар.

Шулай итеп, авыл хуҗалыгы академиясендә тагын бер тынгысыз җан арта, үзе уйлап табучы Кулибин яки җир остасы Мальцев үк булмаса да, Фәрит Садриев авыл хуҗалыгы техникасының яңа үрнәкләрен ясарга алына. Әле комбайн, тракторларның чираты җитәр көннәр алдадыр, фермер үзенең эчен пошырган чәчкечне камилләштерергә керешә.

Басуга орлык чәчү, бер уйласаң, бик гади гамәл кебек, бабайлар тубалдан гына да чәчеп йөргәннәр әле, алган уңышлары да үзләренә ярап торган—бер чәчкәнен алты-җиде итеп кайтарып алганнар, ягъни, хәзергечә әйткәндә, гектарыннан алты-җиде центнер уңыш дигән сүз. Көлкеме? Юк, бер дә көлке түгел! Чәчү эше бик четерекле һәм катлаулы гамәл ул. Бер гектар җирдә биш-биш ярым миллион үсемлек тишелеп чыгарга һәм үсәргә тиеш—фән шулай өйрәтә. Орлыкларны шулай тигез итеп чәчәргә кирәк ки, бер үсенте икенчесенә комачауламасын, һәркайсына кояш яктысы-җылысы да, яңгыры-дымы да, җир мәйданы да җитәрлек булсын. Башкача зур уңыш алырга өмет тә итәсе юк. Бездәге чәчкечләр бу эшкә яртылаш кына әзер әле: орлыкны җиргә, рәт араларын унбишәр миллиметр калдырып, тасма итеп буйга чәчәләр. Рәтендә—куе, аралары—буш! Шуңа күрә игенче чәчүне аркылыга-буйга үткәрергә мәҗбүр. Димәк, бер кат чәчкән мәйданыңны икенче кат чәчеп чыгарга туры килә. Күпме вакыт әрәм, ягулык әрәм, көч түгү әрәм?!

Фәрит Садриев менә шул җитди кимчелекне ничек бетерү турында баш вата. Уйлана торгач, җае табыла икән—ул бөтенләй яңа чәчкеч ясап чыгара. Чәчкеч комбайн!

Мин бу башлы фермерның ни-нәрсәләр ясаганын, нинди тәҗрибәләр үткәргәнен белеп тә бетермимдер, тәртипләрен бутасам, Фәрит Садриев гафу итәр, шәт. Башта чәчкечкә культиватор аякларымы-кулымы (ничек әйтергә дә белмим!) ясый ул, алар чәчкән чакта бер үк вакытта җирне тырмалап та бара. Аннары чәчә торган детальләр үзгәртеп эшләнә, акыллы машина орлыкны рәт-рәт кенә итеп чәчми хәзер, ә җилпәзәләп сибеп-сибеп, әмма тигез сибеп җибәрә. Кара әле, бабайларның тубалдан учлап-учлап сипкәне шикеллерәк була түгелме соң?! Басуыңны икенче кат аркылыга чәчеп йөрүнең кирәге калмый. Шуннан соң Фәрит Садриев чәчкечендә ашлама сибү, җирне тыгызлау, өске катын яңадан йомшарту җайланмалары пәйда була. Комбайн бик авыр килеп чыга. Фермер аны икешәр метрлы биш мөстәкыйль кисәккә бүлә. Хәзер бу чәчкечне көпчәкле «Беларусь» тракторы да тартып йөри ала инде. Фәрит Садриевнең әлеге техник революциясенең нәтиҗәсе мондый: башкалар чәчү вакытында басулары өстеннән биш-алты мәртәбә үтеп йөргәндә, Фәрит Садриев шул ук эшләрне бер үтүдә башкарып чыга. Шунысын да әйтергә кирәк, ул җирен дә үзенчә—Садриевча сөрә. Гадәттә, тракторлар сабанны басу буйлап тартып, басу башына җиткәч, кирәкмәгән аркылы йөреш ясап, янә буй-буй буразналар сыза бара. Никадәр файдасыз гамәл! Садриев исә шома сөрә торган сабан файдалана, басу башында әйләнешләр ясап тормый. Әлбәттә, мондый технология катлаулырак. Ә бит файдасы да күп! Ягулык өч мәртәбә кимрәк сарыф ителә, хезмәт җитештерүчәнлеге ике мәртәбә арта, вакыт отыла!

Сөйләгәндә һәммәсе дә ничек җиңел, ничек тиз эшләнә кебек, ә бит фермер һәм уйлап табучы Фәрит Садриев үзенең улы, булачак инженер-механик Рөстәм белән бергәләп әлеге чәчкечне шулай үзгәртеп ясауга ун ел гомер сарыф иткән! Ун ел буе чәчеп, яңалыгын сынап карый барган, бары тик берсенең уңышлы икәненә ышангач кына, кышларын икенчесен көйләргә тотынган. Төрле кирәкле тимер-томырны, детальләрне сатып алырга да никадәр акча салынган. Бер электродларны гына да өем-өем яндырган алар. Әнә шулай кышның кышында үз мастерскойларында мөш киләләр: чүкиләр, ябыштыралар, игәүлиләр, ялгыйлар. Эшләгәннәрен күрсәтеп хисап бирергә, киңәш алырга авыл хуҗалыгы академиясенә килеп китәргә дә тартынып тормыйлар. Ун ел эчендә аталы-уллы Садриевлар башкарып чыккан конструкторлык эшенең күләмен

бергә җыйсаң, яңа техника уйлап табу белән шөгыльләнүче тулы бер махсус бюроның сызымчыларына, көйләүчеләренә һәм башкаларына җитәрлек булыр иде. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: авыл хуҗалыгы академиясе галимнәре дә Садриев басуларына сукмак сала, гел генә килеп тора, яңа чәчкеч комбайнның ничек эшләгәнен күзәтә-өйрәнә.

Ә ул арада телгә үткен авыл агайлары шундый имеш-мимешләр сөйли башлый: имеш, тынгы белмәс Садриев җир эшкәртә торган ниндидер космик ракета ясый икән, имеш, әллә Марс планетасына, әллә Айга менеп, әллә алмагачлар утыртырга, әллә өрәңге агачында чикләвек үстерергә җыенамы, ди, шунда... Ләкин Фәрит Садриев басуларындагы уңышның елдан-ел арта баруы мондый имеш-мимешләрне дә кимәтә тора. Садриев басуларына «юл уңайдан, болай гына» килеп карап китүчеләр күбәя, гомер күрелмәгән чәчкеч комбайнны тотып-капшап та, селкеткәләп-күтәреп тә карый алар. Шаулап, тигез-матур дулкынланып утырган бодай басуыннан күзләрен ала алмый торалар. «Һе, кара син аны, гап-гади фермер берьюлы ничә төрле эшне башкара торган машина ясаган, диген, ә. Менә баш!»—диләр.

Фәрит Садриевның бу хикмәтләре турында мин дә ишеткән идем инде, әмма, дөресен әйтим, ышанып җитмәдем, озак кына шикләнеп йөрдем. Азмы дөньяда шундый үзешчән уйлап табучылар! Берәүләре үзләре ясаган җилкәнле чанада кар өстеннән җилдерә, икенчеләре автомобиль, өченчеләре мини-трактор, дүртенчеләре очкыч, бишенчеләре тагын әллә ниләр ясый—үзләренең һәр буш минутын яраткан шөгыленә багышлый. Ә тагын әле, даһи ук булмаса, талантсыз да түгел күпме шундый эшләр, завод конвейерларына керә алмыйча, ил-халыкка, дөньяга файда китермичә, югалып каладыр?! Әнә бит, инженер Гарин гиперболоидын беренче булып академик Александр Прохоров уйлап тапмаган, ә язучы-фантаст Алексей Толстой тапкан, хыялый повесть итеп язып та чыккан. Галим исә аның әдәби хыялын тормышка ашырган—лазер нурларын ачкан һәм шуның өчен атаклы-абруйлы Нобель премиясен алган. Бәлки, Садриев басуларында да җирне эшкәртүнең, игенче хезмәтенең әлегәчә күрелмәгән яңа ысул-алымнары сыналадыр? Кешеләрнең хыялын, иҗади илһамлануын тыярга-сүндерергә ярыймы соң? Һич юк!

Узган җәйдә Фәрит Садриевның кыр станына Казаннан рәсми рәвештә республикабызның авыл хуҗалыгы министры урынбасары Таһир Һадиев килеп төшә. Андагы хикмәти яңалыкларны күреп-танышып йөргәннән соң, шунда галимнәр, конструкторлар, игенчеләр һәм башкаларны чакыра да зур киңәшмә үткәрә. Сөйләшү җитди һәм катгый, әмма бик эшлекле, матур килеп чыга. Аннары Фәрит Садриевны авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов үзе кабул итә. Министр белән фермер ни-нәрсәләр турында сөйләшкәндер—анысын төгәен генә әйтә алмыйм. Ә нәтиҗәсе мондый була: үзенең җир сөрә-сөрә кулларына сөялләр чыгып беткәнен министр онытмаган, күрәсең—Садриев комбайнының нинди файдалы булачагын бик тиз аңлап ала һәм, шундый ук чәчкеч комбайн ясар өчен дип, өч миллион сум акча бирергә фәрман чыгара. Ул машиналарны республика заводлары бер кыш эчендә ясап бирергә тиеш була. Язга чыккач, аларны бер басуда гына түгел, ә Татарстанның ун районында рәсми рәвештә сынап карарга ниятлиләр. Хәзер инде ул сынауларның нинди нәтиҗә бирүен көтәргә генә кала. Фәрит Садриевның өметләре акланырмы-юкмы? Әллә аны бөтенләй кире кагарлармы?

...Басуларда хезмәт гөрелтесе тынгач, сөрелгән буразналар өстендә җылы якларга очып китәргә җыенган каргалар гына йөренгән бер мәлдә, яңгырлы кара көздә дип әйтик, мин Фәрит Садриевның кыр станында төн үткәрдем. Безнең аның белән беренче очрашуыбыз гына түгел. Мин бирегә аларның фермер хуҗалыгы оешып кына килгән, әле барлык уй-ниятләре, өмет-хыяллары алдан әйтеп булмастай бер томан эчендә генә чагында килгән идем инде. Ул вакытта Фәрит Садриев менә шушы вагоны эчендә сарык тиреләре эшкәртеп, кичектергесез хаҗәтләренә тотар өчен «акча сугып» утыра иде. Бу килүемдә, әлбәттә, истәлекләргә кереп киттек, ул вакыттагы борчу-мәшәкатьләрне бүгенгеләре белән чагыштырып, көлешеп тә алдык. Аннан соң ул шушында—басу читендә

салыначак йортына газ кертү өчен экскаватор белән траншея казылып куелганын да әйтеп алды. Үзе тиздән җир эшкәртүнең яңа ысуллары турында фән кандидатлыгына диссертация якларга җыена икән. Мин аның әле башкаларга билгеле булмаган тагын бер яңа машинасы белән дә кызыксындым: «Аны эшләрләрме, камилләштерәсең дә бармы әле?»— дип сорадым.

—Әлбәттә, анысы да эшләнәчәк,—дип җавап бирде Фәрит Садриев.— Башкалар өчен гадәти булмаса да, минем чәчкеч комбайным белән җир эшкәртергә-чәчәргә мөмкин. Мин инде шунсыз яши дә алмыйм. Камилләштерүгә килгәндә, билгеле инде, аның чиге юк, бу варианты да соңгысы булмас. Әллә бүгенге трактор-комбайннар, автомобильләр беренчеләре шикелле генәме? Хәзерге авыл хуҗалыгы техникасы да тулысынча яңартылырга, яхшыртылырга тиеш. Әле шундый башлы кешеләр дә табылыр, комбайн игенне урып-сугып алганда ук җирен дә сөреп барырлык булыр. Бирсен генә Ходай!

Аннары фермерлык хәрәкәтенең үзе турында сөйләшүгә күчтек. Нишләп бетәр ул? Сүнеп-сүрелеп калырмы, әллә тернәкләнеп китәрме? Бездә ничек тә, тегеләрдә ничек? «Бездә» дигәнебез—Рәсәйдә, «тегеләрдә» дигәнебез—Көнбатыш илләрендә. Көнбатышта авыл хуҗалыгы алга киткән шундый илләр бар, анда фермер чыгымнарының яртысына кадәрен дәүләт күтәрә икән. Ә Фәрит Садриев, ул ел фермерлык итеп, дәүләттән сукыр бер тиен дә алмаган. Киресенчә әле, өстенлекле шартларда хуҗалык итүгә билгеләнгән вакыт бетүгә үк, аның үзен юкә тунаган күк туный-чишендерә башлаганнар. Россия Федерациясенең 2002 елның 30 гыйнварында көченә кергән салымнар кодексында нинди генә салымнар саналмаган! Ул салымнарны аерым укып-санап чыкканда да башларың әйләнерлек. Бары тик шунысын әйтү генә дә җитәдер—алар хуҗалыкның барлык чыгымнарының биштән бер өлешен тәшкил итә. Сызгырырсың, кодагый!

—Фермерлык хәрәкәтенең язмышы аңа ил-дәүләт тарафыннан нинди мөнәсәбәт булуга бәйле. Сораулар күп, чишелмәгән мәсьәләләр—бихисап! Җиргә мин хуҗа булсам да, Алла ук түгел бит. Сиңа өстән ничек булышалар, хезмәтеңә уңай карыйлармы? Әллә инде, каһәрле заманнардагы кулаклар шикелле итеп, сөрергә үк җыеналармы? Тьфү, тьфү, тьфү— әйттем исә кайттым!—дип, әңгәмәбезне йомгаклап, ачынып-әрнеп сөйли башлады Фәрит Садриев.—Әгәр һәммәсе дә хәзергечә калса, бюрократ түрәләр көн күрсәтмичә, техникага, ягулыкка, ашамлыкларга буй җитмәс бәяләр һаман да арта торса, үз икмәгеңне үз бәяңнән сата алмыйча интексәң—дәүләт сине гел чиклап торса,—ай-һай!—белмим... Бары тик шуны гына әйтә алам: фермерлык хәрәкәте таркалса-таралса да, аның иң соңгы могиканы мин булырмын, мөгаен!

Буа районында күргән-ишеткәннәремнән ялкынланып, Расих Мифтахетдинов белән Фәрит Садриевның уңышларына куанып йөргәннән соң, бөтен илгә ишетелерлек итеп кычкырасы, чаң сугасы килә башлады: әйдәгез, фермерларча хуҗалык итүне киңрәк җәелдерик! Ләкин Мифтахетдинов белән Садриев шикелле уңган-булган, искиткеч сәләтле хуҗаларны кайдан җыеп бетермәк кирәк?! Алар бит дистәләр-йөзләр генә түгел, ә меңнәр-йөз меңнәр кирәк. Аннары шунысы да бар, әле бит күмәк хуҗалык булып яшәүче-эшләүче һәм, әйтергә кирәк, әйбәт итеп эшләүче күпчелек крестьяннар да бар. Берәүләрен мактап, икенчеләрен рәнҗетергә дә ярамыйдыр, мөгаен.

Хәер, бүгенге күмәк хуҗалыклар турында башка вакытта сөйләргә калдырыйк. Чөнки анысы бөтенләй икенче җыр инде.

## БӘХЕТЛЕЛӘР ҺӘМ БӘХЕТСЕЗЛӘР

Фоат Садриевнең «Бәхетсезләр бәхете» исемле романы башта «Казан утлары»нда басылган иде *(2001 ел, 4-5 саннар)*. Аерым өзекләре «Аргамак» журналында һәм «Мәдәни җомга»да булды. Хәзер роман аерым китап булып дөньяга чыкты. Күләме 23 табак чамасы, тиражы 3 мең данә.

«Бәхетсезләр бәхете»... Баштан ук әйтим—исеме уңышлы түгел. Ниндидер мескенлеккә ишарә бар. Һәрхәлдә, укучы күңелен тартып, җәлеп итеп тормый, минемчә.

Әдәби эшләнеше ягыннан да романны бик үк югары дәрәҗәдә дип әйтмәс идем. Әсәр шактый сузынкы, «мускуллары» йомшаграк. Автор вакыйгаларга ияреп бара, очраган бер кешене тасвирлау, аның үткәнен-бүгенгесен сөйләү белән артык мавыга. Шуңа күрә романның сюжеты да шактый сүлпән, укучыны әсәр эченә тиз алып кереп китми. Баштагы өлешләре бигрәк тә.

Шулай да бу әсәрдә кырыс чынбарлык бар. Роман уйландыра, үткән тормышыбызга башкача карарга, аны тирәнрәк анларга ярдәм итә.

Райком секретарьлары ничек яшәде?

Үз вакытында әдәбиятыбызда партия хезмәткәрләре турында шактый күп язылды. Гариф Ахунов, Барлас Камалов әсәрләрен генә искә алу да җитә. Аларда партия вәкиле һәрвакыт диярлек алдынгы идеаллар белән яшәүче унай герой итеп күрсәтелде. Ф. Садриев исә партия хезмәткәрләрен бөтенләй башкача тасвирлый. Менә Баллы Төбәк райкомының беренче секретаре Минзаһит Усманович Арсланов. Иң элек аның яшәү рәвешенә күз ташлыйк.

Районда бер булган йорт—коттедж. Бу өйне райком секретаре иң яхшы төзүчеләрдән, иң шәп осталардан эшләткән. Башта район халкы яна балалар бакчасы салалар, дип уйлый. Тик соңыннан гына хакыйкать ачыла. Зур-зур җиде бүлмә... Һәркайсы эчтән кыйммәтле такталар белән эшләнгән. Нарат идән, нарат түшәм... Такталар шундый итеп тезелгән—ярыкларын кул белән сыпырып карасаң да сизәрлек түгел.

Ванна бүлмәсе дә кара кафель плитә белән әйләндерелгән. Башта акны куеп карыйлар. Секретарь анысын ошатмый, карасын эзләтә. Коммуналь хуҗалык башлыгы андый затлы плиталәрне бөтен дөнья бетереп юллап, Ялтадан алып кайта.

Стеналарда һәм идәннәрдә дә затлы келәмнәр, кайберләре хәтта чит илдә эшләнгән. Чит илдән алып кайткан җиһазлар. Озын һәм биек стенкада җем-җем итеп торучы алтын-көмеш йөгертелгән савыт-саба... Ә ишегалдына чыксан—баш әйләнерлек. Яшелчә, алма бакчаларына нечкә торбалар ярдәмендә су җибәрелгән. Ишегалдында яшел чирәм, чәчәкләр үсә. Пыяладан зур теплица эшләнгән, ана җылылык үткәрелгән...

Бер карасаң, гаҗәпләнерлек әллә ни юк сыман. Кеше шулай матур итеп

яши ала икән—яшәсен. Райком секретаре дә яшәмәгәч... Әмма романның тагы берничә битен уку белән без гади колхозчылар, хезмәт кешеләренең ничек яшәвен күрәбез.

Кырбаш авылы турындагы сәхифәләрне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Кайчандыр зур булган авылда нибары егерме йорт калган. Егерме хуҗалыкка—биш сыер. Аларны да халык беравыздан: «Сатабыз, сатабыз»,—дип торалар. Чөнки сауган сөтләрен савып бетерү белән бик арзан бәягә алып китәләр, үзләренә чәйлек кенә, бер литр чамасы гына кала, ә башкасын дәүләткә тапшыралар.

Чүп үләне баскан буш өй урыннарының исәбе-хисабы юк. Авылда койма дигән нәрсә калмаган. Ихаталар киртә йә булмаса утыртма читән белән әйләндерелгән. Өйләр иске, кыйшайган, кайберләрендә түбәләренең шиферы череп, ватылып беткән. Бөтен авылда эшкә яраклы сигез-тугыз кеше бар, алар да инде пенсия яшенә якынлашып килә. Шулай да биш чакрымдагы колхоз үзәгенә фермага эшкә йөриләр әле...

Романның төп герое, район газетасы редакторы Ирек сугыш ветераны яшәгән өйгә кереп карый. «...Такталары әле бер урыннан, әле икенче урыннан ашалып, киртләчләнеп, кайбер җирләрендә бөтенләй зур уентылар ясалып беткән баскычтан Ирек курка-курка гына күтәрелде. Такталар баскан саен шыгырдый, сыгыла иде. Өйалдына кергәч, ул башта өй ишегенең кайда икәнен күрә алмыйча аптырап торды. Аннан соң гына әллә нинди чүпрәкләр, киезләр, сырган фуфайка җиңнәре, тире калдыклары кадакланган ишекне абайлады. Аның тоткасын таба алмады, кармалана торгач, көч-хәл белән эләктереп, үзенә тартты. Ишек әллә нинди шомлы тавышлар чыгарып, шыгырдап ачылды. Атлап кергәндә, тупса өстенә өеп куелган нindидер иске әйберләргә аягы эләгеп, абынып егыла язды. Пәлтәгә охшаган бу нәрсә тупсага бозланып каткан иде. Ул үзен базга килеп кергән кебек хис итте, чөнки дүрт тәрәзәнең икесе салам тутырып, такта белән томаланган булып чыкты».

Хәзер инде яңадан райком секретарена әйләнеп кайтыйк. Арсланов үз сәламәтлеген кайгырта белә! Көн саен иртәнге күнегү ясый. Көненә ике мәртәбә душ коена. Кышын чаңгыда йөри. Кара һәм кызыл икра, лимон, апельсин, мандарин кебек җимешләрне ел дәвамында кайтартып тора. Район аптекаларыннан да, Казаннан да женьшень, алтын тамыр кебек дефицит даруларны таптыра. Ялгышып томау төшкән очракка дип кварц, УВЧ аппаратларын өендә тота. Ел саен иң яхшы вакытта көньякка санаторийга бара, кап-кара булып кызынып, еллык энергия җыеп кайта. Нindидер авыру сизсә, Казанга, өлкә комитеты шифаханәсенә юл тота, күпме кирәк шул кадәр дәвалана. Кыскасы, үзен кайгырта белә!

Әйдә, кайгыртсын... Тик шул ук вакытта ул гади колхозчылар тормышы турында да әзрәк булса да уйлансын иде... Әнә, сугышта бер аягын, берничә бармагын өздереп кайткан Сиражи ага, әллә ни карт булмаса да, көч-хәл белән генә яши. Өе салкын, утыны булмаганга ул мичкә өч көнгә бер генә яга. Бик салкын көннәрне генә ике көнгә бер яга.

Авылга ипине бик сирәк китерәләр, шуңа күрә Сиражи балалар хаҗәтен үтәү өчен ясалган эмальле савытта бөртек килеш кенә бодай пешереп ашый, аңынча әйткәндә—җүрна. Чәйне дә шул ук савытта кайната, чөнки чәйнүге тишелгән. Аның ит күрмәгәненә дә биш быелтыр. Әнә, ферма сыеры чирләп, үлгәндә генә суеп өлгергәннәр. Сиражига шул сыердан калган үпкәсен һәм эчәкләрен биргәннәр. Ул шуңа да шат. «Болай булгач, бүген ит ашыйм, Аллаһы боерса»,—дип куана ул.

Ә бит ул сугышны үткән, җиңүче булып кайткан кеше! Кайтса—хатынын ач балаларына бер кесә арыш алып кайткан өчен төрмәгә утыртканнар. Ул шунда югалып, кайдадыр үлеп калган. Әнисе һәм өч баласы септик ангинадан үлгәннәр. Менә ни өчен ул хәзер берьялгызы калган. Агач аяк, гарип кул белән шулай азапланып яши бирә, чана белән урманнан утын ташый, ерак чишмәдән чиләкләп су китерә. Үз көнен, үз хәсрәтен үзе күрә. Ә бит ул, җитмәсә, партия әгъзасы да—аны партияга фронтта алганнар...

Ләкин Сиражи зарланмый—үз хәлен түзәрлек дип исәпли. Аның әле электр

плитәсе бар. Ә күршеләре айдан артык электрсыз утыралар. «Нәрсә булган?»—дип сорауга: «Минем күрше алай курка торганнардан түгел. Җыелышта нидер сөйләгән бугай. Минимумы да үтәлмәгән булган. Килгәннәр дә өзгәннәр»,—дип аңлата.

«—Сиражи ага, сез бит инде олы гомер юлы үткән кеше. Тормыш хакында ни уйлыйсыз соң?»—дип сорый аңардан Ирек. Сиражи ага болай дип җавап бирә:

«—Карачкыны ябалак, ябалакны чыпчык алган замандыр инде бу. Үзем генә булсам, төкереп тә бирмәс идем. Сылтар идем әле шунда йә Аллага, йә язмышка, йә бүтәнгә. Кавеме белән бит... Гомере буе эшләгән әдәм баласының тамагы туя алмый икән, нидер дөрес түгел... Тарайганнан тарая гына бара. Нечкә тишек аша карыйсың—бер яктылык та күренми...»

Ирек аның турында газетага язарга җыена. Әмма Сиражи аганың монардан коты оча: «Берүк харап итә күрмәгез! Аннан соң миңа көн бетәчәк». Аныңча, хәтта ташланган сыер эчәкләре өчен дә судка тарта алалар. Чөнки ул аларны яздырып алмаган, аңа акча да түләмәгән.

Автор соңгы сүзендә әйтеп киткәнчә, әсәрнең баштагы, күңелендә генә йөрткән исеме «Партиягә кабер ташы» булган. Чыннан да, роман шул рухта язылган, төп фикере дә партия алымнарын фаш итүгә кайтып кала.

Менә, әйтик, өлкә комитетының беренче секретарен каршылау эпизоды. Арслановның кушуы буенча бөтен район дәррәү аякка бастырыла. Ул барасы колхоз-совхозларда сыерлар, симертүле маллар, бозаулар, дуңгызлар кер порошогы белән әйбәтләп юыла. «Дуңгызларнын борынына помада тидереп, битләренә иннек сөртәсе генә калды»,—дип шаярталар колхозчылар.

Казан кунагының яраткан ризыклары, эчемлекләре—бөтенесе дә алдан ачыклана. Кунакның күңеленә хуш килердәй иң чибәр, иң сылу кызлар кат-кат тикшерелгәннән соң, сайлап алына. Арслановның «Беренче» алдынгы ялагайлануы әсәрдә шундый ышандырырлык, калку итеп күрсәтелгән—һич онытырлык түгел. Әйе, ул халыкка түгел, шул «Беренчегә» генә ярарга тырыша. Аның авызына гына карап тора, ул кушканны гына үти. Сиражиларның аңа бер кирәге дә юк.

Райондагы бөтен партия эше әнә шундый әшнәлеккә корылган. Син—мина, мин—сина, дигәндәй. Менә романның тагы бер персонажы—авыл советы рәисе Кәбиров. Тыштан караганда игътибарны бөтенләй җәлеп итмәүче, юк кына кеше сыман. Чынлыкта исә ул бик елгыр. Райкомның икенче секретаре Шәвәлиевне ул әле урман эчендәге шалашларда, әле умарталык йортларында, әле елга буендагы палаткаларда ашата-эчертә, авылның «хур кызлары» белән йоклата. Үз чиратында Шәвәлиев тә Кәбировны гел яклап килә, теш-тел тидертми, һаман югарырак урыннарга күтәрә. Аның белән төн үткәргән «хур кызларын» да онытмый. Кайсын Кәбиров ярдәме белән, кайсын үзе төрле җылы урыннарга урнаштыра, кайберсен укырга җибәрә. Укып кайтканнарын тагын әйбәт кенә акчасы булган эш урынына куя. Әлбәттә, ул боларның берсен дә үз кулы белән башкармый. Ләкин теге кызлар монын кем кулы белән эшләнгәнен бик яхшы аңлап, белеп торалар.

Райком эш алымнарын фаш итә торган тагы бер эпизодка тукталып китәргә кирәк дип уйлыйм. Райкомның бюро әгъзасы, колхоз рәисе Гайсә Батталов, ачуы килеп, кызмача килеш бер колхозчыны үтергәнче диярлек кыйный. Өч кабыргасын сындыра, бавырын яралый, баш миен селкетә. Аны үлемнән чак-чак кына алып калалар. Ә бит әлеге колхозчы абзый алтмышны куып бара торган өлкән кеше. Кыйнаучысы башка кеше булса, берсүзсез хөкем итәрләр, тиешле җәзасын бирерләр иде. Әмма Батталов өлкә комитетының беренче секретаре белән әшнә-дус булып йөри. Аның колхозындагы нарат урманы эчендә югары кунаклар өчен махсус төзелгән мәһабәт йорт бар. Шунда ук бик шәп мунчасы да. «Беренче» әледән-әле монда килеп мунча керә, мәтрүшкәле себерке белән чабына, елгага чума, коньяк белән сыйлана, «хур кызлары» белән типтерә. Шулай булгач, ничек мондый затны хөкемгә тартасын?!

Йомып кына калырлар иде, кемдер өлкәгә шикаять язган, өстән бу эшне җентекләп тикшерергә кушалар. Менә шуннан инде бу эшкә райкомның шактый шомарган, «әпчүк» (овсюг) кушаматлы кешесе Кәрәм Нәҗмиев алына. Килү белән Нәҗмиевне әлеге наратлык эчендәге йортка алып киләләр. Өстәлдә

кыздырып куелган эре-эре карп балыклары. Зур хрусталь бокалларга ак аракы тутырылган. Ашап-эчеп, рәхәтләнеп ял итеп алганнан соң, алар Батталов белән икәүләшеп бәладән котылу планын коралар. Колхоз коммунистларын берәм-берәм чакыртып, үз якларына аударалар. Каршыларын исә командировкага-мазарга җибәрәләр.

Ә кыйналган кешегә юл таба алмыйча озак кына маташалар. Әлеге кеше алар белән сөйләшергә дә теләми, судка бирүне таләп итә. Шуннан махсус кеше җибәреп, кыйналган кешене ләх исергәнче эчерәләр. Һәм исереп житкәч кенә партия жыелышына алып киләләр! Ә кыйнауның берданбер шаһиты булган кешене, әллә ниләр вәгъдә итеп, үз якларына аударалар. Менә шулай итеп колхозның партия жыелышы кешегә кул күтәргән рәисне яклап чыга, кыйналучыны исә «үзе гаепле» дип, партия җәзасына тарта.

Мондый эпизодлар әсәрдә аз түгел. Автор райкомда хакимлек иткән алдашу, ялагайлану, күз буяу кебек яман чирләрне фаш итә. Моңача әдәбиятта күренмәгән кискен моментларны бик тәэсирле итеп күрсәтә. Романның иң көчле ягы—ачы хакыйкатьне тирән һәм үтемле итеп ачып бирүдә.

## Автор белән бәхәс

Әсәрнең төп герое Ирек—марксизм-ленинизм тәгълиматына чын күңелдән ышанган, партиягә җаны-тәне белән бирелгән кеше. Монысы ышандыра, чөнки ул шул чор кешесе, социализм шартларында үскән, пионер, комсомол оешмаларында тәрбияләнгән. Әмма автор әсәрнең героена караганда югарырак торырга, тормышны тирәнрәк аңларга, күбрәкне күрергә тиеш. Ф. Садриев исә романның соңгы сүзе итеп бирелгән өстәмәдә болай дип яза: «Мин марксизм тәгълиматының дөреслегенә, коммунистик җәмгыятьнең беренче фазасы булган социализмның өстенлекләренә элек тә инанган, хәзер дә инанучы кеше».

Автор шулай дип әйтә. Ләкин романның эчке логикасы бөтенләй киресен раслый. КПСС тормышында урнашкан тәртипне һәм генераль секретарьдан алып райком секретарена кадәр тезелеп килгән культларны автор шактый оста итеп тотып алган һәм күрсәтә дә белгән. Әмма очраклы хәлме бу? Бөтен бәла дә шунда шул! Марксизм ул теория буларак шактый матур, кызыктыргыч. Ләкин аны тормышта куллану бик ямьсез нәтиҗәләргә китерә. Бездә генә булса—бер хәл иде. Әнә бит: егермеләп ил безнең юл белән барып карады—барысында да шул ук хәл кабатланды. Менә ни өчен мин авторның коммунистлар партиясе турында: «гадел, игелекле максатлардан» чыгып, «кешелекле идеологиягә» таянып эш иткән дигән сүзләре белән һич тә килешә алмыйм. Автор әйтергә теләгән фикер мондый: Коммунистлар партиясенең максатлары изге булган, нигездә ул халык мәнфәгатьләрен кайгырткан. Ләкин Арсланов, Шәвәлиев сыман карьеристлар бу изге максатлардан читкә тайпылганнар. Үз-үзләрен генә кайгыртканнар, халыкны бөлгенлеккә төшергәннәр. Автор әйтүенчә, «хикмәт аның (партиянең) барлык изге ниятләрен харап итүче эш алымнарында, эчке тормышында, картлар йортына әверелгән Кремльдә, эгоистик максатлардан чыгып эш итүче җитәкчеләрендә».

Ә бәлки киресенчәдер? Эш изге максатларны начар кешеләр бозуда түгелдер, ә бәлки тормыштан ерак, черек идеологиянең үз тирәсенә шундый ук бозык, череп таркалган кешеләрне туплаудадыр?

Автор өч кисәктән торырга тиешле роман-эпопеянең әлегә беренче кисәген генә тәмамлаган. Әсәрнең алдагы өлешләренә тотынганчы уйланып алырга, күп нәрсәгә башкачарак күз ташларга мөмкин әле...

**Рафаэль МОСТАФИН**

Səngət
Сәнгать

# СӘНГАТЬ—УЛ ҖАНЛЫ ХӘТЕР

## Ю. САФИУЛЛИН ДРАМАТУРГИЯСЕНӘ БЕР КАРАШ

Сәнгать—ул халыкнын җанлы хәтере, анын чын сәнгатькәрләр ярдәмендә янартыла һәм баетыла барганы. Киләчәккә дөрес юлны да без хәтеребезне янартучы, рухыбызны ныгытучы үткәннәребездән башка таба алмабыз. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрынын әдәби бүлек мөдире, Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Сафиуллин әнә шул иҗат доньясына гомерен багышлаган шәхесләрнен берсе. Сәхнә әсәрләре аша халык хәтерен, милләт өметен киләчәккә юнәлтә белгән драматургларыбыздан ул. Анын «Әллә өйләнергә инде» (1978), «Ни булган бу ирләргә?» (1979), «Алмазбулат» (1981), «Кыямәт көне» (1983), «Ләйсән ире Хәсән» (1986), «Пар канат» (1989), «Идегәй» (1994), «Йөзек һәм хәнҗәр» (1996) кебек пьесалары театрларыбыз сәхнәләрендә уныш белән барды. Драматург сонгы елларда Мәхмүт Галәүнен «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» исемле атаклы романнарына нигезләнеп «Ирдәукә» дигән тарихи драма да иҗат итте. Марсель Сәлимҗанов анын беренче вариантын үзенен студентлары белән сәхнәләштереп, театр белгечләренә һәм бер төркем артистларга күрсәтергә өлгерде. Алар бертавыштан «Ирдәукә»нен киләчәге өметле, дип бәяләделәр.

Ю. Сафиуллин драматургиясенен тагын бер мөһим үзенчәлеге: драматургнын әсәрләре кайсы гына чорны тасвирламасын, нинди генә жанрда иҗат ителмәсен, ахыр нәтиҗәдә алар безнен көннәр белән аваздаш. «Алмазбулат», «Кыямәт көне», «Әби, бабай һәм малай», «Ур-тура, сатирик!» кебек пьесаларында экият доньясына алып керәме, «Идегәй» трагедиясендә Җучи Улысы (Алтын Урда) фаҗигаләре белән очраштырамы, «Ирдәукә» тарихи драмасында халык саны алу белән бәйле чуалышлардан кайнап торган Казан губернасына—туган илләреннән чит илләргә мөһаҗирлек итәргә мәҗбүр ителгән кардәшләребез янына алып киләме—барсында да бүгенге тормышыбызда туа торган, ныклы хәл итүне сорый торган мәсьәләләр. Ю. Сафиуллиннын «Шәһри Казан»да 1994 елнын октябрь аенда дөнья күргән «Дәвер кемнен дәвере» дигән мәкаләсендә мондый юллар бар: «һәр чорнын үзенә генә хас конфликты була. Конфликтка, ягъни көрәшкә кергән һәр ике як үз идеологиясенә таянып хәрәкәт итә. Мин Җучи Улысынын тарихын өйрәнгәндә нәкъ әнә шул заман кучәрен әйләндерә торган төп конфликтны эзләп табарга тырыштым да. Идел-Йорт белән идарә итүче чынгызыйларга Идел буенын төп халыклары арасыннан чыккан гаскәр башлыгы Идегәй һәм шагыйрь Сәйфи Сараилар нинди идеологиягә таянып көрәш алып барганнар сон? Чынгызыйлар ил белән идарә итүдә варислык традицияләре сакланырга тиеш, ягъни Чынгыз ханнан туган балалар һәм аларнын оныклары гына Идел-Йорт белән идарә итә ала дип эш йөртсәләр, ирдәмлек тарафдарлары исә: «Юк, тәхеткә ил белән идарә итә алырлык, олы эшләр күрсәткән чын ирләр дә утыра ала»,—дип каршы төшәләр.

Менә бу—Ю. Сафиуллин эзләп тапкан тарихи конфликт—хәзерге чор, безнен бүгенгебез өчен дә актуаль түгелмени?! Россия нәкъ чынгызыйларга охшатып: «Без—Иван Грозный варислары—илне безнен бабаларыбыз каннарын коеп яулап алган. Димәк Татарстан белән идарә итәргә безнен генә хакыбыз бар. Ә сез—жинелүчеләр—Казан губернасы рәвешендә генә яшәп, Мәскәүдән ни кушылса шуны үтәп торырга тиешле!»—дип Татарстан халкын өркетә. Татарстанлылар җавабы да нәкъ «Идегәй»дәгечә диярлек әйтелә: «Татарстан халкы үз көнен үзе күрергә лаек, Мәскәү безнен өстән идарә итәргә тиеш түгел, чөнки идарә иткән чакта без бетү дәрәҗәсенә килеп җиткән идек. Инде әнә күрегез: булдыклы булуыбыз аркасында Идел-Йортыбызга

аз гына вакыт хуҗа булып торган чагыбызда да нинди эшләр эшләргә өлгердек...»

Ю. Сафиуллин кырыс чынбарлыкны матур бизәкләргә төрмичә—ничек бар, шулай тасвирлый. Автор бигрәк тә гыйбрәтле, башкалардан үзгә язмышка ия геройларны яратып сурәтли, әсәрләрендәге көрәш мәйданына Идегәй, Туктамыш, Ирдәүкә, Сажидә, Мәрьямбану, Әхмәт, Хәсән, Линар, Фәрһад кебек көчле характерлары булган шәхесләрне чыгара. Кеше һәм җәмгыять арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, карашлар бәрелеше дә тирән чагыла аларда. Бу яктан авторның «Нигез туздыручылар» (1981), «Пар канат (1989) драмалары үзенчәлекле. «Нигез туздыручылар»дан бер өзек белән танышыйк.

«Самит. Көлдереп үтерәсез, ант әгәр... Бизәкләрен кабат янартырга ди бит. Иртәгә бульдозер килә!

Харитон. Йортны аллап сүттерергә йөрүчеләрнең берсе шушы фиргавен инде. Ике бүлмәле фатир өчен җанын сатарга да әзер.

Назыйм. Менә нәрсә абзый, мольбертны хәзер үк урынына кертеп куйган бул.

Самит. Күптән мие кибеп беткән карт-корыны тыңлап йөрсән, үзенне дә шунда чыгарып бәрермен. Аларныкы беткән... уртада без!.. Кешеләр нишли? Баеганнан-байый. Ие, дин! Машиналар көннән-көн күбәя. Элекке кәкре, тар урамнар гына аларны сыйдыра алмый хәзер. Америкадагы кебек туп-туры, кин-кин юллар салабыз. Иң шәп трасса үтәчәк моннан. Рәсәйнең генә түгел, СССРның иң үзәк урамы булачак бу җирләр.

Назыйм. Әгәр трассаны чак кына читтән үткәрсән...

Самит. Кабан күле төбеннәнме? Булмастайны сорыйсың. Карале, художник әфәнде. Мин гади сөйләшергә өйрәнгән. Катлаулырак итеп акыл сатар исәбен булса, Хөлли Кәлиевичны күр: барсын төшендереп бирер. Чөнки монда ул Алла, ә мин пәйгамбәре генә—ПМК начальнигы ягъни мәсьәләнең».

Әйе, нигезебезне, ягъни, Татарстаныбызны, сүттереп губерна итәргә йөрүчеләрнең Алласы ук булмаса да, «Нигез туздыручылар» драмасында төп урынны биләүче итеп Хөлли Кәлиевич алынган. Фатиры булмаганнан үчләшми әбисенең йортына, ул бу эшне баер өчен үзенә бер кәсеп итеп алган.

«Хөлли. Сатып яхшы эшләгәнсез. Бульдозерлар килгәнче, барын да сатып, файда күреп калыгыз!

Мәрьямбану. Кияү, мине дә тыңла әле!.. Минем синнән квартира сораганым юк. Син әнә Русланыңны минем йортыма пропискага керттең...

Хөлли. Шатлан: оныгың да фатирлы була. Күр әнә,—кешеләр ничек шатлана!

Мәрьямбану. Шушы изге нигезебездән, йортымнан гайре миңа яшәү юк. Син, кияү, әбиеннең үлемен телисең.

Хөлли. Рәнҗеттең син мине, әбкәй. Ит яхшылык, көт шиләк булды бу. Мин инде бер ел, әйеме, правительство кешеләренең җаннарына төшеп йөрим. Мин уйлап куйдым, нигә әле правительство кешеләре бу трассаны нәкъ шушы йортлар өстеннән үткәрәләр икән мәйтәм? Хаклы икән алар: әнә капка артында торган йөздән артык кешенең бәхете турында кайгырту икән бу.

Фәхрезат. 130 фатирның берсен сыз, энекәем! Карчыгым утырткан тупылларны турап, топләп атканнарын күрәсем килми.

Сәлимә. Хөлли Кәлиевич, путепроводогызны йортлардан читтәрәк тә үткәреп була бит.

Харитон. Ул чагында Хөлли Кәлиевич Русланына квартира ала алмый кала. Сез, җәмәгать, сизәсезме, шәһәргә путепровод эстакада төзелеп беткәч кенә кирәк булачак. Ә кайда соң әле аның эстакадасы?! Башланган да ташланган! Путепроводы дисән—ансы менә—йортларыбыз өстенә үк ишелеп килә!..

Хөлли. Ангыралар! Гел елмаеп сөйләшкәч тә, сез әллә мине икенче төрле сөйләшә белмәс дисезме? Путепроводның проекты дистә мен акча! Бу вариантны бер ел карадык, әйеме. Мәскәүдә эшләнде ул! Йөзләгән кешенең хезмәте монда. Изыскательләр, геодезистлар, гидрологлар һәм башка бик күпләр эше. Правительство белән шаярмагыз!

Харитон. Елама, Мәрьямбану: яхшы кеше кайгысы бик күпләр өчен кайгы. Хөлли Кәлиевич, дөньяның тоткасы бер акча гына түгел. Кеше җанын болай бетерергә ярамый. Шуны бел, бабаларыгызның борынгы сәнгатен, тинсез матурлыкны,

яхшылыкны жыйган бу йорт—бәһасыз. Синен кулда зур власть, Хөлли Кәлиевич; хатынына—ана, балаларына—әби тигән шушы намуслы карчык хакына; шушы йортны салган борынгы осталар хакын хакла—йортка тимә!»

Юныс Сафиуллин иҗатында милләтнең киләчәге булган яшьләр мәсьәләсе дә зур урын алып тора. Аны нигездә яшьләрнең дөньяга карашлары, яшәү принциплары, уй-хыяллары, теләкләре, омтылышлары, мәхәббәт-дуслык мәсьәләләре кызыксындыра. Бу аеруча «Бердәнберем минем» (1986) драмасында чагыла.

Драматург «Әллә өйләнергә инде» (1978) монсу комедиясендә заман чиренә әверелгән икейөзлелекне, ваемсызлыкны, ваклануны, мешанлыкны, әхлаксызлыкны, алдап-юмалап мал туплауны, үз-үзенне генә кайгыртып башкаларның теләкләре белән исәпләшмәүне ачынып читкә кага. Аларга каршы халкыбызның борынгыдан килгән әхлакый кагыйдәләрен, кешелек сыйфатларын, милли традицияләрен байрак итеп күтәрә.

Ю. Сафиуллинның «Ур-тура, сатирик!» (1973), «Кайсыгызның кулы җылы?» (1974), «Буйдак ир һәм аның танышлары» (1972), «Зурлар һәм кечкенәләр» (1973), «Остазлар һәм шәкертләр» (1974), «Очрашу» (1979) әсәрләренә публицистик эчтәлек хас. Пьесада барган бәхәс артында автор үзе. Ул персонажлар аша укучыга эндәшә. Аларны үзгәрергә өнди. Миһербансызлыктан, әхлаксызлыктан, ваемсызлыктан, шәфкатьсезлектән арынырга чакыра.



*«Алмазбулат» спектакленнән күренеш. Маһирә ролендә —Н. Гәрәева, Алмазбулат—Ф. Бикчәнтәев*

«Алмазбулат»—Ю. Сафиуллинның академия театрында куелган беренче әсәре. Әсәр сәхнәгә ике тапкыр куелды. 1981 елны аны Дамир Сиражиев (1955—1999), аннары 1987 елны Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерде. Әсәр үзенең күтәргән проблемалары белән игътибарны бүген дә җәлеп итә. Пьеса халыкчан образларга, шартлы алымнарга, символларга гаять бай. Режиссер Дамир Сиражиев, рәссам Рәшит Газиев, композитор Фуат Әбүбәкер һәм артистлар да моны яхшы анлап эш итәләр. «Алмазбулат» спектакленә чыгарылган мәкаләләрнең берсендә тәнкыйтьче Назыйм Ханзафаров болай ди: «Ул рухи традицияләребезне үстерергә, янартырга өндәве белән дә игътибарга лаек. Әсәрдә драматург заман һәм кешеләр турында җитди уйлануларын әйтергә омтыла. Аны хәзерге тормышыбызның актуаль проблемалары борчый. Ул дөнья иминлеге, киләчәк буыннар язмышы, кешенең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлана. Явыз көчләр тарафыннан хәтерләре урланып җен-пәриләргә әйләндерелгән кешеләрне күрсәткәндә автор нәкъ шул гомумкешелек дөньясына янаган куркыныч турында сүз алып бара.»

«Алмазбулат» туган тел, туган ил, яшьләр дөньясындагы үткен проблемаларны күтәргән могҗизалы һәм мажаралы вакыйгаларга корылган социаль эчтәлекле әсәр. Уңай герой белән тискәре геройлар арасындагы көрәш гаделлек һәм әхлакый камиллекнең золымга каршы көрәше буларак гәүдәләнә.

Ю. Сафиуллинның 1999 елда Татарстан китап нәшриятында «Чәчәкләр һәм күз яшьләре» дигән китабы чыкты. Ул мәрхүм Дамир Сиражиевка багышлап язылган. Анда «Алмазбулат»ка бәйле мондый юллар бар: ... «Яшь ленинчы» газетасында очрашулар вакытында: «Бу спектакль М. Җәлил бүләгенә лаек»,—дип зурладылар. ... Рәссам Рәшит Газиев, композитор Фуат Әбүбәкер, режиссер Дамир Сиражиев һәм талантлы артистлар тудырган, тулаем милләтебез язмышы турында сөйли торган бу спектакль зур тәэсир көченә ия иде. Әйе, без шул 1981 елда ук, нәкъ менә Дамирның искиткеч кыюлыгы аркасында, «Туган тел»не сәхнәдән гимн итеп янгырата алдык. Ә бу чорда әле сәхнәдән милләтне яклаган сынар сүз үткәрелсә дә гаҗәеп зур эш эшләндегә санала иде.» Чыннан да, 80 еллар өчен бу спектакль зур кыюлык булган!

Пьесада явыз көчләргә каршы гаскәр башлыгы җинелмәс Сәләхетдин хатыны Мәһирә тора. Ул күпне күргән, кыю, гадел, миһербанлы, тәҗрибәле шәхес буларак бирелә. Гади халыкның хәлен яхшырту, җинеләйтү өчен көрәш алып бара. Мәһирә җаны-тәне белән халыкка хезмәт итәргә чыккан ана. Яшәп килгән система тарафыннан кагылган-сугылган хәлдә дә ул ире Сәләхетдин исеменә тап төшерми, халык, ил бәхете өчен көрәш алып бара. Бу яктан Мәһирә образы, милләт анасы дәрәҗәсенә күтәрелгән символик образ ролен үти. Ананың эчке дөньясы да драматик хисләр белән тулы. Ул башка шәхесләр белән генә түгел, үзе белән дә икеләнүле дөньяда яши. Мәһирә үз улына иң мөһим фикерне вакытында әйтәлмәдем бугай, дип үрсәләнә. Улын атасына тиң батыр итеп үстерү—аның иң зур теләге.



*«Алмазбулат» спектакленнән күренеш. Уңнан сулга Гәүһәр—И. Фазылҗанова, Исерек—Ю. Сафиуллин, Барс—Р. Юсупов, Албасты— Х. Исхакнова*

Тормыш кыенлыклары белән берррәттән, пьесада яшьләрнең үзләренә генә хас якты хисләре, моңлы-ләззәтле кичерешләре тасвирлана. Патша кызы Гәүһәр табигатьтәге барлык гүзәллекне үзенә җыйган саф күңелле, гадел, әхлаклы, тәрбияле, ягымлы кыз. Аның һәр сүзе йомшак, мәгънәле, нияте саф. Ул—матурлык алиһәсе, аның карашы кояш кебек ягымлы, йөзе нурлы ай кебек якты. Һәм пьесада ул матурлык символы булып килә.

Алмазбулат—романтик, фантастик хыяллар белән яшәүче үсмер егет. Явыз вәзир тарафыннан тәрбияләнгән егет әтисенең батырлыкларын белми, «бар дөньяга баш булачакбыз»,—дип ятлар көен көйләп, энисе сүзенә колак салмый. Бар хыялы—гаскәр башлыгы булу. Патша кызы Гәүһәргә гашыйк егет тылсымлы курай хакында уйламый. Тик энисенең ил, халык хакындагы сүзләре егетне үзгәртә, мәхәббәт хисләре көч бирә. Алмазбулатның тылсымлы курайны алыр сәгате җитә. Убырларны, дию-пәриләрне, башка кара көчләрне җиңеп, ул курай яшерелгән агачка якынлаша.

И туган тел, и матур тел
Әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем,
Син туган тел аркылы—

дигән шигъри юлларны әйтүгә агач куышлыгы ачыла һәм егет курайны кулларына ала. Алмазбулат курайны уйнауга, явыз вәзир тарафыннан җен-пәриләргә әйләндерелгән кешеләр үз хәлләренә кайталар. Азат патша белән Мәһирә аларга: «Туган илегезне, Туган телегезне исегезгә төшерегез, Ана телебезне онытмагыз!»—дип мөрәҗәгать итәләр. Биредә драматург «ачык текст» белән сөйли—әсәрнең максатын, мәгънәсен һәркемгә җитәрлек итеп, публицистик рухта әйтеп бирә. Әкияттәге астыртын гамәлләрнең безнең тормышта эшләнүен тагын бер мәртәбә аЗсызыклый. Автор туган телебезнең бөеклеге, илаһи көче хакында сүз алып бара. Туган җирне, Ватанны, туган телне онытмаска чакыра. Вәзир һәм Шымхан кебекләр, нәкъ менә әлеге изге төшенчәләргә кизәнәләр.

Пьеса, нигездә, фантастик әкиятләрнең традицион мотивларына, символларына нигезләнеп корылган. Монда тылсымлы курай да, «яхшы патша» образы да, Убыр, Кәрлә, Дию дә бар. Пьесада һәм халык иҗатында сурәтләнгән Убыр, Дию образлары, әлбәттә, тискәре сыйфатларга ия. Алар баш күтәргән кешеләрнең хәтерләрен югалттырып, җен-пәриләргә әйләндерәләр. Хәтерләре урланып җен-пәриләргә әйләндерелгән кешеләр, хәзергечә әйткәндә, манкортлар хакында сүз барганда, драматург киләчәк буыннар язмышы, халыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйлана.

Пьесада Азат патша олы язмышлы, киң күңелле, ярдәмчел, яхшы ата, «яхшы

патша» буларак сурәтләнә. Бу образ халыкның бәхетле тормыш турындагы хыялларын чагылдыра. Азат патшаның фетнәчеләргә каршы көрәштә төп коралы булып чәчәкләр килә. Бу чәчәкләр—гади чәчәкләр түгел. Алар фетнәчеләр йөрәгенә курку салып, гади халыкка көч һәм өмет бирүчеләр. Патшаның Азат исемле булуы да аерым мәгънәгә ия. Ул халыкның азатлык турындагы хыялын гәүдәләндерә.

Шул ук вакытта Ю. Сафиуллинның «Алмазбулат» пьесасы халык азатлыгын даулап вакытсыз өзелгән гомерләр өчен тирән әрнү хисе белән дә сугарылган. Җирдәге азатлык көрәшенең фаҗигале булуын ассызыклый ул. Әмма азатлыкка омтылыш—мәңгелек!

Әдип кулланган образлар, традицион сурәтләр, символлар бүгенге тормыш турында, кеше язмышы турында уйландыра. Пьесаның үзәгендә аерым бер кеше язмышы гына түгел, ә халык, милләт язмышы. Гомумән, Ю. Сафиуллин драматургиясендә кин яңгыраш тапкан темаларның берсе—ул хәтер, милләт һәм тел язмышы. Әлеге проблемалар кичә дә, бүген дә, иртәгә дә актуаль булачак.

**Фатыйма МИҢНУЛЛИНА,**
*аспирант*

---



## «Казан утлары» елъязмасы

**80 ел элек** (1922) «Безнең юл» журналының 2 (июнь-июль) санында **Газиз Гобәйдуллинның «Фаҗигале төннәрдә»** хикәясе, 4 (октябрь-ноябрь) санында **Һади Такташның «Урман кызы»** шигыре, 5 (декабрь) санында **Муса Җәлилнең «Үги бала җыры»** шигыре чыккан.

**75 ел элек** (1927) «Безнең юл» журналының 1 санында **Хәсән Туфанның «Урал эскизлары»** әсәре, 2 санында **Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»** шигыре, **Кави Нәҗминең «Миңлебикә кодагыйның кайгысы»** хикәясе, **Җамал Вәлидинең «Телебезнең иң иске хәзинәләреннән—«Диване лөгате төрки»** мәкаләсе, 4-5 саннарында **Әмирхан Еникинең «Бүгенге яз»** нәсере, 6-7 саннарында **Хәсән Туфанның «Ике чор арасында»** поэмасы, **Шамил Усмановның «Идел буйлап»** хикәясе, **Мәхмүд Максудның «Кызым, кычкырып көлмә»** нәсере, 9 санында **Салих Батталның «Еллар җыры»** шигыре, 12 санында **Кави Нәҗминең «Ядрәләр»** хикәясе басылган.

**70 ел элек** (1932) «Яналиф» журналының 3 санында **Фатих Кәримнең «Башланды»**, **Хәсән Туфанның «Бибиевләр»** шигырьләре, 4 санында **Фатих Сәйфи-Казанлының «Кызыл эшелон»** хикәясе, 5 санында **Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе»** пьесасы, 6-7 саннарында (июнь-июль) **Фатих Кәримнең «Төнге күзләр»**, **Хәйретдин Мөҗәйнең «Мамык кырларында»** шигырьләре, 9-10 саннарында (сентябрь-октябрь) **Риза Ишморат** белән **Кәрим Тинчуринның «Тургай»** пьесасы, **Муса Җәлилнең «Зәйнәп»** шигыре дөнья күргән.

# 26—ШӨГАРӘ (ШАГЫЙРЬЛӘР) СҮРӘСЕ

**Шөгарә сүрәсе 227 аятьтән тора. Бер өлеше Мәккәдә, икенче бер өлеше Мәдинәдә иңгән. 224 нче аятьтә шагыйрьләр турында, ягъни мөшрикләр әйткәнчә, Коръән-и Кәримнең нииндидер бер шагыйрь яки шагыйрьләр тарафыннан түгел, бәлки дә Аллаһ тарафыннан хасил ителгәнлеге турында сөйләнгәнгә күрә, сүрәгә шул исем бирелгән. Бәкара сүрәсеннән кала Коръәннең иң озын сүрәсе.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Та. Син. Мим. **(2)** Болар хакны *(һәм нахакны)* ачыклаучы Китапның аятьләредер.

**3.** *(Ий, Мөхәммәд)* алар иманга килми дип, син үзенне харап итәр дәрәҗәдә кайгырасың. **(4)** Әгәр Без ихтыяр итсәк, аларның башына Күктән бер могҗиза индергән булыр идек, аларның муены аска килгән булыр иде *(яки: ирексезләп дингә кертердәй бер бәла төшереп, алар муен бөгеп, баш иеп, сәҗдә иткән булыр иде)*. **(5)** Чиксез мәрхәмәтле Аллаһтан тагын аятьләр инсә дә, алар барыбер йөз чөерәчәк *(иман китермәячәк)*. **(6)** Хактыр ки, алар *(Коръәнне)* ялганга чыгарды. Аларның шулай мәсхәрәле көлүләренең нәтиҗәсе озакламый киләчәк. **(7)** Әллә соң алар җир өстенә бакмыйлармы, күрмиләрме? Анда һәрнәрсәне төрле-төрле, парлы-парлы итеп үстердек. **(8)** Хактыр ки, бу эшләрнең гыйбрәте дә бардыр ки. Ләкин аларның күбесе иманга килә торган түгел. **(9)** Шик юктыр ки, синең Раббың—мотлак җиңүче, чиксез мәрхәмәтледер.

**10.** Раббың Мусага әйтте:

—Бар син залимнәргә, **(11)** Фиргавен токымы янына кит. Әле моннан соң да алар Аллаһтан курыкмасларммы, *(гөнаһ гамәлләрен ташлап, иманга килмәсләр микәнни)*?—диде.

**12.** Ул *(Муса)* әйтте:

—Раббым, алар мине ялганчыга чыгарыр, дип куркамын, **(13)** күкрәгем кысылыр, телем әйләнмәс. Шуңа күрә, ярдәмче итеп, зинһар, Һарунны күндер *(аңа да пәйгамбәрлек бир)*. **(14)** Аннан соң алар каршында минем бер гаебем бар. Шул сәбәпле, алар мине үтермәгәе, дип тә куркамын,—диде.

*(«Яһүдләрне каты рәнҗеткән Фиргавеннең кыптый токымыннан булган бер кешенең аеруча рәхимсез кыланганына түзеп тора алмастан, үсмер Муса шул җәлладны үтерә».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**15.** Аллаһ әйтте:

—Юк-юк, *(үтермәсләр)* икегез дә аятьләремне алып барыгыз. Шик юк ки, Мин сезнең белән янәшә булырмын. Барысын да ишетеп торырмын,—диде. **(16)** —Барыгыз, Фиргавен янына китегез. Һәм әйтегез: без—галәмнәрнең

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде

Раббысы тарафыннан күндерелгән пәйгамбәрләр булабыз. **(17)** Син Исраил угылларын безгә биреп җибәр, дип хәбәр итегез.

**18.** Ләкин Фиргәвен әйтте:
—Без сине сабый чагыннан алып, бүгенгә чаклы үз арабызда тәрбияләп үстермәдекме? Син гомереңнең елларын безнең арада узгармадыңмы? **(19)** Кыласы явыз эшеңне дә кылдың *(бер кешене үтердең)*, шуннан соң да син безгә рәхмәтле түгелсең *(оятсыз)*.

**20.** Муса әйтте:
—Мин аны белештермичә үтердем. **(21)** Сездән куркып, качып киттем. Ниһаять, Раббым миңа хөкем *(гыйлем, хикмәт)* бирде вә мине *(сезгә)* пәйгамбәр итеп җибәрде. **(22)** Син мине шелтәли торган ул вакыйга *(минем кеше үтерүем)*ның сәбәбе дә синең Исраил угылларын кол итеп, җәбердә тотуың иде.

**23.** Фиргәвен әйтте:
—Кем инде ул синең «галәмнәрнең Раббысы» дигән нәстән?

**24.** —Күкләрнең, Җирнең вә алар арасындагы нәрсәләрнең Раббысы—Аллаһ Тәгалә. Әгәр дә сез хакыйкатьне белергә теләсәгез *(Аллаһка иман китерегез)*,—диде Муса. **(25)** *(Фиргәвен)* яраннарына:
—Ишеттегезме?—диде.

**26.**—Ул сезнең дә, әүвәлге аталарыгызның да Раббысы,—диде Муса.

**27.** —Сезгә илче итеп җибәрелгән бу Мусаны мотлак җен алыштыргандыр,—диде Фиргәвен. **(28)** Муса әйтте:
—Әгәр дә башыгыз*(да миегез)* булса, сез Аның Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында булган бар нәрсәнең дә хуҗасы икәнен *(әллә кайчан)* аңлаган булыр идегез инде.

**29.** Фиргәвен:
—Ант итеп әйтәмен ки, миннән башка берәүне Илаһ итеп алгансың икән, мин сине зинданга аттырам,—диде. **(30)** Муса:
—Сиңа ап-ачык аңлаешлы, дөрес дәлил китергән булсамдамы?—диде. **(31)**—Тугры сөйләгәнлегеңә *(пәйгамбәрлегеңә)* дәлил китер,—диде Фиргәвен. **(32)** Шунда Муса карышкысын җиргә атты, ул еланга әверелде. **(33)** Шуннан соң ул кулын чыгарды, аның кулы тамашачыларга ап-ак *(нур)* булып балкый иде.

**34.** *(Фиргәвен)* якыннарына әйтте:
—Шик юктыр ки, бу, мотлак, бик оста күз буучы, **(35)** ул сезне сихере белән йортыгыздан куып чыгарырга дип килгән. Хәзер нишләтәбез инде моны?—диде. **(36)**
—Аның үзен һәм дә энесен тоткарлап тор да, *(сихерчеләрне)* җыярга кешеләреңне юлла,—диделәр киңәшчеләре. **(37)**—Алар иң оста сихерчеләрне синең янга алып килсен.

**38.** Шулай итеп, *(олуг бәйрәм көнендә)* билгеләнгән вакытка бөтен сихерчеләр бер җиргә җыелган иде.

**39.** —Барыгыз да җыелып беттеме?—дип сорадылар халыктан.

**40.** Әгәр дә *(сихерчеләр)* җинсә, бәлки, без аларга иярербез,—диделәр кешеләр.

**41.** Ниһаять, барысы да килеп беткәч, сихерчеләр Фиргәвенгә әйтте:
—Аларны *(Муса белән Һарунны)* җиңгәч, безгә әҗере булырмы соң?—диделәр.

**42.**—Әлбәттә,—диде Фиргәвен.—*(Сез җиңгән)* тәкъдирдә сез минем иң якыннарымнан булырсыз. **(43)** Муса аларга әйтте:

—Башта сез ташлыйсы нәстәләрегезне уртага ташлагыз,—диде. **(44)** Тегеләр бауларын, таякларын җиргә атып:

—Фиргәвеннең кодрәте илә, һичшиксез, без җиңәчәкбез,—диделәр.

**45.** Муса да шундук карышкысын җиргә ташлады. Ни күзләре белән күрсеннәр, карышкы таяк күз ачып йомганчы, тегеләрнең ясалма еланнарын йотып бетерде. **(46)** Сихерчеләр *(моны күргәч)* шундук сәҗдәгә егылды. **(47)** һәм әйттеләр:

—Без галәмнәрнең, Муса белән Һарунның хуҗасы булган **(48)** бер Аллаһка иман китердек,—диделәр.

**49.** Фиргәвен әйтте:

—Минем рөхсәтемнән башка сез аңа иман китердегез. Әлбәттә, ул сездән остарак булып чыкты, сез дә аннан өйрәндегез. Ләкин сез озакламый белерсез: мин сезнең кул-аякларыгызны аркылы-торкылы чаптырачакмын. Һичшиксез, сезнең барыгызны да аркылы агачка *(хачка)* калаклатачакмын,—диде.

**50.** *(Иман китергәннәр)* әйтте:

—Зарар юк, без инде Аллаһны таптык. **(51)** *(Фиргәвеннекеләр арасында)* иң беренче иман китергән кешеләр буларак: Раббыбыз безнең *(элеккеге)* гөнаһларыбызны ярлыкар, дип өмет итәбез,—диделәр.

**52.** Мусага вәхий аша әмер иттек:

—Бәндәләрем белән бергәләп төнен юлга чык. Артыгыздан куа чыгачаклар,—дидек.

**53.** Ул арада Фиргәвен дә *(гаскәр тупларга)* чапкыннарын шәһәрләргә җибәрде.

**54.** —Аларның *(Исраил угылларының, яһүдләрнең)* гаскәре бик аз. **(55)** Алар безнең ачуны кабартты. **(56)** Безләр исә һәрвакыт уяу *(сугышка әзер торабыз)*,—диделәр.

**57.** Без аларны *(Фиргәвен токымын)* бакчаларын, чишмәләрен, **(58)** хәзинәләрен һәм ундырышлы туфракларын ташлап чыгарга мәҗбүр иттек.

**59.** Без ул байлыкларга Исраил угылларын варис кылдык. Без аларны *(Фиргәвен халкын)* шулай кызык иттек. **(60)** Таң атканда алар *(Фиргәвен токымы Муса белән Һарун җитәкчелегендәге иман китергәннәр артыннан)* куа чыктылар. **(61)** Ниһаять, ике гаскәр *(Исраил угыллары белән Фиргәвен гаскәре)* бер-берсен күргәч, Мусага иярә чыкканнар әйтте:

—Менә, ниһаять, без тотылдык,—диделәр.

**62.** —Юк,—диде Муса.—Әлбәттә, Аллаһ минем белән бергәдер. Ул миңа котылу юлын күрсәтәчәк, иншаллаһ. **(63)** Шуннан соң Без Мусага:

—Карышкы таягыңны диңгезгә ор,—дип вәхий иттек.

Диңгез шундук урталай ярылды, галәмәт биек ике су тавы хасил булды.

**64.** Шуннан соң тегеләрне дә *(куа чыкканнарны)* монда китердек. **(65)** Мусаны һәм аның әмерендә булганнарны коткардык. **(66)** Аннан соң тегеләрне *(гаскәре белән Фиргәвенне)* суга батырдык. **(67)** Монда, әлбәттә, *(аңлаганнар өчен)* гыйбрәт бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(68)** Шунысы хактыр ки, чыннан да, синең Раббың—җиңүче һәм ярлыкаучы.

**69.** Аларга *(гарәп мөшрикләренә)* Ибраһимның гыйбрәтле хикәясен дә укы. **(70)** Ул атасына вә халкына әйтте:

—Сез ни-нәрсәгә табынасыз?—диде. **(71)** *(Тегеләре)* әйтте:

—Потларга табынабыз,—диделәр.—Без аларга көне-төне гыйбадәт кылачакбыз.

**72.** —Сез ялварганда алар сезне ишетәме?—диде Ибраһим. **(73)**—Яки алар сезгә ярдәм итәме, әллә зыян эшлиме?

**74.** —Юк,—диделәр.—Безнең бабаларыбыз шулай табына иде, *(шуңа күрә, без дә потларга табынабыз).*

**75.** —Менә хәзер аңладыгызмы инде, **(76)** аталарыгыз һәм үзегезнең *(булдыксыз)* ни-нәрсәләргә табынганыгызны? **(77)** Алар *(потлар, сынымнар, ташлар)* минем чын дошманнарым булыр. Ләкин галәмнәрнең Раббысы алай түгел. **(78)** Раббым мине яралтты һәм тугры юлны күрсәтүче дә—Ул. **(79)** Мине ашатучы, сусынымны бастыручы да—Ул. **(80)** Хасталанган чагымда миңа шифа биргән дә—Ул. **(81)** Ул мине жансыз калдырачак, соңыннан мине терелтәчәк. **(82)** Җәза көнендә хаталарымны ярлыкаячак, дип өмет иткәнем дә—Ул. **(83)** Раббым, миңа хикмәтләр гыйлеме бир, мине саф мөселманнардан кыл. **(84)** *(Миннән соң)* килгән буыннар мине яхшылык белән телгә алсыннар иде. **(85)** Мине нигъмәт җәннәтенең варисларыннан әйләсәң иде. **(86)** Атамны да ярлыка, зинһар. Кызганыч ки, ул дөрес юлда түгел иде. **(87)** Бәндәләреннең кабердән кубарылачак Көнендә мине рисвай итмә. **(88)** Ул Көнне мал да, угыллар да файда китермәс. **(89)** Әмма ләкин Аллаһка саф күңел белән инанганнар *(ул Көнне)* бәхетле булыр. **(90)** *(Ул Көнне)* саф мөселманнар гына җәннәткә якынлаштырылыр. **(91)** Җәһәннәм исә азгыннарга ачылыр.

**92.** Һәм аларга әйтерләр:

—Кайда сезнең табынганнарыгыз? **(93)** Аллаһтан башка алар сезгә ярдәм итәме? Алар үзләренә үзләре ярдәм итә аламы? **(94)** Һәм алар да *(потлар, сыннар да),* һәм азгыннар да **(95)** һәм Иблис өере дә җәһәннәмгә ташланыр. **(96)** Шунда алар бер-берсе белән ызгышып әйтер: **(97)**

—Валлаһи, без, чыннан да, адашкан булганбыз икән,—диярләр. **(98)**—Чөнки сезне *(потларны)* галәмнәрнең хуҗасы Аллаһка тиңләштердек. **(99)** Безне азгыннар гына адаштырды. **(100)** Хәзер безне яклаучы юк. **(101)** Чын дустыбыз да юк. **(102)** Их, дөньяга кире кайтарылсак иде дә, без мөэмин булып яшәр идек.

**103.** Шик юктыр ки, монда гыйбрәтләр бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(104)** Синең Раббың, хактыр ки, һәрвакыт җиңүче һәм чиксез мәрхәмәтле.

**105.** Нух кавеме дә *(Безнең тарафтан)* күндерелгән пәйгамбәрне ялганчыга чыгарды. **(106)** Нух үзенең кардәшләренә әйтте:

—Аллаһтан курыкмыйсызмы?—диде.—**(107)** Шик юк ки, мин сезгә күндерелгән пәйгамбәр буламын. **(108)** Инде Аллаһтан куркыгыз һәм миңа иярегез. **(109)** Бу эшләрем өчен мин сездән түләү сорамыймын. Миңа дигән бүләк бары тик Аллаһ хозурында гына. **(110)** Шулай булгач, Аллаһның җәзасыннан куркыгыз һәм миңа иярегез.

**111.** Әйттеләр:

—Сиңа ияргәннәр нәселсез, малсыз бәндәләр, без дә шулар кебек сиңа иярикме? *(Бу була торган эш түгел!)*—диделәр.

**112.** Нух әйтте:

—Мин аларның әүвәл ни белән шөгыльләнгәннәрен белмимен,—диде. **(113)**—Яхшылап уйласагыз: аларның хисабы бары тик Аллаһ хозурында гына. **(114)** Һәм мин ул мөэминнәрне *(никадәр генә фәкыйрь булсалар да, сезнең күңелегез булсын дип)* үз янымнан куачак түгелмен. **(115)** *(Сезне гөнаһ кылудан)* кисәтүче булудан башка минем вазифам юк.

**116.** Тегеләр әйтте:

—Әй, Нух, әгәр дә бу эшеңнән кайтмасаң, без сине таш атып үтерәчәкбез.

**117.**—Йа, Раббым, үз халкым мине ялганчыга чыгарды,—диде Нух. **(118)**—Зинһар, безне хөкем ит, мине дә, миңа ияргәннәрне дә *(таш җәзасыннан)* коткар.

**119.** Шуннан соң без аны да, иярченнәрен дә көймәгә утыртып,

коткарып калдык. **(120)** Аннан соң *(ярда)* калганнарны суга батырып үтердек. **(121)** Шик юк ки, монда *(акылы башында булганнар өчен)* гыйбрәтләр бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(122)** Шик юк ки, синең Раббың, әлбәттә, һәрвакыт җиңүче, чиксез мәрхәмәтле.

**123.** Гад халкы да күндерелгәннәрне *(пәйгамбәрләрне)* ялганчыга чыгарды. **(124)** Һуд үзенең кардәшләренә әйтте:

—*(Аллаһ алдында гөнаһ кылудан)* курыкмыйсызмы?—диде. **(125)**—Хактыр ки, мин сезгә күндерелгән тугры пәйгамбәр буламын. **(126)** Инде Аллаһтан куркыгыз һәм миңа иярегез. **(127)** Бу эшем өчен мин сездән һичбер нинди түләү сорамыймын. Миңа дигән бүләк бары тик галәмнәрнең хуҗасы булган Аллаһ хозурында гына. **(128)** Сез калку урыннарда галәмәт зур биналар *(пирамидалар, төрбәләр)* корып *(килеп-киткәннәр белән)* күнел ачасызмы? **(129)** Мәңге яшәргә уйлап, сез шундый ышанычлы биналар корасызмы? **(130)** *(Бичараларны)* хөкем иткән чакта сез рәхимсез кыланасыз. **(131)** Инде Аллаһтан куркыгыз һәм миңа иярегез. **(132)** Сезгә мәгълүм нигъмәтләрне биргән; **(133)** сезгә мал-туар, угыллар биргән; **(134)** бакчалар, чишмәләр биргән Аллаһның газабыннан куркыгыз. **(135)** Мин сезнең өстегезгә хәтәр җәза көне килер дип куркам,—диде.

**136.** Әйттеләр:

—Безгә барыбер, үгетләдең ни, үгетләмәдең ни. **(137)** Бу әүвәлгеләрнең уйдырмасыннан башка нәрсә түгел. **(138)** Безгә җәза бирелмәячәк.

**139.** Шулай итеп, алар аны ялганчы дип атадылар һәм Без аларны һәлак иттек. Шик юк ки, *(башында акылы булганнар өчен)* монда кайбер гыйбрәтләр бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(140)** Хактыр ки, синең Раббың—мотлак җиңүче һәм чиксез мәрхәмәтле.

**141.** Сәмуд *(халкы да)* пәйгамбәрне *(Салихны)* ялганчы дип атады. **(142)** Салих үз халкына әйтте:

—Аллаһтан курыкмыйсызмыни?—диде. **(143)**—Белеп торыгыз, мин сезгә җибәрелгән ышанычлы Пәйгамбәр буламын. **(144)**—Инде Аллаһның җәзасыннан куркыгыз һәм миңа иярегез. **(145)** Бу эшем өчен мин сездән һичбер түләү сорамыймын. Миңа дигән бүләк бары тик галәмнәрнең хуҗасы булган Аллаһ хозурындадыр. **(146)** Сез монда куркынычсыз иминлек эчендә яшәячәкбез, дип өмет итәсезме? **(147)** Бакчаларыгыз, чишмә-коеларыгыз янында. **(148)** Игеннәрегез вә җимешләре йомшак, татлы хөрмә агачлары хозурында. **(149)** Тау битләрендә чокып-чокып үзегезгә кулай өйләр ясыйсыз. **(150)** Инде хәзер Аллаһтан куркыр вакыт житте һәм миңа иярегез. **(151)** Хәттин ашкан мөшрикләрнең әмеренә буйсынмагыз. **(152)** Чөнки алар Җир йөзендә фетнә чыгаручы һәм игелек кылмаучылардыр,—диде.

**153.** Әйттеләр:

—Син тилергәнсең,—диделәр. **(154)**—Син үзең дә әллә кем түгел, безнең кебек үк гап-гади бәндәсен. *(Мин—Аллаһның илчесе, дигән)* сүзләреңне раслар өчен син бер могҗиза эшләп күрсәт *(шуннан соң без сиңа ышанырбыз)*.

**155.** *(Таш эченнән тере дөя чыгаргач)* Салих әйтте:

—Менә, сезгә ана дөя. *(Чишмәдән)* бер көнне ул су эчәр, икенче көнне—сез. **(156)** Аңа бер дә яманлык эшләмәгез. *(Юкса)* соңыннан, бөек Көн килгәч, сезне хәтәр җәза тотар.

**157.** Шуңа да карамастан, алар дөяне суйды. Ләкин соңыннан бик нык үкенделәр. **(158)** Чөнки алар җәзасын алды. Шик юктыр ки, монда гыйбрәт бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(159)** Хактыр ки, синең Раббың—һәрвакыт җиңүче һәм чиксез мәрхәмәтле.

**160.** Лутның халкы да пәйгамбәрне ялганчы дип атады. **(161)** Лут үз туганнарына әйтте:

—Аллаһтан курыкмыйсызмыни?—диде. **(162)**—Хактыр ки, мин сезгә тугры пәйгамбәр буларак күндерелгән кешемен. **(163)** Инде Аллаһтан куркыгыз

һәм миңа иярегез. **(164)** Бу эшем өчен мин сездән һичбер түләү сорамыймын. Миңа дигән бүләк бары тик Аллаһ хозурында гына. **(165, 166)** Раббыгыз сезнең өчен яралткан хатыннарыгызны *(нәүмиз)* калдырып, сез *(җенси ихтыяҗыгызны канәгатьләндерер өчен)* ирләр янына йөрисезме? Хактыр ки, сез *(хәләлне ташлап, харамга күчүче)* азгын халык икән.

**167.** Әйттеләр:

—Әй, Лут, син бу эшеннән ваз кичмәсән, һичшиксез, сине ватаныбыздан куачакбыз,—диделәр.

**168.** Лут әйтте:

—Шушы кыланмышларыгыз өчен сезгә нәфрәтләнәм,—диде. **(169)**—Йа, Раббым, мине һәм минем халкымны бу кылмышларыннан коткар,—диде Лут.

**170.** Шуннан соң Без аны һәм *(иман китергән)* бөтен гаиләсен коткарып калдык. **(171)** Иман китермәгәннәр *(һәлак булганнар)* арасында аның хатыны да бар иде. **(172)** Аннан соң калганнарның барысын да һәлак иттек. **(173)** Өсләренә шундый *(хәтәр давыллы, дәһшәтле ташлы)* яңгыр койдырдык ки, кисәтелгәннәр *(әмма иман китермәгәннәр)* өчен бик тә хәтәр яңгыр иде ул. **(174)** Шик юктыр ки, монда гыйбрәт бар. Ләкин аларның күбесе иман китерми. **(175)** Хактыр ки, синең Раббың һәрвакыт җиңүче һәм чиксез мәрхәмәтле.

**176.** Айкә *(дигән урман)* халкы да пәйгамбәрне *(Шөгаебне)* ялганчы дип атады. **(177)** Шөгаеб аларга әйтте:

—Аллаһтан курыкмыйсызмыни?—диде. **(178)**—Хактыр ки, мин *(сезгә күндерелгән)* тугры пәйгамбәр буламын. **(179)** Инде Аллаһның җәзасыннан куркыр вакытыгыз җитте һәм миңа иярегез. **(180)** Бу эшем өчен мин сездән бернинди дә түләү сорамыймын, миңа дигән бүләк бары тик галәмнәрнең хуҗасы булган Аллаһ хозурында гына. **(181)** Үлчәүдә төгәл үлчәгез. Ким үлчәмәгез *(кеше хакы ашамагыз)*. **(182)** Дөрес бизмән белән үлчәгез. **(183)** Кеше хакына кермәгез. Җир йөзендә бозыклык *(гаделсезлек)* таратмагыз. **(184)** Сезне һәм килеп-киткән нәселләрне яралткан Аллаһның җәзасыннан куркыгыз,—диде.

**185.** Әйттеләр:

—Син *(сихерләрдән)* тилергән кеше икәнсең,—диделәр. **(186)**—Син үзең дә *(әллә кем түгел)*, безнең кебек үк гап-гади бәндә икәнсең. Без сине, чыннан да, ялганчы, дип уйлыйбыз. **(187)** Әгәр сүзең дөрес булса *(пәйгамбәрлегеңә ышандырасың килсә)*, өстебезгә бер кисәк Күкне иңдер. **(188)** Шөгаеб әйтте:

—Сезнең кылмышларыгызны Аллаһ яхшы белеп тора,—диде.

**189.** Шулай да алар аны ялганчы диделәр һәм аларга җәза ирешә. *(Кояшны каплаган)* күләгәле, болытлы көнне аларга газап килде.

**190.** Шик юктыр ки, монда гыйбрәт бар. Ләкин аларның күбесе иман китермәде. **(191)** Хактыр ки, синең Раббың һәрчак җиңүчедер һәм чиксез мәрхәмәтледер.

**192.** Ул *(Коръән)*, һич ялгансыз, галәмнәрнең хуҗасы Раббыдан иңдерелде. **(193)** Аның белән бергә имин рух *(Җәбраил фәрештә)* иңде. **(194)** *(Аллаһның колларын)* кисәтүче *(үгетче)* булсын дип, синең күңеленә *(Коръән)* иңдерелде. **(195)** *(Җиңел аңлашылырлык булсын дип)* гарәпчә ачык итеп иңдерелде. **(196)** Хакыйкатән, *(Коръән турында хәбәрләр)* моннан элек килгән китапларда да бар.

**197.** Исраил токымы арасындагы галимнәрнең *(Мөхәммәд һәм Коръән турында)* белгәннәре аларга дәлил була алмыймыни? **(198)** Без аны башка кавемнән булган кешегә иңдергән булса идек, **(199)** шуннан ул аны халыкка *(ана телендә)* укыса иде, барыбер алар иман китермәгән булыр иде. **(200)** Шулай итеп, Без гөнаһлыларның күңеленә көферлек керттек. **(201)** Хәтәр җәзаны үз күзләре белән күрмичә алар иман китермәс. **(202)** Газап аларга абайламастан килер. **(203)** Шулчак алар:

—*(Газапны)* кичектереп булмасмы?—дип ялварыр. **(204)** Алар тизрәк җәза килүен *(бу дөньяда ук)* телимени?

**205.** Син әйтеп бир *(ий, Мөхәммәд)*: озак еллар дәвамында Без аларга нигъмәт бирсәк, **(206)** соңыннан алар өстенә вәгъдәбез *(хәтәр газап)* төшсә, **(207)** дөньядагы файдалы маллары аларны коткарып калыр идеме?

**208.** Иң башта кисәтмичә *(пәйгамбәр җибәрмичә)*, Без бер генә халыкны да харап итмәдек. **(209)** Без беркайчан да гаделсез булмадык, *(нахакка җәза бирмәдек)*. **(210)** Ул *(Коръән)* шайтаннар тарафыннан иңдерелмәде. **(211)** Бу аларның кулыннан килә торган эш түгел, аларның андый куәсе юк. **(212)** Шик юктыр ки, алар—*(фәрештәләрнең сүзен)* ишетүдән мәхрүм калган затлар. **(213)** Шуңа күрә, сак бул, Аллаһка тиң дип, башка бер илаһ чакырма. Соңыннан газапларга дучар булырсың. **(214)** Якын туганнарыңны да *(гөнаһ кылганнарны Аллаһның каты җәзасы көтә дип)* кисәтеп куй. **(215)** Сиңа ияргән мөэминнәргә *(игелекле ярдәм)* канатыңны җәй. **(216)** Әгәр алар инкарь юлына басып, гыйсъян күтәрсә, әйт:

—Мин сезнең бу эшләрегездән ерак торамын,—диген.

**217.** Син һәрчак җиңүче һәм ярлыкаучыга *(Аллаһка)* сыен. **(218, 219)** Ул намаз вакытында башка бик күп гыйбадәт кылучылар арасында синең нишләгәнеңне күреп тора. **(220)** Ул барысын да ишетеп, күреп торучы.

**221.** *(Һәй, мөшрикләр)* шайтаннарның кем янына иңгәннәрен сезгә әйтеп биримме? **(222)** Алар гөнаһ кылучылар, ялганчылар башына төшә. **(223)** Алар *(гөнаһлылар, ялганчылар шайтанны)* тыңлыйлар вә аларның күбесе ата ялганчы.

**224.** Шагыйрьләргә килгәндә, эш болай тора. Аларга да адашканнар ияра. **(225)** Күрмисеңмени, алар ни кылганнарын белмичә *(тилереп)*, болыннар буйлап йөри. **(226)** Һәм тормышка ашмастай хыялый сүзләр сөйләнәләр. *(Үзләре булдыра алмаган эшкә башкаларны өндиләр.)*

**227.** Бары тик иман китереп, игелек кылганнар, Аллаһны онытмаганнар вә үзләренә гаделсезлек кылганнардан үзләрен яклый алганнар, алар *(Хакка каршы шигырь язган хаин шигырьчеләр)* рәтендә түгел. Гаделсезлек кылган залимнәр үзләренең кая барачакларын озакламый белерләр.

صدق الله العظيم

*Әдәбият тарихына*

# ИСХАКЫЙ ВАСЫЯТЕНЕҢ ИЯСЕ

## I

Азия һәм Аурупа кыйтгаларын тоташтыручы, үзендә миллионлаган инсаннарны яшәтүче ыгы-зыгылы Истанбул каласы. Бу «мәңгелек шәһәр»нең (К. Маркс сүзләре) кечкенә генә бер фатирында бөек Исхакыйның гомер шәме сүнеп бара. Күпме кешегә рухи ярдәм, яшәүгә көч биргән 76 яшьлек бу зат хәзер япа-ялгыз, матди кыенлыкта, каты авыру. Янында гына Газраил йөрүен инде ул тирәнтен аңлый. Соңламаска!—Гомер юлына йомгак ясарга кирәк! Әмма ничек, ни рәвешле? Менә ул, үзендә көч табып, кулына каләм ала. Хат рәвешендә үзенең бүгенге хәле, тормыш юлы, халык тарихы, милләт, җәмгыять турында уйлануларын бәян итә. Кайчандыр көненә дистәләгән бит язган әдип бу хатын атна буе, ягъни 1954 елның 12-18 апрель көннәрендә яза (хат 21 апрельдә Финляндиягә барып җитә). Бу хакта ул үзе дә искәртә. *«Мин бу арада бик каты хаста булганга,*—ди әдип,—*бу хатны берничә мәртәбә бүлеп яздым. Бу хатымны мөмкин кадәр саклагыз. Мин, бәлки, соңгы атналарымны яши торганмындыр. Шулай булып чыкса, бу хатым мәгънәви васыятем кебек калсын... Мин үлеп китсәм, форсаты килгәндә, бу хатымны бөтен халыкка бер мәртәбә укыгыз...»*.

Берничә битлек хатның атна буе язылуы, әлбәттә, иң беренче чиратта әдипнең «хаста»лыгына бәйле. Әмма хикмәт анда гына түгел. Исхакый бу хатын «бөтен халыкка» җиткерергә теләгән соңгы сүзләре, киңәш-теләкләре, «рухи васыяте» рәвешендә карый. Хатның озак язылуы билгеле бер дәрәҗәдә шуның белән дә аңлатыла.

Әдипнең кызы, кияве, туган-тумачалары бар, билгеле танышлары, аркадашлары да шактый. Ә васыять хаты аларга түгел, ә Финляндиянең Тампере каласында яшәүче гадәти татар кызы Халидә Вафага (Вафинага) адресланган. Бу очраклылыкмы, әллә моның берәр хикмәте, сере бармы?

Мәгълүм булганча, Г. Исхакый Суоми мәмләкәтен ярата, анда яшәүче милләттәшләребез белән күптәннән аралашып тора. Бирегә аның Октябрь инкыйлабына кадәр дә, аннан соң да күп мәртәбәләр килүе билгеле. Әдипне Архангел сөргененнән азат итүдә дә Финляндиядә яшәүче татарларның катнашы бар. Әдип гәҗит-журналлар чыгаруда, китаплар нәшер итүдә дә биредәге милләттәшләребезнең ярдәмен тоеп яши. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналының (1928—1939) төп химаячеләре (спонсорлары)—Финляндия татарлары. Аның битләрендә бу мәмләкәт, андагы милләттәшләребезнең тормышы хакында шактый гына материаллар бар. Аларның күбесе баш мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган. Хельсинки, Тампере, Випури (Выборг) һәм башка шәһәрләрдә гомер кичерүче татарлар Г. Исхакый язмаларын даими укып торалар, аның драма әсәрләрен сәхнәләргә куялар. Әдипнең 60 яше, иҗатының 40 еллыгы биредә зур күләмдә билгеләп үтелә. Г. Исхакый Финляндиядәге милләттәшләребезне туплауда, рухи яктан тәрбияләүдә остаз ролен үти. Аны олысы да, кечесе дә ярата, хөрмәт итә. Биредә әдип аралашкан, озак еллар буе бәйләнеш тоткан берничә гаилә була. Шундыйларның берсе—Вафиннар (Вафалар).

Унтугызынчы гасырның соңгы чирегендә туып, 1941 елда вафат булган Зиннәтулла Вафа—Сергач төбәгендәге Яңапар (Актук) авылының атаклы Аюханнар нәселеннән. Ул яшьли үк Финляндиядә сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Нигездә, Тампере каласында тора. Випури тирәсендәге Тирйокида

җәйге утарлары да була. Аның энергияле эшмәкәр, гаять милләтпәрвәр зат икәнлеге мәгълүм. Зиннәтулла Вафаның хатыны—Мөшфика ханым (13.11.1886—27.11.1966). Күпләр аның киң күңелле, ярдәмчел, зыялы инсан булуы хакында сөйлиләр. Мөшфика ханым вафатының кырыгынчы кичәсендә эшмәкәр һәм үзешчән шагыйрь Гайсә Хәкимҗан (1896—1972) болай ди: «Без бүген бу хөрмәтле ананың кырык кичәсенә җыелдык. Мин үзем бу ана белән 50 елдан артык шул Тампере шәһәрендә бер гаилә кебек бергә яшәп килдем. Бу ана ялгыз балалар анасы гына түгел иде. Бу ана халык анасы иде һәм милләт анасы иде...». Г. Хәкимҗанның «Мөшфика тутай хатирәсенә...» дигән махсус шигыре дә бар. Аның бер строфасы болай яңгырый:

Һич сүнмәслек хәсрәт ялкыннарын
Өстәдең син минем бәгъремә.
Гомерлеккә сулмас гөл орлыгын
Утыртам мин синең кабреңә.

Зиннәтулла һәм Мөшфика Вафалар җиде бала тәрбияләп үстерәләр: Сәмигулла, Фатыйма, Алия, Халидә, Кадрия, Наилә, Гөлсем. Гаиләдә дустанә мөнәсәбәт, туган телгә, төрки-татарга, мәдәнияткә мәхәббәт хөкем сөрә. Ата-ананың матур сыйфатлары, игелекле эш-гамәлләре балаларына да күчә. Мәсәлән, 1990 елда бу гаиләнең бер әгъзасы—Алия апа белән миңа да очрашырга туры килгән иде. Бу зыялы, итагатьле, ачык йөзле инсанның хатирәсе (ул моннан бернинә ел элек вафат булды) хәзер дә күңелдә саклана.

Гаяз Исхакыйның Вафиннар гаиләсе белән озак еллар буе аралашып торуы бик күп фактлар, җөмләдән хатлар, фотокарточкалар, төрле истәлекләр белән расланa. Мәсәлән, 1927 елның мартында язылган бер открыткада Г. Исхакый бу гаиләне «бәйрәм мөбарәк булсын» дип котлый. Икенче бер язмада әдип Вафиннарны «илемезнең хөрмәтле гаиләләрендән» берсе дип атый. Димәк, бөек әдипнең васыять хатын нәкъ менә шушы гаилә әгъзасына адреславы һич тә очраклы хәл түгел. Аннан шунысы да бар: Халидә Вафа—чагыштырмача яшь буын вәкиле. Г. Исхакый исә милләт тәрәккыяте, киләчәк өчен көрәштә һәрчак яшьләргә күңел баглый. Димәк, хатның адреслануы билгеле бер символик мәгънәгә дә ия.

Гыйльми һәм популяр әдәбиятта Исхакыйга мөнәсәбәттә Халидә Вафа исеме сирәк булса да телгә алына. Әмма аның хакында мәгълүматлар юк диярлек.

Мин 1990 елда Финляндиягә баргач, үкенечкә каршы, Халидә апа белән очраша алмадым. «Татар акылы төштән соң» дигәндәй, әле анда вакытта бу мөхтәрәмә зат белән очрашуның зарурлыгын да аңлап бетермәдем булса кирәк. Чөнки васыять хатының машинкада басылып, брошюра рәвешенә китерелгән нөсхәсе (ул гарәп язуында. Күләме—11 бит. Анда Г. Исхакыйның 1951 елгы тәбрик хаты да бар) 1990 елда Финляндиядән китәр алдыннан гына кулга керде. Мин аңа «Ислам җәмгыяте» архивында тап булган идем (Бу кыйммәтле материалны бирүләре өчен мин җәмгыять җитәкчеләре Окан әфәнде Таһирга һәм Хөсәен әфәнде Хәмидуллага янә бер мәртәбә ихлас рәхмәтләр юллыйм.).

Казанга кайткач, Г. Исхакый хатын мин кереш мәкалә һәм тиешле шәрех-аңлатмалар белән матбугатка әзерләдем. Әле ул вакытта СССР чоры иде. Аерым кысу-тыюларга да карамастан, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире кыюлык күрсәтте: мин тәкъдим иткән материаллар журналның 1991 елгы 5 нче санында басылып чыктылар. Татарның киң җәмагатьчелегенә соңарып ирешкән васыять хаты укучылар арасында зур кызыксыну тудырды. Бераздан аны күчереп тә бастылар *(Әхмәт Сәхапов. Исхакый иҗаты.—К., 1997.—336-352 б.; «Мирас» журналы.—1999.—2 нче сан.—42-49 б.).* Әмма текстка, васыять адресатына карата туган аерым сораулар җавапсыз кала килде.

## II

Халидә апаның 1991 елда Идел круизы вакытында Казанга килеп чыгуы да соңрак кына мәгълүм булды. Мин инде, әгәр дә Суомига янә барырга туры килсә, Халидә апа белән очрашуны тәүге бурычларымның берсе итеп куйдым. Менә, ниһаять, 2000 елның җәендә (төгәлрәге 18 июль—15 август көннәрендә) «Ислам җәмгыяте» чакыруы буенча кызым Гөлназ белән

янә Финляндиядә булырга туры килде. Милләттәшләребез безне ачык йөз белән, зурлап каршы алдылар, хөрмәт иттеләр, озаттылар. Мин берничә көн буена аларга Хельсинкида, шәһәр янындагы Трэскулла ял йортында әдәбият һәм халык тарихы, рухи мирасыбыз хакында лекцияләр укыдым, семинар-әңгәмәләр үткәрдем. Кызганыч, ун ел эчендә элек мин күреп аралашкан шактый гына мөхтәрәм затлар китеп барган: Халидә һәм Гомәр Таһирлар, Нурмөхәммәд һәм Сафия Самәрханнар, Лотфулла һәм Халисә Байбулатлар, Госман ага Али, Гәүһәр апа Туганай, Алия апа һ. б. (Авыр туфраклары җиңел булсын үзләренең).



*Бу язманың авторы Хатыйп Миңнегулов үзенең кызы Гөлназ белән Халидә ханым янәшәсендә. 2000 ел.*

Бу сәфәремнең ике көнен, алдан ук ниятләгәнчә, Хельсинкидан 165 чакрым ераклыктагы Тампере каласына багышладым. Гаҗәеп итагатьле, милли җанлы, чын татар егете Алтан Каадәр ярдәме белән шәһәрнең истәлекле урыннарын да карадык, элеккеге танышыбыз, милли җәмгыять җитәкчесе Әсәт ага Байбулат белән дә гаплəштек, иң мөһиме—«Ислам мәхәлләсе» йортында Халидә апа Вафина белән очраштык («Өемдә ремонт бара»,—диде). Өлкән яшьтә булуына карамастан, шактый хәрәкәтчән, җитез табигатьле, җанлы. Зиһене, хәтере әйбәт, җөмләләре төзек, мөгамәләсе зыялы, тактлы. Ике арада сүз иярә сүз китте. Сорыйсы, ачыклыйсы әйберләр күп. Әмма вакыт аз. Икенче көнне китү алдыннан янә очраштык. Халидә апа, ничектер, яшәреп киткәндәй булды. Дулкынлана-дулкынлана хатирәләрен искә төшерде. Үзе дә: «Зур рәхмәт сезгә, яшьлегемә кайткандай булдым»,—диде. Хельсинкига да миңа берничә мәртәбә шалтыратты. Алтан әфәнде аркылы янә берничә фото, язма материал һәм хат та җибәргән иде. Соңгысында мондый эчтәлектәге юллар да бар: «... Хельсинкига сезнең чыгышларны тыңларга бару мөмкинчелеге булмаган иде. Аллаһуның рәхмәте бөектер: сез кыйммәтле вакытыгызны бүлеп, минем белән күрешү өчен үзегез Тамперега килдегез. Бу минем өчен иң бөек шәрәфтер. Олуг галимнәр тарафыннан күрсәтелгән мондый хөрмәтне мин бары тик әти-әниемнән генә күрдем. Бу очрашуда сез бөек, мәшһүр милләтче тарихчыбыз булган Гаяз Исхакыйны да шәрәфләндердегез. Мин шушы изге эштә арадашчы булуыма шатмын... Сезнең белән очрашуга ни дәрәҗәдә сөенүемне белсәгез иде! Мин сезне иске бер дустым кебек кабул иттем, уй-кичерешләремне, ачылып, сезгә сөйләдем. Күз алдыма яшьлек хәятем килде, калебемдәге кыйммәтле хатирәләр яңарды...» (Хат, ни сәбәптәндер, төрекчә язылган.) Хәзер Халидә апа сөйләгәннәрдән аерым өзекләр, фикерләр китерәм. Алар бу затның үзен, тормышын да билгеле бер дәрәҗәдә күзалларга ярдәм итәр дип ышанам.

«Мин,—диде Халидә Вафа,—сезнең инкыйлаблар илендә туганмын: төгәлрәк әйткәндә, 1917 елның 23 нче маенда, Тирйокида. Әмма даими яшәү урыным Тампереда булды. Шактый хәлле, җиту тормышта үстем. Гимназия тәгәлләдем. Үзебезнең динне, телне, әдәбиятны, тарихны өйдә һәм җәйге курсларда өйрәндем. Татар, фин, швед, алман һәм кайбер башка телләрне беләм. Гадәттә, Тирйокида уздырылган җәйге курсларга эшкә күренекле галимнәр, билгеле шәхесләр чакырыла иде. Безне, мәсәлән, Муса Җарулла, Абдулла Баттал, Галимҗан Идриси һәм башкалар укытты. Тирйокидагы дачабыз һәм Тампередагы йортыбызда халкыбызның бөек кешеләре Гаяз Исхакый, Рәшит Рәхмәти һәрчак булып торды. Аларның милләт турындагы сүзләре кечкенәдән үк күңелгә сеңеп барган. Чит илгә тәүге сәфәрем 1938 елда булды. Берлинга электән үк танышыбыз, гаилә дустыбыз Галимҗан Идрисләргә кунакка бардым. Алманча белүемне камилләштердем.

Сугыш башлангач, эти дә үлгәч, яшәү кыенлашты. Совет очкычлары Тамперены көчле бомбага тотып тордылар. Янгыннар чыгып күп зыян күрдек. Сугыштан соң, бераз аякка баскач, 1951 елда чит ил сәфәренә юнәлдем. Әүвәл Ромада *(Румыниядә.—Х. М.)* булдым. Аннан—Мисырга. Биредә Г. Идрисинең улы Урхан каршы алды, Әл-Әзһәр университетын һәм Каһирәнең башка истәлекле урыннарын күрсәтте. Мисырдан Төркиягә килдем. Измир, Истанбул каларында берничә ай булдым. Төрекчәне утызынчы елларда Абдулла Батталдан (аның белән шактый хатлар алыштык) өйрәнә башлаган идем. Төркиядә аны тагын да камилләштердем. Илленче еллардан башлап Төркия-Финляндия арасындагы рәсми, эшлекле сөйләшүләрдә, шул исәптән ил башлыклары очрашуларында да берничә мәртәбә тәрҗемәче буларак та катнаштым».

Халидә апа Муса Җарулла Биги, Садрый Максудый һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләрен фин теленә тәрҗемә итүен дә искәртте.

Күп кенә хатлар, фотолар, башка төр материаллар Халидә Вафаның күренекле затлар (галимнәр, әдипләр, дәүләт эшлеклеләре һ. б.) белән аралашуын раслап торалар. Мәсәлән, аның Финляндия президенты Кекконен белән төшкән рәсеме бар. Халидә ханым күп мәртәбәләр Садрый Максудый һәм аның гаиләсе белән очрашып, хатлар алышып тора.

Илгаз Ваһаб Нәүрүзхан безнең укучыларга «Сөембикә» әсәре белән таныш. Бу тарихи роман татар телендә 1992 елда Чаллыда нәшер ителгән иде (тәрҗемәчесе—Рәис Сабиров). Милләттәшебез Нәүрүзхан (нигездә, ул Измирдә яши) төрек әдәбиятында башка әсәрләре белән дә мәгълүм. Баксаң, Халидә Вафа бу әдип белән дә дустанә мөнәсәбәтләрдә торган. Илгаз Нәүрүзханның 50-60 елларда аңа язган бик җылы эчтәлекле хатлары бар. Халидә апа миңа бу авторның 1949 елда Измирдә иҗат ителгән бер хикәясенең күчермәсен дә бүләк итте. «Завалле аннәчегем» («Фәкыйрь анием») дип исемләнгән бу әсәрдә бөтен барлыгын гаиләсе, балалары өчен сарыф иткән ананың ахыр чиктә фәкыйрьлектә, ялгызлыкта яшәп вафат булуы шактый үтемле итеп тасвирлана.

Халидә апа Вафа 1941 елдан «Истәлекләр дәфтәре» алып бара. Анда килгән кунакларның кызыклы язмалары бар. Төрек әдибе Урхан Каравәли 1962 елның августында Тампереда була. Шунда Халидә апа белән дә очраша. Аның хатирә дәфтәренә мондый сүзләрне язып калдыра: *«Халидә ханым кебек соң дәрәҗәдә айдын (зыялы.—Х. М.), соң дәрәҗәдә зирәк, милләтче вә Ататөреккә ихтирамлы бер төрек кызының хатирә дәфтәренә... язу миңа бик уңайсыз... Аның белән танышуыма, аралашуыма бик шат булдым. Аңа карап хәйрәт (таң.—Х. М.) калдым»*. Бу истәлек дәфтәре хәзер дә гамәлдә. Тамперега, зур халыкара фәнни конгресска (2000 ел) АКШтан килгән милләттәшебез, күренекле профессор Азадә-Айшә Рорлих та Халидә апа белән очрашып, мондый сүзләрне теркәп калдырган: *«Сезнең белән очрашу минем өчен бик кыйммәтле хатирә булып калды. Тарихыбызны яратып, тарихи материалларны саклавыгыз өчен сезгә чын күңелдән рәхмәт укыйм...»*. *Без фәкыйрегез дә бу хатирә дәфтәренә түбәндәге сүзләрне язып куйдым: «... Сез—безнең халыкның билгеле кешесе. Чөнки бөек шәхесебез Гаяз Исхакый Сезне хөрмәт иткән, соңгы васыятен дә Сезгә атап язган. Сезнең белән танышуга мин бик шат булдым. Үзегезгә рәхмәтләр укыйм, исәнлекләр телим...»*

## III

Халидә апа белән әңгәмәнең үзәгендә, әлбәттә, Гаяз Исхакый торды. «Мин,—диде ул,—бу бөек затны кечкенәдән үк ишетеп, күреп беләм. Чөнки ул безнең өебездә гаять абруйлы, мөхтәрәм кеше итеп йөртелә иде. Гаяз әфәнде минем күңелемдә, ничектер, озын буйлы, горур табигатьле, кешеләрне, аеруча хатын-кызларны үзенә магнит кебек тартып торучы кеше рәвешендә калган. Аны гел тыңлыйсы гына килеп тора иде. Гаяз әфәнде аеруча безгә, яшьләргә илтифатлы иде. Шундый олуг затның безне тиң күреп сөйләшүе безгә рәхәт иде.

1937 елда минем апам Алия белән Әнвәрнең туе булды. Анда Гаяз Исхакый да катнашып, бөтен мәҗлесне бизәп торды. Ахырда без аның белән урамнан да йөреп кердек. Гаяз әфәнде белән янәшә бару, аның игътибарына ия булу минем өчен бөек бер дәрәҗә, онытылмас бер хатирә иде. Мин бу әдип язган әйберләрнең күпчелеген укып барырга тырыштым. Әңгәмәләр

вакытында алар хакында да еш кына сүз кузгала иде. Гаяз әфәндегә мин һәрвакыт соклану, инсани сөю хисләре белән карый идем.

Бөек әдип Алманиядә, Польшада яшәгән вакытында Финляндиягә еш килә иде. Әмма Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, ул Төркиягә күчеп китте. Хат-хәбәрләр алышкаласак та, мин аны озак еллар күрә алмадым. Ниһаять, 1951 елның июнендә без аның белән Истанбулдагы бер бакчада очраштык. Ак, пөхтә костюмнан иде. Кулында таяк. Ябыккан, олыгайган, хәлсезләнә төшкән. Күңеле төшенкерәк булса да, милли мәсьәләләрдә иман-ышанычы нык иде. Без аның белән бик озак сөйләштек. Хатирәләрне яңарттык. Бу безнең соңгы очрашу булды. Йа Алла, нинди истәлекле вакытлар бар иде, кадерен белмәгәнмен!

Тампере шәһәренең имамы Хәбибрахман Шакир иде (ул чыгышы белән Туймазы татары иде бугай. Әмма озак еллар Пакистанда яшәгән). Безнең яхшы танышыбыз, бик мөхтәрәм зат. Ул да Гаяз әфәнде белән яхшы мөнәсәбәттә иде. Бервакыт имамыбыз миңа болай ди: Гаяз Исхакыйның хаты килде. *«Авырыйм, Ватан ризыкларын ашыйсым килә»*,—дип язган. Шуннан мин карабодай, май һәм кайбер башка азык-төлек әйберләре алып, Истанбулга берничә пакет (посылка.—*Х. М.*) җибәрдем. Абыем Сәмигулла өс киемнәре салды. Бераздан Гаяз әфәнденең шул васыять рәвешендә язылган хаты килде. Моннан тыш та без 1954 елда янә берничә хат алыштык».



*Гаяз Исхакыйның 1954 елда Халидә Вафага бүләк иткән соңгы фоторәсеме.*

Гаяз Исхакый, васыять хаты белән бергә, үзенең иң соңгы фотоларының берсен дә җибәрә. Аның астына мондый сүзләр язылган: *«Җитмеш җиденче яшемә баскан 1954 нең 23 февралендә алдырган рәсememне, бер хатирә булсын дип, Зиннәт Вафа әфәнденең кәримәсе (кызы,—Х. М.), милләтче Халидә туташка бүләк итеп күндерәм. Гаяз Исхакый, Истанбул, 18 апрель, 1954»*.

Гаяз әфәнденең үлем хәбәрен,—ди Халидә апа,—безгә Гали Акыш ирештерде. Без моңа барчабыз да бик кайгырдык. Аеруча миңа авыр булды. Гаяз әфәнденең үтенечен исәпкә алып, Хәбибрахман Шакир (1903—1975) белән берлектә васыять хатын машинкада бастырып, төпләттек, берничә дистә данә күбәйттек. Милләттәшләребезгә өләштек. Чит мәмләкәтләргә дә бераз җибәрдек».

Бу урында шунысын да әйтү урынлы булыр: машинкада басылган, төпләнгән васыять хаты илдәге, шул исәптән Казандагы аерым татар зыялыларының да кулына эләгә. Әмма сәяси якны күздә тотып, бу хакта алар һич тә дәшмиләр. Әгәр дә хак булса, шушындый хәлне дә сөйлиләр: имеш, СССР дәверендә Финляндиягә барган бер галимгә бу хатны бирәләр. Ә ул аны кайту белән КГБга илтеп тапшыра.

Халидә апа васыять хатының оригиналдан күчермәсен миңа бирде. Мин аны машинкада таралган нөсхәсе белән чагыштырып чыктым. Аерма юк дәрәҗәсендә. Хатның соңгы өлешендәрәк күп нокталар куелган юл бар: *«Әгәр мөмкин булса, бу хатым... хәзрәткә дә укыгыз»*. Оригиналда бу урында «Хәбибрахман» диелгән. Шундагы ук абзацта күп нокталар куелган җөмләне түбәндәгечә уку лязем: *«Ләкин кирәк Финляндиядә, кирәк Япуниядә, кирәк яңа мөһаҗирләремез арасында бу милли иманның көннән-көн зәгыйфьләнүенә хакыйкый иман йиренә русның аракысы илә дуңгыз мае сеңдерелгән ялган иманның... йирләшүенә шайтаный бер куәтнең бик тырышуын күреп бик борчыламыз»*.

Халидә апа Вафа миңа Г. Исхакыйның янә берничә хатының күчермәсен бирде. Мәсәлән, аларның берсе 1954 елның 13 нче февралендә, икенчесе шул ук елның 8 нче маенда язылган. Боларда, васыять хатындагы кебек, тарихи, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләр күтәрелми. Әмма шуңа да карамастан, бу хатлар бөек әдипнең көндәлек тормышын, авыр язмышын, кешеләр белән мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан мөһим. Минем уемча, киләчәктә Г. Исхакыйның җентекле биографиясе, тормыш һәм иҗат хроникасы язылырга тиеш. Бу төр материаллар шул җәһәттән дә игътибарга лаек. Безнең кулыбызда шулай ук

Гаяз Исхакый һәм Халидә Вафа мөнәсәбәтләренә кагылышлы кайбер башка хатлар һәм материаллар да бар. Мәсәлән, 1951 елның 28 нче июнендә Г. Исхакый тарафыннан язылган бер истәлек тексты мондый эчтәлектә: *«Илемезнең хөрмәтле гаиләләрендән Зиннәтулла Вафа, мөшфика Вафа ханымның кызлары Халидә туташның атасы-анасы кебек тууы(н), дөрест булуын күреп, сөендем, халкымызның киләчәге уңышлы чыгачагыны, шундый йитешкән кызларның Финляндия кебек илемездән ерак йирләрендә үсүе, зураюы зур сөенечле галәмәтдер. Тәңре шундый яшьләремезгә, хосусан Халидә туташка шәхси тормышында бәхетле булып, милләтенә файдалы булуыны вә бик күп төрек-татар яшьләренә үрнәк булырлык хәерле эшләр эшләвене насыйп итсен. Рамазан ае, Истанбул»*.

(Бу язу Г. Исхакый белән Халидә Вафаның Истанбулда очрашу вакытында теркәлә.)



*Халидә Вафа 1937-38 елларда*

Гаяз Исхакый һәм Садрый Максудый— бер даирә, әйтергә яраса, бер когорта кешеләре. Аларның берсенә мөнәсәбәтле мәгълүмат теге яки бу дәрәҗәдә икенчесенә дә яктылык сирпи. Халидә апаның бу яктан да роле зур. Әйткәнебезчә, ул Максудыйлар гаиләсе белән шактый аралаша. Бу аеруча илленче елларда көчәеп китә. Чөнки бу вакыттан башлап Халидә Вафа, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «һәр ел саен диярлек Төркиягә бара, андагы мәшһүр милләттәшләр белән аралаша». Хат алышулар да булып тора. Халидә Вафаның 1953 елның 18 мартында язган хаты кызыклы гына. Ул саф татарча язылган. Анда татар кызының Садрый Максудыйга тирән хөрмәте ярылып ята. Финляндия-Төркия мөнәсәбәтләре дә телгә алына. Садрый Максудый үзенең 1953 елның 18 июнендә язган җавап хатында Халидә Вафага гаять тә игътибарлыгын күрсәтә, төрек милләтенең олылыгы, китап укуның файдалы булуы хакында фикерләрен белдерә. Укучыларга тәкъдим ителә торган бу хатлар да җәмәгатьчелек һәм фән өчен мөһим бер факт булыр дип уйлыйм.

Кызганыч, ремонт булу һәм вакытның тарлыгы аркасында Халидә апаның китапханәсе, шәхси архивы белән ныклап танышып булмады. Әмма ул җиткергән мәгълүматлар, биргән материаллар да фәнебез, милләтебез өчен мөһим һәм әһәмиятле. Моның өчен аңа күпме рәхмәтләр укысаң да, аз тоелыр. Бөек әдибебезгә авыр вакытларда таяныч, сердәш булганы һәм аның үтенечләрен гамәлгә ашырганы өчен, Аллаһы Тәгалә аңа исәнлекләр бирсен. Халидә апа, ничектер, дәртләнеп, яшәвеннән мәгънә табып калды. «Әле тагын материаллар җибәрермен»,—дип вәгъдә дә итте.

Шунысы да мәгълүм булсын: Халидә апа үзенең шәхси архивының бер өлешен Хельсинки университетының көтепханәсенә бүләк иткән. Тапшырылган китапларның күпчелеге татарча һәм төрекчә басмалар. Арада Г. Исхакыйның Казанда нәшер ителгән китаплары, «Өйгә таба»ның төрекчә басмасы (Истанбул, 1941), «Көз» һәм «Дулкын эчендә» әсәрләренең Алманиядә 1937, 1938 елларда дөнья күргән нөсхәләре бар. Халидә апа аерым кулъязма материалларның да күчермәләрен университет китапханәсенә тапшырган.

* * *

Гомер уза. Дөньяга килгән һәр инсан китеп бара. Әмма язган сүзләр, хатирәләр кала. Алар—тарих, алар—язмыш. Яшәгән һәр кешегә үзгәләрнең язмышы гыйбрәтле. «Инкыйлаб» яшьтәше Халидә апа Вафа да—безнең халкыбызның бер зыялы вәкиле, аның язмышы да безнең гомуми язмышыбызның бер өлеше.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы, профессор.*

## Халидә Вафа архивыннан хатлар

*13 февраль, 1954. Истанбул.*

Хөрмәтле Халидә туташ!

Сезнең 27 гыйнвар тарихлы (ягъни 27 январьда язылган.—*Х. М.*) мәктүбегез (хатыгыз.—*Х. М.*) берлә күндергән бүләк пакетыгызны бүген үзем постаханәгә (почта йортына,—*Х. М.*) китеп (кереп.—*Х. М.*) алдым. Пакет килү хакында күнderелгән кәгазе гыйлем (мәгълүмат; «извещение».—*Х. М.*) хәбәре алган вакытымда бик каты авырый идем. Өч атна ятакда калып, бүген беренче калыкдым вә беренче эшем бүләгегезне барып алу булды. Ләкин монда андый эшләр бик мәшәкатьле, зәхмәтле (кыен,—*Х. М.*) булган икәнене белгәнгә, яныма бер аркадашымны (иптәшемне.—*Х. М.*) алдым. Иртәдән алып өйләгә кадәр постаханәнең бер катындан икенчесенә, өченчесенә аркадашым менеп-төшеп пакетны алырлык хәлгә китерде. Мин хәлсез, көчсез булганга, кул кую вакытыны көтеп утырып кына тордым. Мин дә әллә ничә йиргә куллар куеп, тамож (таможня,—*Х. М.*) акчасын түләп, бүләгегезне алдым. Күндерүегез өчен бик зур рәхмәт. Пакетның эчендән хатыгыз берлә бергә өч почмаклы пәйнир (сыр), бер пар елы оек, ярты кило кадәр ак май чыкды. Боларның һәммәсе минем өчен файдалы бүләкләрдер... Тагы бер мәртәбә күндерүегез, мине уйлавыгыз өчен рәхмәтләремне укыйм. Ләкин алуы, йөрүе бик мәшәкатьле, зәхмәтле булганга һәм дә бик күп тамож акчасы түләргә тиеш булганга (мин үзем унҗиде лира түләдем. Янымдагы иптәш дә өч-дүрт лира, мине борчымыйм дип, әйтми-нитми түләде булырга кирәк), почта берлә мондый пакетлар йөретү бик мөгазле («файдалы»; «килешле».—*Х. М.*) эш булмый ахырысы. Сәмигулла да (Халидә Вафинаның бертуган абыйсы.—*Х. М.*) күндергән, имеш. Аныкы әле килмәде. Ул да шундый ук булып чыгар инде. Шуларны ихтыярыма алып, поста берлә хатдан башка бер нәрсә күндермәвегезне вә башкаларга да шуны белдерүегезне үтенәм. Тагы бер мәртәбә бүләкләрегезгә рәхмәт укып, хөрмәтләр илә

Гаяз ИСХАКЫЙ.

Мөшфика ханымга (Халидә Вафинаның әнисе.—*Х. М.*), сеңелләрегез, туталарыгызга сәламләр, хөрмәтләремне сөйләгез. Хушыгыз, Гаяз.

*8 май, 1954. Истанбул.*

Хөрмәтле Халидә туташ!

Сезнең күндергән бер килолык май бүләгегезне алдым. Тәшәккер идәрем (рәхмәт белдерәм.—*Х. М.*). Көнләр кызу булганга, үзем бик авыр хаста булу сәбәпле, һичбер майлы нәрсә авызым ала алмаганга, мондый бүләкләрне(ң) хәзергә туктатып торуыгызны үтенәм. Үземне дустларым, докторларым бер хастаханәгә кертергә тырышалар. Ләкин хастаханәдә йир (урын.—*Х. М.*) таба алмыйлар. Чит мәмләкәтдән килеп хастаханә ачкан докторларның хастаханәләре бик кыйммәт. Финляндиядән һичбер суыкда да, елыда да бозылмый торган, һәрбер эшкә ярый торган бер бүләк дә килеп чыкды. Кем күндергәндер,—аңарга да рәхмәт[1]. Минем хәлемдә шундый суыкда да, эсседә дә бозылмый торган бүләкләр тагы яхшырак.

Хушыгыз. Һәммәгезгә сәламнәр (и)лә Гаяз Исхакый.

Халидә Вафаның 1953 елның 18 мартында Тампередан Садрый Максудыйга язган хаты (гарәп язуында; татарча).

Бик хөрмәтле вә сайгылы (мөхтәрәм,—*Х. М.*) милләттәшебез Садрый бәй!

Туганым Галия илә киявебез Әнвәргә биргән кыйммәтле «Төрек тарихы вә хокукы» китабын кулыма алып укыгач та, бөтен кимчелекләремә карамастан, ихтыярсыз саф күңелемдән чыккан рәхмәтләремне укырга теләдем. Чөнки безнең кебек җир шарының нинди генә төрле тарафка таркау хәлдә таралган булсак та, башкалар кебек күкрәк киереп яшәргә хакымыз барлыгын кыйммәт-

[1]Хатның читенә адресат иясенең кулы белән «күндерүче Халидә Вафина» дип язылган. Бу бүләк,—мөгаен, спирт булгандыр.

ле китабыгызны укып бик ачык рәвештә аңладым. Аллаһу Тәгалә сезнең кебек милләт аталарына озын гомер, бәхетле тормышлар бирсен иде дип саф теләктә калам.

Сез, мөхтәрәм бәй абзый, безләрне танымасагыз да, безнең гаиләмезнең телендә еш кына буласыз. Әти мәрхүм (Зиннәтулла Вафа) сезләрне һәр заман сагынадыр иде вә бүгенгәчә үз кулыгыз илә язылган гаилә рәсемегез дә диварымызда торадыр. Димәк ки, күздән еракта торсагыз да, калебләремезгә якындыр. Мәгаттәәссеф (кызганычка каршы,—*Х. М.*), мин Төркия сәяхәтемдә сезләрнең кулларыгыздан кысып сәлам бирергә форсат булмады. Чөнки мисафир өе—хуҗасының кулыдыр. Икенчедән, бәлкем, форсат булып та, үземнең сезнең каршыгызда данә (бөртек,—*Х. М.*) кадәр гайрәтем булмаган булыр иде. Сезне болай, хатым илә рахәтсез итсәм дә, халкымызның яшерелгән җәрәхәтле сызлауларын аңлап, гафу итәрсез дип өметтәмен. Югарыдагы әйткәнем кеби, без кайсы бер чит мәмләкәтдә яшәсәк тә, халкымызны шул ук кайгылар, шул ук шадлыклар бер-берләренә баглыйдыр.

Бу сәнә (ел.—*Х. М.*) бөтен төрекләр өчен сөенечле булган Истанбулның 500 еллык бәйрәменә мин дә шушы рәвештә кальбән (күңелем белән,—Х. М.) катнашып, изге теләкләр илә котлыйм. Бу мөнәсәбәт илә төрле милләтләрдән дә мисафирлар киләчәкдер. Кем белә, бәлкем, кечкенә Финляндиямезнең дә милләт вәкилләре арада булачак. Шуңа күрә сезгә Финляндия парламент барышында язылган кечкенә дәфтәрне хатирә уларак күндерәм. Мотлакан (шиксез.—*Х. М.*), арада кальбән төрек дустлары да булачак. Бәгъзан, мондагы утырышларга кызыксынып тыңларга барганда да, безләргә «төрек» уларак бик хөрмәт вә ачык йөз күрсәтәләр. Без дә бер кечкенә колония генә булсак та, шул кадәрле (кадерле,—*? Х. М.*) милләтнең ачысын вә чөчесен (төчесен.—*Х. М.*) бәрабәр күреп, кыймматле корбаннар да бирдек. Бонлар да халкымызга самимият илә ватан хокукларын бирделәр. Бу яшь бер милләт булса да, бөтен дөнья каршысында да хөр, бәхетле, үз илендә яшәргә хаклы булганын күрсәтте. Аллаһу Тәгалә мондан соң да һәр заман ярдәме илә булсын иде!

Бөтен кадерле гаиләгезне гаиләмез исемендән кальбән сәламлим. Тирән хөрмәт вә сайгыларым илә ерак илләрдәге кече кардәшегез

Халидә ВАФА.

(Садрый Максудый-Арсалның 1953 елның 18 июнендә Истанбулдан язган хаты. Ул төрек телендә, латин хәрефләре белән язылган.)

Хөрмәтле Халидә туташ!

Финляндия парламенты чыгарган брошюра вә гүзәл рухлы хатыгызны алдым. Рәхмәт белдерәм. Төркиядән читтә тууыгызга һәм үсүегезгә дә карамастан, төреклек вә төреклеккә бәйлелек тойгысын саклавыгызны күреп бик шат булдым. Әйе, кызым, төрек милләте дөньяның иң бөек вә иң парлак (күренекле, мәшһүр) тарихка ия милләтләрнең берәдер. Төрек милләте бердер, төрле исемнәр белән йөртелгән төрек кавемнәре бөек төрек агачының ботакларыдыр.

Хатыгызны укып, мине хөрмәт итүегезне аңладым. Хезмәт вазыйфаларын үтәүдән соң иң асыл вә иң файдалы ял—китап укудыр. Инсанның рухын күтәрә, рухи офыгын киңәйтә торган чара—укудыр.

Хатыным Камилә ханымнан вә үземнән мөхтәрәм әниегез Мөшфика ханымга хөрмәт вә сәламнәремне, кыз туганнарың Алия вә Наилә ханымнарга вә абыгыз Сәмигулла бәйгә вә җизнәгез Әнвәр бәйгә сәламнәремне белдерүегезне үтенәм.

Уңышлар теләп профессор

Садрый МАКСУДЫЙ-АРСАЛ.

*Гарәп, латин язуындагы бу хатларны тиешле аңлатмалар белән матбугатка әзерләүче–Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ.*

# БТИҮ МӨРӘҖӘГАТЕ

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ҖИМЕРЕЛҮГӘ
450 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Хөрмәтле милләттәшләр!

Быел татар халкының дәүләте җимерелүгә 450 ел тула. Моннан 450 ел элек, 1552 елның октябрендә Ватаныбыз өстенә олы афәт килгән. Баскынчылар тарафыннан татар халкының дәүләте—Казан ханлыгы җимерелгән. Каһарман бабаларыбыз үз илләрен саклап, соңгы тамчы каннарына кадәр көрәшеп, шәһит киткәннәр. Казан алынгач, татарның башка дәүләтләре—Әстерхан, Себер, Кырым ханлыклары да шул ук ачы язмышка дучар ителгән.

Бу вакыйга шул ягы белән дә фаҗигале: Казанның алынуы Ауразия киңлекләрендә йөзәрләгән милләтләрне инкыйразга яки коллыкта яшәүгә дучар иткән һәм хәзергәчә күп халыкларга бәла-каза, җәбер-золым ясап торучы олы империянең төзелүенә сәбәпче булган. Шуның өчен бу елны Россия империясенең колониаль сәясәтеннән җәбер-золым күргән барлык милләтләр дә билгеләп үтәргә тиешләр дип саныйбыз. Ул, шовинистик даирәләр тарихи чынбарлыкны яшереп күрсәткәнчә, халыкларның ирекле рәвештә Россиягә кушылып һәм цивилизациягә ирешү бәйрәме итеп түгел, ә тарихтагы фаҗигаләрдән гыйбрәт алу чарасы буларак билгеләп үтелсен.

Быелгы ел бәйсезлек өчен тигезсез көрәштә шәһит киткән бабаларыбыз алдындагы изге бурычларыбызны үтәү, күңелләребезне пакьләндерү, рухыбызны яңарту чоры булсын! Милләттәшләребез яшәгән тарихи урыннар пакьләндерелсен, дәүләтебез тарихына багышланган кичәләр уздырылсын, матәм җыеннары үткәрелсен. Хуҗалыкларга, мәктәпләргә, гимназияләргә Кол Шәриф, Япанчы, Сөембикә кебек данлы шәхесләр исеме бирелү тантаналары булсын.

Ел дәвамында күмәк мәгълүмат чараларында бу датага багышланган махсус рубрикалар алып барылсын. Быел Казанны саклап шәһит киткәннәргә һәйкәл куелсын, Казан фаҗигасенә багышланган көн рәсми рәвештә «Хәтер көне» итеп билгеләнсен.

Без бу көнне шулай ук Идел-Урал җирендә күп гасырлар бергә яшәүче урыс, башкорт, чуваш, удмурт, мари, мукшы халыкларының да теләктәшлегенә өмет итәбез. Аларның да бу вакыйгаларны уртак җиребездә тарихи дөреслеккә, гаделлеккә, саф әхлакка нигезләнгән чын дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру өчен уздырыла торган чаралар итеп кабул кылуларын һәм безнең белән бергә булуларын телибез. Кыскасы, быелгы ел барча халыкларның тарихи гаделлекне торгызу, милләтара гаделлек урнаштыру, тарихтан гыйбрәт-сабак алу, дуслык-туганлыкны ныгыту чоры да булсын иде.

Быелгы фаҗигале дата Россия хакимиятенең Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларациясен, референдум нәтиҗәләрен санга сукмыйча, аның Конституциясен дә Россиянеке белән тәңгәлләштерүен кабат тоталитар тәртипләргә кайту, гомумән, рус булмаган халыкларны дискриминацияләү процессы көчәеп киткән авыр чорга туры килде. Бу уңайдан, без үзебезнең дәүләтчелегебезне торгызуда теләктәшлек һәм ярдәм сорап, дөнья халыкларына, халыкара хокук саклау оешмаларына, дәүләт парламентларына мөрәҗәгать итәбез.

Безнең дәүләтебезне торгызу юлындагы омтылышыбыз изге һәм гамәлләребез халыкара хокук нормаларына таянып эшләнә.

Дөньядагы бер империя дә мәңгелек түгел. Күңелебезне төшермик, рухыбызны ныгытыйк! Татар халкы һичшиксез колониаль изүдән котылачак. Безнең дәүләтебез булган һәм булачак!

*Beznen̦ kalendar'*

# Şamun Fidai

*(1902—1920)*

Şamun Fidai (Qasıym Xəsən ulı Şakircanov) 1902 yılnın̦ 15 iyünendə Orenburg şəhərendə tua. Anın̦ ətise Qara dingez həm Azov buylarında kənlekçe bulıp yəri, Orenburgqa kilep, keçkenə genə ber pekarnya açuğa ireşə. Qasıym bik dindar ğailədə tərbiələnə, Orenburgtağı qadim mədrəsələrnen̦ bersendə uqıy. Mədrəsə yıllarında ul, şəkertlər xərəkətendə qatnaşıp, Waqıtlı xəkümətkə, imperialistik suğışqa qarşı oyıştırılğan mitinglarda aktiv çığışlar yasıy. 1917—1918 yıllarda Ufadağı «Ğaliə» mədrəsəsendə uqıy, ədəbi icat eşen şunda başlap cibərə. 1918 yılnın̦ cəyendə ul Orenburgtağı revolütsion yəşlər belən aralaşa, annarı yan̦adan Ufağa kilep, qızıl ğəskərçelər arasında tərle cəməğət eşlərə alıp bara. Şul çorda Kənçığış frontının̦ Bişençe Qızıl Armiə politbülege organı bulğan «Qızıl yaw» gazetasında «Şamun Fidai» iseme astında revolütsion şiğerlər bastıra.

1920 yıl başında Ş. Fidai Ufada Kommunistik yəşlər soyuzının̦ matbuğat organnarın oyıştıra, şiğerləren bastıra. Şağir Ufa gubernası yəşlər soyuzı isemennən komsomolnın̦ III Bətenrossiə s'yezdına delegat itep saylana. Ləkin an̦a bu s'yezd eşendə qatnaşırğa turı kilmi—iyün' urtalarında komsomol eşe belən awılğa barğanda kulaklar 18 yəşlek şağirne həm anın̦ yegerme ike yəşlek dustı Bari Başmakovnı yırtqıçlarça üterələr.

## Yalqınlı telək

Kükrəsen kük, qurqınıp
Kitsen yəşennən yaltırap!
Bar mənafıqlar yiğılsın,
Cirgə təşsen qaltırap!

Tetrəsen cir, yəztübən
Kilsen sənamnər çıltırap!
Əydə taşsın keçle sillər,
Ut qabınsın yıltırap!

## Cırla əle

Sanduğaçqay, cırla əle,
Nurlı cırlar çəçkələp,
Şat cırın̦, yəmle mon̦ın̦
Berlə kün̦elne açqalap...

Bar kün̦ellərdən ağım
Mon̦ taşqının taştır əle!
Uy belən, mon̦nar belən
Aştır əle, şaştır əle!

## Bez

Aq qan dingeze...
Bez şunda şawlap,
Şawlap ta dawlap,
Yəzəbez kəlep,
Aptırıy cir yəze.
........................
........................

Yərəktə taşqın,
Kükrəktə yarsu...
Qaygı-xəsrət, yan...

Dulqınnar suğa...
Kəymə ayqala,
Künel çayqala...
Yəgrep həm uynap
Dulqınnar qua...

Tik qaygırmıybız...
Bez - qızıl çəçək,
Şəfqətle mələk,
Qızıl kübələk,
Ləğnət ormıybız...

Dulqın, kəçləp kil!
Əydəgez, qotır-şaş!
Ğəyrətlən də bas!
Selkenmibez də,—
Dulqın, şunı bel.

* * *

Məqətdəs xəncərem təşməs qulımnan,
Bəten sədne kisərmen min yulımnan.

Əməl yoldızları mənge yanarlar,
Bəten mazlum xalıq bezne tanırlar.

Oçabız, bez şulay mənge oçarbız...
Kiler ber kən—səğədətlər qoçarbız...

Bəxet baqçasına barıp kererbez,
Səğədət çəçkəsen əzep yərerbez.

---

Mənafiq—ikeyəzle.
Sənamnər—məcüsilərnen tabına torğan sınnarı.
Sillər—qəçle taşular məğnəsendə.
Səd—totqarlıq, kirtə, qoyma.
Mazlum—izelgən.

*Юмор-сатира*

## Марсель Галиев

# ЧӘК-ЧӘК ФИКЕРЛӘР

*Язучыларның кулъязмаларын редакцияләгәндә күз төшкән мәзәк җөмләләр, табыннарда, җыелышларда әйтелгән җитди яисә шаян фикерләрнең истә калганнары...*

♦ «Йом күзеңне, дөнья бу!»
*Нәби Дәүли.*

♦ «Әхсән Баяновның прозасы— шигырь, ә шигърияте... проза түгел.
*Сибгат Хәким.*

♦ «Тәре—туганда ук үзен-үзе сызган».
*Ренат Харис.*

♦ «Мин үзем гармунда уйный белмим, вәт минем абый бар!.. Ул да уйный белми...»
*Хәсән Сарьян.*

♦ «Күзгең кыек булса, авызыңа үпкәләмә».
*Илдар Юзеев.*

♦ «Хәйләкәр адәм... Койрыгын кар астыннан йөртә».
*Аяз Гыйләҗев.*

♦ «Бүгенге заманда авызына микрофон каптырсаң, балык та җырлый».
*Туфан Миңнуллин.*

♦ «Өйләнешеп бер ай да үтмәде... килененнең бил тирәсе күзгә күренеп калыная башлады. Терекөмешне алдан ук йөгерткән булганнар...»
*Мөхәммәт Мәһдиев.*

♦ «Кәеф шәп, егетләр, күңел мәтәлчек ата».
*Мәхмүт Хәсәнов.*

♦ «Батулла пьесалар күп язып халыкны туйдырды, үзен туйдыра алмады».
*Разил Вәлиев.*

♦ «Балтачта балта ач тора».
*Ләис Зөлкарнәй.*

♦ «Аның колагы ишетүдән баш тартты».
*Әхсән Баянов.*

♦ «Ул бер сүз дә әйтмичә, сүзне икенчегә борды».
*Атилла Расих.*

♦ «Баш заманы түгел, Каш заманы».
*Мәгъсум Хуҗин.*

♦ «Кайбер кимчелекләре булуга карамастан, доклады начар иде».
*Гәрәй Рәхим.*

♦ «—Зур эш башкаргансыз, Мөсәгыйт ага, бөтен ханнарның туганүлгән көненә чаклы минуты-сәгате белән теркәп чыккансыз. Архивтан чын хан табылса, кертер урын да калмаган...»
*Ркаил Зәйдулла.*

♦ «Шагыйрь Афанасий Феттан да бәхетсез кеше юктыр, мөгаен. Әнкәсе үлеп, биш ай да өч көн үткәннән соң гына дөньяга килгән бит».
*Мөдәррис Әгъләмов.*

♦ «Мин, багърем, гайбәт сөйләмим, ә сообщаю».
*Рәшит Әхмәтҗанов.*

♦ «Киткән кеше урынына яхшырагы килгәне юк әле...»
*Камил Кәримов.*

♦ «Акылын бәлигъ булмаса, житмештә дә шигырь язарсың».
*Марсель Гали.*

♦ «Талантлы... зараза».
*Роберт Миңнуллин.*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЯЗ. ШИГЪРИЯТ. ТУКАЙ

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның туган көненә багышланган Шигърият бәйрәме, һәр елдагыча, республика күләмендә зурлап үткәрелде.

Опера һәм балет театры бинасы янындагы төп тантананы сәламләү сүзе белән Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачып җибәрде һәм ул 2002 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында Татарстан Президенты Указын игълан итте. Аннары яна лауреатлардан рәссам Искәндәр Рафиков, Дәүләт квартеты исеменнән Шамил Монасыйпов сүз әйтте, квартет башкаруында тантаналы көйләр яңгырады.

Шигъри митингта шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗан, Кави Латыйп, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов, Роза Кожевникова, Флера Тарханова, Илсөяр Иксанова, Айдар Хәлим, Резеда Вәлиева, Ркаил Зәйдулла, Резедә Әхтәмова, Фәүзия Солтан, яшьләрдән Луиза Янсуар, Гөлназ Вәлиева, Альбина Әпсәләмова һ. б. чыгыш ясады. Шигырьләр җыр-музыка белән аралашып торды. Җырчылардан Башкорт дәүләт опера һәм балет театры солисты Марат Шәриповның «Пар ат»ны башкаруын тамашачылар аеруча яратып тыңлады.

Быелгы шигырь бәйрәмен шагыйрь Рәдиф Гаташ алып барды.

* * *

Соңгы елларда Г. Тукайның туган көне Балтач районында да билгеләп үтелә башлады. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин җитәкчелегендә бер төркем әдипләр бөек шагыйребезнең әнисе Бибимәмдүдә абыстайның җәсәде яткан Сасна Пучинкәсенә сәфәр тоттылар. Ә ана барышлый кунаклар Балтач районы үзәгендә һәм Субаш авылы мәдәният йортында үткәрелгән тантаналарда катнаштылар. Балтачлылар алдында каләм осталарыннан Туфан Миннуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Бикә Рәхимова, Фирая Зыятдинова, Зиннур Мансуров, Галимҗан Гыйльман, Рәдиф Сәгъди, Асия Юнысова һ. б. чыгыш ясады. Аларны Балтач районы хакимияте башлыгы урынбасары шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин озатып йөрде. Ә Субашта кунакларны Г. Тукай исемен йөртүче хуҗалык рәисе Нурулла Сәгъдиев кабул итте.

* * *

Күп еллардан килә торган күркәм гадәт буенча, Шигърият бәйрәме эстафетасын Габдулла Тукайның туган төбәге—Арча районы кабул итте. Арча сәнгать мәктәбе каршында һәм шагыйрьнең Тукай-Кырлайдагы музее алдында үткәрелгән әдәби-музыкаль тантаналарда Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Фоат Галимуллин, Мәгъсүм Насыйбуллин, Радик Фәизов, Флера Гыйззәтуллина, Резеда Вәлиева, Галимҗан Гыйльман, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Тукай җәмгыяте рәисе Хатип Миңнегулов, шулай ук Тукай бүләгенең быелгы лауреаты рәссам Искәндәр Рафиков, Башкортстаннан килгән бер төркем укытучылар һәм укучылар катнашты. Кунаклар Кушлавычтагы музейда да булдылар, шагыйрь әтисенең каберен зиярәт кылдылар. Тантаналарда катнашучыларны Арча районы хакимияте башлыгы Алмас Нәзиров озатып йөрде.

Шигърият бәйрәмнәре шулай ук республикабызның Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама, Мамадыш, Чистай шәһәрләрендә, башка район үзәкләрендә, татарлар күпләп яши торган чит өлкәләрдә дә оештырылды.

### ХЕЛЬСИНКИДӘ КАЗАН КӨННӘРЕ

Финляндия башкаласы Хельсинкидә «Казан көннәре» булып узды. Тантана Норденшелдинкату урамындагы 1 нче йортта урнашкан Русия фән һәм мәдәният үзәгендә ачылды. Анда күп кунаклар катнашты. Делегация җитәкчесе, Казан хакимияте башлыгы урынбасары Ф. Ишмаков тантанага җыелган барча кешене тәбрик итте. Аннары Татарстан артистлары зур концерт бирде. Тамашачылар Россиянең халык артисты Венера Ганиева, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һ.б. чыгышларын алкышларга күмде. Россия фән һәм мәдәният үзәге залларында «Казанга—1000 ел. Тарих. Мәдәният. Традицияләр» һәм «Казанның сәнәгать предприятиеләре. Тауарлар. Тәкъдимнәр. Ихтыяҗ» дигән тематик күргәзмәләр ачылган иде. Форумда шулай ук Хельсинкинең татар диаспорасы вәкилләре белән очрашулар, Финляндиянең эшлекле даирәләре вәкилләре катнашында «түгәрәк өстәл»ләр узды.

### ШӘҺӘРЛӘР БЕРЛЕГЕ

Петербург шәһәрендә губернатор В. Яковлев һәм Казан мэры Камил Исхаков «Санкт-Петербургның 300 еллыгына һәм Казанның 1000 еллыгына бәйле үзара чараларны үткәрү турында» Санкт-Петербург һәм Казан хакимиятләре арасындагы беркетмәгә кул куйдылар.

Документ юбилей тантаналары кысаларында күп кенә уртак чаралар үткәрүне күздә тота. Болар «Бөек Идел юлы» уртак фәнни-гамәли конференциясен уздыру, «Санкт-Петербург татарлары», «Ике шәһәр—ике язмыш» китапларын бастырып чыгару, сәнгать күргәзмәләре уздыру, ике шәһәрнең сәнгать осталары концертларын оештырудан гыйбарәт.

### ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ—БАШ РЕЖИССЕР

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына яңа баш режиссер билгеләнде.

Ул—әлеге театр режиссеры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Фәрит Бикчәнтәев.

### ЭЛЕКТРОН ГАЗЕТАБЫЗ БАР

Бөтендөнья интернет челтәрендә Татарстан яңалыклары һәм бөтендөньяга сибелеп яшәүче татар халкы тормышы белән таныштыручы яңа мәгълүмати сәхифә ачылды. Март аеннан башлап Җир шарының компьютер аша бөтендөнья мәгълүмат челтәренә тоташкан теләсә кайсы почмагында www.intertat.ru адресы аша Казанда тупланган яңалыклар белән танышырга була. Республиканың intertat. ru электрон газетасы Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә куелды.

Электрон газетаның төп максаты: Татарстан һәм гомумән татар дөньясы тормышы турында зур тизлек белән дөрес мәгълүмат тарату. Интернет челтәренең моның өчен бөтен мөмкинлекләре бар.

Электрон газета өч—татар (хәзер гамәлдәге кириллица һәм латин хәрефләрендә), рус һәм инглиз телләрендә чыга. Бу газета әһәмиятле һәм кызыклы яңалыкларны, дәүләт житәкчеләре, хөкүмәт вәкилләре, депутатлар, сәнәгать-хужалык, әдәбият-сәнгать һәм башка өлкәләрдә танылган абруйлы шәхесләрнең фикерләрен, җәмгыятьне борчыган мөһим мәсьәләләрне күтәрүче мәкаләләрне үз укучыларына даими тәкъдим итеп барачак.

### ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ КОМПЬЮТЕР

Татарстан Фәннәр академиясендә «Милли телләр һәм мәгълүмати технологияләр» дигән темага республика фәнни-гамәли конференциясе булып узды.

Конференция «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Закон кабул ителүгә һәм Татарстан Фәннәр академиясе төзелүгә 10 ел тулуга багышланды.

Күренекле галимнәр Ш. Чабдаров, Р. Бохараев, Ж. Сөләйманов, М. Каюмов һәм башкаларның чыгышында татар телен компьютерга кертү мәсьәләләре тикшерелде, туган телебездәге программалар өлкәсендә кайбер эшләнмәләр, аерым алганда драйвер, корректор, электрон сүзлекләр, татар сөйләме синтезаторы һәм башкалар барлыгы әйтелде. Аларның максаты кириллица һәм латин графикасы нигезендә татар телендә документлар белән эшләү, текстлардагы хәреф хаталарын төзәтү, аларны табышлы итү, телебезне интернет челтәренә тоташтырудан гыйбарәт.

### АРХИВЧЫЛАР КИЛӘЧӘККӘ КАРЫЙ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булды.

Соңгы бер ел эчендә архивчылар өчен мөһим вакыйгалар аз булмады. Шуларның берничәсе: «Татарстан Республикасы архив законнарын бозган өчен административ җаваплылык турында»гы Татарстан Республикасы Законын кабул итү, Истанбулда Татарстан һәм Төркиянең архив хезмәтләре арасында хезмәттәшлек итү турындагы Беркетмәгә кул кую, республиканың милли архивына Али Акышның шәхси архивын тапшыру һ. б.

Коллегиядә әһәмиятле мәсьәләләрне анализлауга һәм аларның чишелеш юлларына зур игътибар бирелде. Архивчыларны бетерелгән оешмаларның, аеруча эре предприятие-банкротларның шәхси составы буенча документларны саклау мәсьәләсе борчый.

Киләчәктә Татарстан Республикасының Архив фондын формалаштыруда архивларны электрон документлар белән тулыландыру бурычы тора.

### «ТАТКНИГА»—ҖИҢҮЧЕ

«Таткнига» Татарстанның республика китап сәүдәсе берләшмәсе коллективы 2001 елгы эш йомгаклары буенча РФ Матбугат эшләре, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы, Бәйсез дәүләтләрнең китап таратучылар ассоциациясе тарафыннан оештырылган Бөтенроссия китап сәүдәсе предприятиеләре конкурсында җиңүче булды.

ТР Президенты М. Шәймиев исеменә ассоциация президенты М. Каменева котлау хаты җибәрде. Анда республика хакимияте органнарының китап сәүдәсе предприятиеләренә ярдәм итүе өчен рәхмәт белдерелә.

### ИСТАНБУЛ—КАЗАН

Күптән түгел «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе оркестры (җитәкчесе—Рөстәм Үтәй, директоры—Әзһәр Хөсәенов) һәм популяр артистларыбыз Римма Ибраһимова, Разия Үзбәкова, Айдар Фәйзрахманов, Равил Харисов Төркиядә төрки халыкларның музыка фестивалендә булып кайттылар.

Истанбул шәһәренең Таһим мәйданында

урнашкан Жамал Рәшит-Рэй исемендәге концерт салонында Татарстан артистларының концертын тамашачы йотылып карады. Истанбулның мәдәният идарәсе башлыгы Шенол Демироз концерт алдыннан безнең жырчыларны бик жылы итеп тамашачыга тәкъдим итте:

—Без барлык төрки халыкларның музыкасын, сәнгатен хөрмәт итәбез, ә татар сәнгатенә игътибарыбыз аеруча зур,—диде ул.

Татарстан артистлары концертында Русия Федерациясенең Истанбулдагы генераль консулы Сергей Величкин катнашты. Концерт «Туган тел» жырын тамашачылар белән бергәләп башкару белән тәмамланды.

Безнең артистлар Истанбулның Үзәк зиратында Гаяз Исхакый һәм Йосыф Акчура каберен дә зиярәт кылдылар.

## ОЛУГ ЯЗУЧЫГА БАГЫШЛАП

Мәскәү шәһәре һәм өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтәриятләре, «Фатиха» хәйрия фонды һәм Татарстан Республикасының Русия Федерациясендәге тулы вәкаләтле вәкиллеге бергәләшеп күренекле татар язучысы Кави Нәжминең тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе оештырдылар.

Кичәгә Мәскәүдәге танылган татар зыялылары жыелды һәм бу чара Әсәдуллаев йортында үтте.

Искә алу кичәсендә язучының улы Тансык Нәжметдинов, якташы—«Татарстан» журналының баш мөхәррире Рифат Фәттахов, шагыйрь Вил Ганиев, язучының туган авылындагы урта мәктәп директоры Рифкать Алимов, журналист Әнвәр Баһаветдинов, Мәскәүнең Жәмигъ мәчете каршындагы мәдрәсә директоры Жәгъфәр Фәйзрахманов, вәкиллекнең жәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге мөдире Зөһрә Миңлеханова һ. б. катнашты. Алар К. Нәжминең тормышы һәм ижат юлы турында гыйбрәтле чыгышлар ясадылар.

## ӘСТЕРХАН КУНАКЛАРЫ

27 апрель көнне Камал театры бинасында Әстерхан өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең зур концерты булып узды. Бу тамашада өлкәнең «Мирас», «Нур», «Ялкын», «Сандугачлар оясы», «Капель» ансамбльләре һәм татар халык драма-комедия театры катнашты. 80 нән артык сәнгатькяр катнашкан бу концерт-тамашаны сәхнәгә куючы—Румия Һидиятуллина. Казанның 1000 еллыгына багышланган бу бай программа Әстерхан шәһәренең «Дуслык» миллимәдәният жәмгыяте тарафыннан оештырылган иде. Жәмгыятьнең бүгенге житәкчесе—Әнвәр Алмаев.

## СӘҮДӘГӘРЛЕКНЕҢ АЛТЫН СӘХИФӘЛӘРЕ

«Яналиф» нәшриятында 3 мең тираж белән дөнья күргән 2 томлы китап әнә шулай дип атала.

Анда Татарстан жирендә X гасырдан алып бүгенге көнгә кадәр сәүдә һәм эшкуарлыкның формалашуы, үсеш тарихы яктыртыла. 3 бүлектән торган тарихи-биографик басмада болгар тәнкәләреннән алып «үзгәртеп кору» кооперативлары, бүгенге индустрия гигантлары һәм кече эшкуарлык предприятиеләре—яшәешнең барлык чорларын чагылдыручы бай материал тупланган.

Китапта Апанаев, Әжемов, Алафузов, Борнаев, Шамов кебек танылган 58 фамилия бар. Моннан тыш, республиканың эре сәнәгать, кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләре, алар житештергән продукция турында да тулы мәгълүмат табарга була.

Китап татар, рус һәм инглиз телләрендә нәшер ителгән.

## АЧЫ ЯЗМЫШ ТУРЫНДА

Башкалабыздагы Журналистлар йортында журналист Венера Якупованың «Крымские татары, или Привет от Сталина» дигән китабын жәмәгатьчелеккә тәкъдим итү кичәсе булды. Китап ТР Хөкүмәтенең кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышу һәм үстерү департаменты генераль директоры Нури Амди улы Мостафаевның матди ярдәмендә нәшер ителгән. «Әлеге гамәлем бу дөньялыкта халкыма эшләгән төп эшемдер әле»,—диде ул үзенең чыгышында. Журналист-язучы Венера Якупованың бу китабы турында язучы-шагыйрьләр Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, Д. Вәлиев, М. Зарипов һ. б. югары фикерләрен белдерделәр. Очрашу, тәкъдим итү кичәсен Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова алып барды.

Шушы елның 15 апрелендә шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Нәжип Гәрәй улы Мадьяров** 75 нче яшендә вафат булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктә музей-йорты.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Нурислам Хәсәнов.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Татары** (коллектив).—Мәскәү: «Наука» нәшр.—2001. 584 б. Тиражы—7400 данә.




Фундаменталь бу фәнни хезмәт «Наука» нәшриятының «Халыклар һәм мәдәниятләр» дигән сериясендә басылган. Әлеге сериядә монарчы чыккан «Руслар», «Белоруслар», «Украиннар», «Идел буе һәм Урал яны халыклары» дигән китаплардан соң бу—бишенче китап. Н. Н. Миклухо-Маклай исемендәге этнология һәм антропология институты әзерләгән (Татарстан Фәннәр Академиясе һәм Тарих институты белән берлектә) бу китапта татар халкының көнкүреше, хуҗалыгы, матди һәм рухи культурасы, шул исәптән, халык шигърияте һәм музыка иҗаты, гореф-гадәтләре тасвирлана. Китапта, шулай ук, Урта Идел һәм Урал буенда, Көнбатыш Себер, Әстерхан өлкәсе, Үзәк Россия, Төньяк Кавказда яшәүче татарларның яшәү хәятен бәян итү дә киң урын алган.

Хезмәтнең авторлары—Д. Исхаков, Д. Рамазанова, Г. Вәлиева-Сөләйманова, Ф. Урманчиев, Н. Халиков, С. Суслова, З. Сәйдәшева, Р. Мөхәммәдова, Р. Мөхәммәтшин һ. б. Кереш һәм йомгак мәкаләләрен Р. Уразманова, Р. Хәкимов, В. Тишков язган.

Җаваплы мөхәррирләр: Р. Уразманова, С. Чешко.

Госман ИСХАКЫЙ. **Ислам әхлагы**.—Казан: Россия ислам университеты.—2002.—270 б. Тиражы—3000 данә.




Кеше акылы гаҗәеп бер могҗиза: аның өчен бернинди чикләр юк сыман. Әмма галәм киңлекләре масштабында фикер йөртеп тә, гавәми яшәешнең бик гади серләренә дә төшенмәү яки, киресенчә, көнкүрешнең нечкәлекләрен яхшы белеп тә, рухи фикерләүдә зәгыйфь булу—адәм балаларын бу тормышта еш кына кыен хәлләргә куя. Чыннан да, кеше акылы камил дәрәҗәдә булырга мөмкинме соң? Кешене дөрес һәм иманлы итеп яшәргә өйрәтеп буламы? Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый үзенең китабында әнә шундый житди сорауларга җавап бирергә алына һәм тормышыбызда Исламның әһәмиятен аңлата. Китап өч бүлектән тора: җомга вәгазьләре, әхлак дәресләре һәм әңгәмәләр.

Китапның мөхәррирләре: Р. Гәрәев, Л. Гәрәева, Н. Ибраһимов.

Индекс 73210



Нурислам Хәсәнов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)